**Р.Х. Мөхиярова**

# ХХ гасыр ахыры — ХХI гасыр башы татар әдәби теле лексикасы

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 811.512.145‘373
ББК 81.2 Тат-3
М98

Китап
2004–2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәү максатында нәшер ителә.

Рецензентлары:
*Ганиев Ф.Ә., Нигъмәтуллов М.М., Әхәтова З.Ф.*

**Мөхиярова Р.Х.**

ХХ гасыр ахыры — ХХI гасыр башы татар әдәби теле лексикасы / Р.Х.Мөхиярова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. — 183 б. — 1500 д. — ISBN 978-5-298-01744-2

УДК 811.512.145‘373
ББК 81.2 Тат-3

ISBN 978-5-298-01744-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Мөхиярова Р.Х., 2009

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ.......................................................................................................................................

I БҮЛЕК

ӘДӘБИ ТЕЛ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ ҮЗ ҖИРЛЕГЕНДӘ ҮСҮЕ

1.1. Лексиканың эчке ресурслар нигезендә үсү юнәлешләре ..................................................
1.2. Сүзләрнең мәгънәсе киңәю .................................................................................................
1.3. Яңа сүзләр ясау......................................................................................................................
1.3.1. Кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр .........................................................
1.3.2. Синтаксик юл белән ясалган сүзләр ....................................................................
1.3.2.1. Парлы сүзләр ......................................................................................................
1.3.2.2. Аныклаулы атамалар...........................................................................................
1.3.2.3. Кушма сүзләр.......................................................................................................
1.3.2.4. Тезмә сүзләр.........................................................................................................
1.3.3. Кыскартылма сүзләр .............................................................................................
1.3.4. Конверсия ысулы белән ясалган сүзләр ..............................................................
1.4. Калькалаштыру юлы белән ясалган сүзләр.......................................................................
1.5. Әдәби телнең кулланылыш даирәсе, стиле, активлыгы чикләнгән сүзләр исәбенә баюы
1.5.1. Әдәби телнең диалекталь сүзләр исәбенә үсеше ................................................
1.5.2. Гомумкулланылыштагы сүзләрнең терминлашуы һәм кайбер тармак атамаларының башка «мәйданга» күчүе
1.5.3. Гади сөйләм лексикасының әдәби телгә йогынтысы ..........................................
1.5.4. Искергән һәм сирәк кулланылыштагы сүзләрнең активлашуы..........................
1.6. Окказиональ сүзләр...............................................................................................................
1.7. Яңа сүзләрне кулланудагы кайбер үзенчәлекләр...............................................................
1.8. Бүлек буенча нәтиҗәләр .......................................................................................................

II БҮЛЕК

СОҢГЫ ЧОР ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫНДА ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫ

2.1. Гарәп-фарсы алынмалары активлашуның сәбәпләре һәм алшартлары .............................
2.2. Яңадан активлашкан алынмаларның тематик төркемнәре.................................................
2.3. Кулланылыш даирәсен, стилен, ешлыгын үзгәрткән алынмалар .....................................
2.4. Гарәп-фарсы элементлары ярдәмендә ясалган сүзләр .......................................................
2.4.1. Морфологик юл белән ясалган сүзләр..................................................................

2.4.2. Синтаксик юл белән ясалган сүзләр ............
2.4.3. Фонетик ысул белән ясалган сүзләр ............
2.5. Гарәп-фарсы алынмаларын яңабаштан үзләштерү процессы ............
2.5.1. Мәгънәви үзгәрешләр ............
2.5.2. Грамматик үзенчәлекләр............
2.5.3. Фонетик-орфографик үзенчәлекләр............
2.5.4. Алынмаларны аңлатмалары белән параллель куллану ............
2.5.5. Гарәп-фарсы сүзләрен куллануда хаталар............
2.6. Бүлек буенча нәтиҗәләр ............

III БҮЛЕК

ӘДӘБИ ТЕЛНЕҢ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬҺӘМ РУС СҮЗЛӘРЕ ИСӘБЕНӘ БАЮЫ

3.1. Яңа рус-европа алынмаларының тематик төркемнәре............
3.2. Электән үзләштерелгән алынмалардагы семантик-стилистик үзгәрешләр............
3.2.1. Мәгънә үзгәреше кичергән алынмалар............
3.2.2. Сүзләрнең кулланылыш сферасы һәм стиле киңәю ............
3.2.3. Искергән яисә элек капиталистик җәмгыятькә карата гына кулланыл-ган алынмаларның активлашуы
3.2.4. Тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә актуальләшкән алынмалар............
3.2.5. Алынмаларны тискәре (пейоротив) төсмер белән куллану ............
3.3. Рус-европа алынмаларын кулланудагы аерым үзенчәлекләр............
3.4. Бүлек буенча нәтиҗәләр ............

ЙОМГАК ............

БИБЛИОГРАФИЯ............

ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР ............

КУШЫМТАЛАР ............

# КЕРЕШ

Иҗтимагый күренеш буларак тел җәмгыятьтәге сәяси, икътисади, мәдәни һәм башка үзгәрешләрдән читтә кала алмый. Татар милли әдәби теле үсешендә дә галимнәр ил тормышындагы төрле зур борылышларга нисбәтле биш чорны аерып күрсәтәләр. Аларның соңгысы — үзгәртеп кору чоры (54. 4 б.). 1985 елда башланып киткән зур вакыйгалар — тоталитар дәүләтнең җимерелүе, җәмгыятьнең сәяси, икътисади һәм рухи нигезләрен үзгәртеп кору, республикабызның яңа дәүләт-хокукый статус алуы, халыкның милли үзаңы уяну, чит илләр белән бәйләнешләр киңәю — әдәби телебездә, бигрәк тә аның сүзлек составында, турыдан-туры чагылыш тапты. Аерым алганда, җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләр белән бәйле яңа төшенчәләрне атау өчен татар теленең үз җирлегендә күп кенә яңа сүзләр ясалды; совет чорында пассив сүзлеккә күчкән кайбер сүзләр, аеруча гарәп-фарсы алынмалары, актив кулланылышка кайтты; шул ук вакытта рус һәм Европа телләре аша яңа интернациональ сүзләр керде; аерым сүзләр яңа мәгънә төсмерләре белән баеды; чикләнгән кулланылыштагы сүзләр әдәби телгә үтеп керде; күп кенә сүзләр стилистик төсмерен үзгәртте; коммунистик идеологиягә бәйле аерым берәмлекләр актив кулланылыштан чыкты.

Үзгәрешләр әдәби телнең барлык функциональ стильләрендә дә чагылыш тапты. 1992 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә татар телен дәүләт теле буларак рәсми даирәдә куллануны канунлаштыру — эш кәгазьләре стиле, гомум һәм махсус белем бирү системасының барлык баскычларында, шул исәптән вузларда ана телендә укытуны гамәлгә кертү, татарча дәреслекләр һәм гыйльми хезмәтләр язу — фәнни-техник стиль үсешенә уңай йогынты ясады. Телебездә Октябрь революциясенә кадәр югары үсешкә ирешкән, әмма соңыннан кулланылыштан төшеп калган дини стиль дә, ислам диненең яңарышына бәйле рәвештә, функциональ стильләр системасында яңадан үз урынын яулый бара.

Шулай да, рус теленә дә хас булганча, «хәзерге әдәби тел үсешенең төп тенденцияләре публицистик стильдә туа һәм аныклана» (41. 46 б.), чөнки башка стильләргә караганда «газета теленә неологизмнар һәм чит тел сүзләре җиңелрәк үтеп керә» (79. 32 б.), яңа яки актуальләшкән сүзләр башта матбугат битләрендә теркәлә. Шуңа да тәкъдим ителгән китапта яңа чор татар әдәби теле лексикасындагы үзгәрешләр 1986—2007 елларда чыккан газета-журнал материаллары буенча, нигездә, публицистика стиле мисалында өйрәнелә.

Лексикадагы үзгәрешләрне билгеләгәндә, нигез критерий итеп татар теленең 1977, 1979, 1981 елларда дөнья күргән өч томлык аңлатмалы сүзлеге (ТТАС) алынды. Ягъни ТТАСтә теркәлмәгән сүзләр һәм мәгънәләр, шулай ук анда күрсәтелгән кулланылыш даирәсен, стилен, дәрәҗәсен, ешлыгын үзгәрткән берәмлекләр генә безнең өйрәнү предметы булып тора. Бу исә ясалган нәтиҗәләрнең объективлыгын тәэмин итү өчен кирәк. Өчтомлыкта булмаган аерым сүзләрнең мәгънәсе 2005 елда чыккан бер томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (ТТАС, 2005) буенча бирелә. Аңлатмалы сүзлекләргә кермәгән, әмма активлаша барган гарәп-фарсы архаизмнарының мәгънәләре — М.И.Мәхмүтов, К.З.Хәмзин, Г.Ш.Сәйфуллиннар төзегән «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» (ГТРАС), аерым очракта гарәп-рус, фарсы-рус, рус-фарсы сүзлекләре буенча, рус теле аша кергән неологизмнар рус теленең аңлатмалы сүзлеге (1998, ТСРЯ) һәм рус телендәге чит ил алынмалары, инглиз-рус сүзлекләре нигезендә аңлатыла.

# I БҮЛЕК

## ӘДӘБИ ТЕЛ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ ҮЗ ҖИРЛЕГЕНДӘ ҮСҮЕ

### 1.1. Лексиканың эчке ресурслар нигезендә үсү юнәлешләре

«Лексика барыннан да элек эчке ресурслар, телдә инде булган сүзләрнең бертуктаусыз баюы, сүз ясалу исәбенә үсә» (23. 132 б.). XX йөзнең 80—90 нчы елларында татар теле лексикасының үсеше дә, нигездә, шушы юл белән бара. Дөрес, әлегә тел белемендә телнең эчке (үз) һәм тышкы ресурслары төгәл генә ачыкланып бетмәгән. Әйтик, Н.А.Баскаков «эчке ресурслар» төшенчәсенә калькалаштыру, иске сүзләрнең мәгънәсен үзгәртү, кушма һәм кыскартылма сүзләр ясауны кертә (19. 192 б.). Төрки әдәби телләрнең үсеш үзенчәлекләренә багышланган коллектив хезмәттә диалекталь һәм профессиональ-һөнәри лексиканы файдалану, яңа синонимик рәтләр барлыкка килү, сүз мәгънәсенең аерымлануы, сүзнең төрле фонетик вариантларын куллану, ясагыч морфемаларның мәгънәләре киңәю, яңа тип фразеологизмнар барлыкка килү совет чорында төрки телләрнең үз ресурслары исәбенә үсү юллары буларак санала (18. 88 б.). Кайбер хезмәтләрдә боларга яңа төшенчә атамаларын ирекле тәрҗемә итү, аерым сүзләрнең актив кулланылыштан төшеп калулары да өстәлә (55. 88, 168 б.). Хәзерге үзбәк теле лексикасы буенча докторлык монографиясендә Э.Бегматов сүзлек составының үз җирлегендә үсешенең ун төрле юлын күрсәтә: 1) үз (төрки) сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү; 2) морфологик һәм синтаксик юл белән яңа сүзләр ясау; 3) кайбер борынгы алынмаларның яңа мәгънәдә активлашуы; 4) төрки һәм алынма сүзләрне кушып, яңа сүзләр ясау; 5) диалекталь сүзләрнең гомумкулланылышка күчүе; 6) алынма нигезләрдән яңа сүзләр ясау; 7) калькалаштыру; 8) сүзнең куллану сферасы һәм функциясе киңәю; 9) төрле типтагы ялгызлык исемнәр ясалу; 10) яңа төр фразеологизмнар, канатлы сүзләр һәм тәгъбирләр барлыкка килү (20. 57 б.). Татар тел гыйлемендә лексиканың эчке һәм тышкы ресурслар нигезендә үсеше әлегә махсус өйрәнелмәгән. Дөрес, Ш.А.Рамазанов, Ф.С.Фасеев хезмәтләрендә бу мәсьәләнең аерым аспектлары чагылыш таба. В.Х.Хаков татар әдәби теленең совет чоры үсешенә багышланган хезмәтендә 20—30 нчы елларда татар теле лексикасының үз җирлегендә халык сөйләм теленнән сүзләр алу, сүзләрнең яңа мәгънәләре барлыкка килү, функциональ стильләрнең лексик яктан баюы (шул исәптән диалектизмнар хисабына) кебек юллар белән актив үсүен билгели (156. 42—74 б.). Р.А.Юсупов яңа төшенчәләрне белдерү өчен беренче чиратта милли телнең үз хәзинәсенә нигезләнеп сүз ясау (гамәлдәге сүзләрнең яңа, өстәмә мәгънә алуы, морфологик һәм синтаксик юллар, шулай ук калькалаштыру һәм ярымкалькалаштыру ысулы белән лексик чаралар барлыкка китерү) мөмкинлекләре файдаланырга тиешлеген ассызыклый (181. 7 б.). Ф.А.Ганиев хезмәтләрендә, шул исәптән татар теленең яңа академик грамматикасында, хәзерге татар теле лексикасы үсеше түбәндәге дүрт юл белән бара дип күрсәтелә: 1) телнең үз чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалу; 2) сүзләрнең мәгънәсе киңәю; 3) башка телләрдән сүзләр алу; 4) диалект һәм сөйләшләрдән сүзләр алу (32. 19 б.). Бу юлларның чит телләрдән сүзләр алудан башка өчесе лексиканың үз җирлегендә үсүенә карый.

Соңгы еллар татар әдәби теле лексикасының телнең эчке ресурслары исәбенә үсүен өйрәнү безгә бу өлкәдә дүрт төп юнәлешне билгеләргә мөмкинлек бирә:

1) сүзләрнең мәгънәсе киңәю;
2) яңа сүзләр ясау;
3) кулланылу сферасы, дәрәҗәсе (активлыгы), стиле чикләнгән сүзләрнең әдәби телне баетуы;
4) калькалаштыру.

Билгеле, бу бүленеш берникадәр шартлылыктан азат түгел. Әйтик, кайбер искергән сүзләр — актив лексикага, кулланылышы бер стиль белән чикләнгән сүзләр башка яисә нейтраль стильгә күчкәндә еш кына мәгънәләрен дә үзгәртәләр. Мондый очракларны сүзләрнең мәгънәләре үзгәрүгә караган бүлекчәдә карап, 1.5 параграфта мәгънәләрен үзгәртмичә гомумкулланылышка күчкән сүзләрне барларбыз. Тюркологиядә кабул ителгәнчә, гомумтөрки характердагы, шул исәптән борынгы кытай, санскрит, фарсы, монгол, угро-фин һ.б. телләрдән кабул ителгән (тун, мәңге, кәрәз һ.б.) сүзләр дә телнең үз сүзләре исәбендә карала (9. 45—46 б.).

### 1.2. Сүзләрнең мәгънәсе киңәю

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр, яңа төшенчәләр барлыкка килү һәрвакытта да телдә яңа сүз ясалуга китерми. Еш кына бу процесс башкача бара: «иске» сүзләр яңа мәгънә төсмере белән байый, киңрәк

мәгънәлегә әйләнә. Бу — объектив һәм телнең зур эчке мөмкинлекләрен күрсәтүче факт. Чөнки, күренекле тел белгече Р.А.Будагов раславынча, яңа сүзләр барлыкка килү лексиканың сан ягыннан үсешен (развитие) күрсәтсә, сүзләрнең мәгънә баю исәбенә сыйфат ягыннан үсеше аның камилләшүе (совершенствование) турында сөйли (24. 35, 71 б.). Сүзләрнең мәгънәсе киңәю төрки телләр лексикасында да иң мөһим күренешләрдән исәпләнә (97. 164 б.). Чөнки, яңа сүз ясамый һәм башка телләрдән сүзләр алмый гына, лексик системаны үстерү татар телен баетуның бик үтемле һәм экономияле юлы (33. 78 б.). Октябрь революциясеннән соңгы чорда яңа төшенчәләрнең барлыкка килүе һәм телнең үсеше нәтиҗәсендә сүзләрдә яңа мәгънә төсмерләре һәм семантик үзгәрешләр тууы узган гасырның 20—30 нчы еллар әдәби теленә караган мисалларда В.Х.Хаков тарафыннан өйрәнелгән иде инде (156. 52—62 б.). Соңгы елларда җәмгыятьтәге зур иҗтимагый-сәяси һәм икътисади үзгәрешләр күп төшенчәләрнең һәм аларга бәйле рәвештә сүзләрнең мәгънәләре үзгәрүгә дә китерде. Мондый үзгәрешләрнең XX гасырның 70—80 нче елларына караган кайбер мисаллары А.С.Зинина хезмәтләрендә күрсәтелгән (62. 63 б.). Аларда, лингвистикадагы хезмәтләргә таянып, сүзләрдә мәгънә үзгәрүнең төрле юллары да билгеләнгән.

Соңгы чорда татар сүзләренең мәгънәләре киңәю нигездә ике төрле юл белән бара:

1) җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән яңа күренешләрне атау өчен, телдә инде яшәп килгән сүзләрне яңа мәгънәдә куллану;

2) алынма сүзләрне алыштыру өчен, телнең үз сүзләрен яңа мәгънәдә куллану.

Бу ике төркемчәгә кергән сүзләрне аерып карыйк.

**1.2.1.** XX гасыр ахырында җәмгыятьтәге иң зур үзгәрешләрнең берсе — финанс системасының үзгәрүе, икътисадның базар мөнәсәбәтләренә күчүе, шәхси эшмәкәрлекнең үсүе. Бу лексикада да чагылышын тапмый калмады, яңа мәгънә төсмере алган сүзләрнең дә шактые шушы өлкәгә карый: мәсәлән, **эшкуар**, **эшмәкәр**, **малтабар**, **йөкләмә**, **ташлама**, **юллама**.

**Эшкуар** — (*и.* Эшләрне (бигрәк тә коммерция эшләрен) бернинди ысулдан да чирканмыйча, оста итеп алып баручы — ТТАС, III, 594 б.). 1981 елгы бу билгеләмәдән тискәре эмоциональ-экспрессив төсмер аңкып торса, хәзер ул стилистик яктан нейтраль һәм күпкә киңрәк «шәхси эшмәкәрлек, табышлы эш (бизнес) белән шөгыльләнүче» мәгънәсендә кулланыла: *Чаллы **эшкуарлары** бертуган Кашаповлар ярдәме белән изге Болгар җиренә сәяхәт оештырылды* (Ш.Ч., 1994, 8 гыйнв.).

Сирәк булса да, бу сүз кире эмоцияне аңлаткан очракта да кулланыла: *Боларның хуҗалары — ... җитәкчеләре, тиз арада кесә калынайтып өлгергән **эшкуарлар**, алыпсатарлар* (Ш.К., 1994, 6 март). *Дәүләтнең болай да саегып калган кесәсеннән миллиард сумнар астыртын сәүдә итүче **«эшкуарлар»** кулына агыла башлады* (К.у., 1991, № 7, 153 б.). Телебездә соңгы елларда барлыкка килгән яңа уңай-нейтраль мәгънә төсмерен элеккеге мәгънәсе белән бутамас өчен, аны еш кына аныклаучы компоненты белән бергә дә кулланалар: *Бигрәк тә ... **эшкуар-меценатлар** үзләреннән зур өлеш керттеләр* (Т-н, 1995, № 11—12, 26 б.). *Хатын-кыз журналы булса да, «Сөембикә»не ир-егетләр дә, **эшкуар-бизнесменнар** да ... яратып укыйлар* (С-ә, 1996, № 8, 5 б.).

**Эшмәкәр** (*и. диал.* Эшчән, уңган, эшлекле — ТТАС, III, 596 б.) сүзе дә хәзер, нигездә, шул ук, ягъни «предприниматель» мәгънәсендә «эшкуар» сүзенең синонимы буларак кулланыла: *Ул **эшмәкәрләр** әзерли торган институтка керде, базар икътисады белгече һөнәрен алачак* (К-н, 1995, № 3—4, 10 б.). *Дөрес, шуннан соң ике елга «Бөрсет»тән китеп, үзен **эшмәкәр** буларак сынап караган* (М-н, 2006, № 6, 146 б.).

**Малтабар** (*и. сөйл.* Үзенең шәхси интересыннан чыгып, мал-мөлкәт, акча артыннан куучы кеше турында — ТТАС, III, 830 б.) сүзе дә шулай ук, мәгънәсен киңәйтеп, сөйләм теле стиле рамкаларыннан әдәби телгә күчте һәм, алда саналган сүзләрнең синонимы буларак, тискәре төсмерсез генә кулланыла: *Илдә яңа тормыш башлангач, **малтабар** булып китәргә теләдем* (В.Т., 1995, 23 сент.). Алдагы мисалларда телгә алынган Кашаповларга карата бу сүзне куллану да шуны раслый: ***Малтабар-химаяче** бертуган Кашаповлар һәм ... башка фидакарьләргә олуг рәхмәтемне белдерәм* (М. җ., 1995, 29 сент.).

Билгеле, телнең эчке законнары нигезендә киләчәктә бу өч синоним сүз арасында мәгънә аерымлану булыр йә аларның берсе генә әдәби телдә ныгып калыр. Бүген үк инде алар арасында **эшкуар** сүзенең башкаларга караганда активрак кулланылуы күзәтелә.

**Йөкләмә** (*и.* 1. Кемгә дә булса тапшырылган, йөкләтелгән эш; задание. 2. Өскә алынган һәм үтәлүе мәҗбүри булган бурыч, вәгъдә. 3. *тар. иск.* Крестьяннарның алпавыт яки дәүләт файдасы өчен түләүсез мәҗбүри эшләү вазифасы. 4. *рәс.* Гражданнарның дәүләт яки урындагы җәмәгатьчелек кирәкләре өчен мәҗбүри тәртиптә эшләнгән эше, хезмәте. 5. Нинди дә булса эшкә җәлеп ителү дәрәҗәсе, шул эшнең микъдары — ТТАС, I, 469 б.) сүзе сәүдә-финанс өлкәсенә караган «вексель», ягъни «билгеле бер вакытка билгеле бер сумма акча түләү турында язма йөкләмә» мәгънәсе белән баеды. Ул аның ТТАСтә теркәлгән икенче мәгънәсеннән үсеп чыкты. Дөрес, әлегә күбрәк җәя эче аңлатмасы белән кулланыла: *Республика хөкүмәте бюджетка средстволар керүнең акчалата*

*булмаган формасына барырга — **йөкләмәләр** (вексельләр) куллануга мәҗбүр булды* (В.Т., 1996, 28 дек.).

**Ташлама** (*и.* 1. Кемгә дә булса гомуми таләпләрне йомшарту, аның хаталарын һ.б. өлешчә гафу итү. 2. Хак-бәя мәсьәләсендә үзара тизрәк килешүгә юнәлтелгән тәкъдим — ТТАС, III, 58 б.) сүзе «льгота, гомумкагыйдәләрдән чыгарма буларак ниндидер җиңеллек бирү» мәгънәсендә кулланыла башлады: *«Хезмәт ветераны» таныклыгы алдым, әмма миңа **ташламалар** бирүдән баш тарттылар* (В.Т., 1998, 21 март). **Ташлама** атамасын **льгота** сүзе белән параллель кулланган очраклар да бар: *Төрле льготалар, мәсәлән, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән, телефоннан, радиодан файдаланган өчен **ташламалар** бар* (В.Т., 1998, 21 февр.).

Элек, нигездә, китап теле стилендә һәм сирәк кулланылган **юллама** (*и.* 1. Берәр кешене кая да булса билгеләүне яки юнәлтүне белдергән рәсми документ, путевка. 2. Дөрес юлга юнәлтү, фатиха бирү — ТТАС, III, 609 б.) сүзе үзенең сүзлектә теркәлгән бу мәгънәләрендә актив кулланылудан тыш яңа «рәсми мөрәҗәгать, послание, ягъни дәүләт җитәкчесенең иҗтимагый закон чыгару органнарына әһәмиятле мәсьәләләр буенча язма мөрәҗәгате» мәгънәләре белән баеды: *Шушы көннәрдә генә Татарстан Президенты Шәймиев Ельцинга тагын бер акыллы **юллама** белән мөрәҗәгать итте* (З.-Т., 1994, 30 дек.). «*Минтимер Шәрипович Шәймиев Дәүләт Советына еллык **Юлламасында** тормыш сыйфатын яхшырту максаты куйды» дип кабатлавын истә тотканда, министрлыкның кыйбласы ачык сыман тоела* (В.Т., 2007, 21 авг.).

Вакытлы матбугатта **юллама** сүзен **юлнамә** белән алыштырырга тәкъдим итүчеләр дә булды (Ш.Ч., 1996, 24 сент.). Конкрет «дәүләт машинасын йөртүчеләргә бирелгән рөхсәт кәгазе, путевка» мәгънәсенә карата бу фикер, бәлки, урынлыдыр. Гомумән алганда исә, саф татар сүзе буларак, юллама күпкә отышлырак.

Нигездә Чечнядагы сугышка бәйле рәвештә актив лексикага кайткан **тотак** (ТТАСтә **тотык**, әмма кушымчаларның мәгънәсен искә алганда, **тотак** вариантын куллану дөрес) (*и. бор.* Берәр таләпнең үтәлүен тәэмин итү өчен, дошман якларның яки үзара сугышучы илләрнең берсе тарафыннан кулга алынган яки көчле якка биреп торылган кеше; заложник — ТТАС, III, 124, 132 б.) сүзе шушы мәгънәдә активлашу белән беррәттән киңрәк «ниндидер сәбәпләр аркасында нәрсәгәдер мәҗбүр ителгән кеше» мәгънәсендә дә кулланыла башлады: *Ә Лена белән Таня хәзер өйдә **тотак** булып утыралар, алар белән психолог эшли* (Т.я., 1997, 18 сент.). *Әфган талиблары кулында калган унтугыз **тотакның** өчесе ачлык игълан итте* (В.Т., 2007, 21 авг.).

**1.2.2.** Телне алынма сүзләрдән арындыру тенденциясе тәэсирендә узган гасырның 80 нче елларыннан күп кенә сүзләр бөтенләй яңа мәгънәдә кулланыла башладылар. Шундыйлардан **берлек** (союз, ассоциация), **бәяләмә** (характеристика), **ия** (лауреат), **узаман** (лидер), **узыш** (авторалли), **төзекләндерү** (реконструкция) сүзләре күрсәтелгән яңа мәгънәләрендә уңышлы ныгыдылар диярга була.

**Берлек** (*и.* 1. Бер сум акча. 2. *лингв.* Сүз бер генә кеше яки предмет турында барганда кулланыла торган төрләнү формасы. 3. Бердәмлек, оешканлык. // Ныклы, тыгыз бәйләнеш. // Уртаклык, тулы охшашлык — ТТАС, I, 153 б.) сүзе хәзер «Дәүләтләр берләшмәсе» һәм «Җәмәгать оешмасы» (ТСРЯ, 753 б.) мәгънәләрендә **союз** һәм «бер юнәлештәге эшчәнлек белән шөгыльләнүче кешеләр яки оешмалар берләшмәсе» мәгънәсендә **ассоциация** сүзләре урынына актив кулланыла. **Берлек** сүзенең өченче мәгънәсе **союз** сүзенең беренче «тесное единение, связь» һәм **ассоциация** сүзенең икенче «связь между отдельными представлениями» мәгънәләре белән нигездә уртак булуы бу сүзне алда әйтелгән яңа мәгънәләрдә куллану мөмкинлеге тудырган. Хәзер Татарстан Журналистлар берлеге, Кинематографистлар берлеге, профессиональ берлекләр, Рәссамнар берлеге, Татарстан хатын-кызлары берлеге, Татар яшьләре берлеге, Язучылар берлеге кебек сүзтезмәләрне һәрбер газета-журналда күпләп табарга була: *Элекке Советлар **Берлеге** таркалу чын мәгънәсендә дөньякүләм әһәмиятле бер вакыйга буларак каралырга хаклы* (М-т, 1994, 23 апр.). *Анда үз мәнфәгатьләрен яклау өчен профессиональ **берлекләргә** берләшү хокукы бирелү турында әйтелә* (В.Т., 1996, 24 май). *Санкт-Петербург Рәссамнар **берлеге** бинасында Габдулла Тукайның 120 һәм Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды* (К.у., 2006, № 12, 192 б.).

**Бергәлек** (*и.* 1. Дуслык, татулык, бердәмлек. 2. *с. мәгъ.* Бергә булган // Уртак, күмәк, коллектив — ТТАС, I, 151 б.) сүзе дә шул ук **ассоциация** сүзе урынына **берлек** сүзе белән параллель рәвештә (а) һәм «сообщество» төшенчәсен бирү өчен, «уртак мәнфәгатьләре, максатлары булган кешеләр, халыклар яки дәүләтләр берләшмәсе» мәгънәсендә дә (ә) кулланыла башлады: а) *Ул Бөтентатар «Мәгариф» һәм «Мәдәният» **бергәлекләрен** төзүдә башлап йөрүче булды* (С-ә., 1996, № 2, 30 б.); ә) *Беренчедән — бу бөтендөнья **бергәлегенә** хас социаль процесслар һәм күренешләр* (К.у., 1996, № 7, 167 б.).

**Бәяләмә** (*и. кит.* Берәр эшнең, хезмәтнең гомуми сыйфатын, әһәмиятен, кыйммәтен күрсәтеп, гадәттә язма рәвештә бирелә торган рәсми бәя, фикер — ТТАС, I, 212 б.) сүзе, соңгы елларга кадәр телебездә үз атамасы булмаган **характеристика** һәм **заключение** сүзләрен алыштырып, берьюлы ике яңа мәгънә алды: а) «кемгә яки нәрсәгә дә булса хас сыйфатлар, үзенчәлекле яклар турында бәя»

(характеристика): *Сез аңа «бик яхшы офицер, профессионал» дигән* ***бәяләмә*** *бирдегез* (В.Т., 1996, 1 нояб.); ә) «нәрсәне дә булса тикшереп өйрәнгәннән соң ясалган нәтиҗә, йомгак, раслау» (заключение): *Владимир төрмәсенә алып килгәндә, Пауэрс, врачлар* ***бәяләмәсе*** *буенча, психик өзлегү алдында була* (В.Т., 1996, 17 май).

Элек, нигездә, русча вариантта кулланылган атамаларны алыштыручы **бистә** (*и.* 1. *тар.* XI—XVIII гасырларда феодаль Русьтагы бәйсез дәүләт кулында яки шәхси милектә булган җирләргә үзләре теләп килеп утырган крестьяннар, һөнәрчеләр һ.б. яши торган пункт, гадәттә кечерәк шәһәрчек. 2. Шәһәрнең аерымрак урнашкан өлеше, районы — ТТАС, I, 169 б.) сүзенең дә мәгънәләре киңәйде дип исәпләргә була. Чөнки, беренчедән, ул ТТАСтә тарихи сүз буларак теркәлгән беренче мәгънәсендә түгел, ә гомумән «шәһәр тибындагы зур авыл, торак пункт» мәгънәсендә **поселок** сүзен тулысынча диярлек алыштыра (а), икенчедән, хәзерге зур шәһәрләрдәге төзелгән яңа берәмлекләрне атау өчен **префектура, микрорайон, комплекс** сүзләре урынына кулланыла (ә), ягъни ТТАСтә теркәлгән икенче мәгънә конкретлаша: а) *Саба районының Шәмәрдән* ***бистәсендә*** *бөтен уңайлыклары булган ясле-бакча ачылды* (В.Т., 1994, 21 дек.); ә) *Казандагы 50 нче* ***бистәне*** *газлаштырып бетерәсе бар ...* (Т.я., 1998, 21 март). *Ирландия Уфаның Сипайлова* ***бистәсендә*** *сәүдә үзәге ... төзергә ниятли* (Өмет, 2007, 20 сент.).

Күпмәгънәле **җирлек** (*и.* 1. Җирнең мул уңыш бирә алу сәләте. 2. Төп төс, фон. 3. Берәр нәрсәнең арткы планы яки күренеше. 4. Нәрсәнеңдер башлангычы булып торган нәрсә. 5. Эшнең уңышын тәэмин итә торган шартлар — ТТАС, 2005, 780 б.) сүзе, бердән, икенче мәгънә нигезендә грунт, **грунтовка**, ягъни «буяр алдыннан өслекне тигезләү өчен кулланылучы махсус составлы буяу, арадаш катлам» мәгънәсе белән баеды. Бу мәгънә инде русча-татарча сүзлекләрдә дә чагылыш таба (РТС, 1997, 119 б.): *Эшкәртелгән түшәмне* ***җирлек*** *(грунтовка) белән каплыйлар* (В.Т., 1998, 27 окт.). Икенчедән, хәзер **җирлек** сүзен элеккеге **авыл советы**, **торак пункт** урынына русча **поселение** атамасының тәрҗемәсе буларак кулланалар: *Участок милиционерлары Гаяз Сәгыйдуллин ... район* ***җирлегендә*** *патрульлек иткән вакытта Боголюбово һәм Ает авыллары арасында шик уяткан бер төркемне туктата* (Өмет, 2007, 20 сент.). Безнеңчә, бу очракта Башкортстанда кулланылган **биләмә** атамасы уңышлырак: *Базытамак авыл советы* ***биләмәсендә*** *дә шундый тенденция яшәде. Соңгы өч елда яңа җитәкче —* ***биләмә*** *башлыгы А.Мосабировның тырышлыгы белән бу юнәлештәге эш кузгалтылып, халыкка 20 гектарда печәнлекләр бирелде* (Өмет, 2007, 21 апр.). *Стәрлебаш авыл советы* ***биләмәсендә*** *секундына 25 метр тизлегендә яңгыр катыш давыл узып, ... ферма түбәсе шиферларын куптарып ташлаган* (Өмет, 2007, 26 май).

**Ия** (*и.* 1. Берәр нәрсәнең, милекнең хуҗасы. 2. Нинди дә булса сыйфатка, сәләткә, дәрәҗәгә һ.б. ирешкән кеше // Нәрсәгә дә булса ... лаек. 3. Берәр эш белән шөгыльләнүче, көн күрүче кеше. 4. Уйлап чыгарган, язган яки әйткән кеше, автор. 5. ... мифик зат. 6. *иск. дини.* Тәңре, Алла. 7. *лингв.* Җөмләдә ... баш кисәк — ТТАС, I, 442 б.) сүзе **лауреат** алынмасын алыштырып, **бүләк** компоненты белән берлектә, сигезенче «фән, әдәбият, сәнгать, халык хуҗалыгы өлкәсендә күрсәткән зур хезмәтләре өчен махсус бүләк, премия алган кеше» мәгънәсенә «ия булды»: *Илбарис Надиров — Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге* ***иясе*** (М. ж., 1998, 20 февр.). Бу очракта, күрәсең, яңа аналитик **бүләк иясе** атамасы ясалды дип әйтергә дә була. Дөрес, **премия иясе** варианты да очрый: *Габдулла Тукай исемендәге* ***премия ияләре*** *исемлеге апрель аенда ук билгеле булса да, аларны рәсми рәвештә ел саен Республика көнендә генә бүләклиләр* (В.Т., 2007, 1 сент.).

**Кайнатма** (*и.* Берәр дару үләне яки җиләк-җимеш һ.б. салып махсус кайнатылган су (дәвалау өчен) — ТТАС, II, 25 б.) сүзе соңгы елларда, күбрәк **варенье** сүзен алыштырып, «җиләк-җимешне шикәр комында кайнатып, пешереп яисә изеп ясалган татлы чәй ризыгы» мәгънәсендә кулланыла: *Мондый* ***кайнатманы*** *чәй эчәргә генә түгел, ә мич ашлары пешергәндә дә файдаланып була* (Ш.К., 1994, 26 июль).

**Киптергеч** (*и.* Язу карасын үзенә сеңдерә, киптерә торган махсус кәгазь — ТТАС, II, 101 б.) сүзе «нәрсәне дә булса киптерү корылмасы, урыны» мәгънәсен дә үзләштереп, **сушилка** (ТСРЯ, 781 б.) алынмасы урынына кулланыла: ***Киптергечләр*** *газга көйләнә* (В.Т., 1998, 1 апр.).

**Колакча** (*и.* 1. *к.* Колакчын. 2. *диал.* Колак алкасы. 3. *сөйл.* Күзлек сабы — ТТАС, II, 132 б.) сүзен «наушник» ягъни «колакка киелә торган тыңлау приборы» мәгънәсендә куллануны да сүзнең мәгънәсе киңәю дип карарга кирәк, чөнки бу мәгънәләр, төрле предметларны атасалар да, бер үк тамырга карыйлар; яңа мәгънә әлегә күбрәк аңлатма белән бирелә: *Әллә аңа үз телендә чыгыш ясарга рөхсәт бирмәделәрме, яки синхрон тәрҗемәне тыңлау өчен кулына* ***колакча*** *(наушник) тоттырмадыларммы?* (Т.я., 1997, 16 дек.). *Алар өчен* ***колакчалар*** *бар бит* (Т.я., 1998, 21 нояб.).

**Колакса** (*и.* 1. к. Көймәдә ишкәк беркетә торган җайланма; уключина. 2. Чабатаның ян-якларында киндерәне чалып тагып алу өчен ясалган тишек. 3. Ниргәнең бәпкә утырту өчен баш-башлары озынаеп чыгып торган иң өске аркылы бүрәнәсе — ТТАС, II, 132 б.) сүзен «клипсы» — «колак йомшагын тишмичә генә тага торган алка» мәгънәсендә куллануга карата да шуны әйтергә була:

*— Витя, ә* ***колакса*** *тагуың нәрсәне аңлата?*

*— Болай гына, әнием такты* (М-т, 1995, 22 июль).

Мисаллардан күренүенчә, бу соңгы ике тамырдаш сүзнең яңа мәгънәләре ТТАСтә теркәлгән мәгънәләрдән шактый ерак һәм **колакса**, **колакча** сүзләре шушы яңа мәгънәләрдә телдә ныгысалар, ул мәгънәләр нигезендә гомоген омонимнар да барлыкка килергә мөмкин.

**Култамга** (*и. бор.* Имза мәгънәсендә йөри торган тамга — ТТАС, II, 188 б.) сүзе, бердән, төп мәгънәсен киңәйтеп, ягъни тулысынча **имза** дигән гарәп алынмасын алыштырып активлашса (а), икенчедән, «танылган шәхеснең үз кульязмасы яки имзасы» мәгънәсендә **автограф** сүзе урынына да кулланыла башлады (ә): а) *Виленнан «улы белән беркайчан да очрашу-күрешүне таләп итмәскә» дигән **култамга** алганнар* (М.җ., 1999, 5 февр.); ә) ... *атаклы шәхесләребезнең истәлекле **култамгаларына** да ия булачаксыз* (М.җ., 1997, 24 окт.). Бу сүзне шулай ук «бармак эзләре» мәгънәсендә рус телендәге **отпечатки** сүзе урынына файдалану да очрый: *Әмма кәгазьдәге **култамгалар** тәрәзәдә калган сызыкларга тәңгәл килмәгән* (В.Т., 1995, 18 окт.).

**Төзекләндерү** (*ф.* Яшәү яки файдалану өчен уңайлы, яраклы хәлгә китерү, рәтләү // *с. мәгъ.* Яшәү яки файдалану өчен уңайлы, яраклы хәлгә китерү белән шөгыльләнә торган — ТТАС, III, 244 б.) сүзе **реконструкция** сүзен алыштыру өчен «яхшырту, камилләштерү максаты белән нәрсәне дә булса тамырыннан үзгәртү, яңадан кору, төзү эше» мәгънәсендә кулланылышка керә бара: *Татарстандагы шикәр заводларында **төзекләндерү** уздырганнан соң, оештыру куәтләре ике мәртәбә диярлек артты* (В.Т., 1996, 21 сент.). *Бүген үк **төзекләндерүгә (реконструкцияләүгә)** әзерлек бара* (В.Т., 1996, 28 дек.). **Төзекләндерү** сүзе кайбер очракларда «реставрация» мәгънәсендә дә кулланыла: *Экспонатлар акрынлап искерәләр, тузалар — алар **төзекләндерүгә**, тузаннан, температура үзгәрешләреннән, дымнан, музей бөҗәкләреннән саклауга мохтаҗлар* (Ш.К., 1994, 5 июль).

**Тугра** (*бор.* Урта гасыр төрки дәүләтләрдә (мәсәлән, Казан ханлыгында) хан мөһере; хан исеме матур итеп боргалап-сыргалап язылган мөһер — ТТАС, III, 148 б.) **герб** сүзе урынына, ягъни яңа «дәүләт, өлкә, шәһәр һ.б. ның махсус тамгасы, дәүләт билгесе» мәгънәсендә актив лексикага кайтты, үзенең беренчел мәгънәсендә ул тарихи әсәрләрдә генә очрый: *Үзебезнең **туграбыз** була торып, күрше Рәсәй дәүләтенең туграсы төшерелгән документ бирү, минемчә, Татарстан гражданнарын кимсетү ул* (Ш.Ч., 1995, 8 авг.). *Алабуганың Әби патша тарафыннан XVIII гасырда ук расланган **туграсы** бар иде инде* (М.җ., 2006, 5 май). Борынгы мәгънәсендә бу сүз XX гасырның 80—90 нчы елларында активлашты. Каллиграф Нәҗип Нәкъкашның 1999 елда оештырылган күргәзмәсендә татар халкының күренекле шәхесләре тугралары да урын алган иде.

**Тупланма** (*и.* Бер урынга күп булып җыйналган, тупланган әйберләр, предметлар төркеме — ТТАС, III, 167 б.) сүзен **коллекция** алынмасы урынына куллану да күзәтелә башлады: *Татар милли сәнгате әсәрләренең гаять зур өлеше чит мәмләкәтләрнең дәүләт һәм шәхси **тупланмаларында** саклана* (З.-Т., 1995, 3 окт.).

Шул ук вакытта **тупланма** сүзе «нәрсәнең дә булса җыелмасы» мәгънәсендә дә очрый: *Ул исән чакта планлаштырылган һәм чыга башлаган «Татар халык иҗаты» **тупланмасының** унөч томы дөнья күрде* (Ш.К., 1994, 9 июль).

**Узаман** (*и. иск. кит.* Уенда башлап йөрүче, оештыручы. Нинди дә булса төркемнең башлыгы, нинди дә булса (гадәттә яман) эшнең башында йөрүче — ТТАС, III, 297 б.) сүзе, «нинди дә булса хәрәкәтнең, оешманың һ.б. җитәкчесе, башлыгы» мәгънәсендә, актив лексикага кайтып, **лидер** сүзен әдәби телдән кысрыклый башлады: *Азау теше чыккан, буар елан булып чыкты элекке комсомол **узаманы*** (К.у., 1997, № 7, 19 б.).

**Узыш** (*и.* 1. Йөгерү, ат узыштыру спортында алга чыгу өчен оештырылган ярыш. 2. Өстен, алдан чыгу өчен ярыш, көрәш — ТТАС, III, 298 б.) **ралли** сүзен алыштыру өчен «автомобильләрдә һәм мотоциклларда ерак араларга оештырылган ярыш» мәгънәсендә конкретлашты, моңа «КамАЗ» автомобильләренең бу узышларда актив катнаша башлавы да этәргеч бирде: *Татарстанның профессиональ командасы ике елда әлеге **узышта** «КамАЗ-Мастер» исеме белән катнашты* ... (Я-н, 1995, № 8, 17 б.).

Бу төр ярышларда катнашучы спортсменнарны (пилот, гонщик) атау өчен **узышчы** (*и.* Чабу, йөгерү ярышларында катнашучы — ТТАС, III, 299 б.) сүзе яңа мәгънә төсмере белән кулланыла: *Әмма вертолет катастрофага эләгә, һәм атаклы **узышчы** шунда һәлак була* (Я-н, 1995, № 9, 17 б.).

**Ятакханә** (*и. иск.* Йокы бүлмәсе (ТТАС, III, 655 б.) сүзе соңгы елларда, яңадан акрынлап актив кулланылышка кереп бару белән беррәттән яңа «укучылар, студентлар өчен тулай торак» мәгънәсен дә алып, **интернат**, **тулай торак** сүзләре урынына да кулланыла башлады: ***Ятакханәдә** торып, 1933 елда мәктәпне тәмам иттем* (К.у., 1996, № 4, 114 б.). *Мәскәүдә **ятакханәдә** тавыш күнегүләре эшләгәндә, төн төшкәч, мине, йокламыйсың, дип ачуланалар иде* (М.җ., 1997, 24 гыйнв.).

Күренүенчә, телнең үз сүзләренең яңа мәгънә һәм мәгънә төсмере белән баюы, нигездә, рус алынмаларын алыштыру хаҗәтенә бәйләнгән. Тикшерелгән мисалларның дүрттән өч өлеше — шундый сүзләр. **Эшкуар**, **эшмәкәр**, **малтабар**, **йөкләмә**, **ташлама**, **юллама** сүзләренең яңа мәгънә төсмерләре белән активлашуы исә беренче чиратта җәмгыятьтәге яңа күренешләрне атау ихтыяҗы белән бәйләнгән; мәгънәсе киңәйгән сүзләрнең күбесе телебездә актив кулланылыштагы берәмлекләр булса

да, **култамга**, **тугра**, **тотак**, **узаман**, **ятакханә** сүзләре, пассив лексикадан «кире кайтып», яңа мәгънә алдылар, **бистә** сүзенең дә беренче мәгънәсе ТТАСтә тарихи сүз буларак теркәлгән. Диалектлардан кергән **эшмәкәр**, сөйләм теле стиленә караган **малтабар** сүзләре дә киң кулланылышка мәгънә төсмерен үзгәртеп керделәр.

### 1.3. Яңа сүзләр ясау

Татар теленең сүзлек составы барыннан да элек телнең үз чаралары ярдәмендә яңа сүзләр ясалу юлы белән үсә (33. 76 б.). Бу без өйрәнгән чорга да карый. Соңгы елларда җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә бик күп яңа төшенчәләр барлыкка килде. Аларны атау өчен төрле ысуллар белән яңа сүзләр ясалды. Шулай ук елдан-ел көчәя барган алынма сүзләрдән арыну тенденциясе дә яңа лексик берәмлекләр барлыкка килүгә китерде. Яңа сүзләр ясауда телебездә булган барлык сүзьясалыш ысуллары да катнашты дияргә була. Без бары лексик-семантик ысул белән ясалган яңа сүзләрне генә аерым күрсәтмәдек, гәрчә алдагы бүлекчәдә караган **бергәлек, йөкләмә, колакса, колакча, ятакханә** сүзләренең яңа мәгънәләре элекке, ТТАСтә теркәлгән мәгънәләреннән бик ерак һәм алар мәгънә таркалу нәтиҗәсендә туган яңа сүзләргә бик якын торалар.

Яңа ясалган сүзләрнең иң зур күпчелеге исем сүз төркеменә карый; сыйфат, фигыльләр аз очрый. Түбәндә сүз ясалышы буенча күпчелек хезмәтләрдә кабул ителгән тәртиптә һәр ысул белән ясалган неологизмнар карала. Сүзьясалыш типлары һәм чаралары татар теленеке булган очракта, алынма нигезләрдән ясалган сүзләр дә телнең үз ресурслары нигезендә үсүен күрсәткән мисаллар исәбенә кертелә.

#### 1.3.1. Кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр

Сүзгә кушымчалар ялгап яңа сүз ясау татар телендә иң продуктив ысуллардан исәпләнә. Соңгы елларда барлыкка килгән сүзләрнең дә күпчелеге шушы ысул белән ясалган. Ясаучы нигезләр исем фигыль, сыйфат сүз төркеменә карый.

**Кушымчалар белән исем ясау**

***-чы/-че*** татар телендә исемнәрдән ни белән дә булса шөгыльләнүче затны, һөнәр атамасын белдерүче исемнәр ясаучы иң продуктив кушымчалардан исәпләнә (30. 149 б.). Безнең картотекада бу кушымча ярдәмендә ясалган иллеләп яңа сүз теркәлгән. Әмма аларның зур күпчелеге әлегә окказиональ кулланылышта; төрки-татар ясаучы нигезләре берничә генә (**көйче**, **мөлкәтче**, **оранчы**), рус һәм интернациональ алынмалардан ясалганнары ярымкалькалар булып торалар (**арендачы**, **дизайнчы**, **компьютерчы**, **омончы**, **рэкетчы** һ.б.), зур күпчелек тәшкил иткән гарәп-фарсы компонентлыларының (**гамәлче**, **груһчы**, **зәркәнче**, **иминиятче**, **инсаниятче**, **иттифакчы**, **кәсәбәче**, **хакимиятче**, **нәзариятче**, **нәүбәтче**, **сәнәгатьче**, **тәфтишче**, **фиркаче** һ.б) ясагыч нигезләре үк актив кулланылышта түгел. Арада **талибанчы, шәркыятьче** кебек урынсыз ясалганнары да шактый. Шуңа да аеруча еш кулланылучы неологизмнарга гына тукталабыз.

Аларның беренчесе **икътисад** (*и. иск. кит*. 1. *к.* Экономика. 2. Малны аз-азлап кына тоту, экономия (ТТАС, I, 377 б.) сүзе гарәп алынмасыннан ясалган һәм «икътисад белгече, җәмгыятьнең хуҗалык тормышын өйрәнүче галим» мәгънәсендә **экономист** сүзенең «татарлаштырылган» синонимы буларак кулланыла: *Фәһим Ибәтуллин — белеме буенча* ***икътисадчы*** (М. ж., 1997, 31 окт.).

**Нәкышче** сүзе нәкыш (*и.* 1. Агач, сөяк кебек нәрсәләргә кисеп, уеп, сырлап яки чокып ясалган бизәк, орнамент. 2. Чигү, чигеш — ТТАС, II, 451 б.) алынма тамырыннан ясалган һәм «төрле материалга чокып, сырлап яисә чигеп бизәк, рәсем төшерүче», ягъни «гравер» мәгънәсенә ия: *Бу күргәзмәдә без Алсу Тимергалинаны* ***нәкышче*** *рәссам буларак таныдык* (С-ә, 1995, № 6, 34 б.).

Соңгы елларда бик активлашкан хәйрия (*ис. гар.* Мохтаҗларга күрсәтелә торган изгелек, яхшылык — ТТАС, 2005, 638 б.) алынмасыннан ясалган **хәйрияче** сүзе мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтүче, изгелек эшләүчене аңлата: ... *гомеренә бер мәртәбә мохтаҗларга ярдәм кулы сузган кеше дә үзен* ***хәйрияче*** *яки волонтер итеп тоя башлый бездә* (В. Т., 2007, 7 авг.).

**Химаяче** сүзе дә, нигездә, «кемгә дә яисә нинди дә булса эшкә матди ярдәм күрсәтүче, спонсор» мәгънәсендә һәм шактый актив кулланыла: *Китапның ел ахырында дөньяга чыгасына ышанам. Бары тик* ***химаячеләр*** *генә табасы калды* (В. Т., 1998, 6 март). *Япониядә билгесез калырга теләгән бер* ***химаяче*** *җәмгать бәдрәфләрендә 10 ар мең иена (60 евро) салынган конвертлар калдырып йөри* (М. ж., 2007, 3 авг.). Безнеңчә, бу неологизм ясагыч сүзнең мәгънәсен дөрес аңламыйча төзелгән, чөнки **химая** сүзе «Кемнең дә булса яклавы, саклавы карамагында булу» (ТТАС, III, 367 б.), *ис.* 1. Яклау, саклау. 2. Берәүнең кулы астында булып саклану (ГТРАС, II, 658 б.), *и. г.* 1. «Берәр яклау астында булу, ярдәмне тоеп яшәү. Кул астында булу, протекторат» (ШАС, 128 б.) мәгънәләренә ия, һәм бу модель белән ясалган сүз «яклаучы, саклаучы; кемнеңдер яклавы, саклавы астында булган кеше» мәгънәсен алырга тиеш иде. Ә алда күрсәтелгән мәгънәне **иганәче** сүзе белән биреп була.

Иң яңа неологизмнардан **кертемче** — «саклык банкында акчасы булган кеше, вкладчы» сүзенең ясагыч нигезе дә әле яңа, ТТАСтә теркәлмәгән, әмма 1985 елгы русча-татарча сүзлектә **вклад** сүзенең тәрҗемәсе буларак инде чагылыш тапкан (РТС, 66 б.): *Банк яки компания банкротлыкка чыкса, алар **кертемчеләргә** түләүләрне башкарырлар* (В. Т., 1999, 16 гыйнв.).

Көй (1. *и.* Авазларның (тоннарның) билгеле бер тәртиптәге эзлеклелегеннән гыйбарәт музыкаль бербөтен // Нинди дә булса бер музыкаль әсәр // Җырлау өчен сүз һәм музыкадан гыйбарәт әсәр — ТТАС, II, 258 б.) исеменнән ясалган яңа **көйче** сүзе «музыкаль әсәрләр иҗат итүче» мәгънәсенә ия, һәм хәзер шактый еш **композитор** алынмасын алыштыра: ... ***көйче**, җырчы һәм музыкант Фирзәр Мортазинның бенефисы зур уңыш белән үтте* (Т. я., 1996, 5 сент.).

Аерым сүз ясагыч морф буларак ***-ымчы*** кушымчасы теркәлмәгән булганлыктан, «кемгә дә булса охшатып чыгыш ясаучы, пародист» мәгънәле яңа **охшатымчы** сүзен «охшату» ( ... 2. Кем яки нәрсәгә охшаш итеп күрсәтү — ТТАС, II, 482 б.) фигыленнән ***-ым*** һәм ***-че*** кушымчаларын бер-бер артлы ялгап ясалган дип карарга була: *Хәзер **охшатымчы** итеп күрсәк тә, егетнең киләчәге җырга бәйле, минемчә* (В. Т., 1997, 19 март).

1988 елда гына дөньяга килгән ТИҮ (Татар иҗтимагый үзәге) аббревиатурасыннан да **тиүче**, ягъни «Татар иҗтимагый үзәге әгъзасы, милли хәрәкәттә актив катнашучы кеше» неологизмы ясалып, кулланылышка керде: ***Тиүчеләр** беренче урынга лаек кеше тапмаганнар* (Т. я., 1998, 24 дек.).

Татар телендә исем ясаучы иң продуктив суффикс булган ***-лык/-лек*** (30. 149 б.) ярдәмендә соңгы елларда да берничә дистә яңа сүз ясалды. Беренчедән, бу кушымча яңа төшенчәләрне атау өчен, рус телендәге ***-н, -ость, -ств*** һәм латин чыгышлы суффиксларны алыштырып, Көнбатыш Европа һәм рус сүзләреннән ярымкалькалар ясауда актив кулланыла (**акционерлык**, **аудиторлык**, **спонсорлык**, **суперменлык**, **фермерлык** һ.б.). Икенчедән, аның ярдәмендә гарәп-фарсы алынмаларыннан әдәби телебездә элекке елларда кулланылмаган бик күп яңа сүзләр ясыйлар (**вәкарьлек**, **дәһрилек**, **мөһәндислек**, **мигъмарлык**, **мөкәммәллек**, **һөнәрмәнлек** һ.б.). Соңгылары, нигездә, интернациональ алынмаларга алмаш буларак төзелгәннәр һәм күбесенчә окказиональ кулланылышта йөриләр. Шул ук вакытта ***-лык/-лек*** ярдәмендә телнең үз сүзләре базасында да шактый гына уңышлы неологизмнар ясалды. Бу модель белән ясалган сүзләрнең күпчелеге һөнәр, эшчәнлек төренең җыелма атамасын белдерә: **алыпсатарлык**, **малкуарлык**, **эшкуарлык**, **эшмәкәрлек**. Бу мәгънәдәш исемнәрнең ясагыч сүзләре мәгънәләре белән 1.2 нче параграфта күрсәтелгән иде, шуңа һәрберсенең конкрет мәгънәсен аңлатып тормыйча, берәр мисал китерү белән чикләнәбез: ***Алыпсатарлыкның** төшемлелегенә хәзер күпләр төшенде, базар урамы көннән-көн озыная* (В.Т., 1996, 16 июль). *Безнең халыкка борынгыдан ук **эшкуарлык, малтабарлык** хас* (Т-н, 1995, № 5—6, 51 б.). ***Эшмәкәрлек** белән шөгыльләнергә теләүчеләр саны кими бара* (К-н, 1995, № 3—4, 30 б.).

Алда каралган неологизмнар нигезендә ясалган **иганәчелек, хәйриячелек, химаячелек**, ягъни «нинди дә булса эшне башкаруда шәхсән яисә оешма исәбеннән акчалата ярдәм күрсәтү», **кәсәбә** (промысел, предприятие — ТТАС, III, 830 б.) алынмасына бәйле **кәсәбәчелек**, ягъни **предпринимательство** сүзләре дә мәгънәләре буенча югарыда саналганнарга аваздаш: ***Химаячелек** турында сүз чыккач, әйтеп үтсәгез иде: хезмәтегезне бастыруда кем ярдәм итте?* (В.Т., 1998, 6 март). ***Иганәчелек** — җәмәгать оешмалары, дәүләт учреждениеләре һәм аерым затларның мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр ачу һәм тотуга, ятим-мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтүе* (М.җ., 2006, 25 авг.). *«Алайл» ябык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Риф Вәкил улы Вафин инде күп еллар Аллаһы Тәгалә кушкан игелекле эш — **хәйриячелек** белән шөгыльләнә икән* (М.җ., 2007, 6 апр.). *Без алга таба да кече һәм урта **кәсәбәчелекне** үстерүгә җитди әһәмият бирергә тиешбез* (М.җ., 1998, 29 дек.).

Тыю (*ф.* 1. Кемгә дә булса берәр нәрсә эшләргә рөхсәт итмәү // Берәр нәрсәне куллануга, чыгаруга юл куймау, рөхсәт итмәү — ТТАС, III, 204 б.) фигыленнән ясалган **тыюлык** сүзе «сирәк очрый торган кыргый үсемлек яки җәнлекләрне саклау һәм үрчетү урыны» мәгънәсендә заповедник алынмасын (ТТАС, I, 342 б.) тулысынча диярлек әдәби телдән кысрыклады: *Җиңүчегә Татарстан әйләнә-тирә мохитне саклау министрлыгы ... Түбән Кама — Раифа **тыюлыгы** маршруты буенча автобуста сәяхәт әзерли* (Т.я., 1995, 19 гыйнв.). Дөрес, кайбер галимнәр **заповедник** мәгънәсен тыюлыкка караганда **саклаулык** сүзе төгәлрәк бирә дип исәпли (36; ТТАС, 2005, 459 б.).

***-лык*** кушымчасы белән ясаучы нигез мәгънәсенә бәйле абстракт төшенчә белдерүче яңа исемнәр дә ясалды.

**Үземчәлек** сүзе ТТАСтә мәгънә аңлатмасы **эгоист** сүзенә кайтарылган сирәк кулланылыштагы **үземчә** (ТТАС, III, 723 б.) сүзеннән ясалган һәм «шәхси мәнфәгатьләрне җәмгыять, башка кешеләр мәнфәгатьләреннән өстен кую; үз-үзеңне генә ярату» мәгънәсенә ия **эгоизм** алынмасы урынына кулланыла: *Изелгән халыкларның милләтчелеге исә тарихи алгарышка вә икътисади максатка ярашу кагыйдәсенә каршы килә торган тар **үземчәлек** һәм аерымчалык дип игълан ителгән* (И-л, 1995, № 11, 39 б.).

**Куларкадашлык** сүзе дә соңгы елларда **партнер** сүзен алыштырып төзелгән яңа куларкадаш сүзеннән ясалган һәм партнерлык, ягъни «уртак хезмәттәшлектә булу»ны аңлата: ***Куларкадашлык*** *(партнерлык) стратегиясе президент Ельцин хөкүмәтенә булышуга иң беренчел әһәмиятне (приоритет) бирә ...* (И-л, 1995, № 2, 43 б.).

**Гыйсъян** (*и. иск. кит.* Баш күтәрү, фетнә — ТТАС, I, 281 б.) гарәп алынмасыннан ясалган **гыйсъянлык** сүзе «беркемгә дә буйсынмау, бунтарьлык» төшенчәсен бирә: *Аның үзенә көчләп тагылган богауларга, мәҗбүриләп кидергән агач камытларга, чыбыркы белән кыйнап керткән тәртә-кысаларга каршы килә торган табигый* ***гыйсъянлыгы****, горурлыгы, затлы каны-җаны кая киткән?* (М-н, 2002, № 6, 113 б.).

**Хәбәрдар** (*с. кит.* Берәр эш яки вакыйга турында белә торган, ишеткән кеше — ТТАС, III, 377 б.) алынма сыйфатларыннан ясалган **хәбәрдарлык** XX гасырның 80 нче елларында матбугат телендә иң актив кулланылыштагы сүзләрнең берсенә әверелде, ул илдәге яңарышның төп сыйфатларыннан берсе булган «бар нәрсәнең дә бөтен халык, җәмәгатьчелек өчен ачык булуы»н аңлата. Рус телендәге яңа **гласность** сүзе белән бер үк мәгънәне белдерсә дә, аны калькалар исәбендә генә карау бик урынлы түгел. Чөнки, И.М.Низамов хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, бу сүзнең төшенчәсе — «безгә читтән килмәгән, ... илебезнең барлык халыкларыныкы кебек үк, үзебезнеке, безне күптән борчыган, халык аңында, аның үз телендә формалашкан төшенчә» (100. 8 б.): *Демократия,* ***хәбәрдарлык*** *заманында «шәһәр радиосы тапшыруларының эфирга чыкмау куркынычы бар» дигән шомлы хәбәргә бер дә ышанасы килмәде* (Ч.И., 1991, 14—20 сент.).

**Хәбәрдарсызлык** неологизмы исә алда караган сүзнең антонимы булып тора: *Мухин әфәндегә* ***хәбәрдарсызлык*** *дигән нәрсә дә объектив булырга комачаулый* (М.җ., 2007, 4 май).

***-даш/-дәш, -таш/-тәш*** кушымчасы белән соңгы елларда татар сүзләреннән **төркемдәш** һәм **эштәш** исемнәре ясалды. Аларның беренчесе төркем сүзенең аңа соңгы елларда **группа** сүзеннән күчерелгән (ТТАСтә теркәлмәгән) яңа мәгънәсе нигезендә ясалган һәм **группадаш** сүзе урынына «уку йортында бер төркем-группада белем алган кеше» мәгънәсендә кулланыла: *Фәнне дә яхшы беләм кебек, әмма* ***төркемдәшләребезнең****: «Безнең билгегә ис китми, аның өчен укымыйбыз, кем генә барыр икән...» — дигәннәре йөрәгемә таш булып утырды* (М.җ., 1997, 21 март).

**Эштәш** сүзе дә шул ук калып буенча беренче мәгънәсендәге **эш** сүзеннән ясалган һәм «кем белән дә булса бергә, бер урында эшләүче» дигәнне аңлата һәм, безнеңчә, гарәп тамырлы **хезмәттәш** сүзенең конкретрак «физик эшне бергә башкаручы» мәгънәле синонимы буларак яшәргә хаклы: ... *үземне,* ***эштәшләремне*** *изалаган хаталарны искә төшермәкче булам* (Т.я., 1996, 11 июль).

Бу кушымча ярдәмендә гарәп-фарсы алынмаларыннан ясалган, сүзлекләрдә теркәлмәгән исемнәр дә шактый очрый. Алар арасында иң активы — **рәистәш** сүзе. Ул «ниндидер оешмага башка кем беләндер бергәләп җитәкчелек (рәислек) итүче кеше» мәгънәсенә ия һәм рус телендәге **сопредседатель** сүзен алыштыра: ***Рәистәшләр*** *берлеге әлеге уй-максатларны тормышка ашырырлык сәләткә ия түгел* (Ш.К., 1991, 24 дек.). *«Төрле телләрдә сөйләшүче күпмилләтле илләрдә билингвизм проблемасы яши», — ди Россия Хөкүмәте каршындагы урыс теле буенча комиссия* ***рәистәше*** *академик Е.Челышев* (В.Т., 2007, 2 март).

Ясаучы нигез белдергән предмет белән уртаклыгы буенча зат атамаларын белдерүче аерым сүзләр күбрәк окказиональ кулланылышта йөри. Берничә мисал китерик: *Һәм ул* ***кавемдәшләре, телдәшләре*** *һәм диндәшләре белән бергә укмашып яшәргә омтыла* (М-т, 1997, 18 окт*.). Соңыннан фикердәш,* ***мәсләктәш*** *һәм каләмдәш булып китәчәк яшьтәшләр Габдулла белән Фатыйма тәүге тапкыр бер-берен әнә шулай белешә* (М.җ., 2006, 3 февр*.).* ***Мәхәлләдәш*** *кешеләр оешканрак булсалар, 5 елда 4 имам алыштырырга ... мөмкин булыр идеме*? (М.җ., 1998, 20 март). *Варна эшмәкәре Любен Кобачев Саддам Хөсәеннең* ***төстәше*** *буларак мәгълүм* (В.Т., 1998, 17 март).

***-ыш/-еш*** — фигыльләргә генә ялганучы продуктив һәм аеруча терминнар ясауда еш файдаланылучы кушымча (38. 59 б.). Бу кушымча белән ясалган **йөгенеш** (тенденция) һәм **түнтәрелеш** (революция, переворот) сүзләрен дә иҗтимагый-сәяси өлкәгә караган терминнар исәбенә кертергә була, сүз ясагыч мәгънәләре — «процесс, эш-хәрәкәт исеме». **Йөгенеш** сүзе, күрәсең, йөгенү (1. Гәүдәне бераз ию (алга таба) — ТТАС, I, 463 б.) сүзеннән ясалган. «Иелү, табыну» мәгънәләрендә «йүкүн» фигыле борынгы төрки язма истәлекләрдә үк актив кулланылган (ДТС, 1969, 285 б.). **Тенденция** сүзенең мәгънәләрендә юнәлеш, омтылыш семалары булу **йөгенеш** сүзен ясарга нигез биргән дип уйларга була. Дөрес, әлегә ул күбрәк җәя эче аныкламасы белән яисә аныклаулы атамалар составында кулланыла: *Тагын бер* ***йөгенеш*** *(тенденция) күрәм ...* (И-л, 1995, № 3, 4 б.).

**Түнтәрелеш** (түнтәреш, түңкәреш вариантлары да очрый) неологизмы сөйләм теленә хас түнтәрү ( ... 4. Берәр нәрсәне икенче бер рәвешкә, төргә әверелдерү — ТТАС, III, 288 б.) фигыленең төшем юнәлеше формасыннан ясалган һәм берьюлы ике мәгънәдә — **революция** һәм **переворот** сүзләрен алыштыру өчен шактый актив һәм, гадәттә, тискәре төсмер белән кулланыла: *17 нче елгы* ***түнтәрелештән*** *соң да әнә «бераз гына көтик инде, гаделлек барыбер җиңәчәк ул» дип әйтүчеләр*

*булган* (И-л, 1995, № 11, 44 б.). *... дәүләт **түнкәреше** булып, самими беренче сәркәтибебезне галәми биеклектәге постыннан алып ташладылар ...* (М.ж., 2007, 6 апр.).

***-ма/-мә*** кушымчасы белән фигыльләрдән алар атаучы процесс нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән предмет, төшенчәне белдерүче дистәгә якын исем ясалды. Шулардан иң активы һәм уңышлысы — **нигезләмә**, нигезләү сүзенең икенче «ышандырырлык, җитди дәлилләр белән исбатлау, дәлилләү» (ТТАС, II, 442 б.) мәгънәсе җирлегендә ясалган һәм «нәрсәнең дә булса тормышка ашырылырга лаеклы булуын исбатлаучы дәлил» мәгънәсендә рус телендәге **обоснование**, **положение** сүзләре урынына кулланыла: *Бу программаның асылын түбәндәге концептуаль **нигезләмәләр** тәшкил итәргә тиешләр* (К.у., 1996, № 7, 167 б.).

**Тәгаен** (...4. *и. мәгъ. иск.* (Берәр эшкә билгеләү өчен) рәсми оешмалар яисә кешеләрнең карары, боерыгы — ТТАС, III, 208 б.) архаизмына бәйле **тәгаенләү** фигыленнән ясалган **тәгаенләмә** неологизмы «эшкә билгеләү кәгазе, направление» мәгънәсен белдерә: *Каракалпак ягындагы бер казакъ районына военкоматка **тәгаенләмә** алып та киткән ...* (М-н, 2002, № 8, 12 б.).

Шушы ук калып буенча ясалган **бәһаләмә** (С-ә, 1991, № 12, 11 б.), **сыйфатлама** (В.Т., 1998, 5 июль) сүзләре **бәяләмә** варианты белән чагыштырганда сирәк кулланылалар. **Раслама** (утверждение — В.Т., 1998, 19 июнь) неологизмының мәгънәсен дә, безнеңчә, әлегә **раслау** исем фигыле аша бирү отышлырак, ә **төзләмә** (учреждение — З.-Т., 1998, 10 апр.) тибындагы төзелмәләрне исә аңлатма белән бирү таләп ителә.

Сыйфат фигыль күрсәткече булган ***-ыр/-р*** хәзерге татар телендә сүз ясагыч аффикс буларак та кулланыла (35. 272 б.). Узган гасырның 90 нчы елларында аның ярдәмендә исем фигыль нигезеннән ике яңа сүз ясалды: **әйдәр** һәм **буйсыныр**. Аларның сүзьясалыш мәгънәләре уртак — «нигездә, аталган эш-хәрәкәтне башкаручы зат». Академик грамматикада бу модельнең мондый мәгънәсе теркәлмәгән, шуңа да аны телебез өчен яңа күренеш дип карарга була.

**Буйсыныр** сүзе «кемгә дә булса буйсынган, ягъни аның хакимлеге, җитәкчелеге астында булган кеше (подчиненный)» мәгънәсенә ия һәм кайчакта дөрес булмаган **буйсынар** вариантында да кулланыла: *Ул һәм аның **буйсынырлары** тәтәйләр йортында тотылганнар* (Ш.К., 1994, 17 дек.). ***Буйсынар**, ярты көн буе «кыйммәтле кәгазьләрдә» казынып, җаваплы кешене тапты һәм, нишләргә дә белмичә, читенсенеп башлыгына керде* (В. Т., 1995, 27 гыйнв.).

**Әйдәр** неологизмы **лидер** сүзе урынына алдагы параграфта телгә алынган **узаман** сүзенең синонимы буларак очрый. Шулай ук әйдәүче варианты белән бергә рус телендәге **ведущий** сүзен дә алыштыра: *Аны (сугышны) күзгатучылар ... Ауропаның **әйдәр** иленә әйләнүне максат итәләр* (И-л, 1995, № 8, 29 б.). Безнеңчә, бу неологизмның телебездә әлегә уңышлы алмашы булмаган рус телендәге **ведущий** сүзе урынына кулланылышка керү перспективасы шактый өметле, әйтик: ведущий специалист — **әйдәр** белгеч, ведущий учитель — **әйдәр** укытучы һ.б.

***-ем/-м*** кушымчасының татар әдәби телендә активлашып баруына Ф.С.Фасеев игътибар иткән иде (147. 136 б.). Соңгы елларда да аның белән ике яңа сүз ясалды: **кертем** һәм **өчләм**. Аларның беренчесе кертү фигыленең бишенче (нәрсә өчен дә булса түләү, бирү — ТТАС, II, 86 б.) мәгънәсенә нигезләнеп ясалган һәм **вклад** сүзе урынына «гражданнар яисә оешмаларның банкка салган (керткән) акчасы» төшенчәсен бирү өчен кулланыла. Алда телгә алынганча, 1985 елгы русча-татарча сүзлектә дә инде ул **вклад** сүзенең бер аңлатмасы буларак чагылыш тапкан (РТС, 66 б.). Сүзьясалыш типлары төрле булганлыктан, **кертем** сүзен калькалаштыру юлы белән генә ясалган дип карап булмый: *Гражданнарның **кертемнәре** 2,2 триллион сум тәшкил итте* (В.Т., 1996, 28 дек.). **Кертем** сүзен **керем** сүзе белән бутап кулланган очраклар да бар: *Саф авыл хуҗалыгы районы буларак, бөтен **кертемнәре** икмәк, ит, сөт сатудан бәйле* (К.у., 1992, № 5, 132 б.).

**Өчләм** — триптих (бер төп идея белән бәйләнгән өч сәнгать әсәре) сүзен дә, татар телендә сүз ясагыч ***-ләм*** кушымчасы булмаганлыктан, өчле ( ... нәрсәнең дә булса өч саны белән белдерелгән үлчәүле булуын ... белдерә (ТТАС, III, 715 б.) санына ***-әм*** кушымчасы ялгап ясалган дип карыйбыз: *Нәкъ менә шул күзгә күренмәүче җеп Габдулла Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим ителүче әсәрләре — Тукай, Дәрдмәнд портретларын, Бакый Урманчега багышланган «Язмыш» **өчләмен** (триптих) үзара бәйләп тора* (М.ж., 1997, 18 апр.).

***-к*** кушымчасы ярдәмендә XX йөзнең 90 нчы еллары уртасында **санау** (... 2. Предметларның микъдарларын бер-бер артлы саннар белән хисаплау; ничә яки күпме икәнен билгеләү (ТТАС, II, 628 б.) фигыленнән **санак** исеме ясалды. Ул «электрон хисаплау машинасы» мәгънәсендә **компьютер** сүзе урынына кулланылышка керә башлады. Компьютер үзе латинча computare — санау дигән сүздән ясалганны исәпкә алсак (СИС, 1997, 144 б.), бу неологизмны уңышлы һәм перспективалы дип исәпләргә була, һәрхәлдә, ул «татарлаштырылган кампитр» вариантыннан күпкә өстен. *Балалар су коенган арада **санакларда** эшләп, төрле уеннар, ярышларда катнашып , ... чын-чынлап, «Сәләт»легә әвереләчәк* (Т.я., 1997, 6 февр.).

***-ман/-мән*** кушымчасының татар телендә сүз ясалышы буенча хезмәтләрдә предмет, урын, корал яки җайланма мәгънәле азсанлы исемнәр ясавы күрсәтелә (38. 78—79 б.). Соңгы елларда аның

ярдәмендә характерлы билгесе, һәвәслеге, шөгыле буенча кешене атаучы сүзләр дә ясалды. Моңа, бәлки, ***-ман*** компоненты белән ясалган, «беренче компонентта белдерелгән нәрсәне көчле яратучы кеше» мәгънәле (СИС, 1988, 291 б.) күпсанлы Көнбатыш алынмаларының йогынтысы да булгандыр. Дөрес, ***-ман/-мән*** кушымчасы ярдәмендә фигыльләрдән ясалган зат белдерүче сүзләр борынгы төрки истәлекләрдә үк теркәлгән (71. 95 б; 177. 108 б.). Бу аффикс белән ясалган неологизмнарның да ясагыч нигезе киләчәк заман сыйфат фигыль формасы: **көярмән** (болельщик), **сөйләрмән** (оратор). Аларның Башкортстан татар матбугатында актив кулланнылучы беренчесе, безнең карашка, бик уңышлы неологизм. Чөнки аның ясагыч нигезендәге мәгънә (көю II *ф.* Кайгыру, көенү, хәсрәтләнү; борчылу, кайгырту —ТТАС, II, 278 б.) әлегә кадәр татар телендә уңышлы атамасы булмаган **болельщик** сүзенекенә аваздаш һәм **көярмән** сүзе җанатар // янатар вариантыннан отышлырак: *Тамашачы никадәр генә битараф калырга тырышмасын, бәйгеләр вакытында ... **көярмәнгә** әверелә* (К.т., 1997, 10 апр.). *Фанатларның, **көярмәннәрнең** тәртипсезлеге аркасында полиция хезмәткәре үлгән ... (*Өмет, 2007, 8 февр.).

**Сөйләрмән** сүзе дә (**сөйләү** сүзенең « ... // Җыелышта һ.б. урында: чыгыш ясау» (ТТАС, II, 715 б.) мәгънә төсмереннән ясалган) телебезнең үз җирлегендәге башка уңышлырак синонимнары булмау сәбәпле, безнеңчә, «чыгыш ясаучы (кеше), докладчы» мәгънәсендә яшәргә хаклы. *Әлбәттә, мондый да көчле оратор-**сөйләрмән** янәшәсендә күп кенә үзешчән дин әһелләребез чүгеп калачак* (М.ж., 1997, 14 нояб.).

**Әйдәү** фигыленең күчерелмә «күпләрне өндәү, үз артыннан ияртү, оештыру, дәртләндерү» (ТТАС, 2005, 744 б.) мәгънәсе нигезендә ясалган **әйдаман** неологизмы «лидер, конкрет эш-ярышны оештыручы» мәгънәсендә кулланыла: *Икенчесе кунакларның һөҗүмдәге **әйдаманы** булды һәм очрашудагы тәүге туп нәкъ менә аның тырышлыгы белән керде* (В.Т., 2007, 3 апр.).

Бу кушымча ярдәмендә гарәп алынмасыннан ясалган, соңгы елларда аеруча популяр **сәясмән** сүзе дә сүзлекләрдә теркәлмәгән. Гарәп, фарсы телләрендә «сәясәтче» мәгънәсендә **сәүвас, сасәт** (АРС, 382 б.), **сийсәтмәдәр, сийаси** (РПС, 642 б.), төрек телендә **политикачы, сийасәтче** (ТТС, 244 б.) сүзләре кулланыла. Бу исә **сәясмәннең** алынма сүз түгеллеген дәлилли. Шулай да, безнеңчә, бу очракта телдә электән кулланылучы **сәясәтче** варианты уңышлырак: *Бәла бит матбугатта, бүтән матбугат чараларында еш кабатланган хата төшенчәнең әкренләп журналистлар, **сәясмәннәр**, әлеге программалар белән эш итүче белгеч һәм җитәкчеләрнең аңына-сөйләменә ... күчә баруында иде* (М.ж., 2006, 24 нояб.).

***-мыш*** кушымчасы белән ясалган неологизмнарга мисал итеп **сынамыш** «белем һ.б. дәрәҗәсен тикшереп, сынап, бәя бирү; тестирование» сүзен китерергә була. Ул **сынау** (II *и.* 1. Уку йортларында: белем дәрәҗәләрен тикшереп, сынап, рәсми бәяләү эше; имтихан — ТТАС, II, 701 б.) исеменнән ясалган һәм сөйләм телендәге **сынамыш** (сынау I. — 1 // Тормышында-эшендә кичереп, шәхси тәҗрибәңнән белү» — ТТАС, II, 701 б.) нигезеннән ясалган сүзенә омоним булып тора: *Укырга керүчеләр **сынамыш** ярдәмендә имтихан бирә* (Т.й., 1995, 15—22 июль).

### Кушымчалар белән сыйфат ясау

Рус һәм аның аша Европа телләреннән кергән сыйфатларны үзләштергәндә, аларның нигезләрен кыскартып яисә аерым ясагыч суффиксларны татар кушымчалары белән алыштырып телебезгә яраклаштыру актив кулланылса да (бу очракларга мисаллар ярымкалькалар бүлекчәсендә карала), татар теленең үз сүзләреннән яңа ясалган сыйфатлар күп түгел, булганнары да, нигездә, алынмалар тәэсирендә барлыкка килгәннәр яисә окказиональ кулланылышта. Шуңа да биредә бер мисал китерү белән чикләнәбез: *Карарның максаты — урта һәм кече эшмәкәрлекне үстерү программасын раслау, яңа оешкан предприятиеләргә **ташламалы** салымнар билгеләү ...* (Ш.Ч., 1998, 12 июнь). **Ташламалы** сыйфаты **ташлама** (*и.* 1. Кемгә дә булса гомуми таләпләрне йомшарту ... — ТТАС, III, 58 б.) сүзеннән ясалган һәм элекке **льготалы** сыйфаты урынына шактый актив кулланыла.

### Кушымчалар белән фигыль ясау

Татар телендә соңгы елларда рус теле аша кергән сүзләрдән алардагы ***-аци, -ализаци, -изаци, -изирова-, -ирова-*** формантларын ***-ла/-лә, -лан/-лән, -лаш/-ләш, -лаштыр/-ләштер*** кушымчалары белән алыштырып, бик күп ярымкалька ясалды (мисаллар 1.4 бүлекчәдә). Алар арасында чыганак (арадаш) телдәге исемнәрдән алда күрсәтелгән формантларны кыскартмый гына, кушымча өстәп фигыль ясау очраклары, ягъни чиста калька итеп кенә карап булмаган мисаллар да бар: *Шау-гөр килеп Президентыбызны **инаугурацияләгән** генә идек, азык-төлеккә һәм аракыга бәяләр сикереп куйды* (М-т, 1996, 9 май).

Җәмгыять тормышындагы яңа күренешләрнең атамалары буларак гарәп-фарсы алынмаларыннан ***-лаштыр/-ләштер*** кушымчалары ярдәмендә ясалган фигыльләрне карап үтик.

Гарәп чыганаклы **хосусый** (... 4. Шәхси милек биләү, аерым хуҗалык итү һәм шуңа ярашлы иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән — ТТАС, III, 372 б.) сыйфатыннан ясалган

**хосусыйлаштыру** сүзе «дәүләт милкен хосусый, шәхси милеккә күчерү»не аңлата, ул илдә узган гасырның 90 нчы еллары башында киң җәелгән процессларга бәйле рәвештә туды. Баштагырак чорда бу төшенчәне белдерү өчен күбрәк **приватизацияләү** сүзе кулланылса, хәзер тулысынча **хосусыйлаштыру** варианты хакимлек итә: *Яр буе паркында 1995 елда ук төзелә башлаган спорт-сәламәтләндерү бинасын ...* ***хосусыйлаштырып*** *аукционга кую мәсьәләсен депутатлар бертавыштан кабул иттеләр* (Ш.Ч., 2007, 5 окт.). Бу сүз хәзер шулай ук исем мәгънәсендә **приватизация** алынмасы урынына да кулланыла: *Татарстан* ***хосусыйлаштыруның*** *үз программасын кабул итте* (Т.я., 1995, 18 февр.).

Шулай ук гарәп-фарсы **сәяси** (политик) сыйфатыннан бу кушымча белән ясалган **сәясиләштерү** — «сәяси төсмер бирү» фигыле дә бик актив кулланыла: ... *һәр елны бюджетны* ***сәясиләштереп****, аңа артык йөк салып, без беркайчан да савыктыруга ирешә алмаячакбыз* (В.Т., 1998, 28 февр.).

Әминият / иминият — 1. ... Куркынычсызлык, хәвеф-хәтәрсезлек. 2. Ышаныч — ГТРАС, 738 б.) алынмасыннан ясалган **иминиятләштерү** неологизмы татарчага авыр тәрҗемәләнүче **страхование**, **страховкалаштыру** сүзен алыштыра бара: *Йортыбыз мәҗбүри һәм ирекле рәвештә* ***иминиятләштерелгән*** *булганлыктан, «Тасфир» страховкалау акционерлык җәмгыятенең Минзәлә бүлегенә мөрәҗәгать иттек* (В.Т., 1996, 6 авг.).

Элек матбугатта очрамавы һәм өч томлык аңлатмалы сүзлектә теркәлмәвеннән чыгып, хәзерге татар теле өчен продуктив булмаган ***-дер*** кушымчасы (38. 141 б.) ярдәмендә ясалган **тернәкләндерү** (*фиг.* Сәламәтләндерү, аякка бастыру — ТТАС, 2005, 533 б.) фигылен дә соңгы чорда ясалган сүзләр исәбенә кертергә була. Ул аеруча **реабилитация** төшенчәсен бирү өчен актив кулланыла: *«Изгелек» инвалидларны* ***тернәкләндерү*** *үзәгенә, Боз сараена, «Бердәм Россия» физкультура — сәламәтләндерү комплексына Россиядә тиңнәр юк* (Ш.Ч., 2007, 15 авг.).

Мисаллардан күренгәнчә, соңгы елларда татар телендә кушымчалау ысулы белән аеруча исемнәр күп ясала. Аларның ясаучы нигезләре булып төрки-татар сүзләре һәм электән үзләштерелгән, шул исәптән соңгы елларда гына активлашкан гарәп-фарсы алынмалары хезмәт итә. Рус-европа алынмаларыннан ясалган исемнәр барысы да диярлек ярымкалька булып торалар. ***-чы/-че, -лык/-лек*** кушымчалары хәзер дә иң продуктив исем ясау чарасы булып кала бирәләр, башка кушымчалар белән ясалган исемнәр күп түгел. Татар сүзләреннән кушымчалар ярдәмендә бүтән сүз төркемнәренә караган неологизмнар ясалмады диярлек, әмма алынма нигезгә татар кушымчалары ялгап ясалган күп кенә сыйфат һәм фигыльләр барлыкка килде.

### 1.3.2. Синтаксик юл белән ясалган сүзләр

«Татар теле агглютинатив тел булу белән беррәттән аналитик тел булып та тора» (37. 20 б.). Шуңа да телебездә синтаксик ысул белән сүзләр бик күп ясала. Соңгы елларда барлыкка килгән аналитик сүзләр, язылышларыннан чыгып, өч традицион төркемгә — парлы, тезмә, кушма сүзләргә бүлеп карала. Парлы сүзләргә — компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылып, сызыкча аша язылучы сүзләр, тезмә сүзләргә — ияртүле бәйләнешкә кереп лексикалашкан бер төшенчә белдерүче сүзтезмәләр, кушма сүзләргә компонентлары үзара ияртүле бәйләнеш нигезендә кушылып ясалган һәм сүзтезмәләрнең лексикалашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән кушылып язылучы сүзләр кертелә.

#### 1.3.2.1. Парлы сүзләр

Соңгы еллар татар язма әдәби теленең, бигрәк тә газета-журнал теленең төп үзенчәлекләренең берсе — сызыкча аша язылган сүзләрне күп куллану. Бу барыннан да элек телебезгә яңа төшенчәләр белән бергә башка теллрдән һәм өлешчә диалектлардан яңа сүзләр керү белән бәйле. Чөнки, галимнәр әйтүенчә, парлы сүзләр беренче чиратта төрле тел һәм диалект лексикасын сөйләмдә аңлашылырлык итеп куллану хаҗәтеннән ясала (44. 136 б; 34. 19 б.). Икенчедән, парлы сүзләр телне алынма сүзләрдән арындыру юлында бер күчмә этап хезмәтен үти; өченчедән, алар яңа төшенчәнең мәгънәсен тулырак, төгәлрәк аңлата.

Билгеле, сызыкча аша язылган тезмәләрнең барысы да парлы сүзләргә керми. Ф.А.Ганиев хезмәтләренә таянып, биредә компонентлары арасында тезүле, үзара тигез хокуклы бәйләнеш булган сүзләр генә парлы сүзләр итеп карала (34. 19 б.).

Соңгы елларда ясалган парлы сүзләр арасында ике компоненты да татар сүзе булганнары очраса да, күбесенең бер компоненты сыйфатында гарәп-фарсы яисә рус һәм Көнбатыш Европа алынмасы кулланыла. Структур яктан алар нигездә «исем + исем» тибына карый, башка (сыйфат + сыйфат, фигыль + фигыль) тип буенча ясалганнары берничә генә. Семантик үзенчәлекләре буенча алар ике төркемгә бүленә:

**1. Бер үк мәгънәдәге төрле чыгышлы компонентлардан төзелгән парлы сүзләр**

Алар телне «татарчалаштыру» максатыннан ниндидер төшенчәнең автор тәкъдим иткән татарча атамасын, укучы ныграк аңласын өчен, телдә электән кулланылган алынма («чит») атамасы белән парлап бирү нәтиҗәсендә туган. Компонентлар арасына сызыкча урынына ягъни теркәгечен куеп була; төзелмәнең мәгънәсе, нигездә, һәрбер компонентның мәгънәсе белән тәңгәл. Шуңа да мондый төзелмәләрне шартлы рәвештә, бары формаль яктан, сөйләм дәрәҗәсендәге парлы сүзләр итеп кенә карап була, алар телнең яңа берәмлеген тәшкил итә алмый. Компонентларның чыгышы ягыннан алар биш төркемчәгә бүленә:

а) рус-европа алынмасы + татар сүзе: **булавка-каптырма**, **кулинар-ашчы**, **монстр-албасты**, **оратор-сөйләрмән**, **план-ният**, **пост-кәнәфи**, **предприятие-оешма**, **пропуск-юллама**, **рецензия-бәяләмә**, **секция-төркем**, **талант-сәләт**: *Аңа күп булса бер* ***булавка-каптырма*** *гына бирәләр* (С-й, 1995, 25 нояб.). *Ә Ришат күзен ачуга кире йомды — ул әллә нинди котчыкмалы* ***монстр-албасты*** *күрде* (К.к., 1996, 20 апр.). *Өстәвенә* ***предприятие-оешмалар*** *салым михнәтләреннән газап чигә* (В.Т., 1996, 23 июль);

ә) татар сүзе + рус-европа алынмалары: **белгеч-кадр**, **келәм-ковер**, **оешма-учреждение**, **тотык-заложник**, **чыгыш-лекция**, **эшкуар-бизнесмен**: *Бу институтның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы тулы штатка эшләүче* ***белгеч-кадрлар*** *кытлыгы кичерә* (В.Т., 1997, 21 февр.). *Киңәшмә эшендә ...* ***оешма-учреждение*** *җитәкчеләре катнашты* (Ш.Ч., 1997, 10 гыйнв.). *... Африкадан башлап Япониягә хәтле, эш таба алсаң, ул зур дөньяга* ***пропуск-юллама*** *булып тора* (В.Т., 2007, 12 окт.). *Ниһаять, Ичкерия сугышчылары Дагстанда алынган* ***тотак-заложникларны*** *республиканың милли хәрәкәт вәкилләренә тапшырдылар* (М.җ., 1996, 26 гыйнв.). *Аның иҗатына гашыйк кешеләр җыелган бу очрашуда шагыйрь татар шигъриятенең бүгенге торышына кагылышлы* ***чыгыш-лекция*** *ясады* (М.җ., 1996, 6 дек.);

б) татар сүзе + гарәп-фарсы алынмасы: **астөшермә-хашия**, **боерык-фәрман**, **бүләк-ришвәт**, **өндәмә-шигарь**: *Хәтта китапларда «киек» сүзенә* ***астөшермә-хашия*** *биреп аңлату очраклары да юк түгел* (М.җ., 1997, 31 окт.). *Әһә, партиянең күрсәтмәсе, хөкүмәтнең* ***боерыгы-фәрманы*** *бар икән* (А-к, 1992, № 7—8, 60 б.). *Безнең мәктәптә* ***бүләк-ришвәт*** *алмыйлар! — диде үпкәле тавыш* (Т.я., 1997, 6 нояб.);

в) гарәп-фарсы алынмасы + татар сүзе: **фәрман-боерык**, **шигарь-өндәмә**: *Әйе, хөкүмәтнең һәр* ***фәрманы-боерыгы*** *хәрам* (Т.я., 1997, 6 нояб.). *Ике* ***шигарь-өндәмәне*** *файдалану да зарурдыр* (В.Т., 1996, 17 май);

г) рус алынмасы + гарәп сүзе: **карта-харита**, **теоретик-нәзари**. *«Татарстан» бер үк вакытта* ***теоретик-нәзари*** *журнал да* (С-ә, 1992, № 9, 20 б.).

Формаль яктан **аҗаган-наҗагай**, **кимәл-дәрәҗә** кебек сирәк булса да соңгы еллар матбугатында очраштырган һәм бер компоненты диалектизм тәшкил иткән төзелмәләрне дә шушы төркемгә кертергә була; тик алар, күрәсең, әдәби тел сүзен конкрет сөйләш-диалект вәкиленә аңлаешлырак итү максатыннан ясалгандыр: *Безнең* ***аҗаган-наҗагай*** *кебек уйнаган телләр шундук авыз эченә кереп бикләнде* (М.җ., 1997, 12 дек.).

**2. Аталган предметларның күплек-җыелмалыгын яисә киңрәк, гомумиләштерелгән мәгънә белдерүче парлы сүзләр**

Бу төр төзелмәләр, нигездә, татар телендә әлегә бер сүзле үз атамалары булмаган яисә яңа төшенчәләрне белдерү максатыннан ясалган. Аларның мәгънәләре һәр компонент мәгънәсеннән киңрәк. Компонентларның чыганаклары буенча бу берәмлекләрне өч төркемгә аерып карарга була:

а) ике компоненты да татар чыгышлы парлы сүзләр: **аракы-сыра** (исерткеч эчемлекләр), **баш-сын** (бюст), **белгеч-зыялы** (интеллигенция вәкиле), **биләмә-урын** (территория), **икмәк-печән** (авыл эшчәннәренә колхоз тарафыннан натуралата түләм), **төбәк-почмак** (регион), **якташ-җирдәш** (чит илдә очрашкан бер ватанда туган кеше): *Алар икәүләшеп шул көннән башлап көне-төне* ***аракы-сыра*** *чөмерделәр ...* (Ш.Ч., 1997, 18 нояб.). *Бер баштан бүлтәеп чыккан ике авыздан гыйбарәт* ***баш-сын*** *(бюст) бүгенге көндә чишелә алмый торган фаҗигале дуализмга ишарәли* (С-ә, 1996, № 2, 34 б.). *Халкыбызның яхшы әзерлекле* ***белгеч-зыялыларын*** *арттыру-тәрбияләүдә үзеннән зур өлеш кертер дип олуг өметләр баглаган идек* (В.Т., 1997, 21 февр.);

ә) татар һәм гарәп-фарсы компонентлы парлы сүзләр: **бәйсез-мөстәкыйль** (суверен), **бизәк-нәкыш** (узор), **богау-зынҗыр** (наручник), **һөнәр-белгечлек** (специальность): *Бу газета тәүге саннарында ук* ***бәйсез-мөстәкыйль*** *республика төзү идеясен кыю яклап чыкты ...* (Ш.Ч., 1997, 12 дек.). *Инде бөтен тирә-якка иман нурын чәчкән җәмигъ мәчетендәге* ***бизәк-нәкышләргә***, *шушы карусыз җан язган шәмаилләргә сокланмаган кеше юк* (А-к, 1993, № 10, 78 б.). *Әнә Русиянең мәшһүр шамакае Жириновский Дума мөнбәреннән* ***богау-зынҗыр*** *чыгарып селкүгә кадәр барып җитте* (М.җ., 1996, 8 май);

б) рус-европа һәм гарәп-фарсы компонентлы парлы сүзләр: **поликлиника-хастаханә** (дәвалау учреждениесе): *Район мәктәпләрендә,* ***поликлиника-хастаханәләрендә*** *хезмәт хакларының соңлап бирелүе шуның белән аңлатыла да* (В.Т., 1996, 13 авг.).

Югарыда каралган мисаллар телебездә соңгы елларда нычыган парлы сүзләрнең зур күпчелеге алынма, шул исәптән гарәп-фарсы чыганаклы сүзләрне татар сүзе белән янәшә куеп ясалганын күрсәтә. Икесе дә татар яисә гарәп-фарсы һәм татар компонентлы сүзләрнең дә шактые рус-европа алынмаларын алыштыруга хезмәт итә, бу исә парлы сүзләр ясалу процессында да лексикабызның беренче чиратта үз ресурслары исәбенә үсәргә омтылуын чагылдыра.

### 1.3.2.2. Аныклаулы атамалар

Язылыш-төзелешләре буенча парлы сүзләргә охшаган төзелмәләрнең бер төркемен соңгы елларда аныклаулы атамалар дигән аерым категория итеп өйрәнә башладылар. Татар тел белемендә аларга беренче булып игътибар иткән Н.В.Максимов фикеренчә, аныклаулы атамалар парлы сүзләрдән һәр компонентның тулы мәгънәле булуы, аларның фонетик яктан бербөтен булып оеша алмаулары (ягъни ике басымлы булулары) белән аерылалар (83. 50—51 б.). Татар телендә басым әллә ни зур роль уйнамаганлыктан, бер яки ике басымлы булуга карап, бу ике категорияне аеру кыен, шуңа да без семантик үзенчәлеккә нигезләндек, ягъни алда каралган парлы сүзләрнең компонентлары йә икесе дә бер үк төшенчәне аңлата, йә башка, киңрәк мәгънә барлыкка китерә; аныклаулы атамаларда исә яңа мәгънә компонентлар мәгънәсенең суммасын тәшкил итә, бер сүз икенчесен конкретлаштыра, аныклый, мәсәлән: **күргәзмә-ярминкә** (әйберләрне реклама максатыннан күпләп халыкка күрсәтү һәм сату), **семинар-киңәшмә** (семинар формасындагы киңәшмә), **утрау-ныгытма** (ныгытма — крепостька әверелдерелгән утрау), **эколог-белгеч** (экология өлкәсендә махсуслашкан белгеч) һ.б.

Аныклаулы атамалар, нигездә, рус теле тәэсирендә совет чорында барлыкка килгән булса да (83. 49 б.), бүгенге көндә аларны тулысынча калькалар рамкаларында гына карап булмый, чөнки араларында шул ук модель буенча рус төзелмәләренә мөнәсәбәтсез рәвештә ясалганнары да бар, мәсәлән: **киңәш-тәкъдим** (киңәш формасында ясалган тәкъдим) (М.җ., 1997, 12 дек.), **сугышчы-мөҗәһит** (дин, ватан бәйсезлеге өчен сугышучы, Чечня вакыйгаларына бәйле рәвештә кулланыла) (С-й, 1995, 6 сент.), **төзү-ачу** (башта оештырып, башлап җибәрү) (В.Т., 1997, 21 февр.) һ.б. Шуңа да аныклаулы тезмәләрне татар телендә аналитик сүзләр ясау ысулының бер төре, Н.В.Максимовча әйтсәк, «сызыкча аша языла торган тезмә сүз калыбы» (83. 57 б.) итеп карарга була.

Соңгы елларда барлыкка килгән аныклаулы атамаларның күбесе «исем+исем» моделе буенча төзелгән, «сыйфат+сыйфат», «фигыль+фигыль» модельләре дә очрый. Компонентларының кайсы телгә каравыннан чыгып, соңгы еллар әдәби телендә аеруча күп кулланылган яңа аныклаулы атамалар 6 төркемчәгә бүленә:

1) татар сүзе + татар сүзе: **бәйге-күргәзмә**, **сүзлек-белешмә**, **төзү-ачу**, **төзү-бизәү**, **уен-бәйге**, **утрау-ныгытма**, **шаукым-йөгенеш**: *Соңгы елларда әлеге әсәрләр төрле* ***бәйге-күргәзмәләрдә*** *күрсәтелде, югары бәя алды* (В.Т., 1996, 24 май). *Һәр югары уку йортында татар теле кафедралары* ***төзү-ачу*** *күздә тотыла* (В.Т., 1997, 21 февр.). *... ә* ***төзү-бизәү*** *эшләрен аның җитәкчелегендәге рәссам-төзүчеләр бригадасы осталары башкарды* (М.җ., 1996, 6 дек.);

2) татар сүзе + рус-европа сүзе: **әңгәмә-диспут**, **әңгәмә-концерт**, **башкаручы-референт**, **белгеч-провизор**, **киңәшмә-летучка**, **күргәзмә-галерея**, **күргәзмә-презентация**, **күргәзмә-ярминкә**, **сөйләшү-зачет**: *Безнең* ***әңгәмә-диспутлар*** *теплоходның алгы өлешендә, ярымтүгәрәк салонда бара* (М. ж., 1997, 14 нояб.). *Комиссиядә* ***башкаручы-референт*** *булып эшләдем* (С-й, 1995, 1 март). *Анда кытайлар игътибарына республиканың социаль-икътисади һәм инвестицион сыйфатларын чагылдыручы* ***күргәзмә-презентация*** *тәкъдим ителәчә*к (В.Т., 2007, 27 март). ***Күргәзмә-ярминкәдә*** *катнашу сезнең өчен тәҗрибә уртаклашу да бит инде ул* (М.җ., 2006, 22 сент.). *Мондый* ***сөйләшү-зачет*** *үзен аклый, чөнки имтихан алучы укытучы билгене гадел куя* (М-ф, 1994, № 11, 49 б.);

3) рус-Көнбатыш Европа сүзе + татар сүзе: **антенна-тапшыргыч**, **концерт-бәйге**, **музей-тыюлык**, **музей-утар**, **концерт-тамаша**, **палатка-кибет**, **семинар-киңәшмә**, **фермер-игенче**: *Дөрес, инде берничә ел Шәмәрдән тирәсендә шул тапшыруларны алырлык* ***антенна-тапшыргыч*** *корыла* (Т.я., 1994, 4 окт.). *Мондый* ***концерт-бәйгеләрнең*** *төп максаты яшь профессиональ җырчыларны барлаудан гыйбарәт* (В.Т., 1996, 28 дек.). *Алабуга дәүләт* ***музей-тыюлыгының*** *Н.А.Дурова* ***музей-утары*** *мөдире Вәлитова Фәридә Хәким кызына «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде* (В.Т., 2007, 21 авг.). *Узган уку елы йомгакларына багышланган республика* ***семинар-киңәшмәсе*** *булды* (М.җ., 1997, 22 авг.);

4) татар сүзе + гарәп-фарсы сүзе: **әңгәмә-бәхәс**, **бәйге-тамаша**, **ил-дәүләт**, **киңәш-мәҗлес**, **малтабар-химаяче**, **сугышчы-мөҗәһит**: ... *азактан исә, сәяхәт барышындагы* ***әңгәмә-бәхәсләргә*** *сөземтә ясала* (М. ж., 1997, 14 нояб.). *«Сөембикә» журналы һәм «Ак калфак» берләшмәсе «Гыйффәт туташ» исемле* ***бәйге-тамаша*** *үткәрде* (С-ә, 1996, № 8, 41 б.). *Ул үзе дә* ***сугышчы-мөҗәһитләр*** *белән Грозный шәһәренең үзәгендә урнашкан Президент сараен саклауда катнашкан* (С-й, 1995, 6 сент.);

5) гарәп-фарсы + татар сүзе: **гамәли-янгынчылык**, **мөнәсәбәт-караш**, **нәтиҗә-бәяләмә**, **рәссам-бизәүче**, **рәссам-сынчы**, **рәссам-төзүче**, **рөхсәт-юллама**, **сәркатип-эш башкаручы**, **тамаша-бәйге**,

**тәкъдим-киңәш**: *Бүген промкомзонада урнашкан 74 нче пожар частенда «Яр Чаллы» призына* ***гамәли-янгынчылык*** *спорты буенча яшүсмерләр чемпионаты була* (Ш. Ч., 1997, 10 гыйнв.). *Шәһәрдә атаклы* ***рәссам-сынчы*** *исемен йөртүче урамга быел Бакый аганың һәйкәле дә куелачак* (К.у., 1997, № 4, 190 б.). *Килгән һәрбер сәүдә әһеле сату итү өчен махсус* ***рөхсәт-юллама*** *алырга тиеш* (С-й, 1996, 31 авг.);

б) рус-европа алынмасы + гарәп-фарсы алынмасы: **автор-рәссам**, **гимназия-мәктәп**, **лицей-мәктәп**, **модельер-рәссам**, **финанс-сәнәгать**: *Эшләпә рәвешендәге төтен үткәргечләре, гаҗәеп матур бизәкләре булган бу оешманың* ***автор-рәссамы*** *атаклы Богородская ханым үзе!* (М. ж., 1997, 12 сент.). *Безнең шәһәрдән «Товиус» предприятиесенең* ***рәссам-модельерлары*** *милли стильдәге өч кием моделе күрсәттеләр* (Ш.Ч., 1997, 20 март). *Коррупция ул — сәяси-икътисади күренеш. Күренеш кенә түгел, ә хакимият белән* ***финанс-сәнәгать*** *капиталының җинаятьчел берләшеп яшәү рәвеше* (М.ж., 2007, 27 апр.).

Мисаллардан күренүенчә, аныклаулы атамаларның компонентлары бик тотрыклы түгел, парлы сүзләрдән аермалы буларак, алар урыннарын алыштырып та кулланылалар: **бәйге-тамаша** (С-ә, 1996, № 8, 41 б.) һәм **тамаша-бәйге** (Ш.Ч., 1996, 15 дек.), **белгеч-эколог** (Т.х., 1995, 3 июнь) һәм **провизор-белгеч** (В.Т., 1996, 24 дек.), **кибет-палатка** (Т.х., 1993, 8 апр.) һәм **палатка-кибет** (Т.я., 1997, 30 окт.) һ.б. Башка телдән калькалаштырып ясалган атамаларда компонентларның урыны үзгәрергә мөмкин: **выставка-ярмарка** // **ярминкә-күргәзмә** (Ш.Ч., 1997, 18 нояб.), **зачет-собеседование** // **сөйләшү-зачет** (М-ф, 1994, № 11, 49 б.), **пожарно-прикладной** // **гамәли-янгынчылык** (Ш.Ч., 1997, 10 гыйнв.).

### 1.3.2.3. Кушма сүзләр

Соңгы елларда барлыкка килгән яңа кушма сүзләр барысы да диярлек интернациональ һәм рус сүзләрен «татарчалаштыру» максатыннан ясалганнар. Структуралары тәңгәл килмәгәнлектән, аларны калька итеп түгел, синтаксик юл белән ясалган сүзләр дип карау дөресрәк. Ясалыш үзенчәлекләре буенча яңа кушма сүзләрне өч төргә бүлеп карарга була:

**1. Ияртүле бәйләнештәге компонентлар (исемнәр) кушылып ясалган неологизмнар: алтакта** — вывеска, **алхәбәр** — передовица, **анайорт** — прародина, **аскорма** — инфраструктура, **аскуйма** — постамент, **аһәңсаз** — композитор, **җанисәп** — халык санын алу, перепись, **җансакчы** — телохранитель, **динкардәш** — бер диндәге кеше, **илбаш** — президент, дәүләт башлыгы, **куларкадаш** — партнер, **кулчатыр** — зонтик, **тактаташ** — мемориаль такта, **үзкичереш** — рефлексия: *Законга туры килерлек итеп эшләнгән* ***алтакталар*** *эленгән* (Ш.Ч., 1998, 11 нояб.). *Төркиләргә дә аз гына булса да* ***анайорты*** *итеп шул ук һинд-ауропачы галимнәр Алтай тирәләрен билгеләгәннәр* (В.Т., 1996, 7 июль). *Спектакль өчен гаҗәеп матур музыка иҗат иткән талантлы* ***аһәңсазыбыз*** *Ренат Еникиев тә минем ниятемне хуплады* (М.ж., 2006, 22 дек.). *Әмма* ***динкардәшләребезгә*** *дә иблис провокацияләренә бирешүдән һәм алар таккан сәяси уеннардан сакланырга өйрәнергә вакыт* (М.ж., 2007, 6 апр.). *Язылышмыйча гына яшәп тору совет заманнарыннан ук килсә дә, бу хактагы рәсми мәгълүматлар 2002 елгы* ***җанисәп*** *вакытында билгеле булды* (В.Т., 2007, 24 авг.). ***Илбашның*** *һәйкәлне күрергә киләсен аларга төнге 11 дә генә телефон аша хәбәр итәләр* (М.ж., 1997, 22 авг.). *Инде 1700 ел буе* ***кулчатырлар*** *безне яңгырдан саклый* (М.ж., 2007, 6 апр.).

**2. Сүзтезмәләрнең лексикалашуы нәтиҗәсендә ясалган кушма сүзләр**

Соңгы елларда барлыкка килгән бу төр кушма сүзләр тулысынча диярлек «исем + киләчәк заман формасындагы сыйфат фигыль» моделе буенча ясалганнар: **җанатар** — болельщик, поклонник, **җанкыяр** — палач, **җансатар** — хыянәтче, сатлыкҗан, **җирсөяр** — фермер, авыл хуҗалыгы эшчесе, **йортбасар** — фатир басучы карак, **күзбуар** — гипнозчы, **күпбелер** — күп белергә яратучы, всезнайка, **таугизәр** — альпинист: *Командаларның көче җитмәсә,* ***җанатарлар*** *(болельщиклар) җавап таба һәм очко ала* (М-ф, 1994, № 11, 53 б.). *Тукай һәм башка шәхесләребез мирасы белән тирәнтен кызыксыну, киләчәктә тиеннәргә эшләргә дә риза булучы берничә* ***җанатар*** *кулына калырга да мөмкин* (В.Т., 2006, 11 нояб.). *Әллә тырышлыгы, үҗәтлеге белән аякка басарга омтылучы* ***җирсөярләрнең*** *дәрт-дәрманын төрле юллар белән сүндерү, эшкә таяк тыгу махсус оештырыла микән бездә?* (Т.я., 1995, 4 май).

**3. Икенче компонентка кушымча өстәп лексикалашкан сүзтезмәләр: астөшермә** — сноска, **башбирмәслек** — беркемгә дә буйсынмау, **сансанак** — калькулятор, **ташкорма** — таштан төзелгән бина: *Кәбир әфәнденең ... тирән мәгълүматлы белгеч икәнлеген без Һәнүз Мәхмүтов вә Ильтани Иляловаңың «Революциягә кадәрле татар театры» исемле китабындагы* ***астөшермәләрдән*** *чамалый алабыз* (М.ж., 1995, № 1, 14 б.). *Һәм нәкъ менә Чечня* ***башбирмәслеге****, үҗәтлеге мисалында соңгы дәрәҗәдә гумансызлыгын фаш итә* (Т.я., 1994, 20 дек.). *Ягъни операция һәм операндларның урыны башкача һәм* ***сансанакларның*** *күбесе шулай эшли дә* (М-т., 1997, 15 нояб.).

### 1.3.2.4. Тезмә сүзләр

Соңгы елларда барлыкка килгән шактый күпсанлы тезмә сүзләр барысы да диярлек рус-европа алынмаларын сүзгә-сүз тәрҗемә итеп ясалганнар. Шуңа да бу төр сүзләргә мисаллар калькаларга багышланган бүлекчәдә китерелә.

### 1.3.3. Кыскартылма сүзләр

Җәмгыятьтәге җитди үзгәрешләр чорында телдә бик күп тотрыклы сүзтезмәләр барлыкка килә, алардан исә яңа аббревиатуралар ясала. Телчеләр 1991 елда рус әдәби теле лексикасының публицистик стилендә иң еш кулланылучы сүзләр итеп **ГКЧП** һәм **СНГ** аббревиатураларын атыйлар (111. 70 б.). Бу татар теленә дә карый, чөнки, галимнәребез әйтүенчә, татар телендә кыскартылма сүзләр башка (нигездә рус) телдәге кыскартылмаларны кабул итү һәм шуларга охшатып ясау юлы белән барлыкка киләләр (144. 22 б.; 127. 219 б.; 38. 32 б.).

Соңгы елларда татар матбугатында кыскартылма сүзләрнең күбесе үзгәрешсез кулланылса да (**ВЧК** — Икътисадны тотрыкландыру буенча вакытлы комиссия, **ГКЧП** — Гадәттән тыш хәл буенча дәүләт комитеты, **ТНВ** — «Татарстан — Яңа гасыр» телеканалы, **ФСБ** — Федераль куркынычсызлык хезмәте һ.б.), шактый аббревиатуралар телнең үз материалында, ягъни татарчалаштырылган сүзтезмәләрне кыскарту юлы белән ясалган. Аларны шартлы рәвештә калька-аббревиатуралар дип атарга була: **АҖ** — акционерлык җәмгыяте (АО), **АлАЗ** — Алабуга автомобил заводы (ЕлАЗ), **БДБ** — Бәйсез дәүләтләр Бердәмлеге (СНГ), **БДИ** — Бердәм дәүләт имтиханы (ЕГЭ), **БТИ** — Бердәм төбәк имтиханы (ЕРЭ), **ДТРК** — дәүләт телерадиокомпаниясе (ГТРК), **ҖЧҖ** — җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять (ООО), **ИПИ** — икътисади планлаштыру идарәсе (УЭП), **ТДГПУ** — Татар дәүләт гуманитар педагогика университеты (ТГГПУ), **ТКН** — тормыш куркынычсызлыгы нигезләре (ОБЖ), **ЭХТ** — электрон-хисаплау техникасы (ЭВТ): *Россия федерациясендә һәм **БДБ** дәүләтләрендә икътисади хәл бик нык кискенләште* (М-с, 1993, № 5, 3 б.). *Безнең алда **БДИ** уздыруны финанслау бурычы да тора (*В.Т., 2007, 20 окт.). *Евразиянең үсеш банкы **(ЕАҮБ)** һәм **ТР** хөкүмәте кичә Казанда стратегик хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куйдылар* (В.Т., 2007, 4 сент.). *... «Актай» **ҖЧҖ**нең Фазенда кушаматлы аты ... беренче килде* (Ш.Ч., 2007, 5 сент.). ***ТДГПУ** каршында ике дәүләт телендә белем бирү буенча методик совет та эшләп килә* (В.Т., 2007, 13 окт.). *Мәгълүмат алмашу теле, шулай ук **ЭХТ**нан файдаланучы интерфейс теле буларак, татар телен компьютер технологияләренә кертүнең програма чараларын күрергә кирәк* (М-ф, 1998, № 4, 85 б.).

Шулай ук рус теленә бәйсез рәвештә, ягъни башлап татар теленең үз җирлегендә туган сүзтезмәләрне кыскарту нәтиҗәсендә барлыкка килгән аббревиатуралар да шактый очрый: **БТИҮ** — Бөтендөнья татар иҗтимагый үзәге, **БТК** — Бөтендөнья татар конгрессы, **ТИҮ** — Татар иҗтимагый үзәге, **ТДН** — Татарстан Диния нәзарәте, **ТР** — Татарстан Республикасы, **ҮДН** — Үзәк Диния нәзарәте, **ХТЯБ** — Халыкара төрки яшьләре берлеге һ.б.: ***БТИҮ**нең Чаллы бүлеге үзенең чираттагы җыенын үткәрде* (Ч.-И., 1991, 6—12 июль). *Конгресс билгеләгән бурычларны — консолидация һәм милли яңарыш мәсьәләләрен хәл итү өчен яши **БТК** башкарма комитеты* (Т-н, 1993, № 7, 3 б.). *Уфада урнашкан һәм Тәлгать хәзрәт Таҗетдин җитәкләгән Үзәк Диния нәзарәте **ТДН** эшенә тыкшына алмый ...* (Т.я., 1997, 23 дек.).

Татар теленең үз җирлегендә соңгы елларда ясалган кыскартылмаларның барысы да диярлек хәрефчә кыскартылма-аббревиатуралар, башка төрле яңа татарча кыскартылмаларның әдәби телгә кереп китәрдәй уңышлылары әлегә күренми. **Дәүсовет** (Дәүләт советы, Госсовет — Т.я., 1998, 8 окт.), **педсыйныф** (педагогик юнәлештәге сыйныф, педкласс — М-т, 1995, 25 нояб.), **техкарау** (техник төзеклекне тикшерү, техосмотр — Т.я., 1999, 16 февр.) кебек еш кулланылучы яртылаш кыскартылмалар исә ярымкалькалар булып торалар.

### 1.3.4. Конверсия ысулы белән ясалган сүзләр

Бу ысул белән соңгы елларда сыйфаттан һәм исем фигыльдән исем сүз төркеменә күчкән берничә сүзне күрсәтергә була.

**Олпат** сүзе ТТАСтә сыйфат буларак (с. Җитди, дәрәҗәле, бөек — ТТАС, II, 467 б.) бирелгән, аның икенче // «Бөеклек, мәһабәтлек» исем мәгънә төсмере теркәлгән булса да, безнең мисалларда ул беренче мәгънәсендә исемгә күчкән, килеш, тартым белән төрләнә һәм «дәрәҗәле, хөрмәтле кеше» мәгънәсендә кулланыла: ***Олпатка** олы котлау* (В.Т., 1994, № 2, 17 б.).

**Караучысыз** (Караучысыз, тәрбиячесез бала; үсмер; беспризорник — РТС, 37 б.) сүзен дә, ***-сыз*** кушымчасы сыйфат ясагыч аффикс кына булганлыктан (35. 338 б.), лексик-грамматик ысул белән ясалган сүз итеп карыйбыз: *Бүген Русиядә ике миллионнан артык **караучысыз** (беспризорник), 530 мең дөм ятим, бер миллионлап гарип-гораба бала исәпләнә* (Т. я., 1997, 27 нояб.).

**Килешү** (*ф.* 1. Дус булу, тыныч яшәү, бер-береңне аңлау, бергә яши алу. 2. Дошманлашуны, талашны туктату, бетерү; дуслашу, татулашу. 3. Солых төзү. 4. Кемнең дә булса фикерен, тәкъдимен, сүзен дөрес дип табу; шуңа кушылу, риза булу, күнү. 5. Берәр нәрсәгә карата түземлелек, чыдамлылык белән карый башлау; берәр төрле хәлгә буйсыну, күнү. 6. Сатулашып, әйбернең бәясе турында ризалашу. 7. Ярәшү; өйләндерү яки кызын бирү турында сөйләшеп кую, ризалашу — ТТАС, II, 95—96 б.) фигыле, исем сүз төркеменә күчеп, хәзер өч төрле мәгънәдә исем буларак бик актив кулланыла:

1) ике яки берничә зат яисә оешманың нәрсәнедер бергәләп башкару буенча сүз куешуы (соглашение): *Фондның рәисе белән аның филиалын шәһәрдә ачу турында **килешү** төзелгән* (Ш.Ч., 1995, 15 сент.);

2) төрле өлкәләрдә хезмәттәшлек турында якларның йөкләмә, бурыч, хокукларын күрсәтеп, язма рәвештә төзелгән, расланган рәсми сүз куешу (договор, контракт): *Узгән атнада Киевта Татарстан белән Украина арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турындагы **килешүгә** кул куелды* (Т.я., 1994, 20 гыйнв.);

3) халыкара киңәшмә, корылтайларда сөйләшүче якларның уртак килешүе нигезендә, рәсми каршы килүчеләр булмаган очракта, тавыш бирүләрсез генә кабул ителгән карар (консенсус): *Англия, Франция, Италия, Япония һәм кайбер башка илләр катнашында Лозаннада уздырылган халыкара конгресс үзенең 1923 ел 24 июль **килешүе** белән Төркияне Босфор һәм Дарданелла бугазларына ия булу хокукыннан мәхрүм итте* (К.у., 1996, № 10, 172 б.).

## 1.4. Калькалаштыру юлы белән ясалган сүзләр

Калькалаштыру, гадәттә, әдәби тел лексикасын баетуның өченче — катнаш юлы итеп исәпләнә. Калькалаштыруның нигезендә телнең эчке мөмкинлекләрен файдаланып яңа сүз ясау ятканлыктан, Н.А.Баскаков, Э.Бегматов, Ф.А.Ганиев һәм башка галимнәрнең хезмәтләренә таянып, калькаларны бу бүлек рамкаларында карыйбыз. Чөнки калькаларның ясалу ысуллары һәм структурасы татар теленең үз сүзләре ясалу ысуллары һәм структурасыннан берни белән дә аерылмый (33. 80 б.).

Иң элек шуны билгеләргә кирәк: XX гасырның 80—90 нчы елларында телне «татарчалаштыру» тенденциясе тәэсирендә калькалаштыру ысулы белән бик күп яңа сүзләр ясалды. Аларның күбесе — илнең иҗтимагый-сәяси тормышы һәм финанс-икътисад өлкәсендәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә туган яңа төшенчәләрнең сүзгә-сүз тәрҗемәләре. Дөрес, барлык яңа калькаларны да уңышлы дип булмый, арада ашык-пошык ясалган, «кытыршылары» да шактый очрый. Калькалар, нигездә, язма юл белән, ягъни рус телендәге чыганакларны татарчага тәрҗемә итү процессында туа. Монда матбугатның роле аеруча зур. Шул ук вакытта соңгы елларда сөйләм теле калькаларының активлашуы да күзәтелә. Аларны махсус өйрәнүче Р.С.Абдуллина язуынча, «рус мәктәбендә укыган кешеләр сөйләменә хас, көндәлек аралашуда очрый торган калькалар ... рус культурасында тәрбияләнгән укымышлылар сөйләме аша телебезгә таралыш ала бара ... аларның кайберләре әкренләп матбугатка да үтеп керә» (3. 80 б.).

Татар телендә калькалар үзенчәлекләре һәм төзелешләре ягыннан шактый җентекле өйрәнелгән (11; 84; 128; 185 h.б.). Шунлыктан, теоретик мәсьәләләргә тукталып тормыйча, соңгы елларда ясалган калькаларның фәндә гомумтанылган төрләренә мисаллар китерү белән чикләнәбез. Алдагы бүлекчәләрдә каралган рус теле йогынтысында ясалган сүзләр (аныклаулы атамалар, кыскартылмалар) биредә яңадан тикшерелми, чагыштырмача киң кулланылышка кергән һәм уңышлы дип саналган калькалар гына мисаллар эчендә карала.

### 1.4.1. Структур-семантик калькалар

Структур-семантик калькаларны ике төргә (тулы калькалар һәм ярымкалькалар) бүлеп карыйбыз. Алар үзләре структур яктан тагын берничә төркемчәгә таркалалар.

#### 1.4.1.1. Тулы, ягъни барлык компонентлары да татарча яисә күптән үзләштерелгән элементлардан торган калькалар

1. *Гади сүзләр*: **акчалаштыру** — монетизация (льготалар турында), **әйдәүче** — ведущий, **бәрмә** — ударный, **боралак** — вертолет, **иртәлек** — утренник, **мәгълүматлаштыру** — информатизация, **орлыкландыручы** — осеменатор, **сөйләүлек** — разговорник, **сызылмалар** — чертежи, **тартымлык** — привлекательность, **туңдыргыч** — морозильник, **тыгызлаткыч** — уплотнитель, **уйнаткыч** — проигрыватель, **укылыш** — чтение, **чүкелмә** — чеканка: *Пенсия системасы һәм ташламаларны **акчалаштыру** реформаторы булып тарихка кереп калачак ... Зурабов ...* (В.Т., 2007, 25 авг.). *Уз тәҗрибәсен уртаклашучы **әйдәүче** терәк-мәктәп* (М-т, 1995, 23 гыйнв.). *Кирилл Долганов **бәрмә** инструментларда уйный* (М-т, 1995, 23 сент.). *Иртәнге якта утар янына кечерәк кенә **боралак** төшеп утырды* (В.Т., 1999, 6 февр.). *Апас районы үзәгендә соңгы вакытларда ятим сабыйлар **иртәлеге** үткәрү гадәткә кергән* (В.Т., 1995, 4 февр.). *Хәзерге **мәгълүматлаштыру,** компьютерлаштыру*

*чорында балалар еш кына үз укытучыларыннан да уздыра* (К.у., 2006, № 12, 190 б.). *Терлекләрне ясалма **орлыкландыручылар** лаборатория шартларында приборлар белән дөрес эш итә белүләрен раcладылар* (В.Т., 1998, 12 авг.). *... моңа кадәр бездә татарча-төрекчә **сөйләүлекләрдән** башка төрек телен өйрәнергә ярдәм итә торган сүзлек кебек кулланмалар юк иде* (В.Т., 1997, 19 дек.). *Хезмәткәрләр әзер детальләрнең күләмнәрен үлчиләр, нәрсәләрдер саныйлар, **сызылмаларының** астын өскә китерәләр* (Нур, 1995, 6 апр.). *Әйтик, хатын-кыз кесә карагы, кагыйдә буларак, корбанның уяулыгын үзенең сексуаль **тартымлыгы** белән киметә* (В.Т., 1998, 7 гыйнв.). *Әгәр дә сез гадәти **туңдыргычка** (морозилкага) бернича килограмм ... ит салып куйсагыз ...* (В.Т., 1997, 19 сент.*). **Тыгызлаткычны** вакыт-вакыт тальк белән эшкәртегез* (В. Т., 1997, 9 сент.). *Унбиш башлангыч укытучысына бары тик ике **уйнаткыч*** (М-т, 1995, 14 окт.). *Россия коелмалары һәм **чүкелмәләре** фонында татар бизәкләре аерым бер бөртекләү һәм мәхәббәт белән сурәтләнә* (В.Т., 1997, 18 апр.). *Мәсәлән, халык депутатлары игътибарына беренче **укылышта** карау өчен «Товар алышу (бартер) операцияләре өчен махсус түләү турында»гы Закон проекты тәкъдим ителәчәк* (В.Т., 1997, 11 нояб.).

2. *Кушма сүзләр*: **бөекмәмләкәтчел** — великодержавный, **катнашазык** — комбикорма, **күктерәү** — небоскреб, **күппартиялелек** — многопартийность, **төбәкара** — межрегиональный, **үзөйрәткеч** — самоучитель, **яфраказык** — веточные корма: *Әнә бит **бөекмәмләкәтчел** көчләр, ризасызлык белдереп, тавыш куптаралар ...* (Ш. К., 1994, 5 апр.). *... 1 июньгә **катнашазык** заводы ... үз эшен башлап җибәрергә тиеш* (Өмет, 2007, 20 сент.). *Дөньядагы беренче **күктерәү** (небоскреб) Чикагода 1885 елда төзелгән* (Т.я., 1998, 26 февр.). ***Күппартиялелек** — җәмгыятьнең иң мөһим компоненты булуын аңлыйбыз* (В.Т., 1995, 1 март). *Бүген ВИКО күргәзмә үзәгендә «Шәһәр проблемалары» дигән **төбәкара** күргәзмә ачылды* (Т.я., 1997, 11 февр.). *Югалган буыннарны кайтару юлында туган тел ачкычы буласы әлифбалар, **үзөйрәткеч** һәм сүзлекләр мөһим роль уйный.* (К.у., 1996, № 2, 178 б.). ***Яфраказык** 650 тонна ... әзерләнде* (В.Т., 1998, 7 июль).

3. *Тезмә сүзләр.* Бу төр калькалар сан ягыннан иң зур күпчелекне тәшкил итәләр. Шуңа да, китапның күләме чикле булганлыктан, алар җөмләләр эчендә бирелми, чыганакка сылтама ясау белән чикләнелә. Тезмә калькаларның күбесе рус телендәге сүзтезмәләрне сүзгә-сүз тәрҗемәләү юлы белән ясалган: **антлы утырышчылар** — присяжные заседатели (В.Т., 2006, 9 дек.), **базар икътисады** — рыночная экономика (Я-н, 1995, № 5, 24 б.), **базар мөнәсәбәте** — рыночные отношения (В.Т., 1996, 1 нояб.), **Бәйсез дәүләтләр бердәмлеге** — Содружество Независимых государств (В.Т., 1992, 17 июль), **газ санагыч** — газовый счетчик (В.Т., 1998, 16 окт.), **җаваплылыгы чикле ширкәт / чикләнгән җаваплылыктагы ширкәт** — общество ограниченной ответственности (В. Т., 1996, 6 авг.; 1996, 16 июль), **җәмәгать үзәге** — социальный центр (В.Т., 2007, 25 авг.), **җирле үзидарә** — местное самоуправление (К.т., 1997, 30 сент.), **икътисади планлаштыру идарәсе** — управление экономического планирования (В.Т., 1996, 24 дек.), **икътисади тотрыклылык —** экономическая стабильность (Т-н, 1995, № 5—6, 33 б.), **җирле хакимият** — местная власть, **икътисади тотрыксызлык** — экономическая нестабильность (К.к., 1995, 4—10 сент.), **исемле тавыш бирү** — поименное голосование (Т.я., 1997, 5 март), **кече эшмәкәрлек** — малое предпринимательство (В.Т., 1996, 16 июль), **куллану кәрҗине / кулланучылар кәрзине** — потребительская корзина (В.Т., 1997, 1 март; Т. я., 1997, 2 дек.), **кәрәзле элемтә** — сотовая связь (В.Т., 1997, 4 апр.), **кыйммәтле кәгазьләр базары** — рынок ценных бумаг (Т.я., 1997, 7 окт.), **махсус икътисади зона** — особая экономическая зона (В.Т., 2007, 3 май), **мәҗбүри иминият** — обязательное страхование (В.Т., 1996, 6 авг.), **Мәшгульлек үзәге** — Центр занятости (Ш.К., 1994, 9 июнь), **Милли-мәдәни мохтәрият** — национально-культурная автономия (М.ж., 2007, 4 май), **сәяси тотрыксызлык** — политическая нестабильность (В.Т., 1996, 16 июль), **торгынлык еллары** — застойные годы (Ш.Ч., 2007, 15 авг.), **үстерешле укыту** — развивающее обучение (М-т, 1996, 15 нояб.), **хезмәт базары** — рынок труда (Т. я., 1995, 1 авг.), **хосусый мәктәп** — частная школа (Т-н, 1995, № 9—10, 156 б.), **һөнәри берлек** — профессиональный союз (Ш.К., 1994, 26 март), **шарчыклы каләм** — шариковая ручка (М.ж., 1995, 20 окт.) һ.б.

Калькалаштыру процессында кушма сүзләрнең тезмә сүзләргә әверелүе татар теле өчен типик күренеш булган кебек (128. 64 б.), кайбер рус телендәге гади сүзләрне тезмә сүз рәвешендә татарчага күчерү очрый. Шундыйлардан **үзгәртеп кору** — перестройка, **тәкъдим итү тантанасы** — презентация, **күчемсез / күчми торган милек** — недвижимость кебекләре инде телдә бик актив кулланыла, башкалары, гадәттә, җәя эче аңлатмасы белән бирелә: *Аларга **үзгәртеп кору** идеологиясе таләп иткән яңалыклар кертергә тырышылды* (М-ф, 1996, 12 б.). ***Күчми торган милек** сатып алу ышанычлы ...* (Т.я., 1995, 15 февр.). *Унбер ел буена ул ... бер генә тапкыр да хастаханәдән **авыру белешмәсе** алмый [«больничный лист» урынына. — Р.М.]* (К-н, 1996, № 3—4, 40 б.). *Әлбәттә, мал азыгын базар хакы белән сату **иң урта** (оптималь) юл булыр иде дә ...* (Т.я., 1996, 4 май). ***Сәүдә бәясе** (наценка) төрле җирдә төрлечә* (Т.я., 1998, 17 март). *Ә бит эстрада артистының, бигрәк тә җырчының **сәхнә чырае** (имидж) бик күп төрле вак нәрсәләрдән туплана* (Т.я., 1998, 5 сент.). ***Товар алмашу** (бартер) операцияләрен ясау өчен махсус түләү турында ...* (В.Т., 1998, 23 гыйнв.).

**1.4.1.2. Ярымкалькалар**

1. *Гади сүзләр.* Калькаларның бу төре алынма сүзнең тамырын саклаган хәлдә кушымчаларын «татарчалаштырып» ясала. Кушымчалау ысулы белән яңа сүзләр ясауга багышланган бүлекчәдә мондый калькаларның кайберләре телгә алынган иде. Биредә аларны җөмләләр эчендә карап үтәрбез. Шунысы игътибарга лаек: гади ярымкалькалар арасында исемнәр чагыштырмача аз. Күрәсең, хәзерге чорда тел гади алынма исемнәрне үзгәрешсез куллануга өстенлек бирә. Актив кулланылышка кергән яңа ярымкалькалар исә зат исемен белдерүче ***-чы*** һәм абстракт исем ясагыч ***-лык*** кушымчалары белән төзелгән: *Әйе, **гэкачэпэчылар** гына түгел, күрәзәчеләр дә куркыта безне* (Т.я., 1991, 5 сент. — гэкачэпист). *Наилә — **дизайнчы**, сәхнә эскизы һәм пейзажда беркемнекенә охшамаганча иҗат итә* (С-ә, 1995, № 6, 34 б. — дизайнер). ***Контрактчы** солдатларга аена уртача 800—900 мең сум түләнә ...* (В.Т., 1996, 6 дек. — контрактник). *Болары да үзем сатып алганнар, — ди **маникюрчы*** (Т.я., 1996, 20 июнь — маникюрщица). *Кырым татарларының ярсынуы ... **омончылар** белән канлы бәрелешкә китергән* (Ш.К., 1995, 28 июнь — омоновец). *Шаһназаровның **рэкетчылар** белән сөйләшкәнен капканың эчке ягында Гөлшаһидә тыңлап торган икән* (К.у., 1995, № 3, 117 б. — рэкетир). ***Иждивенчылык** күренешләренә ... һич кенә дә юл куярга ярамый* (В.Т., 1997, 14 нояб. — иждивенчество). *Безнең **легитимлык** берничек тә шик астына алына алмый* (Т-н, 1993, 4 б. — легитимность). *Тантаналы төстә ачылачак биналарның тагын берсендә ТР Финанс министрлыгының **казначылык** департаменты территориаль бүлеге булырга тиеш* (М.җ., 2006, 25 авг. — казначейство). *Сәнгатьнең **элитарлыгына**, массовыйлыгына ничек карыйсыз?* (С-ә, 1995, № 8, 13 б. — элитарность).

Сыйфатлар арасында исә ярымкалькалар шактый, чөнки татар һәм рус телләрендә сыйфатлар грамматик төзелеше ягыннан бер-берсеннән нык аерыла, һәм аларны үзгәртмичә кабул итеп тә булмый. Бу ярымкалькалар рус сыйфатларын татар әдәби теленә үзләштерүнең Э.М.Ахунҗанов тарафыннан ачыкланган (12. 310—315 б.) барлык ысулларын да диярлек файдаланып ясалганнар. Мисалларны шушы төркемчәләргә туплап карыйк:

а) ***-н*** суффиксын ***-лы*** кушымчасы белән алыштыру: ***Ликвидлы** акцияләрне һәрвакыт акчага әйләндереп була* (Нур, 1996, 27 февр.). *Өлкәннәргә **льготалы** подписка* (Ш.Ч., 1995, 3 июнь). *Хәзер коллективыбыз **мобильле ...*** (Т.й., 1995, 5—12 авг.). *Аерым алганда, **инновацияле** мәгариф программаларын актив гамәлгә кертүче 87 мәктәп билгеләнгән* (А.т., 2006, № 123);

ә) ***-ск*** һәм өлешчә ***-н*** суффиксын күпмәгънәле ***-лык*** кушымчасы белән алыштыру: *«Җидегән» **акционерлык** оешмасы ...* (М-ф, 1995, № 3, 51 б.). ***Аудиторлык** тикшерүе үткәрергә кереште* (Т.я., 1997, 6 гыйнв.). ***Менеджерлык** бүлеге мөдире Тихонов ...* (В.Т., 1996, 15 июнь.). *Аны «Афәрин-Браво» **продюсерлык** үзәге оештырды* (Ш. Ч., 1998, 19 дек.). *Аның каравы авыл мәктәпләрендә трактор, **фермерлык** эше дәресләре еш керә* (М-т, 1996, 9 май.);

б) алынма ***-озн*** формантын ***-чел*** кушымчасы белән алыштыру: *Алар өчен бердәнбер юл — тере мишень кыяфәтендә Россия армиясенә бару яки **мафиячел** бандит структураларына керү юлын калдыра* (М-т, 1996, 8 март). Бу ысул продуктив түгел, Э.М.Ахунҗановта ул бөтенләй күрсәтелмәгән. **Мафиячел** сүзенең дә, түбәндә күренгәнчә, башка варианты бар.

Яңа ярымкалькалар арасында фигыльләр дә шактый. Алар барысы да диярлек рус теленең үзе өчен дә алынма булган сүзләрдәге ***-аци*** аффиксына (76. 85 б.) ***-ла/-лә*** кушымчасы өстәлеп (а) яисә ***-аци, -изаци, -ирова*** формантларын ***-ла, -лап, -лаш, -лаштыр*** кушымчалары белән алыштырып (ә) ясала: а*) Республика формаль булмаган хезмәт базарын **адаптацияләү** һәм керемнәрне **легальләштерү** ведомствоара комиссиясе составын үзгәртү турында ...* (В.Т., 2006, 12 сент.). *... күч-хәл белән хезмәт хакын **индексацияләүне** керттерә алдык* (Нур, 1995, 16 сент.). *Директорлар советы ... **конвертацияләү** турында карар кабул итте* (В.Т., 1997, 2 июль). *Мәгарифнең төп фондларын тоташ **приватизацияләүдән** коткару җәһәтеннән зур эшләр башкарылды* (М-т, 1997, 31 май). *Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән җәмәгать туклану хезмәтенә **сертификацияләү** кертелә* (В.Т., 1997, 22 июль); ә) *... хосусыйлаштыруның иң мөһим төре — **акционерлаштыру*** (Т.я., 1992, 7 апр.). *Алыпсатарлар **ваучерлаштыру** процессын үз кулларына алмакчы булалар* (В.Т., 1992, 17 дек.). ***Газлаштыру** буенча республикада әйдәп баручылар рәтендә атлыйбыз ...* (В.Т., 1998, 14 гыйнв.). *... Мәскәү даирәләренең республикаларны йомшак **губерналаштыру** идеясен күтәреп йөрүләре турында борчылып сөйләде ...* (В.Т., 1995, 4 апр.). *Башкортостан Президенты Мортаза Рәхимов ... дәүләт югары уку йортларын **коммерцияләштерүгә** каршы булуын белдерде* (Өмет, 1998, 30 май). *... бәяләр **либеральләштерелгәннән** соң да вкладның кагылгысызлыгын игълан итте* (В.Т., 1997, 26 дек.). *... КамАЗ бурычларын **реструктурлаштыру** мәсьәләләре җентекләп тикшерелде* (М.җ., 1999, 15 гыйнв.).

2. *Кушма сүзләр.* Ясалма ярымкалькаларның беренче компонентлары гадәттә интернациональ сүзләрдән тора, ә рус чыгышлы икенче компонентлары татар сүзләре белән алыштырылган: *Казан дәүләт университеты галимнәре булачак **авиаһәлакәтләрне** кисәтә торган компьютер системасы эшләгәннәр* (Т.я., 1996, 24 февр.). ***Автоузышларны** республикада белүче дә юк иде* (В.Т., 2007, 3 март).

*Ә менә Резидәнең икенче* ***аудиоҗыентыгы*** *бездә чыкмады ...* (Т.я., 1998, 29 авг.). *Беренче тапкыр* ***аэротамаша*** *үткәрелде* (В. Т., 1995, 23 сент.). *... улы Марсельне* ***аэрочана*** *белән өч чакрымдагы Түбән Шөнгә җибәрде* (В.Т., 2006, 3 нояб.). ***Биотикшерү*** *(биопроба) узып, организмның корт агуына мөнәсәбәтен белергә кирәк* (Т.я., 1998, 14 июль). *Кешенең энергетик кырын,* ***биотышчасын*** *бары тик күз белән генә күрергә мөмкин* (Т.я., 1995, 6 апр.). *Рапс маеннан эшләнгән* ***биоягулык*** *Алтай краенда кулланыла башлаган инде* (В.Т., 2006, 18 окт.). *Авыру балаларга табиблар ясаган барлык операцияләр дә* ***видеотасмага*** *язылып барган* (С-й, 1995, 27 сент.). ***Видеоязмалар*** *дигәннән, без фольклор коллективларының чыгышларыннан аерым фильмнар эшләргә уйлыйбыз* (В.Т., 1995, 17 нояб.). *Бозауларны* ***радиоманаралар*** *торган көтүлектә көттеләр ...* (В.Т, 1992, 30 окт.). *... Чаллы мәйданчыгына* ***суперзаманча*** *техника китерелде* (В.Т., 1997, 18 июль). *... 1998 ел башында корылган «Әнкарә-Төркестан» спутник элемтә каналы аша Төркиядән лекцияләр укый,* ***телекүперләр,*** *видеоконференцияләр оештыра башлаганнар* (В.Т., 1998, 23 окт.). *Тышлыкның беренче битендә рәссам Фаил Зыязовның «Кояшлы иртә» картинасыннан* ***фотокүчермә*** (К.у., 1997, № 4, 190 б.). *Илдар ... «Себер һәм Казан татарлары:* ***этносәяси*** *багланышлар» темасына гыйльми хезмәт яза башлаган* (К.у., 1998, № 7, 131 б.). *Мәшһүр* ***фоторәссам*** *Ләлә Кузнецова фикеренчә, мин фотога төшә белми идем* (С-ә, 1991, № 3, 12 б.).

3. *Тезмә сүзләр.* Ярымкалькалар арасында да тезмә сүзләр иң зур күпчелекне тәшкил итә, шунлыктан аларның иң активларын җөмләләрдән тыш кына санyйбыз: **акционерлык җәмгыяте** — акционерное общество (Нур, 1995, 28 сент.), **беркетү талоны** — прикрепительный талон (Ш.Ч., 1997, 5 март), **депозит кертемнәре** — депозитные вклады (Нур, 1995, 16 сент.), **икътисади кризис** — экономический кризис (В.Т., 1996, 24 май), **икътисади реформа** — экономическая реформа (Нур, 1995, 23 нояб.), **Иминлек советы** — Совет безопасности (В.Т., 1996, 2 нояб.), **ирекле әйләнештәге валюта** — свободно-конвертируемая валюта (В.Т., 1994, 21 дек.), **исемле хосусыйлаштыру чеклары** — именные приватизационные чеки (Ш.К., 1994, 14 дек.), **крестьян хуҗалыклары берләшмәсе** — ассоциация крестьянских хозяйств (В.Т., 1996, 3 сент.), **лазер тәлинкәсе** — лазерный диск (Я-н, 1997, № 7—8, 43 б.), **магнит давылы** — магнитная буря (В.Т., 1996, 17 гыйнв.)., **мәҗбүри медицина иминияте** — обязательное медицинское страхование (Ш.Ч., 1997, 5 март), **милли инвестиция фонды** — национально-инвестиционный фонд (М-т, 1996, 16 нояб.), **муниципаль берәмлекләр** — муниципальные образования (М.җ., 2006, 29 дек.), **пластик карточка** — пластиковая карточка (В.Т., 1999, 23 гыйнв.), **салым полициясе** — налоговая полиция (Ш.Ч., 1994, 26 окт.), **сәүдә-сәнәгать палатасы** — торгово-промышленная палата (В.Т., 1996, 15 июнь), **уен бизнесы** — игорный бизнес (В.Т., 2006, 19 дек.), **уртак предприятие** — совместное предприятие (В.Т., 1999, 13 гыйнв.), **утырышчылар суды** — суд присяжных (В.Т., 2006, 9 дек.), **хезмәт һәм мәшгульлек бюросы** — бюро труда и занятости (Ш.К., 1996, 28 дек.), **хисап палатасы** — счетная палата (В.Т., 2007, 15 март), **хосусыйлаштыру чеклары** — приватизационные чеки (Т.я., 1995, 20 июль), **Федераль җыен** — Федеральное собрание (В.Т., 2007, 27 апр.).

### 1.4.2. Семантик калькалар

Бу бүлекчәдә рус теле тәэсирендә яңа мәгънә алган, дөресрәге, рус телендәге үзенә тәңгәл лексемадан җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән, яңа мәгънәсен үзләштергән сүзләр карала.

**Зәңгәр каскалар** (голубые каски) — гражданнар сугышы барган ил территориясенә тәртип саклау өчен БМО тарафыннан кертелгән төрле яисә бер нейтраль илнең ялланган солдатларыннан торган гаскәр (баш киемнәренең төсе буенча): *Төрек* ***«зәңгәр каскалар»ы*** *безнең дошманнарыбыз булмаса да, аларның туфрагыбызга аяк басуын да теләмибез* (Ш.К., 1994, 27 апр.).

**Кайнар нокталар** (горячие точки) — элекке СССР территориясендә милли, сәяси каршылыкка нигезләнеп кабынып киткән сугышлар, төрле чуалышлар барган урын: *Ә* ***кайнар нокталарга*** *Татарстан егетләрен җибәрү мәсьәләсендә комиссарның фикере катгый* (Т.я., 1994, 5 май).

**Кайчы** (ножницы) рус телендәге күчерелмә «үзара бәйле әйберләр арасында кискен аерма» — ТСРЯ, 420 б.) мәгънәсендә кулланыла башлады: *... транспорт һәм башка төр хезмәтләргә түләү* ***«кайчысын»*** *урнаштыруны үз өстенә алырга разый* (В.Т., 2007, 21 авг.).

**Коңгыз** сүзе **жучок** сүзенең күчерелмә «яшерен тыңлау җайланмасы» (ТСРЯ, 196 б.) мәгънәсен үзләштерде: *Аппаратка да* ***«коңгыз»*** *куярга мөмкин, ләкин бу үзешчәннәргә хас нәрсә* (В.Т., 1997, 4 апр.).

**Тәлинкә** (тарелка) сүзе «тышкы форма охшашлыгы буенча чит планеталардан килгән космик корабль, НЛО» мәгънәсен алды, күбрәк сөйләм теленә хас: ***«Тәлинкә»дән*** *өч сары гәүдә чыга ...* (В.Т., 1999, 7 гыйнв.).

**Тере акча** (живые деньги) — хезмәт хакын төрле продукция белән түләү, үзара исәп-хисапны бартер ысулы белән ясаудан һ.б. үзгә буларак кулланылган чын акча: *Мәсәлән, коррупция, акча талау, наркотиклар, корал белән сату итү бары тик* ***«тере» акчага*** *бәйле* (Ш.Ч., 1999, 19 гыйнв.).

**Түбә** (крыша) — махсус түләү бәрабәренә яисә хезмәт урынын файдаланып, кемнәрнедер яклап, саклап торучы кешеләр яки оешма: *Эшкуарларның байтагы, милициянең ярдәм итәчәгенә ышанмыйча, «түбә» эзләп, Эчке эшләр органнарына түгел, җинаятьчел төркемнәргә мөрәҗәгать итәләр* (В.Т., 1999, 23 гыйнв.).

**Текәләр** (крутые) — төрле юллар белән акча табып, аны теләсә ничек туздырып йөрүче, башкалар белән үзләрен бик дорфа тотучы кешеләр: ***«Текә»ләр,** бик аз гына акча түләп, Медведевтан яхтасын ял итү өчен алып торалар һәм аны һәрвакыт диярлек җимереп кайтаралар* (Т.я., 1997, 18 окт.). Бу сүз хәзер берлек сан формасында һәм сүз ясагыч нигез буларак та кулланыла: *Авыл яшьләре дә шәһәрнекеләрдән калышмаска тырыша, бу бит **«текә»лек** билгесе* (В.Т., 2007, 12 окт.).

**Тимер пәрдә** (железный занавес) — торгынлык елларында башка илләр, халыклар белән аралашмау, СССРда яшәүче кешеләрне капиталистик илләргә сәяхәткә чыгармыйча бикләп тоту: *Ә бит моннан чирек гасыр элек, илдә **«тимер пәрдә»** сәясәте хөкем сөргән елларда, без бернәрсә дә белми идек* (Т.х., 1993, 8 апр.).

**Яңа урыслар** (новые русские) — яңа заманга яраклашкан, бизнес, шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче кешеләр: ***«Яңа урыслар»** шәһәр читләрендә коттеджлар салуны өстенрәк күрәләр* (В.Т., 1996, 27 авг.).

Бу сүз йогынтысында хәзер **«яңа татарлар»** сүзтезмәсе дә кулланылышка керде, ул татар милләтеннән булган яңа чор «каһарманнарына» карата кулланыла: ***«Яңа урыслар», «яңа татарлар»** арасында туберкулез белән авыручылар шактый* (В.Т., 1998, 21 март).

Тикшерелгән материал соңгы елларда татар әдәби теленең калькалар исәбенә шактый интенсив баюын күрсәтә. Бу чорда калькаларның барлык төрләре дә ясалды, структур яктан тулы калькалар арасында да, ярымкалькалар арасында да иң зур күпчелекне тезмә сүзләр тәшкил итә. Рус телендәге гади сүзләрне тезмә сүзләр белән калькалау да очрый, алар, нигездә, исем һәм өлешчә фигыль сүз төркемнәренә карый. Гади һәм кушма калькалар арасында сыйфатлар һәм фигыльләр күп. Соңгы елларда барлыкка килгән дистәгә якын семантик калька илдәге иҗтимагый-икътисади вазгыятьне чагылдыра. Гомумән, калькалаштыру күренешенең активлашуы, бер яктан, телдәге «татарлашу» тенденциясенең көчәюен дәлилләсә, икенче яктан, рус сүзләре үрнәгендә ясалган лексемаларның күбәюе бер үк мохиттә яшәү, икетеллелек шартларында әдәби тел лексикасының рус теле йогынтысыннан азат була алмавын күрсәтә.

### 1.5. Әдәби телнең кулланылыш даирәсе, стиле, активлыгы чикләнгән сүзләр исәбенә баюы

Яңа сүзләр ясалу һәм электән яшәп килгән сүзләрнең мәгънәләре киңәю белән беррәттән XX йөзнең 80 нче елларыннан соң татар әдәби теле лексикасы төрле сүзлек катламнарының бер-берсенә актив тәэсир итүе нәтиҗәсендә дә шактый тулыланды. Бу процесс шулай ук башлыча яңа күренеш-төшенчәләргә атама бирү хаҗәте һәм телнең үз сүзләренә юнәлеш тоту тенденциясе белән бәйле.

Кулланылыш сферасы, стиле, дәрәҗәсе чикләнгән сүзләрнең гомумхалык лексикасын, әдәби телне тулылындырып торуы, аерым алганда, диалекталь һәм һөнәри сүзләрнең гомумкулланылышка, конкрет стильгә «беркетелгән» берәмлекләрнең стильара лексикага, неологизмнарның актив сүзлеккә күчүе, нигездә, телләр үсешенең барлык чорлары өчен дә хас. Өйрәнелгән чорның төп үзенчәлеге — моңа капма-каршы процессларның да күзәтелүендә, ягъни соңгы елларда кайбер гомумхалык сүзләре тормыштагы үзгәрешләргә бәйле иҗтимагый-сәяси терминнарга әйләнделәр, күп кенә төрки-татар чыгышлы архаизмнар һәм хәтта тарихи сүзләр яңадан актив лексикага кайтты.

#### 1.5.1. Әдәби телнең диалекталь сүзләр исәбенә үсеше

Диалектизмнар һәрвакыт әдәби телгә йогынты ясап торалар. Әмма, күренекле диалектолог Л.З.Җәләй билгеләп үткәнчә, «диалектларның әдәби тел формалашу процессындагы катнашлары аерым чорларда төрле төстә була» (48. 11 б.). Үсешләренең төрле этапларында татар әдәби теле белән диалектларның үзара йогынтысы мәсьәләләре фәндә махсус өйрәнелгән (52. 87; 14 һ.б.). Ул хезмәтләрдә яңа иҗтимагый-икътисади шартларда әдәби телнең җирле сөйләм элементларына йөз тотуы ачыкланган (52. 317 б.). XX гасырның 80—90 нчы елларындагы җәмгыять тормышындагы зур үзгәрешләр дә әдәби тел лексикасы, публицистик стильнең демократлашуына йогынты ясады. 60—70 нче елларга карата телчеләребез «хәзер әдәби телгә диалектлардан сүзләр алу бик аз» дип язсалар (49. 14—25 б.; 184. 23 б.), 80 нче еллар азагы — 90 нчы еллар башыннан җирле сөйләм сүзләре белән кызыксыну, аларны матбугат битләренә кертү көчәйде. Дөрес, әдәби тел өчен зарурлыгы, кыйммәте ягыннан алар бердәй түгел. Гадәттә, диалекталь сүзләр әдәби телгә түбәндәге очракларда күчә: 1) әдәби телдә шушы төшенчәне белдерердәй сүз булмаса; 2) персонажларның сөйләм үзенчәлеген сурәтләү өчен; 3) язучының үз хикәяләвенә милли колорит бирү өчен; 4) этнографик лексиканы бирү максаты белән (133. 140 б.); 5) әдәби телдәге сүздән мәгънә яисә эмоциональ төсмере белән аерылучы синоним

буларак (87. 27 б.). Соңгы елларда диалектизмнарга алынма сүзләрдән арыну чарасы буларак та еш мөрәҗәгать итәләр. Боларның беренче һәм соңгы икесен генә әдәби, гомумхалык телен баету юллары дип карарга була. Өйрәнелгән чор матбугат һәм әдәбиятында диалекталь сүзләр белән мавыгу көчле булганлыктан, түбәндә, нигездә, шушы өч төр прогрессив диалектизмнарга тукталырбыз. Җирле сөйләм сүзләренең мәгънәләре телебезнең төрле елларда чыккан диалектологик сүзлекләре буенча бирелә. Аерым очракларда ТТАСтә диалекталь сүз тамгасы белән бирелгән соңгы елларда аеруча активлашкан сүзләр дә китерелә.

Диалектологиядә кабул ителгәнчә, соңгы елларда әдәби телгә үтеп кергән диалектизмнарны саф лексик (ягъни әдәби телдә синонимнары булган), лексик-грамматик (әдәби телдәге сүзләрдән сүз ясау модельләре, кушымчалары белән аерылып торган) һәм алынма (диалектларга башка, нигездә, күрше халыкларның теленнән кергән) төрләргә бүлеп карыйбыз.

1. *Саф лексик диалектизмнар*: **алагаем** (*диал.* Бик артык, искиткеч, чамадан тыш (ТТАС, I, 43 б.); *минз., стрл.* Чамадан тыш, ифрат, гаять, артык — ТТДС, 1993, 24 б.); **диңкетү** (*минз.* Аптырату, йөдәтү — ТТДС, 1969, 127 б.); **илерү** (*ф.* Ямьсез тавыш белән бик каты кычкыру, акыру — ТТАС, I, 379 б.; *минз.* Саташу — ТТДС, 1969, 144 б.); **ихата** (*и. диал.* 1. ... киртә, читән яки койма. 2. Киртә, койма яки читән белән әйләндереп алынган урын; ишегалды — ТТАС, I, 434 б.; 2. *минз.* Ишегалды — ТТДС, 1993, 104 б.); **кәбәркә** (*минз.* Мич аралыгы — ТТДС, 1969, 266 б.); **күзелдерек** (*диал.* Өркәк атка читкә карарга комачаулау өчен йөгәндә махсус эшләнгән каплавыч — ТТАС, II, 289 б.), **матавык** (*диал.* Мәшәкать, комачау, һәртөрле борчу — ТТАС, II, 371 б.; *каз. ар. блт.* Комачау — ТТДС, 1969, 300 б.); **мокыт** (*диал.* Аңсыз, аңгыра, мәнсез — ТТАС, II, 401 б.; *гәй., злт.* Юаш, аз сүзле — ТТДС, 1993, 224 б.); **наный** (*диал.* Иркәләп эндәшү сүзе — ТТАС, II, 434 б.), **тәҗел** (*диал.* Бик тиз эшләнергә тиешле булган, ашыгыч — ТТАС, III, 238 б.); **олан** (*минз. д. т.я. каз. ар., минз., гәй.* Бала — ТТДС, 1969, 326 б.); **томса** (*диал.* Тонык, томанлы, аныксыз — ТТАС, III, 116 б), *злт.* Караңгы, ачык түгел — ТТДС, 1993, 301 б.), **чаган** (*диал.* Өрәңге — ТТАС, III, 398 б.; *кмшл. бөре, минз., гәй.* Өрәңге, клен — ТТДС, 1969, 471 б.), **чос** (*диал.* Булдыклы, өлгер, уңган — ТТАС, III, 441 б.; *минз., стрл.* Әвәс — ТТДС, 1993, 356 б), **шыкаю** (*каз. ар.* Курку — ТТДС, 1969, 518 б.), **эркелү** (*диал.* 1. Күпереп, өрелеп, тулышып тору — ТТАС, III, 580 б.; йомшак булып эреп тору — ТТДС, 1993, 390 б.), **яренгә** (*диал.* Киләсе ел — ТТАС, III, 647 б.; *кузн., хвл., мәл., чст. Бөре; т.я.-к.т., нокр.* Киләсе елга — ТТДС, 1969, 182 б.): ***Алагаем** зур ялкын телләрен суза-суза, ут сарайны бөтенләе белән ялмап ала* (Т.я., 1996, 17 сент.). *Мең, миллион төрле утлы-давыллы уйлар **диңкетте** аның башын. **Диңкетте**. Изде. Мәмрәтте.* (К.у., 1996, № 10, 53 б.). *Күзләре тонган, бу сәер күренештән тәмам **илергән** хайваннар башларын чайкый-чайкый үкерешергә тотындылар* (К.у., 1991, № 9, 115 б.). *Инде менә идарә янындагы буш **ихатага** нигез салынды* (К.у., 1990, № 11, 13 б.). *Ләкин тәнкыйтьче кигән **күзелдерек** аның күзен генә түгел, аңын да томалап ташлый* (М.ж., 2007, 4 май). *Галия үзен киләчәктә каланың «тормыш» дип аталган **матавыгында** калырмын дип күз алдына да китерә алмады* (И-л, 1992, № 5—6, 2 б.). *Сәхнәдә авызыннан сүзе чыкмый торган, авылның **мокыт** кызы түгел, гайрәтле, тере Катерина иде* (В.Т., 1994, 26 март). — ***Наный**, ничек исән калганбыздыр, — ди ул* (А.о., 1996, 22 июнь). — *Җәмәгать, мәйданга көрәшче **оланнарны** чакырам* (А.х., 1989, № 7, 13 б.). *Халык өчен **тәҗел** хәл итәсе мәсьәләләргә килеп төртелгәч, акчабыз җитми башлый* (В.Т., 2006, 15 нояб.). *Җиңгәчәй ... йөз граммлы рюмкага **томса** гына нәрсәне тутырып бирә* (И-л, 1991, № 7—8, 37 б.). ***Чаган** яфрагы ул — йөрәк сурәтең* (К-н, 1995, № 1—2, 36 б.). *Альбина кечкенә вакытында бик **чос** кыз булган* (М.ж., 1995, 27 окт.). *Кузла өстендә **шыкаеп** барган агайның аһ-зар тулы җыруы йөрәккә төшә* (И-л, 1995, № 11, 22 б.).

*Кызыл-кызыл төймәләр*

***Эркелешеп** утыра* (С-а, 1994, № 2—3, 11 б.).

***Яренгә** беренче класска барасың бит, балам!* (А-к, 1993, № 1, 28 б.).

Күренүенчә, бу төр диалектизмнарның күбесе йә әдәби телдә күп сүзле тезмәләр белән белдерелгән атамаларны алыштыру (ихата, кәбәркә, яренгә), йә төшенчәләрнең мәгънә төсмерен конкретлаштыру (диңкетү, матавык, мокыт, томса, чос, эркелү), йә эмоциональ төсмер бирү өчен (алагаем, күзелдерек, шыкаю) кулланыла.

2. *Лексик-грамматик һәм фонетик диалектизмнар*. Бу төр диалекталь сүзләр прогрессив диалектизмнар исәбенә керми. Шулай да матбугат һәм әдәби әсәрләр телендә **авырыксынмый** — авырсынмый (И-л, 1995, № 8, 4 б.); **астарлы** — аска яшерелгән, кинаяле (сүз, мәгънә) (К.у., 1996, № 1, 129 б.); **җирсәү** — җирсү (С-ә, 1996, № 2, 25 б.); **картый** — карт әни, әби (С-й, 1992, 25 нояб.); **соңра** — соңыннан (В.Т., 1994, 18 июль); **бармай** — бармый (Нур, 1995, 21 окт.) тибындагы диалектизмнарның бик еш урын алуын билгеләп үтәргә кирәк. Газета-журнал битләрендә моңа борчылу белдергән язмалар күренүе дә юкка түгел (82. 20 б.). Әдәбиятка һәм эстрадага килгән яшь язучы һәм җырчыларның үз әсәр-җырларында җирле сөйләм элементларын күп куллануы, тугандаш башкорт авторларының җырларын фонетик яктан гына «татарлаштырып» җырлау да акрынлап әдәби телебезгә йогынты ясамый калмый.

3. *Алынма диалектизмнар*. Диалектлар аша акрынлап әдәби телгә кереп барган бу сүзләр чыгышлары буенча рус (а), башкорт (ә), гарәп (б) һәм фин-угор (в) алынмалары.

а) **көрәгә** (*рус.* Коряга; *злт.* Бал ачыта торган мичкә — ТТДС, 1993, 201 б.); **көрәгәче** (*рус.+афф. -се злт.* Мәҗлестә кыстаучы, алып баручы; тамада — ТТДС, 1993, 201 б.), **нәүрәп** (рус. Погреб мәл., чст., Т.я., *орнб., орнб.-миш.* Кар базы — ТТДС, 1969, 324 б.); **пучинкә** (*рус.* Починок *бөре, байк.* Икенче берәр җирдән күчеп утырган кечкенә авыл — ТТДС, 1969, 353 б.): *Һәм һәрберсе **көрәгәче** булырлык* (И-л, 1991, № 7—8, 41 б.). *Авыл мунчасы кадәр салам түбәле йорт, кырыйлары томылмаган ярымбуш яшелчә бакчасы, киртә, сарай, **нәүрәп** ише нәрсәләр юк* (М-т, 1995, 16 сент.). *Без яши торган **пучинкәнең** таулар ягына сузылган сукмагыннан йөрергә ярамый иде* (М.җ., 1995, 8 дек.);

ә) **җәйгор** (*рус.* Радуга; *и.* Йәйгор — РБС, 693 б.); **кимәл** (*и. диал.* Сыеклык өсйөзе җитеп торган чик, горизонт; тәңгәл; русчасы: уровень — ТТАС, III, 829 б.; **Уровень** — 1. Кимәл; уровень воды в реке, йылгалагы һыузың кимәле; 2. перен. (степень) кимәл, дәрәҗә; уровень развития — үсеш дәрәҗәһе; культурный уровень — культура кимәле — РБС, 895 б.); **тәү** (*с. диал.* Беренче, әүвәлге; тәүге — ТТАС, III, 236 б.); **тәүдә** (*эчк.* Элек — ТТДС, 1969, 441 б.); **токсай** (токча — *гәй.* Чүпрәктән тегелгән сумка — ТТДС, 1969, 417 б.; мешок — ток — РБС, 370 б.); **төпкел** (*диал.* Иң түбәнге өлеш, иң эчке урын — ТТАС, III, 257 б.); **төпкөл** (*злн.* Сазламык җир — ТТДС, 1993, 320 б.); **шәлкем** (бердәй әйберләр бәйләме, төркеме): ***Җәйгор** канат җәйгән җәйнең иртәсендә ...* (К.у., 1987, № 10, 105 б.). *Гомумән, мондый проблемаларны федераль **кимәлдә** чишәргә кирәк тә ...* (В.Т., 2007, 2 март). — *Бу зат фән тарихында **тәү** мәртәбә генә очрый әле, — ди. Ул минем **тәүдә** тәпи атлап киткән, мине олы тормыш юлына хәстәрләгән төп нигезем* (С-й, 1995, 18 окт.). *Кыз брезент сумкадан **токчай*** чыгарып *миңа сузды* (Нур, 1995, 25 нояб.). *Хәзрәтнең ... вәгазе дә һәркайсыбызның күңел **төпкелләренә** барып җиткәндәй булды* (Ш.К., 1994, 16 нояб.). *РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре» **шәлкемен** мәктәп программасына мәҗбүри кертүне хуплады* (М.җ., 2006, 13 гыйнв.);

б) **җәт** (*чст. крш.* Тиз — ТТДС, 1993, 419 б.); **мәл** (*гар. каз.ар. әт., каз.ар.* **-мам.**, *кмшл.* Мөмкинлек, җай, рәт — ТТДС, 1969, 313 б.); **мәшәләнү** (*гар.*+афф. **-ләнү** *орнб.* Маташу — ТТДС, 1969, 316 б.): *Дәресләрне әзерлибез дә **җәтрәк** урамга ашыгабыз* (С-й, 1995, 8 март). *Боздан әрчелгән елганың ярларына сыешмыйча шашып-шашып аккан **мәле** иде* (М-т, 1994, 19 нояб.). *... хәрби комиссариат аны, эшенннән чыгартып, мәҗбүри рәвештә шоферлыкка укыта, аннан ярты елы шул хезмәт белән **мәшәләнеп** үтә* (А-к, 1993, № 8, 4 б.);

в) **лабра** (*мар. каз.ар. к.* Йубалгы, **йубалгы** — *минз.* 1. Җыйнаксыз. 2. Булдыксыз — ТТДС, 1993, 210, 116 б.); **пима** (*угор бөре, минз., байк., орнб., орнб.-миш.* Киез итек — ТТДС, 1969, 339 б.): *Аббау, нәрсә уйлый икән инде ул минем хакта. **Лабра, юбалгы** бер кызый диптер инде* (И-л, 1995, № 12, 15 б.). *Әртилдә, акчага эшли, итекләр тегә, **пималар** төпли* (К.у., 1995, № 7, 66 б.).

Алда каралган мисаллар матур әдәбият һәм публицистика стилендә соңгы елларда диалекталь сүзләрнең күпләп кулланылуын дәлилли. Яңа чорда телнең үз сүзләренә игътибар көчәю шартларында аларның күбесенең әдәби телдә ныгу мөмкинлеге зур. Болар телчеләребезнең татар әдәби теле, терминологиясе үсешендә «диалекталь лексика киләчәктә дә зур урын тотачак әле» (147. 132 б.) дигән фаразының чынга ашуы турында сөйли.

### 1.5.2. Гомумкулланылыштагы сүзләрнең терминлашуы һәм кайбер тармак атамаларының башка «мәйданга» күчүе

Әдәби телдәге гомумаңлаешлы сүзләрне терминлаштыру татар телендә күптән кулланыла (147. 126—128 б.). Узган гасырның 80 нче еллары уртасында җәмгыять тормышындагы кискен үзгәрешләргә бәйле рәвештә дә гомумхалык лексикасына караган кайбер сүзләр шушы үзгәрешләрне атау буенча «махсуслашып», ягъни мәгънәләрен конкретлаштырып, яңа даирәдә — иҗтимагый-сәяси терминнар буларак кулланыла башладылар. Мондыйларга мисал итеп беренче чиратта **борылыш** (*и.* 1. Берәр нәрсәнең икенче якка борылган, авышкан, тайпылган урыны, борма. 2. *куч.* Берәр нәрсәнең барышында яңа юнәлеш; үзгәреш, күчеш. / *с. мәгъ.* Борылыш моменты — ТТАС, I, 180 б.); **торгынлык** (*и.* Бәрәр нәрсәнең үсешендә тукталыш, алга китеш булмау, алга бармау күренеше — ТТАС, III, 119 б.); **тотрыксызлык** (*и.* Тотрык (1, 3 мәгъ.) булмау — ТТАС, III, 128 б.); **үзгәреш** (*и.* Бер хәлдән икенче хәлгә күчеш, яңарыш, әверелеш. // Алга китеш, үсеш. 2. *иск. линг.* Төрләнеш — ТТАС, III, 722 б.) сүзләрен күрсәтергә була: *КПССның XXVII съездыннан соң **борылыш, үзгәреш, тизләнеш** кебек сүзләр яңа бер мәгънә алдылар* (К.у., 1986, № 12, 161 б.). *Илдә **торгынлык** — киләчәк буыннар өлешенә кереп, үтечкә яшәү чоры башланды* (М.җ., 2007, 6 апр.). *Гаять зур югалтуларга, **тотрыксызлыкка** дучар ителгән җәмгыятебездә хатын-кызның ана булу гамәле бик түбән бәяләнә* (С-ә, 1986, № 2, 3 б.). *Без Татарстанның **борылыш** чорына аяк басуын аңларга ... тиешбез* (Т.х., 1992, 20 июнь.).

Җәмгыяви үзгәрешләр белән беррәттән, фәнни-техник алгарыш та кайбер гомумкулланылыштагы сүзләрнең терминлашуына китерде. Әйтик, **кәрәз** (*и.* Бал туплау, күкәй салу өчен бал кортлары яки шөпшәләр тарафыннан тигез рәтләр итеп балавыздан ясалган күзәнәкләр — ТТАС, II, 253 б.)

исеменнән ясалган **кәрәзле** сыйфаты элек бары кәрәзле бал сүтезмәсендә «кәрәзеннән суыртып алынмаган ... кәрәзе белән алынган (бал)» (ТАСС, II, 253 б.) төшенчәсен генә белдерсә, соңгы чорда рус телендәге тәңгәле «сотовый» йогынтысында яңа төр элемтә чарасын белдерүче атамага әверелде: *Модада бүген — **кәрәзле** телефоннар* (Т.я., 1997, 18 окт.). Дөрес, соңгы елларда бу бик уңышлы булмаган калька урынына «кесә телефоны» тәгъбире ешрак кулланыла: ***Кесә телефоныннан** да шалтыратып, хәлен белгертеп тора* (Өмет, 2007, 22 февр.).

Иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләр шулай ук кайбер аерым тармак, фән өлкәсенә караган атамаларның иҗтимагый термин буларак та, ягъни башка «мәйданда» (100. 5 б.) файдалануга китерде. Әйтик, элегрәк физика термины гына булган **тизләнеш** (*и. физ.* Тизлекнең вакыт берәмлегендә үзгәреше — ТТАС, III, 95 б.) сүзе XX йөзнең 80—90 нчы елларында иң актив иҗтимагый терминнарның берсенә әверелде: *Нәкъ менә шушы елның гыйнварында Горбачев реформаларның икенче этабын игълан итә: «**тизләнеш**» дигәннәре «үзгәртеп кору» белән алышына* (М.ж., 1999, 1 гыйнв.).

Каралган мисаллардан «ана теленең үз сүзләрен фәнни термин дәрәҗәсенә күтәрү — телнең эчке мөмкинлекләреннән рациональ файдалануның иң гади һәм табигый күренеше» (147. 126 б.) буларак хәзер дә файдаланыла дигән нәтиҗә ясарга була.

### 1.5.3. Гади сөйләм лексикасының әдәби телгә йогынтысы

«Әдәби телнең сүзлек хәзинәсен үстерүдә һәм функциональ стильләрне төрле яклап баетуда җанлы сөйләм үзенчәлекләре зур урын тота» (156. 48 б.). Чөнки «әдәби телнең үсү һәм камилләшү дәрәҗәсе аның халык сөйләменә якынлык дәрәҗәсе белән билгеләнә» (58. 22 б.).

Соңгы елларда төрки-татар чыгышлы шактый гына гади сөйләм сүзләре газета-журнал лексикасына актив үтеп керде. Базар мөнәсәбәтләренең тормышыбызда ныклап урнашуына бәйле рәвештә **алыпсатар** (*сөйл.* Берәүдән алып, табыш белән икенче берәүгә сатучы, спекулянт — ТТАС, I, 54 б.) һәм **арадашчы** (1. *сөйл.* Арадашлык итүче, маклер ... — ТТАС, I, 64 б.) сүзләре тискәре эмоциональ төсмерләрен дә җуеп, стилистик нейтраль сүзләргә әверелделәр. Алар, аеруча беренчесе, гадәттә һөнәр атамасы буларак күплек формасында кулланыла: *Чаллы **алыпсатарлары**, Мәскәү ерак, юл кыйммәт дип тормыйлар* (В.Т., 1994, 29 март.). *Җитештерүче түгел, **арадашчы** ота мондый шартларда* (С-ә, 1996, № 9, 9 б.).

**Ярлыкау** (*дини сөйл.* Гафу итү, аклау, кичерү, гөнаһларны йолу — ТТАС, III, 648 б.) сүзе дә хәзер күбрәк дини төсмердән башка гына һәм төрле стильләрдә кулланыла: *Үпкәләрем, нәфрәтем өчен **ярлыкау** сорыйм* (И-л, 1995, № 8, 17 б.). « *... бары тик вакыт үтү белән генә **ярлыкау** алырга мөмкин», — ди композитор* (М.ж., 1998, 27 март.).

Инде алда әйтелгәнчә, гади сөйләм сүзләре дә әдәби телдә күпчелек очракта алынма сүзләрне алыштыру чарасы буларак активлашалар: **алыпсатар** — спекулянт, **арадашчы** — маклер, **кәрәзле** — сотовый, **канунлашу** — законлашу. Куллану стиле киңәю белән беррәттән аерым сүзләрдәге элекке тискәре эмоциональ төсмер дә югала.

### 1.5.4. Искергән һәм сирәк кулланылыштагы сүзләрнең активлашуы

Соңгы чор татар әдәби теле лексикасы үсешендәге иң әһәмиятле тенденцияләрнең берсе — XX йөзнең 30—40 нчы елларында интернациональ һәм рус сүзләре тарафыннан пассив сүзлеккә кысрыкланган кайбер сүзләрнең яңадан акрынлап активлашуы. Яңа мәгънә алып әдәби телгә кайткан сүзләрнең кайберләре 1.2 параграфта каралган иде (тотак, тугра, узаман, ятакханә һ.б.). Биредә, нигездә, элекке, ТТАСтә теркәлгән мәгънәләрендә актив лексикага кайткан сүзләргә тукталабыз. Функциональ үзенчәлекләреннән чыгып, алар дүрт төркемгә бүленә.

#### 1.5.4.1. Алынма сүзләрне алыштыру максатында активлашкан сүзләр (архаизмнар)

ТТАСтә «искергән сүз» тамгасы белән теркәлгән бу сүзләр телебезнең барлык стильләренә дә ныклап үтеп кергән рус-европа алынмалары урынына аларның абсолют синонимнары буларак кулланылышка керә баралар. Алар арасында телнең үз җирлегендә күптән үзләштерелгән гарәп-фарсы алынмаларыннан һәм татар сүзләренә ***-ханә, -намә*** компоненты ялгап ясалган сүзләр дә бар. Түбәндә бу сүзләрне үзләре алыштырган синонимнарын күрсәтеп санап үтәбез: **әбүнәче** — абонент, **алтатар** — пистолет, револьвер, **басмаханә** — типография, **зыялы** — интеллигент, **иганәче** — спонсор, меценат, **йолдызнамә** — гороскоп, **кизү** — дежур (сыйфат һәм исем мәгънәләрендә), **корылтай** — съезд, конгресс, **сәясәтче** — политик, дипломат, **чәчтараш** — парикмахер һ.б.: *Әгәр баллистик тикшерү **алтатарны** атуга яраклы дип тапса, милициядә әлеге коралны кабул итеп алачаклар* (М.ж., 1995, 13 окт.). *Безнең эшнең нигезендә **әбүнәчеләр** санын арттыру тора* (К.т., 1995, 24 март). *Безнең Казанда гына да 20 дән артык татар **басмаханәсе** эшли* (С-й, 1994, 9 нояб.). *Татар **зыялысы*** (М-с, 1992, № 9,

23 б.). *Шуңа күрә ... малтабарларны, кооператорларны, конкурсның* ***иганәчеләре*** *булырга чакырабыз* (С-ә, 1992, № 3, 6 б.). *Шул нигездә, дин, фән, гореф-гадәтләр, сихерчелек, ырымнар,* ***йолдызнамә*** *һ.б. бик күп, бик күп гыйлем тупланган* (С-ә, 1992, № 4, 21 б.). — *Крайкомга шалтыратыгыз, әмер булса, озатам, ди* ***кизү*** *кыз* (В.Т., 1995, 1 апр.). *Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең XV* ***корылтайдан*** *соңгы беренче утырышы булды* (К.у., 2005, № 8, 190 б.). *Болар хакында мин язучы буларак уйлансам, җавабын азатлык, дәүләт өчен көрәштә милли* ***сәясәтче*** *буларак табам* (А-к, 1992, № 3—4, 14 б.). *Әмма алар без йөри торган* ***чәчтарашка*** *яисә теш дәвалаучыга бара бит* (Т.я., 1994, 1 дек.).

**1.5.4.2. Җәмгыять тормышындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә әдәби телгә кайткан (тарихи) сүзләр**

Яңа шартларга «җайлашулары» ачыграк күренсен өчен, бу сүзләрне ТТАСтәге мәгънә аңлатмалары белән карыйбыз.

**Баскын** (*тар.* 1. Тыныч илгә, кабиләгә һ.б. (күбесенчә талау нияте белән) ясалган һөҗүм. 2. *диал.* Баскынчы — ТТАС, I, 128 б.). Бөек Ватан сугышыннан соң онытылып торган бу сүз Чечнядагы вакыйгалар уңаеннан яңадан кулланылышка кайтты: *Рәсәй* ***баскыннарының*** *бу сугышы Әлмәт шәһәрен дә читләтеп үтмәде* (В.Т., 1995, 26 дек.). Кайбер газета-журнал битләрендә шушы ук мәгънәдә ялгыш **баскак** сүзен дә кулланалар: *Чәчәннәр әле һаман Рәсәй* ***баскакларына*** *каршы тора* (Ш.Ч., 1994, 18 апр.). Моның белән килешеп булмый, чөнки **баскак** (*тар.* Алтын Урда ханының биләмә өлкәләрдәге урынбасары; ханга ясак җыеп тапшыручы отряд башлыгы — ТТАС, I, 128 б.) сүзе башка төрки тел-диалектларда да «баскын» мәгънәсендә теркәлмәгән (ЭСТЯ, 1978, 77—78 б.). Бу бары охшаш яңгырашлы пароним сүзләрнең мәгънәләренә игътибар итмәү нәтиҗәсе генә.

**Җыен** (*иск.* Нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен җыйналган җәмәгать җыелышы — ТТАС, III, 796 б.) сүзе беренче чиратта шундый чын-чынлап җәмәгать башлангычында эшләүче оешмалар уздырган ирекле халык җыелышларының яңадан гамәлгә керүе нәтиҗәсендә активлашты. Аны шулай ук башка төрле җыелышларны атау өчен **сбор**, **сессия**, *конференция* сүзләре урынына да куллана башладылар: *Узган елның август аенда балалар оешмасы активистларының ... «Лидер» республика* ***җыены*** *(сборы) булган иде* (С-й, 1996, 14 сент.). *Татарстан Фәннәр академиясендә узган олуг* ***җыенда*** *күпләр күңелендә яңарды бу фикер ...* (В.Т., 1996, 24 май). *Ким дигәндә 200 кеше катнашачак* ***җыенда*** *Свердловск өлкәсе татарлары дүртенче корылтайга делегатлар да сайламакчы* (В.Т., 2007, 19 сент.).

**Качак** (1. Дошман явыннан яки эчке дошманнардан һ.б. качып, илен-йортын ташлап киткән кеше. 2. Дошман явыннан һ.б. качып йөрү хәле. 3. *диал.* к. Качкын — ТТАС, II, 76 б.) сүзе дә элеккеге СССРның төрле төбәкләрендә милли, этник һ.б. чуалышлар, сугышлар башлану нәтиҗәсендә активлашты, бүгенге шартларда ул күбрәк милли-этник кыерсытулар аркасында яшәгән урын-дәүләтен ташлап китәргә мәҗбүр ителгән кешеләргә карата кулланыла: *Шул сәбәпле илдә миллион чамасы* ***качак*** *сыенып урын эзләп газап чигә* (Т-н, 1995, № 1, 16 б.).

Мисаллардан күренгәнчә, бу төркемгә караган сүзләр яңа чорга бәйле рәвештә берникадәр мәгънә төсмерләрен дә конкретлаштырып активлашканнар.

**1.5.4.3. Искерү төсмере булмаса да, элек бик сирәк, нигездә китап теле стилендә, аерым авторлар тарафыннан гына кулланылып, соңгы елларда алынма синонимнарын алыштырып активлашкан сүзләр**

ТТАСтә бу сүзләр күбесенчә «сирәк кулланылыштагы сүз» тамгасы белән бирелгәннәр: **аклама** — беловик, **алгарыш** — прогресс, **ашчы** — повар, **белешмә** — справка, **белешмәлек** — справочник, **иләт** — население, **керем** — доход, **кулдаш** — партнер, **күчермә** — копия, **очкыч** — самолет, **салым** — налог, **сынчы** — скульптор, **таныкнамә** — таныклык, удостоверение, **эскәнҗә** — тиски һ.б.: *Узе аны редакцияләп басарга әзерли, үз кулы белән* ***акламага*** *күчерә ...* (Т-н, 1993, № 3, 41 б). *... ул илнең социаль-икътисади* ***алгарышка*** *һәм сәяси тотрыклылыкка таба юнәлешен дәвам иттерү зарурилыгын аңлап эш итә* (В.Т., 2007, 9 окт.). *Ничек итеп* ***ашчы*** *булып киттегез?* (З.-Т., 1996, 11 окт.). ***Белешмәсен*** *тотып, «теге» мәктәпкә барган ...* (М-т, 1995, 23 сент.). *Дөньядагы күп илләр «Сары сәхифәләр» дигән* ***белешмәлектән*** *күптән файдаланалар* (В.Т., 1995). *Иҗтимагый-икътисади бәйләнешләр ярдәмендә генә Рәсәйдәге* ***иләтне*** *(население) бергә укмаштыру* (В.Т., 1996, 28 дек.). ***Кулдаш*** *аны һәр көнне иртән сәгать алтыга китереп җиткерә* (К.у., 1996, № 12, 29 б.). *Һәр* ***күчермәгә*** *һәм оригиналга конкурста катнашуга гаризаның берәр* ***күчермәсен*** *... иртеп бирергә кирәк* (В.Т., 1996, 2 апр.). *3 октябрьдә Һиндстан башкаласы Дәһлидән Казанга* ***очкыч*** *белән кайтып төшкән сәяхәтчеләрнең 66 сын да тотып 6 тәүлеккә ябып куйганнар* (Т.я., 1994, 6 окт.). *... Россиядәге татарлар бит* ***салымны*** *Россия бюджетына түлиләр* (В.Т, 2007, 2 март). *Узган җомгада Казанда халкыбызның бөек рәссамы,* ***сынчы*** *Бакый Урманче хөрмәтенә ул яшәгән йорт диварына истәлек тактасы куелды* (М.җ., 1997, 28 февр.). *«Сугыш инвалиды» дигән* ***таныкнамә*** *дә йөртергә хокуклы, шул турыда дәүләтебезнең мәгълүм Законы чыга* (М-т, 1995, 6 май). *Шушы өч сүз* ***эскәнҗә*** *кебек баса* (Т.я., 1995, 4 март).

### 1.5.4.4. Фонетик архаизмнар

Бу төргә **оглан // углан** — ул, **олуг** — олы, **ошбу** — бу, шушы архаизмнары керә. Алда анализланган искергән сүзләрнең активлашуы прогрессив, телнең үз җирлегендә камилләшүен раслаучы күренеш булса, фонетик архаизмнар турында моны әйтеп булмый. Аларны аерым стилистик максатларда, китап телендә куллану гына үзен аклый. Ә соңгы елларда бу искергән фонетик вариантларны урынлы-урынсыз, мәгънә-стиль төсмеренә игътибар итми куллану ешайды: **олуг** байлар (Я-н, 1996, № 1, 25 б.); **олуг** матәм (Ш.К., 1994, 26 окт.); **олуг** чыганаклар (С-й, 1996, 16 нояб.); **олуг** ялгыш (В.Т., 1996, 17 май); **ошбу** ай (Нур, 1995, 6 апр.); **ошбу** бау (В.Т., 1994, 24 окт.); **ошбу** басма (М-т, 1994, 26 март); **ошбу** вакыйга (И-л, 1994, № 2, 2 б.); **ошбу** программа (Ш.К., 1994, 31 май); **ошбу** күренеш (В.Т., 2006, 4 нояб.) һ.б. Мисалга бер генә җөмлә китерик: *Яшь чагында мондый **олуг** бүләккә ия була алмаган һәм машина йөртергә дә өйрәнмәгән Илһам ага ак төстәге «Ока»ны сатып җибәргән, ди* (М-т, 1994, 7 май). Халыкның иң атаклы җырчысына бирелгән иң арзанлы машинаны олуг түгел, зур бүләк дию дә артык.

**Оглан // углан** сүзен дә олы кешенең балаларга, яшьләргә мөрәҗәгать формасында куллану гына, безнеңчә, бүгенге көндә максатка ярашлы.

Ялгызлык исемнәрен элекке яңгыраш-язылышта куллану да хәзерге матбугатта еш очрый: *Императрицага Себер һәм **Азак** диңгезе буйларындагы курганнардан табылган борынгы хәзинәне бүләк итәләр* (В.Т., 2007, 17 авг.). ... ***Мари иле** дәүләт университетының фәнни китапханәсеннән, **Ижау** шәһәренең үзәк муниципаль китапханәсеннән вәкилләр катнашты һәм чыгыш ясады* (М.җ., 2007, 6 апр.).

Совет власте шартларында онытылуга дучар ителгән һәм, нигездә, тарихи әсәрләр, аерым авторлар телендә, сүзлекләрдә генә сакланган шушы дистәләрчә төрки-татар чыганаклы сүзнең актив кулланылышка кайтуы соңгы елларда лексиканың үз җирлегендә баюына зур өлеш кертте. Карап үткән сүзләрнең күпчелеге рус-европа сүзләрен алыштыру хаҗәтеннән активлаштырыла, арада яңа иҗтимагый шартларга бәйле рәвештә кире кайткан **баскын**, **җыен**, **качак**, **иганәче** кебек сүзләр дә бар.

## 1.6. Окказиональ сүзләр

Тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә яңа сүзләр ясау, булганнарын яңа мәгънәдә куллану тенденциясе узган гасырның 80—90 нчы елларында матур әдәбият һәм газета-журнал битләрендә окказиональ сүзләр иҗат итү белән мавыгуның көчәюенә китерде. Дөрес, әдәби әсәрләрдә, бигрәк тә поэзиядә, сатира-юмор өлкәсендә сүз уйнату чарасы буларак аерым авторлар тарафыннан индивидуаль-стилистик неологизмнар ясау элек тә күзәтелә иде (125. 89—91 б.; 127. 80—82 б.; 61). Соңгы елларда окказионализмнар белән мавыгу башка стильләрдә, аеруча матбугат телендә һәм хәтта фәнни-техник хезмәтләрдә дә урын алды. Әдәби телебезне рус алынмалары һәм интернациональ сүзләрдән «чистарту» максатында кайбер басмалар һәм авторлар хәтта махсус сүзлекчәләр дә тәкъдим иттеләр (188; 65). Алар, нигездә, гарәп-фарсы алынмаларыннан һәм өлешчә пассив лексикага күчкән иске төрки-татар сүзләреннән торсалар да, арада авторларның үз иҗат җимешләре дә шактый. Шушы чорда дөнья күргән төрле тармак һәм фәннәр буенча русча-татарча сүзлекчәләр дә мондый гомумкулланылышка кереп китүе шикле булган берәмлекләрдән азат түгел.

Яңа окказионализмнарның барлык төр ысуллар белән дә диярлек ясалгананнарын табарга мөмкин. Түбәндә «кирестройка», «таңстан», «төнбагыш» кебек поэтик-стилистик окказионализмнарга һәм «астәгмән», «инанча», «су барусы» тибындагы перспективасыз төзелмәләргә тукталып тормыйча, киңрәк кулланылышка кереп китү мөмкинлеге бар дип исәпләнгән, татар теле материалыннан ясалган индивидуаль-автор неологизмнарыннан кайберләрен санап үтәбез.

**1.6.1.** *Кушымчалау ысулы белән ясалган окказиональ сүзләр*: **аслама**, **аумагалы**, **башлаткыч**, **корыш**, **көлкелеш**, **сикергеч** (трамплин мәгънәсе), **токымдар**, **уйдар**, **уйма** (резьба мәгънәсе), **үзебезчәлек**, **хыялдаш**, **шомагур** (крутой), **юксыллык** (юклык, хәерчелек мәгънәсе), **ятулык**.

*М.З.Зәкиев оппонентларының, янәсе, «ул, телче, ничек инде тарих проблемалары буенча чыгыш ясый» дигән **асламалары** да ниндидер анахронизм булып тора* (В.Т., 1996, 10 июль.).

*Аркалынып **аумагалы** еллар килде,*
*Тормышыма ил күзендә аһәң иңде* (А-к, 1995, № 12, 57 б.).
*Әйтәм сезгә башваткыч,*
*Башны эшкә **башлаткыч*** (Я-н, 1995, № 3, 13 б.).
*Кемнәр янар, кемнәр кайнар анда,*
*Үзгәртелгән шушы **корышта**?* (Т.я., 1995, № 65—66.).
*Ша-ярыш,*
***Көлкелешнең** беренче этабы тәмам.*

*Яшәсен* ***көлкелизм!*** (И-л, 1995, № 1, 77 б.).

*Илгизнең һәм башка малайларның теләген искә алып, без бу санда* ***сикергеч*** *(трамплин) сызымын тәкъдим итәбез* (Я-н, 1995, № 1, 32 б.). *Иң элек шуны әйтү кирәктер, әлеге җитди, җаваплы гамәлне башлап ниятләүчеләр — Барҗы-Умга авылы* ***токымдарлары****, ягъни ата-бабалары бирегә яшәгән, үзләре дә шушы авылда туып үскән ...* (Ш.Ч., 1997, 11 окт.). *Уйчан кеше генә язучы була ала.* ***Уйдар*** *булу, дип тә әйтәм* (Я-н, 1995, № 6, 9 б.). *...* ***уйма*** *...* (А-к, 1993, № 10, 118 б.). *Соңгы елларда Чаллы сабан туйларында* ***үзебезчәлек*** *сизелә башлады* (Т.й., 1995, № 21). *Әнә шул таләпләргә җавап итеп язылган шигырьләрдә үзенчәлекле яңа сүзләр еш очрый, мәсәлән:* ***хыялдаш****,* ***сәламдәш*** (К.у. 1991, № 6, 175 б.). *Алары өстенә* ***шомагурлар*** *(«крутой»), әрсезләр дә чиратсызлар сафын нык ишәйтәләр* (В. Т., 1995, 5 сент.). *Һаман шул* ***юксыллык****, һаман шул зар-моң, бер почмагың булмау, үзеңне артык кеше итеп сизә башлау канатларны талдыра иде* (М-т, 1994, 15 гыйнв.). *Бәләкәй генә* ***ятулыкта*** *су кереп алдым* (С-й, 1995, 26 июнь).

Нинди дә булса бина яисә оешманы атау өчен ***-ханә*** элементы белән күп сүзләр ясыйлар: **айныткычханә**, **гәзитханә**, **журналханә**, **кабымлыкханә**, **кәефханә**, **консулханә**, **музейханә**, **назханә**, **радиоханә**, **сихәтханә**, **юлханә** һ.б.

*Мондый йогышлы чиргә каршы бердәнбер дару — вытрезвиловка (татарча* ***айныткычханә*** *буладыр инде)* (К.т., 1998, 25 март). ***Гәзитханәдә*** *була торган һәммә эшләр белән дә ул яхшы таныш иде* (С-ә, 1993, № 7, 22 б.). *... «Салават күпере»* ***журналханәсенә*** *елмаеп-балкып килеп керә ...* (М.җ., 1997, 24 окт.). *Арбат та үзенә күрә башкала — ул матрешкалар,* ***кабымлыкханәләр*** *һәм рәссамнар башкаласы* (Т я., 1998, 25 июнь). *Хатын-кызлар бәйрәмендә бу* ***кәефханә*** *(«Татарстан» кунакханәсе рестораны) публикасы Нәфкать Нигъмәтуллин җырлавын тыңлап хозурланган иде* (Т.я., 1998, 9 май). *Мәҗлестә Русия илчелеге вә* ***консулханә*** *кешеләре вә башка мосафирлар күп иде* (С-ә, 1997, № 6, 14 б.). ***Музейханә*** *(*рубрика исеме*)* (М.җ., 1997, 7 март). *Монда карт-корылар өчен аерым шәфкать йортлары, сыену почмаклары,* ***иркә-назханәләр*** *ачыла тора* (Ш.Ч., 1996, 4 нояб.). *Шушы елның җәендә миңа Казан* ***радиоханәсендә*** *СССРның беренче һәм соңгы Президенты Михаил Горбачев белән сөйләшеп утырырга туры килде* (М.җ., 1996, 27 дек.). *Яшьләр хатын-кыз* ***сихәтханәсенә*** *килеп керделәр* (И-л, 1995, № 1, 70 б.). ***Юлханәдә*** *ни калган бу Мөслимәгә?* (А-к, 1996, № 12, 72 б.).

Шулай ук ***-намә*** элементы белән дә соңгы елларда бик күп сүз ясала: **игъланнамә**, **нигезнамә**, **озатнамә**, **рөхсәтнамә** һ.б.: *Экология* ***игъланнамәсе*** *(*мәкалә исеме*)* (Ч.-И., 1991, 14—20 сент.). *1991 елда оешкан «Татарстан варислар берлеге» нәкъ менә «Мирас юлы»* ***нигезнамәсенә*** *таянып эш итә* (Я-н, 1997, № 6, 13 б.). *СССР Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы Всеволод Троицкийның* ***озатнамә*** *хаты һәм кара төстәге бер сәер капсуласы була* (В.Т., 1998, 25 март). *Әбәт ашаганнан соң, порт белән танышырга рөхсәт бирделәр һәм берничә төркемгә «ярга чыгу»* ***рөхсәтнамәләре*** *өләштеләр* (Ш.Ч., 1997, 16 сент.).

**1.6.2.** *Кушма сүзләр:* **канункүз**, **сынчыбагар**, **уткызган**, **төнгизәр** һ.б.

*Казанда халык мәгарифенең шәһәр һәм район бүлекләре мөдирләре, ... Татарстан җөмһүриятенең баш* ***канункүзе*** *(прокуроры) ... — барысы да чит милләт вәкилләре* (С-ә, 1991, № 12, 13 б.). *Фешин мәктәбенең* ***«сынчыбагарлары»*** *күпме буын рәссамнарын багып үстерде инде* (И-л, 1995, № 9, 45 б.). *Алар дага өчен* ***уткызган*** *тимер таптый: чаң-чең, чаң-чең ...* (С.к., 1995, № 11—12.). *Дәшә мине Шигырь —* ***Төнгизәр*** (К.у., 1992, № 2, 81 б.).

*Җыр буенча ярыш уздырылса*
*Җир шарында барлык кошларга,*
*Булыр иде сиңа Гран-при*
***Кошларара*** *конкурсларда* (М. җ., 2007, 4 май).

**Сөяр** компоненты белән төрле кушма сүзләр ясала: **уйсөяр**, **фәнсөяр**, **футболсөяр**, **эшсөяр**: *Ул чын мәгънәсендә уйдар, уйларга яратучы,* ***уйсөяр*** (М.җ., 1995, № 8.). *Рухи һәм матди яктан зур булышлык алган яшь* ***фәнсөярләр*** *инде бүген вуз укытучылары* (Т.я., 1995, 23 февр. — *В.Гарифуллин*). *Кибет, чәчханә, ашханә, автомобильләрдә, кыскасы,* ***футболсөярнең*** *кул астындагы бөтен җирдә байрак һәм вымпеллар урын ала* (И-л, 1996, № 2, 41 б.). *Тырыш, алтын куллы* ***эшсөярләр*** (Ш.К., 1994, 6 июль).

**1.6.3.** *Тезмә сүзләр:* **бөтенхалык тикшерүе** — референдум, **җәйлек өй** — дача, **сулы буяу** — акварель һ.б.

*Шимбә көнне съезд* ***бөтенхалык тикшерүе*** *(референдум) үткәрү турында СССР Законы проектын тикшерергә керешә* (Нур, 1990, 25 дек.). *Фатирлы,* ***җәйлек өйле****, машиналы булып, хөр тормыш кичер әле син.* (М.җ., 1997, 24 гыйнв.). *...* ***сулы буяу*** *...* (А-к, 1993, № 10, 118 б.).

**1.6.4.** *Лексик-семантик ысул белән ясалган (окказиональ) сүзләр:* **бүленеш** («эшкә билгеләнү, распределение» мәгънәсе), **төмән** («дивизия», мәгънәсе һ.б.)

*Һәр елны уку елы тәмамлангач, **бүленеш** (направление) буенча күп сәләтле яшьләребез читкә җибәрелә* (Т.я., 1989, 29 июнь). ... ***төмән*** ... (А-к, 1993, № 10, 118 б.).

**1.6.5.** *Фонетик окказионализмнар:* **тәмнүшкә**, **хистәлекләр**.

*Бүгенге кибет киштәләре **«тәмнүшкәләрнең»** авырлыгыннан ишелеп төшәргә тора* (Я-н, 1996, № 11, 30 б.). *Ш.Галиев **«хистәлекләре»*** (С-й, 1995, 1 апр.).

**1.6.6.** Элекке елларда ясалып, тел тарафыннан кире кагылган кайбер окказионализмнарны яңадан кулланылышка кертергә омтылу очраклары да күзәтелә. Әйтик, 1930 елларда «колхоз» атамасы урынына тәкъдим ителеп тә, активлаша алмаган **күмхуҗ** сүзен Илдус Гыйләҗев үз шигырендә «терелткән» (И-л, 1995, № 6, 3 б.), кайчандыр Рәдиф Гаташ шигырьләрендә яратып кулланылган **җирский** сүзе Аяз Гыйләҗевнең хәтеренә сеңеп калган (К.у., 1986, № 10, 33 б.). Гамил Афзал иҗат иткән **мин-минизм** окказионализмын Тәлгат Галиуллин әдәби-тәнкыйть мәкаләсендә шул чорны характерлаучы атама буларак файдаланган (К.у., 1992, № 11, 169 б.).

Югарыда саналган соңгы еллар «җимеше» булган окказионализмнар арасында да шулай вакыт-вакыт урынын белеп кулланырдайлары да, гомумкулланылышка кереп китәрдәйләре дә байтак.

## 1.7. Яңа сүзләрне кулланудагы кайбер үзенчәлекләр

Яңа сүзнең телдә ныклап урын алуы күп вакыт таләп итә. Күбесенең кулланылышы әле тотрыклы түгел. Матбугатта алар берничә төрле юл белән активлашалар:

а) телнең үз җирлегендә ясалган яңа яисә активлаштырылган сүзләр әле рус-европа чыгышлы синонимнары белән параллель кулланылалар: **кертем** (В.Т., 1997, 4 нояб.) һәм **вклад** (Т.я., 1999, 6 февр.); **санак** (Т.я., 1995, 29 апр.), **кампитр** (М.ж., 1997, 18 апр.; 2007, 9 март) һәм **компьютер** (Т-н, 1995, № 9—10, 49 б.); **суверенлык** (Т-н, 1991, № 8, 5 б.) һәм **суверенитет** (Т-н, 1993, № 8, 8 б.); **хосусыйлаштыру** (Т.я., 1992, 24 авг.) һәм **приватизация** (В.Т., 1992, 5 окт.) һ.б.;

ә) яңа ясалган яки кире кайтарылган сүзне халыкка аңлаешлырак итү максатында аларны алынма тәңгәлләре белән аныклап бирү дә кулланыла: *Русия матбугаты **әбүнәчеләрдән (подписчиклардан)** кергән акчаның ике өлешен ... секунд эчендә югалтты* (Т.я., 1998, 8 окт.). *Президент Б.Ельцин пенсия һәм эш хакларын үз вакытында түләүне тәэмин итү кирәклегенә сылтап, **Вакытлы Гадәттән тыш Комиссия (Временная Чрезвычайная Комиссия — ВЧК)** оештырды* (В.Т., 1997, 21 февр.). *... техник таләпләргә туры килү-килмәү буенча ... **мәҗбүри тикшерү (сертификация)** узарга тиеш* (В.Т., 1998, 27 окт.). *Әлеге система шәһәр **хакимияте башлыгы (мэры)** карары белән 3 ел элек кертелде* (М-ф, 1995, № 2, 4 б.). *Илдә **тамгалык (таможня)** салымнарын җыю хокукы Березовскийның көндәше «ОНЭКСИМ» банкына бирелде* (З.-Т., 1998, 10 апр.). ***Тапшыргычлар (датчик)** нерв җепләре очына беркетелгән булып чыга* (В.Т., 1999, 7 гыйнв.);

б) яңа төшенчәләрне атау, чит тел сүзләрен алыштыру өчен уңышлы сүзләр ясау җиңел түгел. Шунлыктан күп кенә яңа атамаларны бер үк матбугат органында да берничә вариантта куллану еш очрый. Мәсәлән, **вывеска** сүзен **алтакта** (В.Т., 1998, 7 апр.), **күрсәтмә такта** (Т.я., 1998, 15 сент.), **элмә такта** (В.Т., 1998, 13 нояб.; Т.я., 1998, 4 июль), **элмә язу** (Т.я., 1998, 13 окт.); «больничный лист / лист нетрудоспособности» атамасын **авыру белешмәсе** (К-н, 1996, № 3—4, 40 б.), **хастаханә белешмәсе** (К-н, 1996, № 3—4, 57 б.), **шифаханә белешмәсе** (К-н, 1995, № 5—6, 108 б.); «характеристика»ны **бәһаләмә** (С-ә, 1991, № 12, 11 б.), **бәяләмә** (В.Т., 1996, 17 май), **сыйфатлама** (В.Т., 1998, 5 июнь); **болельщик** алынмасын **җанатар** (Т.я., 1996, 9 апр.) һәм **көярмән** (К.т., 1997, 10 апр.); **небоскребны күктерәү** (Т.я., 1998, 26 февр.) һәм **күкашар** (К.к., 1998, 12 нояб.), **разговорник** сүзен **сөйләүлек** (В.Т., 1997, 19 дек.) һәм **сөйләшмәлек** (В.Т., 1998, 26 июнь); **упаковка** алынмасын **төрем** (В.Т., 1998, 19 сент.) һәм **төрелеш** (В.Т., 1997, 10 окт.); **композиторны аһәңсаз** (В.Т., 2007, 14 апр.), **көйязар** (В.Т., 2006, 8 дек.) һәм **көйче** (Т.я., 1996, 5 сент.) сүзләре аша бирү һ.б.

Әлбәттә, вакытлар узу белән телдә бу вариантларның берсе генә ныгып калачак. Әйтик, алда саналган мисаллар арасында беренче урында күрсәтелгән сүзләрнең активрак кулланылуы күзәтелә.

## 1.8. Бүлек буенча нәтиҗәләр

Үзгәртеп кору елларыннан башланып киткән милли үзаңның көчәюе татар теленең үз җирлегендә үсү процессын тизләтте. Бу үзгәрешләр түбәндәге юнәлешләрдә барды:

1. XX йөзнең 80 нче елларыннан соң татар теленең үз ресурслары нигезендә йөзләрчә яңа сүзләр барлыкка килде. Аларның бер өлеше җәмгыятьтәге үсеш-үзгәрешләргә бәйле рәвештә туган яңа төшенчәләрнең атамасы буларак, күпчелеге исә телдәге рус-европа алынмаларын алыштыру максатында ясалды.

2. Яңа сүзләр ясауда татар теле өчен хас барлык сүзьясалыш ысуллары да катнаша. Неологизмнарның зур өлеше — морфологик юл белән кушымчалар ялгап ясалган исемнәр (җиде дистәдән артык сүз). Иң продуктив сүз ясагыч кушымчалар булып ***-чы/-че*** (кертемче, нәкышче), ***-лык/-лек*** (эшкуарлык, кәсәбәчелек) кушымчалары кала, ***-даш/-дәш/-таш/-тәш*** (төркемдәш, рәистәш), ***-ман/-мән*** (сөйләрмән, көярмән), ***-ыш/-еш*** (йөгенеш, түнтәрелеш), ***-ар/-р*** (әйдәр, буйсыныр), ***-ма/-мә*** (нигезләмә, раслама), ***-ым/-ем*** (кертем, өчләм), ***-к*** (санак) кушымчалары белән ясалган неологизмнар да бар. Калькалаштырып ясалган сүзләрне исәпләмәгәндә, кушымчалау ысулы белән телнең үз җирлегендә башка сүз төркеменә караган берәмлекләр ясалмый диярлек.

3. Татар теле агглютинатив тел булу белән беррәттән аналитик тел булып та торганлыктан, яңа сүзләрнең шактый өлешен аналитик төзелешле сүзләр тәшкил итә. Аеруча парлы сүзләр күп ясала, аларның күпчелеге алынма сүзне татарчасы белән парлап куллanудан гыйбарәт (булавка-каптырма, эшкуар-бизнесмен, шигарь-өндәмә — сөйләм дәрәҗәсендәге берәмлекләр), ике татар сүзен тезүле бәйләнешкә кертеп ясалган һәм алынма сүзләр урынына кулланылучылары да бар (баш-сын, биләмә-урын, төбәк-почмак). Берсе икенчесенең мәгънәсен конкретлаштырып, аныклап килүче компонентлардан торган сызыкча аша язылучы сүзләр — аныклаулы атамалар арасында да яңа ясалганнары кырыктан артык (бәйге-тамаша, рәссам-сынчы, мәктәп-гимназия). Соңгы елларда ясалган саф кушма сүзләр исә өч дистә (алтакта, илбаш, куларкадаш). Телнең үз материалы нигезендә тезмә (бүләк иясе, сәүдә бәясе, тәкъдим итү тантанасы) һәм кыскартылма сүзләр дә (БТК, ТИҮ, ХТЯБ) барлыкка килде.

4. Лексик-семантик һәм конверсия ысуллары белән яңа сүз ясалу — озак вакыт таләп итә торган процесс. Шулай да соңгы елларда берничә сыйфатның исемгә, исем фигыльнең исемгә күчүе күзәтелде (караучысыз, килешү, олпат). Телдә күптән кулланылып килгән аерым сүзләрнең соңгы елларда чорга бәйле рәвештә туган яңа мәгънәләре дә гомоген омонимнар буларак кабул ителә ала. Гомумән, өйрәнелгән чорда тормыштагы яңа күренешләрне атау яисә рус теленнән кергән алынмаларны алыштыру максатыннан утызлап татар сүзе яңа мәгънә яки мәгънә төсмере белән баеды (берлек, бистә, култамга).

5. Телне «татарчалаштыру» тенденциясе йогынтысында соңгы елларда бик күп рус алынмалары татар теленең грамматик законнары һәм сүзьясалыш модельләре буенча калькалаштырылды. Бүген матбугатта калькаларның барлык төрләре дә күзәтелә. Россия белән бер үк мохиттә яшәгәнлектән, чорга бәйле яңа төшенчә атамасы булган кайбер берәмлекләрнең калькамы, әллә тулысынча татар теленең үз җирлегендә рус теленә бәйсез рәвештә ясалганмы икәнен аеру да кыен, бу бигрәк тә кыскартылма сүзләргә карый.

6. Әдәби тел лексикасы төрле сүзлек катламнарының бер-берсенә актив тәэсир итүе нәтиҗәсендә дә шактый тулыланды. Кайбер гомумхалык сүзләре тормыштагы үзгәрешләргә бәйле иҗтимагый-сәяси терминнарга әйләнде (борылыш, торгынлык, тотрыксызлык), аерым гади сөйләм сүзләре газета-журнал лексикасына үтеп керде (алыпсатар, арадашчы), диалекталь сүзләрнең әдәби телгә йогынтысы да көчәйде (кимәл, төпкел, шәлкем).

7. Соңгы еллар татар әдәби теле лексикасының үз ресурслары исәбенә үсешендәге әһәмиятле тенденцияләрнең берсе буларак, совет чорында рус алынмалары тарафыннан пассив лексикага кысрыкланган бер катлам архаизм һәм тарихи сүзләрнең яңадан активлашуын күрсәтергә кирәк, аларның инде әдәби телдә ныклап урын алганнары гына да дистәдән артык (әбүнәче, баскын, җыен).

8. Татар теле җирлегендә ясалган окказиональ сүзләрне күп куллану — соңгы еллар татар матбугаты лексикасы өчен иң характерлы үзенчәлекләрнең берсе. Бу сүзләр арасында әдәби телдә урын алырдай, әһәмияткә лаеклылары да очрый (сынчыбагар, җәйлек өй, үзебезчәлек).

9. Гомумән, 80—90 нчы елларда татар теле лексикасы үз җирлегендә төрле юллар белән үсеш-үзгәреш кичерә, һәм бу процесс матбугат теле мисалында гаять ачык күренә.

# II БҮЛЕК

## СОҢГЫ ЧОР ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫНДА ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫ

### 2.1. Гарәп-фарсы алынмалары активлашуның сәбәпләре һәм алшартлары

Гарәп-фарсы алынмаларының активлашуы узган гасырның 80 нче һәм бигрәк тә 90 нчы еллар татар әдәби теле лексикасының иң характерлы үзенчәлеге дияргә була. Телебезгә ун гасыр (X—XIX) дәвамында дин, әдәбият аша, сәүдә, фәнни һәм мәдәни багланышлар нәтиҗәсендә өзлексез кереп торган гарәп-фарсы алынмаларының күбесе совет власте чорында әдәби телебездән акрынлап интернациональ, рус һәм яңа ясалган татар сүзләре белән алмаштырылган иде (89. 799 б.). Илдә демократик үзгәрешләр башлангач, халыкның милли үзаңы уянуга бәйле рәвештә бу процесс капма-каршы юнәлеш алды: интернационализмнар һәм рус алынмалары урынына яңадан гарәп-фарсы сүзләрен куллану белән мавыгу көчәйде. Профессор Р.А.Юсупов хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, «бу күренештә татарларның дистәләрчә еллар буена социализм, совет флагына яшеренеп, милләтләрне кысып килгән тоталитар Россия дәүләте бәйсезлегеннән котылып мөстәкыйльлек алырга теләге чагылыш таба» (184. 6 б.). Гарәп-фарсы алынмалары белән мавыгу XX йөз ахыры — XXI йөз башы татар әдәби теленең барлык функциональ стильләре өчен хас. Хәтта соңгы елларда чыккан кайбер фәнни-техник хезмәтләр, төгәл фәннәр буенча югары уку йорты дәреслекләрендә дә күп термин-атамалар гарәпләшкән. Әйтелгәнчә, бу алынмаларның күпчелеге рус сүзләрен һәм рус теле аша Европа телләреннән кергән интернациональ сүзләрне алыштыру өчен кулланыла: **вазгыять** — ситуация, положение, **вакыф** — фонд, **ватандар / ватанпәрвәр** — патриот, **вәзен** — ритм, **вәсика** — документ, **гаделия** — юстиция, **гаммә** — масса, **гамәлият** — производство, операция, **гаувас** — водолаз, **дәһри** — атеист, **иҗазатнамә** — диплом, аттестат, **зәнки** — негр, **икътисад** — экономика, **иттифак** — союз, **канун** — закон, **кафия** — рифма, **кәсәбә** — промысел, **кыйтга** — материк, **маддә** — статья, **матбага** — типография, **мәэмүр** — чиновник, **мәхкәмә** — суд, **мирасханә** — архив, **моназарә** — дискуссия, **мөддәт** — срок, **мөхбир-әгъза** — член-корреспондент, **мөһәндис** — инженер, **мөһаҗәрәт** — эмиграция, **мөһер** — печать, штамп, **мөштәри** — подписчик, **нәмаеш** — демонстрация, парад, **нәшир** — издатель, **низамнамә** — устав, **нотык** — речь, **өслүп** — стиль, **сәнәгать** — промышленность, индустрия, **сәрмая** — капитал, инвестиция, **солыхнамә** — (мирный) договор, **сәясәт** — политика, **тәрәккыят** — прогресс, **тәшкиләт** — структура, **тәхлил** — анализ, **фазә** — пространство, **фәтташ** — ревизор, инспектор, **һәйәт** — делегация, коллегия, **һиҗрәт** — эмиграция, **шартнамә** — договор, **шәкел** — форма, **шигарь** — лозунг, **ширкәт** — компания, предприятие, **шура** — совет һ.б.

Татар теленә кыскартылган формада кабул ителгән рус-европа чыгышлы сыйфатларны гарәп-фарсы чыгышлы сүзләр белән алыштыру да активлашты: **вәсикави** — документаль, **гамәли** — практик, **гаммәви** — массовый, **җисмани** — физик, **җәмгыяви** — социаль, **икътисади** — экономик, **инкыйлабый** — революцион, **мантыйкый** — логик, **нәзари** — теоретик, **сәнәгати** — индустриаль, **сәяси** — политик, **тәрәккый** — прогрессив, **һөнәри** — профессиональ, **шәхсән** — индивидуаль һ.б.

Билгеле булганча, алынмалар куллануның төп сәбәпләренең берсе — телдәге берничә сүздән торган атамаларны бер сүз белән алыштыру тенденциясе (150. 150 б.), ягъни телдә объектив яшәгән экономия, башкача әйткәндә, «минималь гамәл принцибы» (78. 250 б.) бер төшенчәне берничә сүзле тезмә белән белдерүгә караганда бер генә сүз белән бирүне өстен күрә. Соңгы елларда активлашкан гарәп-фарсы алынмаларының да шактые шул максатка хезмәт итә: **горбәт** — туган җирдән еракта, читтә йөрү, **гонҗә** — ачылып бетмәгән чәчәк, **иганә** — нәрсә дә булса эшләү өчен халыктан акчалата ярдәм, **инсаният** — кешелек дөньясы, **кабилият** — белү-төшенү сәләте, **кәсафәт** — нинди дә булса эшнең начар йогынтысы, нәтиҗәсе, **кәшеф** — фәнни ачыш, уйлап табу, **нәкъкаш** — уеп, төрле бизәкләр төшерүче, **сәргаскәр** — гаскәр башлыгы, **фигълият** — эшләнгән эшләр, **хадим** — берәр идеяне яки кемнең дә булса интересларын яклаучы, **хашия** — китап, хат һ.б. читендәге язу; **химая** — кемнең дә булса яклавы, саклавы карамагында булу; **шәрик** — берәр эшне бергәләп алып баручы, бергә укыган кеше һ.б. «Сүзнең беренче компонентында аталган төшенчәне сөюче» мәгънәсен белдерүче кушма сүзләр ясаучы ***-пәрвәр*** компонентлы исемнәр һәм ***-намә, -ханә*** компонентлы сүзләрнең кайберләре дә шушы төркемгә карый: **милләтпәрвәр** (милләтчедән аермалы буларак), **хөрриятпәрвәр, тәрәккыйпәрвәр**, **васыятьнамә** — васыять язылган кәгазь, **тәгъбирнамә** — төш юрау китабы, **фалнамә** — фал ачу (күрәзәлек) китабы, **дәресханә** — дәрес алып бару бүлмәсе, **каһвәханә** — кофе эчә торган бина һ.б.

Соңгы елларда активлашкан алынмаларның бер төре исә телдә булган сүзләрнең идеографик синонимнары буларак, ягъни төшенчәгә яңа мәгънә төсмере өстәп, конкретлаштыру максаты белән (74. 57 б.) кулланыла. Әйтик, **гаммә** — гомумән масса, «халык»ны түгел, ә «гади (кара) халык» төшенчәсен бирә; **җәсәд** — [үле] гәүдә, **нам** — [данлы, шөһрәтле] исем, **солыхнамә** — [тынычлык турында] килешү, **таифә** — [бериш җанияләре] төркеме һ.б.

Җәмгыятьнең демократияләнүеннән файдаланып, ислам диненең тиз арада җанланып китүе, дини әдәбият басылу, мөселман уку йортлары ачылу соңгы чорда дини терминологиянең кискен активлашуына китерде. Ә **мәдрәсә, шәкерт, ураза, имам** кебек күп кенә сүзләр архаизм, тарихи сүзләр исәбеннән актив лексикага күчтеләр.

Шунысын әйтергә кирәк: соңгы еллардагы иҗтимагый-мәдәни вазгыять үзе үк гарәп-фарсы алынмаларының активлашуы өчен уңай шартлар тудырды. Әйтик, яңа буын татар укучысы искергән гарәп-фарсы сүзләре белән Г.Тукай, Г.Ибраһимов кебек әдипләребезнең әсәрләре аша гына таныша алган булса, узган гасырның 80 нче елларыннан киң катлау татар укучысы Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдинов, Г.Гобәйдуллин кебек мәшһүр галимнәребезнең XIX йөз ахыры — XX йөз башы иске татар әдәби телендә язылган хезмәтләрен, Г.Исхакый, Ф.Кәрими һәм башка акланган әдипләребезнең әсәрләрен уку мөмкинлеген алды. Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Г.Кандалый һ.б. шагыйрьләребезнең шәрык сүзләрен мулдан кулланып язган әсәр-җыентыклары да шушы елларда яңадан дөнья күрде; Г.Акыш, Н.Дәүләт кебек рус теле йогынтысыннан азат татар телендә сөйләүче-язучы мәшһүр эмигрантларыбызга да трибуна бирелде. Матбугат органнары бу әдәби, тарихи ядкәрләребезнең телен халыкка аңлаешлы итү буенча әһәмиятле чаралар күрделәр: М.Мәхмүтов, К.Хәмзин, Г.Сәйфуллиннарның әтрафлы «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» яңадан басылды (1993), Җ.Зәйнуллинның җыйнак «Шәрык алынмалары сүзлеге» дөнья күрде (1994), кайбер газета-журналлар үз битләрендә махсус сүзлекчәләр бастырдылар (64; 188 һ.б.).

Телебездә шәрык алынмаларының активлашуына шулай ук Төркия дәүләте белән икътисади, мәдәни, сәяси бәйләнешләрнең ныгып-көчәеп китүе дә уңай тәэсир ясады. Республикабызның барлык зур шәһәрләрендә төрек лицейлары ачылды, татарча-төрекчә «Заман-Татарстан» газетасы чыга, фән һәм сәнгать эшлеклеләре, язучылар, хәтта алыпсатарлар да Төркиядә еш була, күпләр җәйге ял урыны итеп тә шушы илне сайлый. Болар барысы да кайбер төрек сүзләре белән беррәттән бу телдә актив кулланылышта сакланган гарәп-фарсы алынмаларын татар теленә кайтаруга уңай йогынты ясый. Кайбер алынмаларның нәкъ төрек телендәге формада яисә мәгънәдә активлашуы да моны раслый. Әйтик, **аләт** (җиһаз, прибор), **гамәлият** (операция), **вакыф** (фонд), **җәррах** (хирург), **хафта** (атналык, фестиваль) сүзләре бу мәгънә яисә формаларында аңлатмалы сүзлектә дә, алынмалар сүзлегендә дә теркәлмәгәннәр, ә төрек телендә алар шул рәвешле кулланышта (Тур.РС, 27, 31, 77, 163 б.). **Әҗнәби**, **дәкыйка**, **иттифак**, **каһвә** кебек сүзләрнең активлашуында, күп кенә ялгызлык исемнәрен шәрыкчә әйтү-язуда да төрек теленең йогынтысы бәхәссез.

1979 елда башланган Әфганстандагы вакыйгалар уңае белән рус теле аша да телебезгә **талибан, шурави** кебек яңа гарәп-фарсы сүзләре керде, ә **мөҗәһит** сүзе **шуравиның** (совет сугышчысы, агрессор) антонимы буларак яңа «Ватан бәйсезлеге өчен көрәшүче» мәгънәсендә активлашты.

Рус-европа сүзләреннән качарга омтылу күп кенә географик атамаларны, ялгызлык исемнәрен һәм башка кайбер сүзләрне искечә, ягъни гарәп телендәгечә куллануда да чагылыш тапты: **Алмания** (Германия), **алман** (немец), **Аурупа** (Европа), **Әлҗәзаир** (Алжир), **Фәләстин** (Палестина), **Дәһли** (Дели), **Тәһран** (Тегеран), **рум** (грек), **харита** (карта), **җәгърафия** (география), **фәйләсуф** (философ) һ.б.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: соңгы елларда яңадан активлашкан гарәп-фарсы алынмаларының күбесе телебезгә совет чорында үзләрен кысрыклаган рус-европа алынмалары урынына «кире кайта»; шулай ук алынмалар теориясендә билгеле сәбәпләр — сүзтезмәләрне бер сүзле атама белән алыштыру, төшенчәләрнең мәгънә төсмерен конкретлаштыру максатында актуальләштерелүчеләре дә байтак. Халыкның үзенең тарихи үткәне белән кызыксынуы көчәю, Октябрь революциясенә кадәрге татар әдәби телендә иҗат ителгән бай мирасыбызның киң катлам укучыларга кире кайтуы, Көнчыгыш дәүләтләр белән багланышларның ныгуы, ислам диненең яңарышы исә гарәп-фарсы сүзләренең әдәби тел лексикасында активлашуы өчен уңай шартлар тәэмин итте.

Соңгы чорда кулланылышка кергән гарәп-фарсы сүзләрен лексик-семантик яктан өч төркемгә бүлеп карарга була:

1) телебезгә X гасырдан башлап дин, сәүдә, әдәбият, мәдәният бәйләнешләре аша кереп татар әдәби телендә актив кулланылган, әмма XX йөз башында, аеруча 20—30 нчы еллардан соң пассив сүзлеккә күчкән һәм соңгы елларда яңадан активлаша башлаган сүзләр;

2) куллану даирәсен, стилен, ешлыгын үзгәрткән алынмалар;

3) гарәп-фарсы элементлары ярдәмендә татар теле җирлегендә яңа ясалган сүзләр.

Бу төркемнәрне аерым-аерым карап үтәбез.

**2.2. Яңадан активлашкан алынмаларның тематик төркемнәре**

Соңгы елларда активлашкан гарәп-фарсы алынмалары үзләре, ТТАСтә теркәлү-теркәлмәвенә карап, ике төркемгә бүленә:

А. XX йөз башыннан пассив сүзлеккә күчкән һәм 80 нче елларга кадәр татар әдәби телендә бөтенләй диярлек кулланылмаган сүзләр. Алар татар теленең аңлатмалы сүзлегендә теркәлмәгәннәр. Алга таба бу алынмаларны А группасы сүзләре дип атарбыз.

Ә. Совет чорында архаиклашып, соңгы елларда активлашкан сүзләр. Алар аңлатмалы сүзлектә «искергән», «борынгы», «тарихи сүз» билгеләре белән тамгаланганнар. Түбәндә китереләчәк тематик төркемчәләр эчендә алар Ә группасы алынмалары дип билгеләнә.

Гарәп телендә күпмәгънәле сүзләр, синонимия, омонимия киң таралган булганлыктан (89. 801 б.), сүзләрне тематик төркемчәләргә туплау җиңел эш түгел, бер үк сүз бер мәгънәсендә бер, икенчесендә башка төркемчәгә кararга мөмкин. Күпмәгънәлелек белән омонимия чикләрен билгеләгәндә дә кыенлыклар туа. Әйтик, гарәп теле сүзлекләрендә бер сүзнең мәгънәләре буларак теркәлгән кайбер берәмлекләр фарсы сүзлекләрендә омонимнар буларак бирелгән; мондый төрлелек татар теле һәм алынмалар сүзлекләрендә дә очрый. Шуңа түбәндә мәгънәнең төрле тематик төркемгә карау очраклары мөстәкыйль сүз буларак карала. Төркемчәләргә бүлү системасы Ш.Рамазанов классификациясенә нигезләнде. Ул үзенең «Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы» дигән мәкаләсендә татар әдәби телендә кулланылган гарәп сүзләренең җиде төркемен: 1) дини эчтәлекле сүзләр, дини терминнар; 2) уку-укыту эшләренә караган сүзләр; 3) фән һәм матбугат өлкәсенә караган сүзләр; 4) җәмгыять, дәүләт төзелеше, администрация һәм идарә эшләренә караган сүзләр; 5) кеше исемнәре, 6) ыруг, семья мөнәсәбәтләренә караган сүзләр; 7) бу тармакларның теге йә бусына гына карамаган сүзләр, фарсы алынмаларының өч төрен күрсәтә: 1) дини эчтәлекле сүзләр; 2) көнкүреш әйберләренең исемнәре; 3) кеше һәм көн исемнәре (113. 100—101 б.). М.И.Мәхмүтов та, татар телендәге гарәп-фарсы алынмаларына багышланган җитди хезмәтендә берникадәр төгәллек кертеп (төркем исемнәре конкретлаштырыла, хәрби һәм медицина терминнары аерып күрсәтелә), шушы ук классификацияне куллана (89. 798—799 б.). К.З.Сабиров, Ф.С.Сафиуллиналар татар лексикологиясе буенча дәреслекләрендә, бу классификацияне тагын да конкретлаштырып, әдәбият һәм мәдәният өлкәсенә караган, сәүдә һәм юл йөрү төшенчәләрен белдерүче, кешенең эчке һәм тышкы сыйфатларына, психологик кичерешләргә бәйле төшенчәләрне белдерүче, вакыт белдерүче, кыйммәтле ташларны белдерүче сүзләрне аерым төркемчәләр итеп күрсәтәләр (121. 43—44 б.; 127. 50 б.).

Соңгы елларда активлашкан гарәп-фарсы алынмаларын өйрәнү аларны тематик яктан 13 төп төркемгә бүлеп карарга мөмкинлек бирә. Лексик-грамматик яктан бу сүзләрнең зур күпчелеге исем сүз төркеменә карый. Шулай ук әйбер яки эш-хәрәкәт һәм билгенең билгесен белдерүче сүзләр (сыйфатлар һәм рәвешләр) дә шактый, алмашлыклар һәм ярдәмлек сүзләр дә бар. Без аларны, алда саналган хезмәтләрдән үзгә буларак, аерым төркемчәләргә туплап карыйбыз. Теркәлгән мисалларның кимүе тәртибендә санаганда, бу төркемчәләр түбәндәгеләр:

**1. Абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләр**

Хәзерге вакытлы матбугат телендә совет чорында кулланылыштан төшеп калган яисә пассивлашкан абстракт төшенчәләрне белдерүче күп кенә сүзләр кире кайту процессы кичерәләр.

А$_1$: **зарурият, зиһният, мәгънәвият, мәшгулият, миллият, рухият.**

***Зарурият*** *кенә түгел, мөһимият тә бар әле* (С-ә, 1994, № 4, 15 б. — зарурият — чарасызлык, котылгысызлык ... үтә кирәклелек — ГТРАС, 125 б.). *Йосыф-Зөләйхадагы* ***зиһният****, хиссият, әүлиялык күренми бу сүзләрдә* (М.җ., 1995, 24 февр. — зиһният — ... интеллект — АРС, 272 б.). *Яшәсен чын татар кызы, яшәсен* ***мәгънәвият!*** (С-ә, 1992, № 9, 25 б. — мәгънәвият — рухи халәт — ГТРАС, 294 б.). *Зарурият тә,* ***мәшгулият*** *тә, хаҗәт тә юк* (А-к, 1996, № 9, 12 б. — мәшгулият — эш белән мәшгуль булу, эшчәнлек — ГТРАС, 340 б.). ***Миллият*** *янә Мөхәммәдьяр яисә Тукайлар заманындагы төсле, иҗатның мөһим принцибы буларак, әсәрләрнең кыйммәтен билгеләүче төп сыйфатка әверелде* (К.у., 1998, № 8, 156 б. — миллият — миллилек ... — ГТРАС, 260 б.). *Нишләмәк кирәк, чын милли* ***рухиятка*** *үзебез дә кереп кенә барабыз бит әле* (С-ә, 1993, № 12, 3 б. — рухият — рухи халәт — АРС, 319 б.).

Ә: **бәян, вазгыять, вөҗүд, гамил, ганганә, гаргарә, гафләт, горбәт, горуһ/груһ, дәкыйка, җәһел/җәһаләт, зәвал, зольмәт, иҗтиһат, инсаният, истирахәт, ихсан, кабилият, кәррә, кыйсем, кыйтга, мантыйк, мәҗбүрият, мәнфәгать, моназара, мөддәт, нам, нәҗасәт, нәҗат, ригая, сафа, сәнә, сәгадәт, сөаль, тәшвиш, тәэссорат, фазыйләт, фал, фәһем, фигълият, хилаф, хиссият, хосус, шан, шәкел, шәүкәт, шәхсият**.

*Әмма кешелек өчен мондый каршы куюлар юлы түгел, ә берсен-берсе күтәрә торган кодрәтле, гамьле* ***бәяннар*** *кирәк* (С-ә, 1996, № 1, 16 б. — бәян — *иск. кит.* Аңлатма — ТТАС, I, 212 б.). *Иелгән башны да кылыч кисә дип аңларга кирәк моны, дигән нәтиҗәгә килгән журналист республикадагы* ***вазгыятькә*** *анализ ясаганнан соң* (В. Т., 2006, 15 сент. — вазгыять — *иск. кит.* Торыш, халәт, хәл —

ТТАС, I, 49 б.). *Бу мизгелдә аның күзләре мут очкыннар чәчеп кысыла, иреннәр сөйкемле бөрешеп килә, бөтен* ***вөҗүдennән*** *дәрт ташып тора иде* (И-л, 1995, № 12, 32 б. — вөҗүд — *иск.кит.* 1. Яшәеш ... — I, 249 б.). *Бу* ***гамил*** *аеруча мөһим* (И-л, 1995, № 8, 3 б. — гамил — *иск. кит.* ... Нигез фактор, сәбәп — I, 258 б.). *Зәкия Туишева исә ирешелгәннәрне —* ***ганганәләрне*** *(традиция) дәвам итеп, классикага йөз тоту чоры* (А-к, 1995, № 8, 113 б. — ганганә — *иск.* Традиция — I, 259 б.). ***Гаргарә*** *мизгелләрендә дә хәтер коточкыч көннәргә юл табачак* (И-л, 1995, № 5, 19 б. — гаргарә — *иск. кит.* ... соңгы сулыш // *күч.* Үләр вакыт ... — ТТАС, I, 259 б.). *Милләтебезнең, бигрәк тә яшь буынның күзенннән* ***гафләт*** *элпәсен салдыру юлында армый-талмый хезмәт иттеләр* (К.у., 1994, № 10, 145 б. — гафләт — *иск. кит.* 1. ... игътибарсызлык, ваемсызлык ... — I, 262 б.). *Алар* ***горбәттә*** *татарның күзе, колагы, туган милләтнең җан авазы булып кала* (К.у., 1995, № 3, 147 б. — горбәт — *иск.* Ил гизеп, туган җирдән еракта, читтә каңгырып йөрү — I, 254 б.). *Киләчәкнең варисларын тагын мәйдан җыя бүген* ***горуһ-горуһ*** (Т.я., 1995, 6 дек. — горуһ / груһ — *иск.* Төркем, өер — ТТАС, I, 279 б.). *Егет берничә* ***дәкыйка*** *вакытка аңын да югалтып алды* (М-т, 1995, 21 окт. — дәкыйка — *иск. кит.* ... мизгел, минут — I, 318 б.). *... авыл, бистә атамаларын бирүдә череп аккан принципсызлык, наданлык,* ***җәһаләт*** *күзгә ташлана* (А-к, 1996, № 5—6, 20 б. — җәһел / җәһаләт — *иск.* Наданлык, аң-белемсезлек — III, 813 б.). *Татар теленә хәзер* ***зәвал*** *юк* (Ш.Ч., 1994, 17 май — зәвал — *иск. кит.* 1. Бетү, югалу ... — I, 352 б.). *Тагын көн туачакмы-юкмы — бу* ***зольмәттә*** *әйтүе кыен иде* (И-л, 1995, № 5, 10 б. — зольмәт — *иск. к.* Караңгылык — I, 348 б.). *Гүя бабамнарның горур рухы миңа: тор, уян,* ***иҗтиһат*** *итәргә вакыт, елар көннәр түгел, ди кебек иде* (В.Т., 1995, 27 май — иҗтиһат — *иск. кит.* Тырышлык — I, 446 б.). ***Инсаният*** *һаман төннәр кичеп, таңнарына бара яктырып* (А-к, 1994, № 12, 178 б. — инсаният — *иск. кит.* Кешелек дөньясы, кешеләр — I, 395 б.). *Утырабыз* ***истирахәт*** *кичереп ачык верандада ...* (И-л, 1995, № 12, 41 б. — истирахәт — *иск. кит.* Ял, рәхәт — I, 425 б.). *Бу кадәр мәрхәмәт һәм* ***ихсаннар*** *күреп тә, сездән аерылу зур ялгышлык булыр* (И-л, 1995, № 3, 36 б. — ихсан — *иск. кит.* Кешегә эшләнгән изгелек, ярдәм, мәрхәмәт — I, 436 б.). *Иҗатындагы кимчелекләргә килсәк, ул аларны үзе күрәчәк — камилләшү өчен* ***кабилияте*** *җитәрлек* (К.у., 1992, № 4, 173 б. — кабилият — *иск. кит.* Сәләтлелек, булдыклылык, кулдан килү — II, 10 б.). *Минем күз яшьләрем аныкыннан мең* ***кәррә*** *әчерәк* (С-ә, 1996, № 4, 20 б. — кәррә — *иск.* Мәртәбә, тапкыр — II, 253 б.). *Шул сәбәптән хәзер Русиянең иң алдынгы бер* ***кыйсемен*** *тәшкил итәләр* (К.у., 1995, № 9, 89 б. — кыйсем — иск. ... Өлеш, кисәк, бүлем — II, 217 б.). *Ә шул ук вакытта илнең йә бер, йә икенче* ***кыйтгасында*** *кан коела ...* (Я-н, 1996, № 3, 11 б. — кыйтга — *иск.* 1. Өлеш, кисәк, бүлек. 2. Континент — II, 218 б.). *Һичбер* ***мантыйгы*** *булмаган бу сәер әңгәмә Хәлимне чыгырыннан чыгарды* (И-л, 1994, № 9, 23 б. — мантыйк — *иск. кит.* к. Логика — II, 424 б.). *Кыскасы,* ***мәҗбүрият*** *бездән әлеге эш белән даими шөгыльләнүне таләп итә* (М. ж., 2004, 23 июль — мәҗбүрият — *иск.кит.* к. Мәҗбүрилек — II, 424 б.). *Бездә хакимият* ***мәнфәгатьләре*** *халыкныкыннан бик күпкә өстенрәк куелган ...* (М. ж., 1996, 10 май — мәнфәгать — *иск.* Файда, игелек, интерес ... — II, 420 б.). *Аяк белән* ***моназара*** *кылу — акыл белән керү низагка* (А-к, 1996, № 7, 45 б. — моназара — *иск. кит.* Бәхәс, сүз көрәштерү, дискуссия ... — II, 402 б.). *Санаторийда булу* ***мөддәте*** *төгәлләнер алдыннан Габделбарый абыйның дүрт аяклы дустына булган илтифаты — кайгырту — тагын да арта төште* (К.у., 1995, № 6, 138 б. — мөддәт — *иск. кит.* Вакыт, срок, ара — II, 426 б.). *Исеме Татарстан булган, мөселман халкының* ***намын*** *йөрткән дәүләтебездә мондый «Святой источник» сатып чиркәү торгызу өчен акча җыю бу дәүләтне дә, бу халыкның үзен дә кимсетү түгелме?* (М.ж., 1997, 18 июль — нам — *иск.* Данлы, шанлы, яхшы ат ... — II, 433 б.). *Кайчандыр олуг акыл, зирәклек, бөеклек вә дан-шөһрәт сарайлары юынтык сулар —* ***нәҗасәт*** *түгү урыннарына әйләнгән* (А-к, 1991, № 1, 44 б. — нәҗасәт — *иск. кит.* Пычраклык, ... шакшы нәрсә — II, 455 б.). *Басу капкасы янына җыелган авылдашларның күз карашлары* ***нәҗат*** *өмете белән офыкка төбәлгән иде* (И-л, 1995, № 5, 9 б. — нәҗат — *иск. кит.* Котылу, исән калу — II, 455 б.). *Министрлар белән син* ***сафа*** *сөрдең* (А-к, 1995, № 10—11, 22 б. — сафа — *иск.* Рәхәтлек, ләззәт — II, 635 б.). *Ә хәзергә без, 1991* ***сәнәдә,*** *ярымтатар шәһәре Чаллыда, әгүзе бисмилланы әйтеп, журналыбызның фәлсәфә бүлегеn ачып җибәрдек* (А-к, 1992, № 5—6, 65 б. — сәнә — *иск.* Ел — II, 710 б.). *Ак калырга кирәк безгә, ак калырга, ауныймчы бер* ***сәгадәтнең*** *ак карында* (М.ж., 1996, 9 февр. — сәгадәт — *иск. кит.* бәхет — II, 707 б.). *Сезнең барчагызга да бер генә* ***сөаль*** *...* (Ш.К., 1994, 2 февр. — сөаль — *иск.* Сорау — II, 713 б.). *Һәм галәмнең шушы булмас карашлары астында күңелгә* ***тәшвиш*** *тә килеп куна* (М.ж., 1995, 29 дек. — тәшвиш — *иск.* Күңел тынычсызлыгы, шик-шөбһә ... — II, 234 б.). *Тик рәсем бер нәрсә, аның үзен күрү бөтенләй икенче* ***тәэссоратлар*** *тудыра икән* (М-т, 1994, 26 март — тәэссорат — *иск. кит.* ... Тойгылар, кичерешләр ... — III, 235 б.). *Бу язма рамазан аенда ураза тотуның* ***фазиләтләре*** *турында ...* (Нур, 1995, 31 гыйнв. — фазыйләт — *иск. кит.* ... Өстенлек, ... яхшы эш ... — III, 333 б.). *Табигать безне канат астына ала, ди ул. — Бу әйбәт* ***фал*** (И-л, 1995, № 6, 30 б. — фал. — *иск.* Күрәзәлек, [яхшыга] юрау — III, 335 б.). *Мин үзем, башлангыч татар классы укытучысы буларак, бу экскурсиядән зур* ***фәһем*** *— файда алдым* (С-й, 1995, 13 сент. — фәһем — *иск.* Акыл, зиһен // аңлау, төшенү — III, 358 б.). *Иңли алмастай* ***фигълиятен,*** *мөкатдәс омтылышларын барыбызга да затлы өлге итәсе иде* (К.у., 1994, № 10, 154 б. — фигълият — *иск. кит.* Эшләнгән эшләр — III, 341 б.).

*Халкыбызның күңеленә илаһи нур булып иңгән азатлык **хиссияте** сүнеп кара көлгә әверелмәсме ...* (С-ә, 1993, № 12, 1 б. — хиссият — *иск.* Хисләр — III, 369 б.). *Монда, өченче параграфның икенче өлешендә, телгә алынган **хосусларга** басым ясалмый үтеп китү мөмкин түгел дип ышанам* (А-к, 1992, № 11—12, 7 б. — хосус — *иск. кит.* Очрак, мөнәсәбәт — III, 372 б.). *Ата-бабаларыбыз тормышының **шанын** алып киләләр* (К.у., 1992, № 11, 45 б. — шан — *иск. кит.* Дан — III, 489 б.). *Шушы миссияне юл башыннан ук аңлатмаса, шагыйрь әлеге уй-гамәлен мондый **шәкелдә** ачып салыр идемени?* (В.Т., 1995, 20 гыйнв. — шәкел — *иск.* Форма ... — III, 533 б). *Әлбәттә, без сүз алып барган чорларда бу нәселнең **шәүкәте** инде нык зәгыйфьләнгән* (К.у., 1992, № 6, 157 б. — шәүкәт — *иск. кит.* 1. Көч, куәт. 2. Бөеклек, олылык даны — III, 537 б.). *Үзләре булып калырга, иҗади **шәхсият** тудырырга комачау иткәндер* (И-л, 1995, № 2, 74 б. — шәхсият — *иск.* Шәхси интереслар, үзе турында гына кайгыртучанлык ... [индивидуализм] — III, 537 б.).

**2. Билге белдерүче сүзләр**

Совет чорында кулланылыштан чыккан дистәләгән иҗтимагый-сәяси һәм фәнни сферага караган билге белдерүче сүзләр соңгы елларда күпләп яңадан кулланылышка керделәр. Аларның һәрберсе совет чорында интернациональ формага күчеп беткән була: **гаклый** — интеллектуаль, **гамәли** — практик, **зәүкый** — эстетик, **кадими** — архаик, **тәрәккый** — прогрессив, **хәбәри** — информацион һ.б. Хәзер, киресенчә, бу интернациональ сүзләрдән «качу» процессы күзәтелә.

Сыйфатлар

А: **гаклый, дәүләти, зәүкый, инсани, мәсләки, мәхкәм, мәхкүм, мигъмари, мөдһиш, сәнәгый, хәбәри, хәерхаһ, хисси**.

***Гаклый** (интеллектуаль) элитаның төп таянычы дин булырга тиеш* (И-л, 1996, № 1, 57 б. — гаклый — акылга бәйләнешле — ГТРАС, 71 б.). *Безне сәяси һәм **дәүләти** үзгәрешләр көтә* (Т.я., 1998, 12 сент. — дәүләти — дәүләткә бәйләнешле [правительственный] — ПРС, I, 682 б.). *Илшатның моңлы, йомшак тавыш белән моңлы-матур җыр башкаруы **зәүкый** ләззәт чишмәсеннән саф су эчү кебек гүзәл шәй булды* (М.җ., 1996, 6 март — зәүкый — эстетик — ГТРАС, 139 б.). *Үзбәк, казакъ, төркмән, кыргыз галимнәре дә татар **инсани** фәннәренә һәм аларның гыйльми үзәге — ТӘҺСИгә тирән хөрмәт белән карыйлар* (М.җ., 2006, 25 авг. — инсани — с. Кеше(гә), адәмгә бәйләнешле — ГТРАС, 162 б.). *Аларның рухы кыйбласызлыкка, **мәсләки** талымсызлыкка, әхлакый кануннар белән исәпләшми башлауга сәбәпче була* (М-т, 1995, 21 гыйнв. — мәсләки — принципиаль [идейный] — ПРС, II, 510 б.). *Ул мәрмәр таштан, бик **мәхкәм** сурәттә эшләнгән* (И-л, 1995, № 8, 38 б. — мәхкәм — таза, чыдамлы, нык; төгәл, анык — ГТРАС, 423 б.). *Тиз арада булачак гыйбадәт йортының **мигъмари** проекты сызымнары да әзерләнде* (З.-Т., 1994, 2 сент. — мигъмари — төзүчелек (кә караган) — ГТРАС, 258 б.). *Биредә кылт итеп **мөдһиш** Иванның 1552 елның 2 октяберендә Казанны алгач, таш өстендә таш калдырмавы искә килеп төшә* (К.у., 1994, № 2, 169 б. — мөдһиш — куркыныч, куркытырлык — ГТРАС, 360 б.). *Дөнья компьютерлары да латинда сөйләшә. Ә компьютер — **хәбәри** кыр* (Т.я., 1998, 27 гыйнв. — хәбәри — яңалык белдерүче, информацион — ПРС, I, 538 б.). ... *Татарстан китап нәшрияты җитәкчесе Дамир Шакиров язучыларга һәрвакыт **хәерхаһ** булырга тырыша ... (*В.Т., 2006, 3 нояб. — хәерхаһ — теләктәш ... — ГТРАС, 672 б.). *Шул сәбәпле **фикри** һәм **хисси** йөк алып килү ягыннан Сирин әсәрләре Г.Кутуйның «Сулф» остаханәсеннән чыккан шигырьләргә караганда отышлырак кабул ителә* (М.җ., 1996, 20 дек. — хисси — сизү(гә), тою(га караган) — ГТРАС, 660 б.).

Ә: **әгъла, әсасый, бакый, бәйнәлмиләл, бихисап, гайре, галиҗәнап, гамәли, гидай, җисмани, икътисади, инкыйлаби, кадим/кадими, кануни, лязим, мантыйкый, мәҗрух, мәзлум, мәсъүл, монафикъ, мөбәрәк, мәэюс, нәзари, сәмави, сәяси, тәрәккый, фидаи, хали, хилаф**.

*Иң **әгъла** коньяклар шушында җитештерелә ...* (А-к, 1995, № 8, 11 б. — әгъла — *иск.* Бик яхшы, бик затлы, кыйммәтле — III, 114 б.). *Бөтен физикада, философиядә «материя» **әсасый** төшенчә* (К.у., 1988, № 9, 185 б. — әсасый — *иск. кит.* Төп, нигез — III, 686 б.). ***Бакый** да ул, түгелдер дә борынгы һәм яшь Казан* (В.Т., 1996, 19 июль — бакый — *иск.* Мәңгелек, мәңге яшәүче ... — I, 114 б.). *Һәм аларның зур күпчелеге Әфганстанда **бәйнәлмиләл** бурыч үтәп яки Ичкериядә конституцион тәртип урнаштырып абруй казанган кешеләр* (М.җ., 1995, 24 нояб. — бәйнәлмиләл — *иск.* Интернациональ — I, 206 б.). ... *Русиядә яшәүчеләр кеше хокукларын санга сукмауның докладта күрсәтелмәгән **бихисап** төрләрен көндәлек тормышта үз күзләре белән дә күреп белә* (М.җ., 2006, 27 окт. — бихисап — *иск.* Хисапсыз, исәпсез, чиксез күп — I, 171 б.). *Безгә моның өстәмә мәшәкатьтән **гайре** бер файдасы да юк* (Т-н, 1995, № 1—2, 9 б. — гайре — *иск.* Башка, бүтән — I, 255 б.). *Без бүген дә **галиҗәнап** татар китабын мәсхәрәли торган данлы традицияне бик лаеклы рәвештә дәвам итәбез әле* (М.җ., 1995, 1 дек. — галиҗәнап — *иск.* 1. Олы күңелле, олы хисле, мәрхәмәтле ... — I, 256 б.). *Укытучы сайлаган ысуллар укучыларның иҗади сәләтен үстерә, **гамәли** белемнәрен тирәнәйтә* (М-ф, 1996, № 5, 51 б. — гамәли — *иск. кит.* Тормышка нигезләнгән, практик — I, 259 б.). *Алар, үзләренә яшәү урыны таба алмыйча, төрле якларга сибелделәр, таралдылар, милләт буларак югалдылар, **гидай** халык булдылар*

(З.-Т., 1995, 24 нояб. — гидай — *иск.* Ярлы, фәкыйрь — I, 268 б.). *Болар урыс хакимиятенең безнең халкыбызны рухи һәм* ***җисмани*** *юк итүгә юнәлдерелгән сәясәтенә тугрылыклы булып калуын дәлилли* (М. ж., 1996, 6 март — җисмани — *иск. к.* Җисми — III, 782 б.). *Ник дисәң,* ***икътисади*** *мөнәсәбәтләрне күз уңына куеп, ул базар экономикасына, радикаль үзгәрешләргә юл ачарга теләгәндер* (С-ә, 1991, № 1, 4 б. — икътисади — *иск.* Экономик — I, 376 б.). *Шулай икән, димәк, ул тормышны* ***инкыйлаби*** *үсештә сурәтли, аның герое коммунизм төзүче уңай каһарман була ...* (К.у., 1996, № 2, 181 б. — инкыйлаби — *иск. кит.* к. Революцион — I, 395 б.). *Абыйсы да, җиңгәсе дә бик коры,* ***кадим*** *кешеләр* (К.у., 1999, № 10, 15 б. — кадим — *с. иск. кит.* Прогресска дошман, искелекне яклаучы — II, 17 б.). *Бездә китап бастырып чыгару эшенә үтә дә* ***кадими*** *караш яшәп килә әле* (М.ж., 1995, 1 дек. — кадими — *иск.* Борынгы, әллә кайчангы — II, 18 б.). *Димәк, андый «хакимият органнары» арасында төзелгән килешүләр, низамнамәләр үз вазифалары даирәсендә чикләнгән күләмдә генә* ***кануни*** *көчкә ия булачак* (Ш.К., 1994, 5 апр. — кануни — *иск. кит.* Канунга бәйләнешле, канунга әйләнгән [законлы] — II, 42 б.). *Сибгат Хәким әйтмешли, бер-беребезгә төрткәләп тору* ***лязим*** *шөгыль* (В.Т., 1995, 28 апр. — лязим — *иск.* Кирәкле, тиешле, зарур — II, 328 б.). *«Милли төсмерсезлек» идеясе* ***мантыйкый*** *яктан Жириновскийның «автономияләрне ябу» ... мәсләгенә бара да тоташа* (Ш.К., 1994, 14 июнь — мантыйкый — *иск. к.* Логикалы — II, 366 б.). ***Мәҗрухлар****, моңлылар иде алар* (К.у., 1994, № 12, 35 б. — мәҗрух — *иск. кит*. Яралы, җәрәхәтле — II, 425 б.). *Революция* ***мәзлум*** *халыкларга хөррият китерер дип өметләнә* (К.у., 1995, № 6, 165 б. — мәзлум / мазлум — *иск.* Изелгән, җәберләнгән, кимсетелгән — II, 356 б.). *Икенче көнне иртән үк кырый урамга баруны* ***мәсъүл*** *санадык* (А-к, 1994, № 6, 81 б. — мәсъүл — *иск. кит.* 1. Соралган. 2. Җаваплы — II, 422 б.). *Мондый күзләр гадәттә рухи яктан бик бай булмаган, вакчыл ... , үз-үзен яратучы һәм* ***монафикъ*** *кешеләрдә очрый* (С-ә, 1992, № 7, 7 б. — монафикъ — *иск.* Икейөзле, усал, эчкерле — II, 402 б.). *Татар мәдәнияте әһелләренең бар булган хәзинәсен Мәскәүгә алып барып күрсәтү миңа бик* ***мөбарәк****, бәрәкәтле хасият рәвешендә тоела* (В. Т., 1995, 27 май — мөбарәк — *иск. кит*. Кадерле, хөрмәтле — II, 425 б.). ***Нәзари*** *яктан караганда бу төшенчә тиешле дәлилләнгән — исбатланганмы?* (Ш. К., 1994, 11 июнь — нәзари — *иск. кит.* к. Теоретик — II, 432 б.). *Ходай тылсымыннан яратылган* ***сәмави*** *тавышың белән уят газиз җаннарны!* (И-л, 1995, № 2, 2 б. — сәмави — *иск. кит.* 1. Күктән иңә торган. 2. *куч.* Абстракт, хыялый ... — II, 709 б.). *Җәмгыять үсешенең хәзерге этабында, миңа калса, игътибар үзгендә* ***сәяси*** *мәсьәләләр белән бергә экономиканы савыктыру торырга тиеш* (С-ә, 1991, № 1, 2 б. — сәяси — *иск. к.* Политик — II, 712 б.). ***Тәрәккый*** *дөньяда мәгълүмат чараларын дүртенче хакимият дип йөртәләр* (Т.я., 1993, 2 дек. — тәрәккый — *иск. кит. ... // с. мәгъ.* Алга киткән, үскән, камилләшкән — III, 229 б.). ***Фидаи*** *җанлы шагыйрьләр кулына чәчәк бәйләмнәре яуды* (Ш.Ч., 1995, 1 июнь — фидаи — *иск. к.* Фидакарь [үзен-үзе аямаучы] — III, 342 б.). *Гадел булыйк, урыс халкы да куркудан* ***хали*** *түгел* (К.у., 1993, № 10, 125 б. — хали — *иск. кит.* (Нәрсәдән дә булса азат, мәхрүм, буш — III, 361 б.). ***Хилаф*** *эше өчен ул адәм баласына үч итә, аны тез чүктерә* (А-к, 1993, № 9, 91 б. — хилаф — *иск.* Ярамый торган, каршы, кире — III, 367 б.).

Рәвешләр

А: **җисмән, тәкълидән, тәхминән, хәрфи / хәрфәи, һәмишә.**

*Бәхетебез, чын әдипләрнең гомере алар* ***җисмән*** *яшәүдән туктау белән өзелми* (М.ж., 1996, 6 дек. — җисмән — гәүдә ягыннан, гәүдә буларак — ГТРАС, 768 б.). ***Тәхминән*** *сигез көнлек расходыма җитәрлек акча булды* (Т.я., 1996, 20 февр. — тәхминән — чама белән, ... якынча — ГТРАС, 603 б.). *Бу сүзләрне* ***хәрфәи*** *аңларга кирәкми* (К.у., 1992, № 10, 180 б. — хәрфи / хәрфәи — ... 2. Хәрефкә-хәреф [буквально] — ГТРАС, 683 б.). *«Ялкын» журналында саннан-санга Разил абыйлары тәрҗемә иткән төрле халык әкиятләрен укып, балалар* ***һәмишә*** *сөенә* (К.у., 2007, № 1, 149 б. — һәмишә — *иск.* Һаман — III, 825 б.).

Ә: **биниһая, бихәбәр, бихисап, биһуш, галибанә, дустанә, маһиранә, мотлак, нисбәтән, һәрдаим, шәхсән**.

*Урманче* ***биниһая*** *мәгърур иде бит* (К.у., 1991, № 2, 165 б. — биниһая — *иск.* Чиксез, очсыз-кырыйсыз, бик күп — I, 165 б.). *Үлгәннәргә кабат җан өрерлек илаһи куәткә ия булучылар хакында хәтта диннәрдән* ***бихәбәр*** *әдәби затларга да мәгълүмдер* (К.у., 1993, № 2, 54 б. — бихәбәр — *иск.* Хәбәрсез, хәбәрдар булмаган, мәгълүматсыз ... — I, 171 б.). *Әйе, ялгызлар —* ***бихисап****, димәк, шулкадәр кайгылы, зарлы-моңлы кешеләр бар* (А.х., 1990, № 12, 7 б. — бихисап — *иск.* Хисапсыз, исәпсез, чиксез күп — I, 171 б.). *Иманга оеган мөритләр шикелле* ***биһуш*** *булып, сокланып һәм илһамланып торалар иде* (В.Т., 1995, 17 март — биһуш — *иск.* Һушсыз — I, 172 б.). *Яшь чак, ни дисәң дә, кеше тормышының* ***галибанә*** *яктырткан ал таңы ... , рухи көч формалашкан чак* (Ш. Ч., 1996, 7 март — галибанә — *иск. ...* Эреләнеп, тәкәббер генә, үзен югары тоеп — I, 256 б.). *Бер-береңә хөрмәт белән карап, тынычлык-иминлек саклап* ***дустанә*** *гомер кичерергә тиешбез* (М-т, 1994, 26 февр. — дустанә — *иск. кит*. Дусларча — I, 315 б.). *Мандолинада* ***маһиранә*** *уйнаучы Исмәгыйль Һилалов кебек мәшһүр музыкантлар белән аралашып үтте көннәрем* (К.у., 1992, № 12, 129 б. — маһиранә — *иск. кит.*

Осталык белән, осталарча — II, 377 б.). *Госманлы дәүләте үз эчендә «төркичәлек», «ислам» сәясәте уздырганча, тышкы сәясәтендә дә «пантюркист», «панисламчы» булуның* ***мотлак*** *ихтыяҗы юк* (К.у., 1992, № 11, 158 б. — мотлак — *иск.* Һичшиксез, абсолют рәвештә, һичсүзсез — II, 406 б.). *Ханбикәнең башыннан узган вакыйгаларга* ***нисбәтән*** *кушымталар да үзгәреп, аларга үзләренә хас бер драматик бизәк өстәлә* (С-ә, 1991, № 1, 19 б. — нисбәтән — *иск.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса бәйләнешле рәвештә ... — II, 444 б.). *Шуңа күрә ирем дә, улым да минем хезмәтемне аңлыйлар, бәяли беләләр һәм* ***һәрдаим*** *ярдәм итәләр* (Ш.Ч., 1995, 16 нояб. — һәрдаим — *иск.* Һәрвакыт — III, 825 б.). *Компьютер исә һәр укучының мөстәкыйль эшләвенә, аңа* ***шәхсән*** *(индивидуаль) якын килергә мөмкинлек бирә* (М-ф, 1994, № 2, 13 б. — шәхсән — *иск.* Шәхес буларак үзе, индивидуаль — III, 537 б.).

**3. Иҗтимагый-сәяси тормышка бәйле алынмалар**

Матбугат күбрәк иҗтимагый-сәяси тормышны яктырта. 1905 елгы революция нәтиҗәсендә барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси төшенчәләр матбугатта күпчелек очракта гарәп-фарсы атамалары белән бирелгәннәр (2). 20 нче еллардан башлап гарәп-фарсы алынмалары урынына рус һәм Европа алынмалары кулланыла башлаган. XX гасырның 80—90 нчы елларында бу процесс үзгәрә һәм рус-европа алынмалары урынына иҗтимагый-сәяси төшенчәләр яңадан гарәп-фарсы алынмалары ярдәмендә белдерелә башлый.

А: **гаделия, гамәлият, инкыйраз, мәрасим, мохтарият, мөһаҗәрәт, тәшкилат, фәгалият, хәйрия, һәйәт**.

*Чөнки* ***гаделия*** *кануннары гадәттә кешеләр арасындагы көн саен үзгәреп торган мөнәсәбәтләрне җайлау — тәртипкә салуны максат итеп куялар* (М-т, 1995, 7 гыйнв. — гаделия — юстиция — ГТРАС, 64 б.). *«Вафа»* ***гамәлият*** *предприятиесе генераль директоры ...* (В. Т., 1995, 30 май — гамәлият — производство, операция, процесс — АРС, 542 б.). *Татар театрының түгәрәк юбилеен бәйрәм иттек итүен, 100 елдан театрларда* ***инкыйраз*** *башланмагае әле* (В. Т., 2007, 30 июнь — инкыйраз — 1. Бетү, юкка чыгу ... 2. Регресс — ГТРАС, 162 б.). *Узган шимбәдә «КамАЗ» фәнни-техник үзәгендә Париж-Дакар марафонында катнашачак «КамАЗ»ларны һәм аларның экипажын тәкъдим итү* ***мәрасиме*** *булды* (Нур, 1995, 19 дек. — мәрасим — 1. Рәсмиләшкән гадәтләр, йолалар [церемония] — ГТРАС, 319 б.). *Бүген милли-мәдәни* ***мохтариятьләр*** *федераль кануннарга нигезләнеп эшли, һәм аларның кайбер программаларына җирле бюджетлардан күпмедер дәрәҗәдә акча бирелә* (М. ж., 2004, 24 дек.— мохтарият — ... 2. Бәйсезлек, идарә үз ихтыярында булучылык [автономия] — ГТРАС, 282 б.). *Бу эшчәнлек аркасында Ерак Шәрекътәге* ***мөһаҗәрәт*** *дини-милли үзенчәлеген саклап калуда кимчелек күрсәтмәде* (К.у., 1992, № 5, 140 б. — мөһаҗәрәт — үз илен ташлап читкә күчеп китү [эмиграция] — ГТРАС, 436 б.). *Бүгенге көндә исә Нәфыйков дөньяның төрле почмакларында яшәүче татар рәссамнарын милли* ***тәшкиләткә*** *туплау, аларның иҗатын өйрәнү, күргәзмәләр оештыру дәрте белән яна* (К.у., 1993, № 1, 171 б. — тәшкилат — оешма — АРС, 413 б.). *Бу кунакчыллык кагыйдәләрен бозу, рәхмәт әйтәсе урында ярдәмчене тәнкыйтьләү кебегрәк бер* ***фәгалиять*** *булыр иде* (Т. я., 1995, 6 апр. — фәгалиять — эшлеклелек ... , эшчәнлелек, эшчәнлек — ГТРАС, 632 б.). *Шул рәвешле аларга ярты миллиард сумлык* ***хәйрия*** *акчасы кергән* (С-ә, 1996, № 8, 33 б. — хәйрия — яхшылык, изгелек, хәерлелек [благотворительность] — ГТРАС, 674 б.). Махсус Хәйрия елы дип игълан ителгәнлектән, бу сүз 2007 ел матбугатында аеруча актив кулланылды: *Халыкның тәрәккыятенә куәт өстәрдәй* ***хәйрия*** *үрнәкләре халыкның үзенә күренеп, ишетелеп торсын* (В.Т., 2007, 19 гыйнв.). *Башка бәйсез төрки дәүләтләрнең вәкилләре дә шактый күләмле, хөкүмәтләре тарафыннан тупланган* ***һәйәтләрдән*** *(делегацияләр) гыйбарәт иде* (И-л, 1996, № 7, 40 б. — һәйәт — ... 3. Комиссия, комитет, коллегия, миссия, делегация — ГТРАС, 786).

Ә: 1) гомуми һәм соңгы еллардагы иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләргә бәйле сүзләр: **әләм, вилаять, җиһад, җөмһүрият, иганә, икътисад, инкыйлаб, ислах, иттифак, кәсәбә, мәзһәб, мәмләкәт, мәкам, мөнбәр, нәмаеш, пайтәхет, сәнәга / сәнәгать, сәрмая, сәясәт, тәрәккыят, хакимият, химая, хөррият, һиҗрәт, шигарь**.

*Быел анда җөмһүриятебез* ***әләме*** *дә җилфердәячәк* (В.Т., 1993, 23 апр. — әләм — *иск. к.* Байрак — III, 682 б.). *Угылларның берсенә дә, урыслардагы кебек,* ***вилаять*** *бүлеп бирелми, аларны аздырмыйлар, үсендермиләр* (М-н, 2002, № 6, 195 б. — вилаять — *иск. кит.* Өлкә, губерния — I, 239 б.). *Ул көрәшә, ул* ***җиһад*** *игълан кыла ...* (А-к, 1995, № 10—11, 69 б. — җиһад — *иск.* Изге сугыш ... — III, 794 б.). *Аның олуг юбилее Татарстан* ***Җөмһүриятенең*** *Бәйсезлек турында Декларация кабул итүенең алты еллык бәйрәменә туры килүе белән икеләтә истәлекле* (К.у., 1996, № 8, 181 б. — җөмһүрият — *иск.* Республика — III, 815 б.). *Дини һәм милли идеалларга тугры калучы һәрбер эшмәкәр яки аерым кешеләр дә* ***иганәләре*** *белән булышлык итсеннәр иде* (Т.я., 1993, 8 июль — иганә — *иск.* ... 2. Халыктан акчалата ярдәм, булышлык — I, 357 б.). ***Икътисадны*** *түбәнгә сөйрәүче тискәре күренешләр бар* (Ш.К., 1994, 16 окт. — икътисад — *иск. кит. к.* Экономика — I, 377 б.). *Шушы сәүдәгәр аякка бастырган предприятие 1917 елгы* ***инкыйлабка*** *кадәр уңышлы гына эшләп килә* (М-н, 2006, № 6, 148 б.— инкыйлаб — *иск. кит.* Революция — I, 395 б.). *Соңгы ун елда ...* ***ислах*** *(реформа) хәрәкәте пәйда*

*булды* (И-л, 1995, № 6, 44 б. — ислах. — *иск. кит.* ... Реформа — I, 422 б.). *Бәлки, моннан соң коммунистлар белән **иттифак** (союз) төзегән кайбер милли оешмаларыбыз уйлана төшәр?* (Ш. Ч., 1997, 5 март — иттифак — *иск.кит.* 1. Берлек, берләшү, союз ... — I, 432 б.). *Үз эшләрен башлап җибәргән милләттәшләребез хәзер **кәсәбә**, эшмәкәрлек белән шөгыльләнә* (А-к, 1993, № 8, 118 б. — кәсәбә — *иск.* Промысел, предприятие — III, 830 б.). *Кешеләрнең бер тарихи язмыш белән бергә берләшкән тотрыксыз төркемнәре — түгәрәкләр, **мәзһәбләр** яшәп килә* (И-л, 1994, № 9, 44 б. — мәзһәб — *иск.* 1. Гыйлемдә, фәлсәфәдә, дөньяга караштa тоткан юл, юнәлеш — II, 417 б.). *Чит **мәмләкәтләрдән** ярдәм көтәбез* (С-ә, 1992, № 4, 20 б. — мәмләкәт — *иск.* Ил, дәүләт — II, 419 б.). *Татар теленең **мәкаме** (статусы) һич тә үзгәрмәгән икән* (И-л, 1995, № 5, 46 б. — мәкам — *иск. кит.* ... 2. Дәрәҗә, тоткан урын — II, 418 б.). *Биек **мөнбәрләрдән** аңа мәдхия яудыралар* (В.Т., 1995, 24 февр. — мөнбәр — *иск.* 2. Трибуна ... — II, 379 б.). ***Нәмаешларда** үз тавышыңны кызгынмыйча җырладың, сөйләдең* (М.җ., 1995, 13 окт. — нәмаеш — *иск.* Демонстрация, парад — II, 433 б.). *Париж — дөньядагы иң матур **пайтәхетләрнең** берсе* (А-к, 1996, № 1, 7 б. — пайтәхет — *иск.* Башкала — II, 494 б.). *Татарстан Республикасы **сәнәгате** тармаклары үсешен фаразлау* (В.Т., 2005, 30 дек.). *Әйтик, ни өчен нибары дүрт-биш ел эчендә Русиядә, Татарстанда **сәнәгать** тармагында җитештерү ике тапкыр кимеде, ә җиңел **сәнәгатьтә** 1990 елда җитештерелгән продукциянең биштән бер өлеше генә җитештерелә* (М.җ., 1996, 29 март — сәнәга / сәнәгать — *иск.* Промышленность, индустрия — III, 830 б.). *Бертуган Рәмиевләр ... үзләренең **сәрмаялары** белән хәрәкәтнең икътисади базасын тәэмин иттеләр* (Т-н, 1996, № 6, 30 б. — сәрмая — *иск.* Берәр нәрсәне башлап-корып җибәрү өчен билгеләнгән акча, төп капитал — II, 711 б.). *Шуңа күрә озак еллар буена рәсми **сәясәт** аны хуплады да* (С-ә, 1991, № 12, 13 б. — сәясәт — *иск.* Политика — II, 712 б.). *Әйдәгез, бергә-бергә милләтне **тәрәккыят** юлына бастыру юлларын эзлик* (М.җ., 1995, 1 сент. — тәрәккыят — *иск. кит.* Алга китеш, үсеш, прогресс — III, 230 б.). *Тәрәккый дөньяда мәгълүмат чараларын дүртенче **хакимият** дип йөртәләр* (Т.я., 1993, 2 дек. — хакимият — *иск. кит.* Власть, хөкүмәт, дәүләт идарәсе — III, 360 б.) *«Исламия» мәхәлләсенең Япониядәге күп кенә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең **химаясеннән** файдалануын да билгеләп үтәргә кирәк* (М-н, 2001, № 8, 121 б. — химая — *иск.* Кемнең дә булса яклавы, саклавы карамагында булу — III, 367 б.). ***Хөррият** өчен көрәшкән язучы алты елын төрмәдә яки сөргендә уздыру ачысын да татый* ... (С-ә, 1995, № 11, 20 б. — хөррият — *иск. кит.* Азатлык, ирек — III, 360 б.). *1954 елда исә тагын **һиҗрәт** дулкыннары башланды* (К.у., 1992, № 4, 95 б. — һиҗрәт — *иск.* ... 2. ... [эмиграция] — III, 822 б.). *Аннары бу сәясәт ... «интернационализм» **шигаре** астында дәвам иттерелде* (М.җ., 1996, 6 март). *Мине бары бер **шигарь** белән аркамнан этәрделәр: «Кыскартырга!» (*В.Т., 2005, 28 дек.— шигарь — *иск.* 1. Лозунг. 2. Максат — III, 504 б.);

2) «халык» төшенчәсен аңлатучы алынмалар: **гавам, гаммә, өммәт, таифә**.

*Очын очка ялгап яшәүче гавамны башлыча ипи, сөт, ярма, үсемлек мае белән генә туклануын да исәпкә алсаң, зур сан бу* (В.Т., 2007, 25 авг. — гавам — *иск.* Халык, халык массасы — I, 250 б.). *Болар бездә **гаммәнең** кыйммәтле җан азыгы — үзләшкән әсәрләре булганга, әлбәттә, шул вакытның тарихын тулы белү өчен бездә өйрәнелергә тиешләр* (К.у., 1993, № 11, 163 б. — гаммә — *иск. кит.* 1. Халык, масса, гади халык — I, 258 б.). *Рәсәй чыннан да төрле **өммәтләр** (этнослар) өчен уртак йорт булды* (М-т, 1995, 25 март — өммәт — *иск.* 1. ... Бер диндәге халык. 2. Милләт — III, 703 б.). *Иртәгесен эшкә килсәм, сизәм-күрәм: хатын-кыз **таифәсе** профессор Вахит Хаковны кыскан* (М-т, 1994, 26 февр. — таифә — *иск.* 1. Бериш җан ияләренең аерым төркеме ... — III, 17 б.);

3) күбрәк күчерелмә, ягъни ике дөнья, ике цивилизация мәгънәсендә кулланылучы **гареп, мәгърип, шәрык, мәшрикъ** сүзләрен дә бу төркемгә кертеп карарга була, гәрчә поэтик стильдә аларны төп мәгънәләрендә файдалану да очрый.

***Шәрык** һәм **гареп** дөньясындагы халык арасында киң таралган шифа серләрен тирәнрәк өйрәнергә, үзләштерергә керешә* (С-ә, 1993, № 4 — шәрык — 1. Көнчыгыш... — III, 535 б.; гареп — *иск.* Көнбатыш — I, 260 б.). *Күк гөмбәзен урталай бүлеп, **мәшрикътән мәгърипкәчә** космос пәрәвезе, Галәм картның ак өрфия билбавы — Киек Каз Юлы сузылган* ... (К.у., 1995, № 4, 32 б. — мәшрикъ — көнчыгыш — II, 423 б.; мәгърип — көнбатыш — II, 416 б.). **Кыйтга** сүзе дә алда саналганнарга якын мәгънәсендә активлашты: *Дөньяның төрле **кыйтгаларында** гомер итүче милләттәшләребезгә сезнең теләкләрегез нинди булыр?* (М-н, 2003, № 3, 123 б. — кыйтга — *и. иск.* ... 2. Җир шарының бер кисәге; континент ... — II, 218 б.).

#### 4. Вазифасы, һөнәре, характерлы сыйфаты буенча кеше атамалары

Хәзерге матбугатта алда күрсәтелгән сүзләрдән тыш кешеләрнең вазифасы, һөнәре, характерлы сыйфаты буенча атамалары да иске татар телендәгечә, ягъни гарәп-фарсы сүзләре белән алышына башлый. Хәтта татар теленең үз сүзләре була торып та, гарәп-фарсы сүзләрен кулланган очраклар бар: **инсан** (кеше), **мөгаллимә** (укытучы), **рәфика** (кәләш) һ.б.

А: **җәррах, мәйхур, мәэмүр, мигъмар, милләтпәрвәр, мөәррих, мөҗаһид, мөһаҗир, мөһәндис, нәкъкаш, рәфика, сәнгатькяр, сәйях, сәрдар, талибан, фәтташ, хөрриятпәрвәр, һәйкәлтараш, шурави**.

*Баш **җәррах** егетнең тәнен һәм канын хәмердән чистартты* (А-к, 1996, № 5—6, 99 б. — җәррах — хирург — АРС, 124 б.). ***Мәйхурлар** (алкоголиклар) еш кына чынбарлык белән һич бәйләнеше булмаган шәүләләр, өрәкләр күрә, тавышлар ишетә* (З.-Т., 1995, 22 дек. — мәйхур — эчкече — ГТРАС, 304 б.). *Соңгы вакыйгалар ... Рәсәйнең тук вә канәгать губерна **мәэмүрләре** катлавына әйләнеп баруын күрсәтә* (И-л, 1995, № 7, 37 б. — мәэмүр — ... 3. Чиновник — ГТРАС, 343 б.). *Язучысы, рәссамы, композиторы бар татар халкының, **мигъмары** (архитекторы) бар халкыбызның* (К.у., 1993, № 10, 142 б. — мигъмар — төзүче, архитектор — ГТРАС, 259 б.). *... шунда төпләнгән Җәмилә Низаметдин **милләтпәрвәр,** фидакарь зат икәнен беләбез* (М. җ., 2007, 27 апр.— милләтпәрвәр — *г.-ф.* 1. Үз милләтен сөюче, үз милләте файдасы өчен тырышучы [патриот]. 2. Милләтче — ГТРАС, 260 б.). ***Мөәррих** — хәтәр һөнәр* (И-л, 1996, № 3, 30 б. — мөәррих — тарихчы — ГТРАС, 431 б.). *Агрессорларны илдән куып чыгарганда, **мөҗаһидлар** бердәм булып тырыштылар, ә хәзер инде үзара көрәшәләр* (З.-Т., 1995, 27 окт. — мөҗаһид — 1. Тырышучы, дин өчен көрәшүче... — ГТРАС, 433 б.). *Союз таркалгач, үзе дә башсыз калган, ... Энергетика министрлыгы Татарстан качакларына, **мөһаҗирләренә** сазлыклары, ярык тагарак, җимерек дамбалары белән түләсенмени?* (А-к, 1992, № 3—4, 10 б. — мөһаҗир — ... башка җиргә күчүче, чит илгә күчеп баручы — ГТРАС, 435 б.). *Инглиз **мөһәндисләре** искиткеч зур казанышка ирешә* (Ш.Ч., 1997, 31 окт. — мөһәндис — инженер ... ГТРАС, 437 б.). *Иҗат мәйданына асыл сынчы, **нәкъкаш**-рәссамнар чыга тора икән* (С-ә, 1996, № 2, 34 б. — нәкъкаш — ... бизәкче, буяучы [гравер] — ГТРАС, 456 б.*). Гади генә кайры тун кигән Илбашы солтанатлы **рәфикасы** Сәкинә ханым һәм оныгы белән килгән* (С-ә, 1996, № 2, 11 б. — рәфика — ... 2. Кәләш, хатын ... — ГТРАС, 488 б.). *Бакый ага Урманче үзе исән чагында ук даһи **сәнгатькәр** диген лаеклы бәя алды* (В.Т., 1996, 27 нояб. — сангатькяр — *г.-ф.* Сәнгатьче ... — ГТРАС, 501 б.). *Сәнгатенә исә бернинди канатлы **сәйях** иңли алмаслык дәверләр, персонажлар тулды* (С-ә, 1992, № 3, 24 б. — сәйях — турист, сәяхәтче, илгизәр — ГТРАС, 517 б.). *... ул тагын **сәрдар** Александр Македонскийның көнчыгышта таралган икенче төрле исеме генә икән* (А-к, 1994, № 11, 15 б. — сәрдар — *ф.* Гаскәр башлыгы, командир — ГТРАС, 524 б). *Әфган **талибаннарына** эләккән Татарстан очучыларын әсирлектә исән яшәтеп, аннан качыру да Әмирлектәге дусларның булышлыгыннан башка эшләнмәде бит* (З.-Т., 1996, 6 дек. — талибан — беренчел мәгънәсе — «гыйлем эстәүчеләр» — АРС, 477 б.). *Ул килгәндә **фәтташ** басып тора иде инде* (К.у., 1995, № 3, 139 б. — фәтташ — тикшерүче, ревизор, инспектор, контролер — ГТРАС, 539 б.). ***Хөрриятпәрвәр** булу ягыннан Шакирҗан абыйсы аннан уздырып та җибәрде хәтта* (К.у., 1996, № 11, 20 б. — хөрриятпәрвәр — *г.-ф.* Иреклелек сөюче, иреклелек яклы — ГТРАС, 693 б.). *Язучысы, рәссамы, композиторы бар татар халкының ... **һәйкәлтарашы** (скульпторы) бар* (К.у., 1993, № 10, 142 б. — һәйкәлтараш — *г.-ф.* ... скульптор — ГТРАС, 786 б.). *... **«шурави»ларының** канлы образы әфганлыларның ничә буыны хәтерендә сакланыр!* (Нур, 1995, 19 гыйнв. — шурави — «совет кешесе» мәгънәсендә — РПС, 860 б.).

Ә: **әҗнәби, ватандар, гаувас, җасус, зәнки / зәнҗи, инсан, кятиб, мәхбүс, мөгаллим, мөгаллимә, сәргаскәр, сәркатип, хадим, хаким, хәким, хөкемдар, һөнәрмән / һөнәрмәнд, чәчтараш, шәрик, пәрвәр, ватанпәрвәр, тәрәккыйпәрвәр**.

*Шул кануннарны бүгенгәчә **әҗнәбиләр** кулланды* (К.у., 1993, № 3, 135 б. — әҗнәби — *иск.* 1. Чит, ят кеше. 2. Чит ил [кешесе] — III, 691 б.). *Кем соң ул Илдар Хаҗи? Артист. Режиссер. Оештыручы. **Ватандар*** (С-ә, 1996, № 5, 26 б. — ватандар — *иск.* Ватанчы, патриот — I, 233 б.). ***Гаувас** никадәр тирән сулышлы булмасын, инешкә генә чумса, ул аннан, җәүһәр табу түгел, үзе дә ләмгә-дуенга буялып чыгачак* (И-л, 1995, № 5, 48 б. — гаувас — *иск. кит.* Су төбенә чумучы, водолаз — I, 263 б.). *Аны **җасус** итеп, советлар НКВДсы Әфганстанга да юллый* (М. җ., 2006, 3 февр. — җасус — *иск.* Шымчы — III, 753 б.). *... **зәнкиләрне** маймыл дип кенә атыйлар* (И-л, 1995, № 11, 49 б. — зәнки / зәнҗи — *иск. кит.* Негр ... — I, 353 б). *Диңгез шаулый, төбе тулы корбан, нинди өмет яши **инсанда*** (К.у., 1991, № 5, 6 б. — инсан — *иск. кит.* Кеше — I, 395 б.). *Идарәдә дүрт кеше эшли — рәис-мөхтәсиб, ике мөшәвир, бер җаваплы **кятиб*** (А-к, 1993, № 12, 210 б. — кятиб — *иск. кит.* Секретарь ... — II, 70 б.). *Тиккә генә **мәхбүс** булмагандыр ...* (А-к, 1993, № 9, 26 б. — мәхбүс — *иск. кит. шигъ.* Тоткын — II, 422 б.). *Мин яшь **мөгаллим** белән таныштым* (С-й, 1996, 21 авг. — мөгаллим — *иск.* Укытучы — II, 425 б.). *Монысы инде укытучы, **мөгаллимә** бәхете* (С-ә, 1991, № 12, 24 б. — мөгаллимә — *иск.* Укытучы хатын-кыз — II, 426 б.). *Күзләрен кан баскан патша **сәргаскәрләре** тарафыннан ир-атларны бөтенләй кырып бетерергә әмер бирелә* (В.Т., 1992, 18 июль — сәргаскәр — *иск.* Гаскәр башлыгы — II, 711 б.). *Ике дәүләт телен дә камил белүче **сәркатипләр** әзерли торган бүлекләр ачылды* (М-ф, 1995, № 2, 41 б. — сәркатип — *иск. к.* Секретарь — II, 711 б.). *Сездәй милләт **хадимнәре** күбрәк булсын иде ...* (К.у., 1991, № 1, 165 б. — хадим — *иск. кит.* Хезмәтче, ялчы ... — III, 359 б.). *Татарстан Җөмһүриятенең баш канункүзе (прокуроры), баш **хакиме** (судьясы) ... — барысы да чит милләт вәкилләре!* (С-ә, 1991, № 12, 13 б.). *Кичә Илдар Шәфкатович Халиковның Чаллы шәһәре **хакиме** итеп*

*билгеләнүенә 4 ел тулды* (Ш.Ч., 2007, 15 авг.— хаким — 1. *иск.* Судья, хөкем итүче. 2. Башлык ... — II, 360 б.). *Азатлык даулаучы Ичкериядә колониаль сугыш алып баручы Рәсәй* ***хөкемдарларының*** *дөньяның төрле төбәкләрендә «тынычлык урнаштыручы» битлеге киеп йөрергә маташуларыише мәгънәсезлеккә дә бик гаҗәпләнәм мин* (Т-н, 1996, № 9, 14 б. — хөкемдар — *иск. кит.* 1. ... ил башлыгы ... — III, 389 б.). *Төрле мәмләкәтләрнең сәнгатендә элек-электән фотографиягә якын ялтыравык рәсемнәр ясый белүче* ***һөнәрмәннәр*** *хәтсез күп булган* (В.Т., 1996, 27 нояб. — һөнәрмән / һөнәрмәнд — *иск.* 1. Һөнәрче. 2. *с. мәгъ.* ... оста ... — III, 827 б.). *Мәшһүр шагыйребез Такташ иркәләнер өчен* ***чәчтарашка*** *йөргән* ... (М. җ., 1995, 25 июль — чәчтараш — *иск.* Чәч алучы, парикмахер — III, 472 б.). *Унбиш-уналты яшьләреннән үк* ***шәрикләре*** *арасында узаман булып җитешкән* ... (Т-н, 1996, № 4, 6 б. — шәрик — *иск.* ... иптәш ... , классташ — III, 535 б.). *Каланың милли йөзен үзгәртүдә милли хәрәкәт* ***пәрвәрләре*** *дә ... зур өлеш кертте* (М. җ., 1996, 28 июнь — пәрвәр — *иск. кит.* Берәр нәрсәне, эшне сөюче, ... шуңа чын күңелдән бирелгән — II, 569 б.). *Бу җәһәттән җөмһүриятебезнең барлык милләтпәрвәр,* ***ватанпәрвәр*** *көчләре берләшергә тиеш* (Ш.Ч., 1997, 5 март — ватанпәрвәр — *иск.* Ватанчы, патриот — I, 233 б.). *Шушы* ***тәрәккыйпәрвәр*** *кеше гаиләсендә 1906 елда беренче бала булып Хәбиб дөньяга килә* (С-ә, 1993, № 7, 21 б. — тәрәккыйпәрвәр — *иск. кит.* ... прогрессны яклаучы, яңалыкны сөюче — III, 229 б.).

**5. Фән, мәгариф, әдәбият һәм мәдәният өлкәсенә караган сүзләр**

Татар теленең фәнни стиле формалашуда, аерым терминнар ясалуда гарәп, фарсы телләренең һәм ул телләрдән кергән алынмаларның роле зур булган (158. 156 б.). Совет чорында фәнни стиль күпмедер үсеш алса да, аның үрнәкләре, нигездә, русча языла башлый. Үзгәртеп кору башлангач, югары уку йорты өчен дәреслекләр, фәнни мәкаләләр татарча языла башлый һәм элеккеге фәнни стильгә кайтуга омтылыш туа. Шуңа күрә фән, әдәбият, мәдәният өлкәсендә гарәп-фарсы алынмалары арта бару процессы күзәтелә.

1) Гомумфәнни терминнар.

А: **гонсыр, кәшфият, тыйб**.

*Кайбер* ***гонсырлары*** *(элементлар) хәтта Ананьино мәдәниятендә дә бар* ... (И-л, 1996, № 3, 33 б. — гонсыр — 1. Элемент ... — ГТРАС, 95 б.). ***Кәшфият*** *буенча дөньяда бүген иң алга киткән ил — Япония* (А-к, 1994, № 8, 203 б. — кәшфият — уйлап табылган нәрсәләр, яңа барлыкка китерелгән гыйльми, фәнни һәм техник яңалыклар — ГТРАС, 229 б.). *Хәзер сатуга чыккан күп җимешләрнең сыйфаты турында безнең* ***тыйб*** *әдәбиятында мәгълүматлар юк* ... (З.-Т., 1997, 28 март — тыйб — медицина — ГТРАС, 549 б.).

Ә: **кәшеф, нәзария / нәзарият, фәлсәфә, һәндәсә**.

*Кул көче белән түгел, акыл көче белән фән эшкә җигелә, ачышлар, уйлап табу-****кәшефләр*** (А-к, 1994, № 8, 203 б. — кәшеф — *иск. кит.* Ачыш, уйлап табу — II, 255 б.). *Әдәбият* ***нәзариятенең*** *максаты — бу эш-гамәлне, андагы активлыкны, аның агенты булган Кешене аңлау* (М-т, 1996, 15 март — нәзария / нәзарият — *иск. кит.* Теория ... — II, 432 б.). *Ә бу үз чиратында ...* ***фәлсәфә****, тарих, хокук, әдәбият белеме һәм башка фәннәр буенча галимнәр үсеп чыгуга җирлек була* (С-ә, 1991, № 4, 21 б. — фәлсәфә — *иск.* 1. Философия... — III, 357 б.). *«Мәгариф» нәшрияты бастырган бу җитди хезмәтнең авторы — гамәли* ***һәндәсә*** *һәм инженерлык сызымы белгече* (М.җ., 1996, 19 апр. — һәндәсә — *иск.* Геометрия — III, 825 б.).

2) Әдәбият һәм тел белеме терминнары.

А: **хашия, мөтәшагыйрь**.

*Бу әсәрне галимнең урыс тарихын укыганда-өйрәнгәндә китап читләренә теркәп куйган уй-хисләре —* ***хашияләр*** *дип кабул итәргә була* (И-л, 1995, № 4, 45 б. — хашия — ... 2. Китап яки хат читендәге язма [сноска, комментарий] — ГТРАС, 654 б.). *Кайбер композиторларыбызны коммерсант* ***мөтәшагыйрьләр*** *сатып ала башлады* (Ш.К., 1994, 13 гыйнв. — мөтәшагыйрь — ялган шагыйрь, үзен-үзе шагыйрь санаучы — ГТРАС, 141 б.).

Ә: **вәзен, җилд, ләкаб, мәдех, мәҗмуга, мәүзугъ, өслүп, рисалә, тәкълид, тәхәллүс, хәтимә, гыйбарә, лөгать, нәхү, сарыф, шивә**.

*Яшь шагыйрьнең иректә шигырь, сөйләм шигыре дип* ***вәзен****-формага селтәнүен нык тәнкыйтьләп чыга* (А-к, 1995, № 10—11, 70 б. — вәзен — *әд. иск.* Шигырь үлчәве; ритм — I, 246 б.). *Аның ... 8* ***җилден*** *(томын) фольклор һәм язма әдәби үрнәкләр тупламы тәшкил итәчәк* (З.-Т., 1995, 6 окт. — җилд — *иск. к.* том — III, 766 б.). *Ул хәзер үзенә Гадел Низам дигән чын мөслими* ***ләкаб*** *алды* (И-л, 1994, № 10, 8 б. — ләкаб — *иск.* Кушамат [псевдоним] — II, 349 б.). *Ул шундый ук үзенең тантаналы* ***мәдех*** *шигыре белән тәбрикли* (М.җ., 1996, 23 май — мәдех — *иск.* Ода, мактау — II, 416 б.). ***Мәҗмуга*** *«Русия. XX гасыр. Документлар» программалары кысаларында «Демократия» фонды ярдәме белән нәшер ителгән* (М.җ., 2006, 3 февр.— мәҗмуга — *иск.кит.* Җыентык, сайланма әсәрләр — II, 425 б.). *Беренче карашка анда бер мәхәббәт тарихы гына тасвирлана кебек, әмма тел астында бөтенләй бүтән сүз, бүтән* ***мәүзугъ*** (К.у., 2007, № 1, 148 б.— мәүзугъ — *иск.* Тема — II, 274 б.). *Аның үзенә хас*

***өслүптә** иҗат ителгән хикәяләре ... культурабыз тарихында үзенә бер этап* (Т-н, 1993, № 3, 49 б. — өслүп — *иск. кит.* Стиль, сөйләү-язу рәвеше — III, 709 б). *Тик берзаман әдипнең кул астында үз **рисаләсе** ничектер булмаган, күрәсең* (Т-н, 1996, № 4, 10 б. — рисалә — *иск. кит.* Хикәя — II, 596 б.). ... *Тукайга **тәкълид** булса, тапшыру «Кузгатмакчы ... » дип башланырга тиеш иде* (Т. я., 1994, 8 дек. — тәкълид — *иск.* ... 2. Башка берәүнең иҗат методыннан файдалану, иярү — III, 214 б.). *Илгөлем — шагыйрәнең илһамлы сәгатьтә табылып кушылган **тәхәллүсе** (псевдонимы) ... (*В.Т., 2006, 15 сент.— тәхәллүс — *иск. кит.* Әдәби псевдоним — III, 234 б.). *Искә алынган кече жанрны тәшкил иткән әдәби ядкәрләр арасында китап **хәтимәләре** (ахырлары), төрле төрки догалар һ.б. бар* (К.у., 1994, № 3, 167 б. — хәтимә — *иск. кит.* Соңгы сүз, эпилог — III, 364 б.). *Мәскәү матбугатында хәзер безгә нык таныш булган **гыйбарәләр** очрый башлады* (В. Т., 2007, 2 март — гыйбарә — *иск.* ... 2. Сүз тезмәсе, әйтелмә ... — I, 280 б.). ***Лөгатьләр** төзүдә катнаша, ...* (Т-н, 1995, № 1—2, 39 б. — лөгать — *иск.* 1. Сүз, сөйләм. 2. Сүзлек — II, 352 б.). ***Нәху-сарыф** хаталары юк* (А.х., 1986, № 4, 10 б. — нәху — *иск. линг.* Синтаксис — II, 454б.; сарыф — *иск. линг.* Морфология — III, 633 б.). *Әмма хәзерге татар әдәби теле Себер татар **шивәсеннән** аерыла* (К.у., 1998, № 7, 133 б. — шивә — *иск.* Диалект, җирле сөйләм — III, 504 б.).

3) Уку-укыту өлкәсенә караган алынмалар.

А: **дарелфөнүн, көллият, тыйбабәт** (белгечлек атамасы буларак).

*Татар шәкертләре Мисыр, Сүрия, Төркия, Бохара һәм башка илләрдәге мәдрәсә, **дарелфөнүннәрендә** белем алган ...* (Я-н, 1995, № 1, 26 б. — дарелфөнүн — фәннәр йорты, университет — ГТРАС, 107 б.). *Хәзерге вакытта республикада 42 гимназия, 20 лицей, 6 **көллият** ... эксперименталь режимда эшлиләр* (М-ф, 1995, № 1, 3 б. — көллият — колледж — ШАС, 75 б.). ***Тыйбабәт** белгечлеге буенча уку срогы 8 ел һәм 6 ел* (Ш. К., 1994, 18 авг. — тыйбабәт — табиблык, врачлык (белгечлек атамасы) — ГТРАС, 549 б.).

Ә: **җәдвәл, инша, талибә, талип, тәгълим, тәгътил, шәкерт.**

*Авыл мәктәбенең элекке укытучысы Мостафа Галимов тапкырлау **җәдвәлен** дә күптән оныткан иде* (И-л, 1995, № 11, 66 б. — җәдвәл — *иск.* 1. Таблица. 2. Расписание ... — III, 803 б.). *Мин теге сумкаларның да эчендә диктант, **инша** дәфтәрләре булмаганлыгына төшендем* (А-к, 1992, № 5—6, 84 б. — инша — *иск.* ... 2. *пед.* ... изложение, сочинение ... — I, 401 б.). *Урыс һәм татар **талип** вә **талибәләре** нисбәте уртача 50 гә 50 процент туры килеп бара* (А-к, 1993, № 11, 19 б. — талип — *иск.* ... студент — III, 24 б.; талибә — *иск.* Укучы кыз, студентка — III, 23 б.). *Яшь буынга **тәгълим**-тәрбия бирүдә әлегә хәл ителмәгән мәсьәләләр гаять күп* (М-ф, 1994, № 7, 4 б. — тәгълим — *иск. кит.* Өйрәтү, укыту, дәрес бирү — III, 209 б.). *Инде менә кышкы **тәгътил**, ягъни каникул башлану сәбәпле, Сафиулла абзый Мөхәммәтзакирны алып кайтты* (Я-н, 1996, № 12, 13 б. — тәгътил — *иск. кит.* Каникул, ял — III, 533 б.). *Казан каласында укучы **шәкертләргә** дә кагыла бу* (М-т, 1995, 29 апр. — шәкерт — *иск.* Мәдрәсәдә укучы — III, 533 б.).

4) Матбугатка бәйле лексика.

Ә: **әбүнә, җәридә, матбага, мөхбир, мөштәри.**

*Бу санда 1997 елның икенче яртысы өчен әзерләнгән **әбүнә** кәгазе (абонемент үрнәге) тәкъдим итәбез* (К.у., 1997, № 4, 192 б. — әбүнә — *иск.* Абонемент — I, 2 б.). *Шуңа күрә гарәп язулы гәзит-**җәридә** чыгару тәкъдименә ризалык бирдем* (Ш. К., 1992, 6 сент. — җәридә — *иск.* Газета — III, 810 б.). *Мәскәү, Әстерхан, Оренбург **матбагалары** акрынлап ябылдылар* (З.-Т., 1994, 19 авг. — матбага — типография — II, 371 б.). *Атналык «Аң» журналы, көндәлек «Кояш» газетасы редакцияләре дә аңа үзләренең даими Истанбул **мөхбире** булып китүне тәкъдим иткәннәр* (А-к, 1992, № 3—4, 90 б. — мөхбир — *иск. кит.* Хәбәрче, корреспондент). *Кайбер **мөштәриләребез** өчен ул чыннан да күңелләргә моңсулык өсти торган соңгы сан* (Ш.К., 1994, 30 июнь — мөштәри — *иск.* Газета-журналларга язылучы — II, 429 б.).

### 6. Дини эчтәлекле сүзләр

Үзгәртеп кору елларында дингә караш үзгәрде, халкыбызга иман кайтты, яңадан мәчетләр ачыла башлады, дини китаплар киң кулланылышка керде. Шуның нәтиҗәсе буларак, матбугатта дини сүзләр активлашты. Түбәндә, нигездә, публицистик һәм поэтик стильләрдә башлыча күчерелмә мәгънәдә кулланылучы дингә бәйле сүзләр генә китерелә. Махсус дини әдәбиятта урын алган дини атамаларның саны исә күпкә артыграк.

А: **бәйтулла(һ), гөнаһкяр, имамәт, Коръән хафиз, мөтәвәллият, мөхтәсиб, мөхтәсибәт, саим, сәхабә, фәкыйх, фидая, һидаять, ширек.**

*Нәчәлникләр аша рәсми юл белән эш йөртә башласаң, атаклы йомры кунакханә көненә калуы да бар **бәйтулланың*** (А-к, 1994, № 4, 165 б. — бәйтулла(һ) — Алла йорты — ШАС, 18 б.). *Мин моны гөнаһның нинди нияттән кылынуы, **гөнаһкярнең** нинди кеше булына да бәйледер дип уйлыйм* (С-ә, 1995, № 4, 29 б. — гөнаһкяр — *ф.* 1. Гөнаһ эшләүче кеше — ГТРАС, 104 б.). *Шамил Веденода **имамәт** эшләре белән шөгыльләнеп, үзен күренекле дәүләт эшлеклесе итеп тә таныта* (А-к, 1996, № 8, 37 б. —

имамәт — имамлык, дини җитәкчелек ... — ГТРАС, 158 б.). *Коръәнне яттан укырга зиһеннәре җиткән **Коръән хафизлар** каны уйный бүген бездә* (А-к, 1992, № 5—6, 65 б. — Коръән хафиз — Коръәнне яттан белүче). *Барлык татар авылларында һәм шәһәрләрендә төзелгән мәчетләрдә, ... **мөтәвәллият** төзеп, аны район советында мөстәкыйль оешма итеп теркәүгә ирешергә* (С-ә, 1994, № 1, 33 б. — мөтәвәллият — мәчет идарәсе — АРС, 912 б.). *50 дән ким, 150 дән артык булмаган мәхәлләләрне караучы бу идарәдә дүрт кеше эшли — рәис-**мөхтәсиб**, ике мөшәвир, бер җаваплы кятиб* (А-к, 1993, № 12, 210 б. — мөхтәсиб — муллалардан өстен дин галиме — ГТРАС, 424 б.). *Без Татарстан Диния нәзарәте каршында төзелгән Апас районы дин әһелләренең **мөхтәсибәт** идарәсе әгъзалары* (С-ә, 1994, № 1, 33 б. — мөхтәсибәт — бер өлкә, шәһәр, район һ.б. дин әһелләрен берләштерүче оешма — ГТРАС, 424 б.). *Төннәрдә **саим** ди, көннәрдә сахир ди* (М-т, 1995, 25 март — саим — ураза тотучы — ГТРАС, 497 б.). *Эссе сахрада, ком чүлендә җәяүләп күп михнәтләр күреп, Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең **сәхабәләре** белән Мәдинәи Мөнәвүрә шәһәренә барып җитәләр* (Ш. Ч., 1995, 27 июль — сәхабә — Мөхәммәт пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән кешеләр — ГТРАС, 529 б.). *Яңа динне халыкка аңлату өчен укытучы-мөгаллимнәр һәм ислам нигезләрен өйрәтүче **фәкыйхләрен** җибәрүен үтенә* (С-й, 1995, 9 дек. — фәкыйх — шәригать законнарын яхшы белүче ... — ГТРАС, 784 б.). *Мохтаҗларга, гарип-горабаларга, ятимнәргә **фидая**, садака бирү, ярдәм итү фарыз* (С-ә, 1994, № 2, 30 б. — фидая — 1. Йолым. 2. Дини, үлгән кешенең гөнаһысын йолып калу (коткару) өчен бирелгән мал, йолым — ГТРАС, 628 б.). *Ул ... Аллаһы Тәгаләдән үзенә дә, юлын кисүчеләргә дә **һидаять** бирүен сорый* (С-ә, 1996, № 1, 31 б. — һидаять — туры юлга керү ... — ГТРАС, 784 б.). *Исламның төп принциплары: Аллаһы Тәгаләнең берлеген һәм аңардан башка бернинди илаһи, бөек зат юк икәнен белү, Аңа **ширек** катмау ...* (Т.й., 1995, 1—8 июль — ширек — күп аллага ышану, мәҗүсилек — ГТРАС, 704 б.).

Ә: **алиһә, бәддога, вәгазь, газават, гареш, голәмә, госел, дәфен, дәһри, җәбраил, зәкят, илаһият, имам-хатиб, исламият, канун, мәзһәб, мәкам, мәхәллә, мөрит, фәтва, хаҗ, хаҗи, хәрәм, хитап, хөтбә**.

*Ул — мәхәббәт, гүзәллек, тугрылык **алиһәсен** гәүдәләндерүче җыелма образ* (С-ә, 1991, № 5, 23 б. — алиһә — *иск. дини*. Хатын-кыз алла — I, 47 б.). *Ул үзенә карата үпкәләүләр, рәнҗешләр, **бәддогалар** киләсен бик ачык чамалады* (К.у., 1992, № 11, 13 б. — бәддога — *иск*. Каргау, каһәрләү догасы, каргыш — I, 203 б.). *Бер карыйсың — Рафикъ әфәнде **вәгазь** укучы дин әһелен хәтерләтә* (С-ә, 1996, № 3, 15 б. — вәгазь — *иск*. 1. Үгет, нәсихәт ... 2. Мәчеттә ... дини нәсихәт бирү ... — I, 245 б.). *Горур Чечен халкына бу **газаватта** Ходай Тәгалә үзе ярдәм бирсен!* (С-ә, 1995, № 1, 8 б. — газават — *иск. Дини* ... ислам динен тарату ... максаты белән алып барган «изге сугыш» — I, 253 б.). *Фәтхи ярым ачык күзләрен **гарешкә** терәгән* (К.у., 1995, № 4, 16 б. — гареш — *иск*. ... Алла тәхете урнашкан иң югары кат; күк — I, 260 б.). *... **голәмә** шурасы рәисе Габдулла хәзрәт Галиуллa да катнашты* (Ш. Ч., 1998, 14 авг. — голәмә — *иск*. 2. Дини кануннарны, шәригатьне белүче кешеләр, дин башлыклары — I, 272 б.). *Хаҗның иң беренче таләбе — **госел** кылып, ихрамнарга төрену* (А-к, 1995, № 5—6, 77 б. — госел [коену] — *иск*. Чистарыну, юыну ... — I, 275 б.). *Харбин вә Истанбул калаларында гомер сөргәннәр, шунда **дәфен** ителгәннәр* (С-ә, 1994, № 1, 25 б. — дәфен — *иск*. Мәетне җирләү, күмү йоласы — I, 320 б.). *Әмма **дәһри** ата-аналардан туган дәһри балаларны ничек кеше кыяфәтенә кертергә?* (И-л, 1994, № 9, 27 б. — дәһри — *иск*. Динсез, алласыз ... — I, 321 б.). *Килгән иде сиңа кем? **Җәбраилме**?* (К.у., 1995, № 11, 3 б. — Җәбраил — *иск. дини*. [Яхшылык фәрештәсе.] // Илче, хәбәр китерүче — III, 803 б.). *... Хәерчеләргә бай мөселманнар тарафыннан махсус салым — **зәкят** түләнгән* (Т-н, 1995, № 11—12, 23 б. — зәкят — 1. *иск. дини*. ... Байлыкның ярлыларга һәм дин файдасына бирелергә тиешле кырыктан бер өлеше — I, 353 б.). ***Имам-хатиб** лицейларының да, **илаһият** факультетларының да эшчәнлеге дәүләт карамагында һәм аның хозурында алып бара* (З.-Т., 1995, 17 нояб. — илаһият — *иск*. ... 2. Дини, фәлсәфә гыйлеме — I, 378 б.; имам-хатиб — *иск*. Җомга, гает намазларын уку хокукына ия мулла ... — I, 385 б.). ***Исламияттән** башлап ул бигрәк тә тиз үсеп китә* (З.-Т., 1995, 15 сент. — исламият — *иск. кит*. Ислам дине, мөселман дине — I, 422 б.). *Ислам дине **кануннарын** төгәл үтәргә гадәтләнгән Тимербулат катнаш никахка каршы төшә* (Т-н, 1995, № 5—6, 132 б. — канун — 1. *иск. дини*. Дини догма, шәригать законнары — II, 42 б.). *Шагыйрь гыйшыкны, күңелләрендәге дин һәм **мәзһәб** аерымлыкларына карамастан, гүзәл бер кыйммәт итеп аңлый* (К.у., 1993, № 10, 175 б. — мәзһәб — *иск*. ... 2. *дини*. Секта, дин — II, 417 б.). *Кайдадыр моңлы **мәкам** белән Коръән укый башласалар, тәнемә каз тиресе чыга* (К.у., 1993, № 2, 74 б. — мәкам — *иск. кит*. Көйле тавыш, көйле тон [Коръән укыганда] — II, 418 б.). ***Мәхәлләдәге** Равил хәзрәт белән дә бик дуслар без* (С-й, 1996, 20 гыйнв. — мәхәллә — *иск*. 1. Шәһәр һәм авылның бер мәчеткә караган өлеше ... — II, 423 б.). *Муллаларның бөтенесе диярлек зур ишаннарның **мөритләре** булганнар* (А-к, 1993, № 12, 211 б. — мөрит — *иск. дини*. Берәр мәзһәб башлыгы булган ишанга ант иткән турылыклы иярчен — II, 428 б.). *Озакка сузмыйча мөфти хәзрәт бер **фәтва** игълан итеп, мәхәлләләргә таратсын иде* (М-т, 1996, 22 март — фәтва — *иск. кит*. ... Берәр эшнең яравы-ярамавы турында дин әһеле тарафыннан аңлатып бирелә торган рәсми рөхсәт, фатиха — III, 358 б.). *Димәк, **хаҗ** кылырга, **хаҗи** булырга уйладыгыз ...* (А-к,

1992, № 3—4, 66 б. — хаҗ — *иск. дини. ...* мөселманнарда гыйбадәт кылу өчен билгеләнгән изге урын — Мәккә шәһәре — III, 365 б.; хаҗи — *иск.* ... Мәккә шәһәренә барып ... кайткан кешегә бирелә торган исем, дәрәҗә ... — III, 365 б.). *Билгеле — мөселманга дуңгыз ите* ***хәрәм*** (С-ә, 1992, № 7, 19 б. — хәрәм — 1. *иск.* Дин, шәригать тарафыннан тыелган ... — III, 385 б.). *Франциядә мөслимәләргә мәктәп һәм башка уку йортларына* ***хиҗаптан*** *керүне тыя* (М.җ., 2007, 6 апр. — хиҗап — *иск.* Битне каплап йөри торган пәрдә ... — III, 369 б.). *Коръән тәфсирләрен,* ***хөтбәләрне*** *һәм төрле догаларны эченә алган бу китаплар мәдрәсәдә матур яза белгән хаттатлар булуы турында сөйлиләр* (А-к, 1994, № 75. — хөтбә — *иск. кит.* 2. Вәгазь — III, 390 б.).

**7. Документ, рәсми кәгазь, төрле язма атамалары**

Эш кәгазьләре стиле безнең халкыбызда күп гасырлар буе иске татар телендә төзелә килгән. Шәрык белән бәйләнеш көчле булганлыктан, табигый, аларда гарәп һәм фарсы сүзләре зур урын алып торган. Совет чорында пассивлашкан яисә кулланылыштан чыккан бу сүзләр яңадан активлашып китте, эш кәгазьләре өчен генә хас булган ***-намә*** компонентлы дистәләгән сүз кире кайтты.

А: **вәрәка, вәсика, дәстүр, гуаһнамә, иҗазәтнамә, кануннамә, сәнәд, солыхнамә, бәяннамә, дәгъвәтия**.

*1987 елны КПСС Үзәк Комитетына язган* ***вәрәкамда*** *мин ... СССРның таралачагы турында кисәткән идем* (И-л, 1995, № 11, 44 б. — вәрәка — ... 2. Хат, записка. 3. Документ — ГТРАС, 57 б). *Монастырь-тәкыяләрдә безнең меңләгән* ***вәсика,*** *китаплар саклана* (М.җ., 1995, 25 июль — вәсика — 1. Ышанырлык, таянырлык нәрсә (документ) ... — ГТРАС, 58 б.). *Зур галим кешеләр дә аннан дингә ничек хезмәт итәргә кирәклеге турында* ***дәстүр*** *ала алачаклар* (А-к, 1993, № 10, 122 б. — дәстүр — *ф.* ... 3. Кулланма, инструкция ... — ГТРАС, 118 б.). *Аны оештыруда катнашкан кайбер кешеләрнең* ***гуаһнамәләре*** *сакланып калган* (М. ж., 1997, 28 нояб. — гуаһнамә — таныклык — ПРС, 960 б.). *Биредә аңа Коръән хафиз* ***иҗазәтнамәсе*** *тапшыра* (А-к, 1994, № 1, 217 б. — иҗазәтнамә — *г.-ф.* ... 2. Аттестат, диплом — ГТРАС, 193 б.). ***Кануннамә*** *кабул ителү турындагы хәбәр анда урыс телендә басылып чыкты* (Ш.Ч., 1996, 7 февр. — кануннамә — *г.-ф.* Законнар җыентыгы — ГТРАС, 202 б.). *Соңгарак калып туса да, бик камил булмаса да, бу бик кирәк* ***сәнәд*** (Ш.Ч., 1995, 6 гыйнв. — сәнәд — 1. Ышандыргыч дәлил. 2. Документ — ГТРАС, 522 б.). *Клинтон җитәкчелеге ... дошманлашкан якларны* ***солыхнамә*** *имзаларга инандыра* (З.-Т., 1995, 5 дек. — солыхнамә — солых договоры — ГТРАС, 509 б.).

**Бәяннамә** (декларация), **дәгъвәтия** (чакыру кәгазе) сүзләрен дә, гәрчә алар бу вариантларда гарәп-фарсы сүзлекләрендә теркәлмәгән булсалар да, гарәп тамырлы булуларын искә алып (ШАС, 21, 44 б.), бу төркемгә кертәбез. Төрек телендә кулланылышта булулары, нигездә, Төркиягә бәйле материалларда һәм «Заман-Татарстан» газетасында очраулары бу сүзләрнең әдәби телебезгә төрек теле аша керүе турында сөйли: *Исраил белән Фәләстыйн Азатлык оешмалары арасында 1993 елда солых принциплары* ***Бәяннамәсе*** *имзаланганнан соң, ... киң күләмле региональ проектлар бер-бер артлы алга сөрелә башлады* (З.-Т., 1995, 9 дек. — бәяннамә — белдерү, декларация — Тур. РС, 60 б.). *Без икенче курста укыганда, Истанбул университеты ректоры, яхшы укучы КДУ студентларын җәйгә 15 көнлек сәяхәткә чакырып,* ***дәгъвәтия*** *җибәргән иде* (М-т, 1996, 15 март — давәтия — чакыру билеты — Тур. РС, 96 б.).

Ә: **лаихә, нотык, фәрман, шикаять, васыятьнамә, дәгъватнамә, низамнамә, тәгъбирнамә, фалнамә, шартнамә, шаһәдәтнамә, шикаятьнамә**.

*Аннары — комиссия исеменнән Декларация* ***лаихәсен*** *игълан итү* (И-л, 1996, № 8, 42 б. — лаихә — *иск.* Проект — II, 328 б.). *Мәскәү түгел, без үзебез, — диде үзенең* ***нотыгында*** *... Минтимер Шәрип улы Шәймиев ...* (С-ә, 1991, № 1, 2 б. — нотык — *иск.* Речь [чыгыш] — II, 448 б.). *Мәсәлән, Татарстан Президенты Тышкы элемтәләр департаментын булдыру турында* ***фәрман*** *чыгарды* (Ш.Ч., 1995, 15 авг. — фәрман — *иск.* Боерык — III, 358 б.). *Хикмәт шунда: соңгы вакытта журналга бик күп санда* ***шикаятьләр,*** *үтенечләр килә* (С-ә, 1991, № 4, 11 б. — шикаять — *иск.* 1. Гаделсезлекне күрсәтеп, шуны хәл кылуны сорап язылган рәсми гариза ... — III, 505 б.). *Безнең татар халкында кеше үзе исән чагында* ***васыятьнамә*** *язу гадәте традициягә кермәгән* (С-ә, 1995, № 1, 27 б. — васыятьнамә — *иск.* Васыять язылган кәгазь — I, 232 б.). *Бервакыт дустыннан мәҗлескә чакырып* ***дәгъватнамә*** *килде* (М-ф, 1995, № 6, 60 б. — дәгъватнамә — *иск.* Чакыру язуы — I, 318 б.). *Университет* ***низамнамәсе,*** *аның концепциясе, эксперт комиссиясе әгъзаларында зур канәгатьләнү тудырды* (М-т, 1994, 12 март — низамнамә — *иск.* Берәр төрле мәсьәләгә карата язылган закон, кагыйдәләр җыелмасы, устав. — II, 442 б.). *Ә хәзер инде без бөек галимебез Каюм Насыйри туплап калдырган* ***фалнамәгә*** *күз салыйк* (М.җ., 1996, 27 дек. — фалнамә — *иск.* Фал ачу [күрәзәлек] китабы — III, 335 б.). *Без* ***Шартнамә*** *төзүгә җиңел генә килмәдек* (М.җ., 2007, 3 авг.) — шартнамә — *иск.* Килешү кәгазе — III, 494 б.). *Ул Татарстан Республикасы Дәүләт милек комитетында расланды, Финанс министрлыгында теркәлде һәм 1994 елның 15 февралендә акционерлык* ***шаһәдәтнамәсе*** *алды* (А-к, 1994, № 8, 217 б. — шаһәдәтнамә — *иск.* Нәрсәне дә булса раслап бирелгән язу, таныклык [аттестат] —

III, 501 б.). *Идарәнең кадрлар бүлеге инспекторы Лидия Цветова, **шикаятьнамәне** үзе укып чыккач, бар язылганнарны да тулысы белән инкарь итте* (В.Т., 1995, 21 февр. — шикаятьнамә — *иск.* Шикаять язылган рәсми кәгазь, шикаять кәгазе — III, 505 б.).

**8. Оешма, бина атамалары**

Бу төркемгә караган сүзләр узган гасырның 20 нче елларыннан алып килеп чыгышлары ягыннан рус һәм интернациональ сүзләр булганнар (больница, гостиница, мастерская һ.б.). 80—90 нчы еллардан оешма һәм бина атамаларын белдерүдә искиткеч зур активлык белән *-ханә* элементы «эшли башлады».

А: **даруханә, тәҗрибәханә, шәрабханә.**

*— Әһә, монда даруның исеме дә язылган ич, — дип, якындагы **даруханәгә** чыгып йөгерде* (С-й, 1996, 22 май — даруханә — аптека — РПС, 34 б.). *Фәннәр академиясенең ясалма интеллект мәсьәләләре буенча фәнни-тикшеренү **тәҗрибәханәсе** булдырылды* (М.ж., 1995, 22 дек. — тәҗрибәханә — лаборатория — ПРС, I, 350 б.). *Клиент **шәрабханә** каршында торучы милиция машинасын күреп алды* (И-л, 1995, № 1, 75 б. — шәрабханә — 1. Шәраб ясый торган йорт. 2. Эчемлек эчә торган йорт, мәйханә — ГТРАС, 711 б.).

Ә: **вакыф, нәзарәт, фирка, ширкәт, шура, дәресханә, каһвәханә, кярханә, мәйханә, мосафирханә, фәхешханә, хаҗәтханә, хәбесханә / хибесханә, хәстәханә, шифаханә, һөнәрханә**.

*... бу уку йортлары ... төрле **вакыф**, фирмалардан да ярдәм ала* (А-к, 1995, № 7, 131 б. — вакыф — *иск. кит.* Берәр кеше яки җәмәгать тарафыннан уку-укыту, ярлыларга ярдәм итү өчен бүләк итеп бирелә торган акча яки мал, [фонд] — I, 247 б.). *Милләт мәҗлесенә, мәгариф **нәзарәтенә** әгъза итеп сайлана* (С-ә, 1992, № 11, 18 б. — нәзарәт — *иск. кит.* ... 2. Идарә — II, 451 б.). ... *депутатлыкка кандидат итеп бары тик аерым **фирка** әгъзалары гына күрсәтелергә тиеш ...* (С-ә, 1995, № 2, 4 б. — фирка — *иск. кит.* 1. Төркем ... 2. Дин, партия — III, 346 б.). ***Ширкәт** мөлкәтендә һәр әгъзаның өлеше бар* (В.Т., 1995, 21 июнь — ширкәт — *иск.* Промышленность, сәүдә һ.б. эшләрдә бергәләп эш итү максатында тигез хокуклы члennardан оешкан берләшмә [компания] — III, 507 б.). *Күптән түгел Кама политехника институтының гыйльми **шурасы** утырышы булды* (Ш.Ч., 1995, 6 апр. — шура — *иск.* Совет — III, 523 б.). *Автобус эче үзе бер **дәресханәгә** әверелә иде, Али сөйли башласа* (К.у., 1995, № 3, 127 б. — дәресханә — *иск.* Дәрес алып бару бүлмәсе, класс — I, 319 б.). ... ***Каһвәханәдә** ишек башындагы лампа сүнгәч тә, ... егет шатланып китә* (М-с, 1992, № 9, 35 б. — каһвәханә — *иск.* Кофе эчә торган урын — II, 257 б.). *... ындыр табагы, мөгезле эре терлек фермасы, авыл хуҗалыгы машиналары **кярханәсе** — барысы бер тирәдә — уч төбендәге кебек* (М.ж., 1998, 26 июнь — кярханә — *иск.* Мастерской, берәр нәрсә эшләп чыгара торган оешма [предприятие] — II, 247 б.). *Солдат **мәйханәсендә** бер танкист акча сорады* (Т. я., 1992, 25 май — мәйханә — *иск.* исерткеч эчемлекләр сатыла торган йорт, кабак — II, 418 б.). *Усия пристане каршысында **мосафирханә**, склад, кибет биналарыннан бөтен бер бистә калкып чыкты* (К-н, 1996, № 3—4, 74 б. — мосафирханә — *иск.* Юлчылар өчен номерлар; гостиница — II, 405 б.). *Бүген инде башкалада меңнән артык **фәхешханә** бар* (В.Т., 1994, 6 авг. — фәхешханә — *иск.* Фахишәләрнең тору һәм кабул итү йорты — III, 358 б.). *Беркөнне 3 кеше **хаҗәтханәгә** кергәч, тишектән ... чыгып качалар* (Т.й., 1995, 4—11 март — хаҗәтханә — *иск.* Бәдрәф ... — III, 365 б.). *Исән икәнлегемә инангач, ... **хәбесханәгә** алып кереп киттеләр (*И-л, 1991, № 6, 12 б. — хәбесханә — *иск.* Төрмә, зиндан ... — III, 376 б.). *Җиңел яраланган 3 милиционерны **хастаханәгә** озаталар* (Ш.Ч., 1994, 13 гыйнв. — хәстәханә — *иск.* Дәвалау йорты, больница — III, 386 б.). *Шулай ук биредә яшәүче күпләр авырып **шифаханәгә** эләккәннәр (*В.Т., 1995, 25 февр. — шифаханә — *иск.* Дәвалау йорты, больница — III, 508 б.). *Ә бит **һөнәрханә** нинди игелекле һөнәр ияләре әзерли* (А-к, 1996, № 4, 87 б. — һөнәрханә — *иск.* Мастерской — III, 827 б.).

**9. Тормыш-көнкүреш лексикасы**

Төрки-татар дөньясы шәрык дөньясы белән гаять тыгыз бәйләнештә яшәгән. Шуларның чагылышы буларак, гарәп һәм фарсы алынмалары татарларның тормыш-көнкүреш өлкәсенә дә кереп калганнар. Аларның шактые соңгы чорда активлашып бара.

А: **аләт, дәстәрхан, кальб.**

*Шуның өчен ул әхлаксызлар кулында әхлак бозар өчен бер **аләт** булган иде* (К.у., 1995, № 10, 157 б. — аләт — 1. Корал, эш коралы, инструмент, прибор [җиһаз]. 2. чара, әмәл — ГТРАС, 17 б.). *Бәйрәмнәр каршы алабыз сыйлы **дәстәрханнарда*** (К.у., 1990, № 1, 4 б. — дәстәрхан — ашъяулык, эскәтер — ГТРАС, 118 б.). *Ислам дине пакьлектән башлана — тәне дә, **кальбе** дә пакь, ризыгы да хәләл* (С-ә, 1995, № 6, 18 б. — кальб — йөрәк, күңел — ГТРАС, 200 б.).

Ә: **гонҗә, җәсәд, зынҗыр, каберстан, каһвә, кәбап, мәгъдән, мәктүп, мөһер, низаг, сәйран, тәгам, хәер-фатиха, һәдия**.

*Бөек Болгар болан башлы чүлмәк аша образлы рәвештә сурәтләнә, аңардан ике **гонҗә** үсеп чыга — болары Казан белән Чаллы* (Нур, 1995, 23 март — гонҗә — *иск.* Чәчәк бөресе; ачылып бетмәгән чәчәк — I, 95 б.). *Туфрак белән күмелгән **җәсәде** туган төбәгендә, Арча районының Гөберчек авылы*

*зиратында ята ...* (С-ә, 1995, № 12, 14 б. — җәсәд — *иск.* Гәүдә — III, 811 б.). *Ләкин инде йөрәгебезгә төшкән* ***зынҗырны*** *бер селтәнү белән генә алып ташлау мөмкин түгел иде* (В.Т., 1995, 13 гыйнв. — зынҗыр — *иск. кит.* 1. ... чылбыр ... . 2. ... богау ... — I, 350 б.). *Таң аткач, кояш чыкканда халык* ***каберстанга*** *гает намазына ашыга* (Т.й., 1995, 18—25 февр. — каберстан — *иск.* Каберлек [зират] — II, 10 б.). *Тротуарда исә сәүдә гөрли — кайнар* ***кәбап****, тутырма,* ***каһвә****, чәй, фанта, цитрус нигъмәтләре һәм башка җиләк-җимеш* (А-к, 1995, № 8, 13 б. — каһвә — *иск.* Кофе — II, 80 б.; кәбап — *иск.* Турыдан-туры утта кыздырылган ит, куырма; шашлык — II, 247 б.). *Урал тауларының* ***мәгъдәннәре*** *— җир асты байлыклары хакында сөйләп торган укытучы кулын чак кына алыштырды* (К.у., 1992, № 4, 69 б. — мәгъдән — *иск.* 1. Руда, металл ... — II, 415 б.). *Берничә* ***мәктүбенә*** *җавап хаты салсам да, башкаларына җавап бирмәдем* (И-л, 1994, № 9, 25 б. — мәктүп — *иск.* Хат — II, 415 б.). *Хуҗадан имза алып,* ***мөһер*** *сугып, бу көннәрдә озатырга исәп* (К.у., 1996, № 1, 12 б. — мөһер — *иск. к.* Печать — II, 429 б.). *Дару препаратлары ... таләп итеп, көнаралаш диярлек* ***низаг*** *чыгаруы мәгълүм булды* (К-н, 1996, № 3—4, 142 б. — низаг — *иск.* Ызгыш, талаш, гауга — II, 442 б.). *Бераздан тәнәфескә таралышып* ***сәйранда*** *йөргәндә, шыбырдап җылы яңгыр коеп ява башлады* (К.у., 1994, № 10, 101 б. — сәйран — 1. *иск.* Саф һавада ял итеп күңел ачу — II, 708 б.). *Халык таралгач, шундагы чатырларның берсенә кереп, сабан туен оештыручылар белән бергә* ***тәгам*** *җыйдык, табын янында берничә кытай кешесе дә бар иде* (М.җ., 2006, 3 февр. — тәгам — *иск.* Азык, ашамлык, ризык — III, 208 б.). *Күңелдә калырлык* ***хәер-фатиха*** *бирүчеләр дә булгандыр* (С-й, 1996, 18 дек. — хәер-фатиха — *иск.* Ризалык — III, 378 б.). *Арада иң затлысы — Чаллы спонсорлары* ***һәдия*** *иткән «Ока» машинасы икән* (И-л, 1995, № 4, 73 б. — һәдия — *иск.* Бүләк — III, 723 б.).

**10. Модаль (кереш) сүзләр: бәс, вакыйган, хакыйкатән**

***Бәс****, шулай булгач, мөстәкыйль вә бәйсез республика халкы үз җирләренә, табигый байлыкларына үзе хуҗа* (А-к, 1992, № 11—12, 88 б. — бәс — *кер. сүз. иск.* Димәк, шулай булгач — I, 210 б.). *Һәм,* ***вакыйган,*** *бик файда иткәннәр* (К.у., 1995, № 10, 157 б. — вакыйган — *кер. сүз. иск. кит.* Чынлап та, чыннан да, дөрестән дә — I, 228 б.). ***Хакыйкатән****, Сибгат Хәким дөрес әйткән: премия ул язучыны боза гына* (М.җ., 1997, 7 март — хакыйкатән — *иск. кит. ...* 2. *кер. сүз.* Дөрестән дә, чыннан да, ихластыр — III, 361 б.).

**11. Алмашлыклар: бәгъзе, җәмг(ысы)**

*Аларның бәгъзеләре безгә кара кайгы китерде,* ***бәгъзеләре*** *шатлык өрде* (С-ә, 1992, № 4, 1 б. — бәгъзе / бәгъзы — *алм. иск.* Кай, кайсы, кайбер — I, 203 б.). *Бу куркыныч чирне* ***җәмгысы*** *10 меңнән артык кеше йоктырган* (Т.я., 1997, 27 сент. — җәмгысы — *алм. иск.* Барысы бергә, бөтенесе ... — III, 807 б.).

**12. Ымлык: афәрин**

***Афәрин****, бик булдырдыгыз* (К.у., 1992, № 10, 168 б. — афәрин — *иск. кит.* «Бик шәп», «бик яхшы», «яшә» мәгънәсендәге хуплау сүзе — I, 87 б.).

**13. Ярдәмлекләр**

1) теркәгеч: *Шундый илаһи* ***вә*** *затлы сүзгә ия бер кеше бар безнең татар дөньясында* (В.Т., 1996, 24 май — вә — *терк. кит.* Һәм — I, 245 б.);

2) бәйлек: ***Мисле*** *миңле лалә — төрки гүзәлләр* (К.у., 1995, № 11, 5 б. — мисле — *бәйл. иск.* Кебек, күк, шикелле, төсле, сыман — II, 397 б.);

3) кисәкчә: *Бу* ***гайре*** *табигый булмаса да, тиз үзгәрүчән тормышыбыз өчен гадәти булмаган һәм көтелмәгән хәл* (Ш.К., 1994, 2 июнь — гайре — *иск.* Үзеннән соңгы сүзгә карата инкярлау кисәкчәсе булып килә — I, 255 б.).

**2.2.1. Тезмә сүзләр һәм фразеологик әйтелмәләр составында активлашкан алынмалар**

Соңгы елларда активлашкан гарәп-фарсы алынмаларының бер өлеше бары тезмә сүзләр составында, ягъни ***бир, бул, ит, кыл*** ярдәмче фигыльләре белән генә кулланыла: ***Агяһ булырга****, сак булырга кирәк: империя һәрчакта да сателлитларны оста куллана белә* (А-к, 1995, № 4, 4 б. — агяһ — *ф.* Белеп торучы, хәбәрдар булучы — ГТРАС, 16 б.; ягъни агяһ булу алдан белеп торуны аңлата). *Документаль кино һәм фотолардан экранда күренеп барган фильм һәм шул фильм фонында үзәк өзгеч җырлар милләттәшләребезнең каһәрләнгән язмышын* ***бәян итте*** (В.Т., 2007, 21 март — бәян — *и. иск. кит.* Аңлатма; бәян итү — аңлату, сөйләп-язып бирү — I, 212 б*.). Грозный һәм Гудермес шәһәрләре* ***вәйран ителгәч****, чечен халкы тауларга китеп, урыс армиясенә каршы партизан хәрәкәтләре алып бара башлады* (М.җ., 1996, 2 февр. — вәйран итү — 1. Җимерү, вату, юк итү... — I, 246 б.). *Татарстаннан китеп* ***гаип булган*** *бу күргәзмә хакында искә төшереп торуның ни мәгънәсе бар?* (С-ә, 1998, № 11, 15 б. — гаип булу — югалу, юкка чыгу ... — I, 251 б.). ***Гөман итүемчә****, башым беләнниндидер каты әйбергә бәрелгән булырга тиешмен* (К.у., 1991, № 5, 109 б. — гөман итү — ... дип уйлау, фараз итү, күз

алдына китерү — I, 283 б.). *Баксаң, мәктәпнең пионерлар отряды Мәхмүт Латыйпов исемен алу өчен* ***иҗтиһат итә*** *икән* (С-ә, 1994, № 8, 10 б. — иҗтиһат итү (кылу) — тырышу, тырышып эшләү, тырышлык күрсәтү — I, 446 б.). *Ул шулай ук проектның асылы аерым чаралар үткәрүне генә түгел, ә мәгарифне системалы рәвештә* ***ислах кылуны*** *күздә тотуына да басым ясады* (М.ж., 2006, 18 авг. — ислах — *иск. кит.* ... 2. ...; реформа; ислах итү (кылу) — ... 2. Яңалык кертү, реформалар ясау, үзгәрешләр кертү — I, 422 б.). *Үрчергә генә түгел, ә югарыга таба да үсәргә кирәк — гаилә бакчасы* ***мәдәд бирсен*** *сезгә, туганнарым!* (С-ә, 1992, № 9, 12 б. — мәдәд — ярдәм, булышлык — ГТРАС, 299 б.; ягъни мәдәд бирү — ярдәм итү). *Таң беленгән сәгатьтә авылдашлар тагын кат-кат йөкләрен, малтуарын барладылар һәм йортларга, каралты-курага, авылга* ***тәваф кылдылар*** (И-л, 1995, № 5, 19 б. — тәваф итү (кылу) — *иск.* ... 2. Берәр кеше яки берәр нәрсә тирәсендә әйләнү, йөрү — III, 207 б.). *«Аңардан гафил булып, күз йому, әлбәттә, хатадыр», — дип ...* ***тәгъриф итте*** (И-л, 1995, № 5, 39 б. — тәгъриф итү (кылу) — 1. Берәр нәрсә турында аңлату... — ТТАС, III, 209 б.). *Монда без шулай ук бу эшләрне тикшерүдә катнашкан Галимҗан Ибраһимовның хезмәтен һәм үз шаһитлыгын* ***тәкъдир итәргә*** *тиешбез* (А-к, 1994, № 6, 96 б. — тәкъдир итү — берәүнең эшләгән эшен тану, уңай бәя бирү — ТТАС, III, 213 б.). *Ниһаять, 1982 елның 29 декабрендә иң югары гыйльми совет минем диссертацияне* ***тәсдыйк итте*** *һәм аны «иң яхшы» дип бәяләде* (С-ә, 1993, № 11, 10 б. — тәсдыйк итү (кылу) — *иск. кит.* ... 2. Берәр нәрсәне, эшне рәсми рәвештә раслау — ТТАС, III, 231 б.). *Кылган хезмәтләренә* ***тәшәккер итәсе*** *иде* (К.у., 1992, № 6, 63 б. — тәшәккер итү — (кемнең дә булса яхшылыгына каршы) рәхмәт әйтү, рәхмәт белдерү — ТТАС, III, 234 б.). *... үзегезнең журналистлык һөнәрегезгә* ***хилаф кылмыйча****, объективлык юлы белән барсагыз, мактаулы эш башкарган булыр идегез* (А-к, 1991, № 1, 88 б. — хилафлык итү (кылу) — хаксыз рәвештә нәрсәгә дә булса каршы килеп эш итү — ТТАС, III, 367 б.). *Күңелемне биләп алган чиксез җиңеллектән тамган күз яшьләрем ...* ***шаһәдәт бирә*** (Нур, 1995, 19 дек. — шаһәдәт бирү — гуаһ булу, шаһит булу, раслау — ТТАС, III, 501 б.). *Монда инде, әлбәттә, артык* ***шәрех кыйлуның*** *хаҗәте калмый шикелле* (А-к, 1993, № 11, 122 б. — шәрех — *иск.* Аңлатма — ТТАС, III, 535 б.; ягъни шәрех кылу — аңлату).

Гомумән, гарәп-фарсы компонентлы күп кенә фразеологик әйтелмәләр һәм терминологик характердагы тезмә сүзләрнең соңгы елларда актив кулланылышка кайтуы күзәтелә, мәсәлән: *1993 елда Казакъстан президенты Нурсолтан Назарбаев, Мисырга рәсми* ***зиярәт кылганда****, аның президенты Хөсни Мөбарәк белән Казакъстанда Ислам мәркәзе төзү эшен килешкән* (З.-Т., 1995, 9 дек. — зиярәт кылу — ... 2. *куч.* ... күрешергә яки хәл белергә килү — ТТАС, II, 348 б.; биредә «визит» мәгънәсендә). *Ата-баба җиренә* ***сәҗдә кылып****, аңа иминлек теләп, сагыну тулы шигъри сәламнәр юллавы табигый* (К.у., 1992, № 11, 79 б. — сәҗдә кылу — 1. ... табыну. 2. *куч. иск.* ... хөрмәт белән ... баш ию — ТТАС, II, 712 б.). *... мәйдан өстендә илебезне, динебезне саклап* ***шәһит китүчеләр*** *рухына атап укылган изге дога авазлары тибрәлә* (Нур, 1995, 19 окт. — шәһит китү — ... нинди дә булса эш өчен һәлак булу — ТТАС, III, 538 б.). «... икенче берәүгә тапшыру, бирү» мәгънәсендә «тәслим кылу» тәгъбире хәзер «җан тәслим кылу» (үлү, вафат булу) фразеологизмы составында гына кулланыла: *Хәтта* ***җан тәслим кылганнан*** *соң да гүзәллеген югалтмый ята иде хатын* (С-ә, 1991, № 1, 9 б.).

Сүзлекләрдә теркәлмәгән булса да, **гафләт йокысы** гыйбарәсен дә соңгы елларда активлашкан идиомалар исәбенә кертергә була, ул, нигездә, беренче компонентның мәгънәсен саклап «ваемсызлык», «гамьсезлек» (ГТРАС, 89 б.) төшенчәсен белдерә: *Ул* ***гафләт йокысы****, җәһаләт һәм иттифаксызлык заманасы* (А-к, 1996, № 11, 84 б.).

Барлык компонентлары да гарәп чыгышлы булган гомер бакый,ioктаи назар идиомалары да соңгы елларда активлашты. Аларның беренчесе сүзлекләрдә теркәлмәгән, «мәңге», «гомергә» мәгънәсенә ия, икенчесе ГТРАСтә бар (ioктаи назар — берәр нәрсәгә караш [рус. точка зрения] — 451 б.): ***Гомер бакый*** *бил бөккәннәр, тир түккәннәр нәселеннән* (М-т, 1995, 16 сент.). *Анда Алтын Урда чорларын татар милли тарих фәне* ***ioктаи назарыннан*** *карап өйрәнү омтылышы ясала* (И-л, 1996, № 3, 31 б.).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XX йөз ахыры — XXI йөз башында активлашкан гарәп-фарсы алынмаларын өйрәнү аларның искерү дәрәҗәсе буенча ике төргә бүленүен күрсәтә: совет чорында әдәби телдән тулысынча төшеп калган, татар теленең аңлатмалы сүзлегенә кертелмәгән сүзләр һәм XX йөзнең аерым чорларында матур әдәбият әсәрләре һәм матбугат битләрендә еш очрап та, соңыннан архаиклашкан, «искергән сүз» тамгасы белән аңлатмалы сүзлектә теркәлгән алынмалар. Икенче төркем сүзләр сан ягыннан күбрәк. Активлашкан сүзләрнең күпчелеге исемнәр. Активлашкан алынмаларның икенче зур төркемен билге белдерүче сүзләр — сыйфатлар һәм рәвешләр тәшкил итә. «Кире кайткан» гарәп-фарсы алынмалары арасында алмашлыклар, модаль сүзләр, ымлык һәм ярдәмлек сүзләр (теркәгеч, бәйлек, кисәкчә) дә бар. Аерым алынмалар аналитик сүзләр составында татар ярдәмче фигыльләре белән һәм тотрыклы сүзтезмә компоненты буларак активлашты.

### 2.3. Кулланылыш даирәсен, стилен, ешлыгын үзгәрткән алынмалар

Гарәп-фарсы сүзләре белән мавыгу соңгы елларда кайбер алынмаларның, еш кулланылу сәбәпле, аерым стиль чикләреннән стильара лексикага күчүенә дә китерде. Әйтик, **дивар**, **матәм**, **мәдәни**, **мәдәният**, **мәркәз, мәхкәмә**, **рәссам**, **табиб**, **фараз**, **хәбәрдар** кебек аңлатмалы сүзлектә «китап теле», «югары стиль» билгеләре белән тамгаланган сүзләр хәзер төрле стильгә, шул исәптән публицистикага караган әсәрләрдә дә үзләренең стилистик яктан нейтраль рус һәм интернациональ чыгышлы стена, траур, культура(лы), суд, художник, врач, прогноз кебек синонимнарын актив кулланылыштан кысрыкладылар: ***Диварлары*** *бозга каткан зур бер зал идәннән түшәмгә кадәр туңдырма белән тулган иде* (К.к., 1996, 22 февр.). *Шулай ук Казанда һәм республикада «Түгәрәк өстәл»ләр, конференцияләр,* ***матәм*** *җыеннары уздыру күздә тотыла* (М-т, 1995, 16 сент.). *Закон нигезеннән чыгып караганда, КамАЗ —* ***мәдәни****-иҗтимагый оешма* (А-к, 1994, № 5, 203 б.). ***Мәркәзебез*** *шәһри Казанның кайчандыр сине үлемсезлеккә озатып калган мәһабәт манарасы хәзер дә исән* (М-н, 2003, № 11, 91 б.). *Ул сиксән икенче, туксанынчы һәм туксан беренче елларда халык* ***мәхкәмәсе*** *тарафыннан 3 мәртәбә хөкем ителә* (К.т., 1996, 29 февр.). *Ир хатыны да,* ***рәссам*** *да булу җиңел түгел, әлбәттә* (С-ә, 1995, № 2, 34 б.). *Британиядә* ***табибларга*** *ак халат, озын җиңле кием кию тыела* (Өмет, 2007, 20 сент.). *Тунгус феноменын тикшерү-өйрәнүнең 90 елга якын тарихы йөздән артык* ***фараз*** *туплады инде* (В.Т., 1995, 15 сент.). *Степанков безнең килү хакында* ***хәбәрдар*** *иде кебек* (В.Т., 1995, 4 март).

Аңлатмалы сүзлектә сөйләү теле, гади сөйләм сүзләре буларак теркәлгән **кавем**, **кәсафәт**, **сәмән**, **хаста** алынмаларын да стильара лексикага күчкән сүзләр исәбенә кертергә була. Чөнки алар үз «кырларында» бик кирәкле сүзләр; баштагы икесе бер сүз белән төгәл төшенчә белдерә, күпсүзлелектән котылырга ярдәм итә: кавем — «...2. Халык төркеме» (ТТАС, II, 13 б.) генә түгел, ә кардәш, токымдаш кешеләр; **кәсафәт** — «*и*. Нинди дә булса эшнең яки күренешнең начар нәтиҗәсе, начар йогынтысы, шаукымы, зарары» (ТТАС, II, 254 б.): *Әллә бетеп барган бичара татар* ***кавеме*** *тәмам бөлеп, бетеп югалырмы?* (Ш. Ч., 1994, 3 дек.). *Алфавиттагы инде күпме сөйләнелгән шушы кимчелек аркасында сөйләм бозу* ***кәсафәте*** *буыннан буынга күчеп, тирәнәеп бара* (М-т, 1994, 11 июнь).

**Сәмән** сүзе «акча» (ТТАС, II, 710 б.) төшенчәсен генә бирми, ә, гомумән, матди чыгымнарны аңлатып, рус телендәге **средство** сүзен алыштыра: *Университетлар кирәкле* ***сәмәнне*** *каян табарлар* (З.-Т., 1994, 30 сент.).

**Хаста** сүзе дә әдәби телдәге синонимнары арасында үз урынын тапты, ул, нигездә, конкрет авыру исемнәре белән кулланыла: *Әни хастаханәдә җан биреп, алар яхшы белүенчә, авыруы* ***йөрәк хастасы*** *иде* (К-н, 1996, № 3—4, 157 б.).

**Дәхел** (*сөйл*. Берәр эш-хәлгә мөнәсәбәт (ТТАС, I, 320 б.) гарәп алынмасы хәзер әдәби стильләрдә дә кулланыла: *Тамашачының зәвыгын үстерүдә* ***дәхелебез*** *юк, Мәдәният министрлыгы вазифасын такмасыннар* (В. Т., 2007, 7 гыйнв.).

**Канун**, **кыйтга**, **мөхәррир** сүзләренең «закон», «континент», «редактор» мәгънәләре аңлатмалы сүзлектә стилистик тамгаларсыз бирелсә дә, аларның чын-чынлап актив кулланылышка кайтуы XX йөзнең 80—90 нчы елларына карый: *Биредә дә шул базар* ***кануннары*** *хөкем сөрә ...* (М.җ., 1996, 8 май). *Безнең татар халкы кебек таралып, дөньяның төрле* ***кыйтгаларына*** *сибелгән халык күп түгелдер, мөгаен* (С-ә, 1992, № 8, 4 б.). *Тиражны арттыруда иң нык тырышып эшләгән* ***мөхәррирләрдән*** *Рафаэль Мостафинны күрсәтү дөрес булыр* (Т-н, 1994, № 5—6, 141 б.).

Бер үк төшенчәнең ике синонимик атамасыннан гарәп-фарсы чыгышлысына өстенлек бирү (татарча вариант булмаганда), нигездә, тормыштагы үзгәрешләргә бәйләнгән. Әйтик, татар телендә җыелышлар уздыра башлау, төрле татар милли иҗтимагый оешмалары төзелү аларның алып баручылары, җитәкчеләрен атаучы **рәис** сүзен активлаштырды: *Колхоз* ***рәисен*** *үтерүчегә — 8 ел* (Т.як, 1996, 1 окт.). Татар мәктәпләре, татар класслары ачылу **сыйныф** сүзенә өстенлек бирде: *V* ***сыйныфта*** *укучы Алсу быел да уку елын бишле билгеләренә генә тәмамларга ниятли* (С-й, 1996, 18 дек.).

Демократия һәм хәбәрдарлык **ришвәт** сүзеннән табуны алды: *Ниһаять, күп еллардан соң безнең җәмгыятьтә дә дәрәҗәле чиновникларның* ***ришвәт*** *алуларын белдек* (В.Т., 1995, 22 дек.).

«Тимер пәрдә» күтәрелеп, чит илләргә юл ачылгач, әдәбиятта һәм публицистикада сәяхәтнамә жанры нык активлашып китте: *Әлеге* ***сәяхәтнамә*** *авторның гуманистик омтылышларын югары дәрәҗәдә ачып күрсәтә* (М.җ., 1996, 26 гыйнв.).

Күренүенчә, архаиклашкан сүзләрнең кире кайтуы белән бер вакытта соңгы елларда кулланылыш кысалары аерым стиль белән чикләнгән кайбер гарәп-фарсы алынмаларының стильара лексикага күчүе дә күзәтелә. Элек «югары», күтәренке-патетик стиль берәмлеге буларак файдаланылган күп кенә сүзләр рус-европа чыгышлы синонимнар урынына барлык функциональ стильләрдә дә кулланыла башлады. Сүзлектә «сөйләү стиле» билгесе белән тамгаланган кайбер көнчыгыш алынмалары да идеографик синонимнар сыйфатында стильара лексикага күчеп баралар. Элек сирәк кулланылышта йөргән күп кенә гарәп-фарсы сүзләре газета-журнал лексикасында актуальләште. Бу үзгәрешләр, нигездә, әдәби тел лексикасын рус сүзләреннән арындыру юнәлешендә бара, кайбер алынмаларның актуальләшүе шулай ук иҗтимагый тормыштагы конкрет үзгәрешләргә бәйле.

## 2.4. Гарәп-фарсы элементлары ярдәмендә ясалган сүзләр

Соңгы елларда гарәп-фарсы сүзләре белән мавыгу элек әдәби телдә булмаган яңа сүзләр үзләштерүдә, хәтта гарәп-фарсы сүз ясагыч элементлары ярдәмендә яңа сүзләр-формалар ясауда да чагылыш таба. Түбәндә алынмалар һәм гарәп-фарсы сүзлекләрендә (ГТРАС, ШАС, АРС, ПРС) теркәлмәгән шундый сүз-формантларны карап үтәбез.

### 2.4.1. Морфологик юл белән ясалган сүзләр

«Гарәп телендә сүз ясалу юлларының иң әһәмиятлесе — сүзнең эчке флексиясе үзгәрү юлы» (89. 812 б.). Әмма, сүзнең гомуми идеясен чагылдырган тамырга өстәлеп, конкрет мәгънәле сүзләр ясаучы кайбер авазлар (хәрефләр) татар телендә сүз ясагыч аффикслар буларак кабул ителәләр (89. 812 б.). Бу исә аларны аналогия буенча башка, шул исәптән хәтта гарәп-фарсы чыгышлы булмаган лексемалардан яңа сүзләр ясау өчен файдаланырга мөмкинлек бирә. Ә башка телдән бер үк аффикслы сүзләрне күпләп алганда, бу кушымчаның үзләштерүче тел өчен дә продуктив сүз ясагыч чарага әверелүе — гомумтел белемендә билгеле күренеш (70. 233 б.). Әйтик, төрки телләрдән алынган ***-чы*** кушымчасы фарсы телендә иң продуктив суффикслардан исәпләнә (116, 819 б.; 107. 50 б.). Гарәп чыгышлы ***-и/-ый***, фарсы теленнән кергән ***-стан, -ханә, -намә, -сар, -тараш, -кәр*** аффиксларының татар телендә яңа сүз ясау чарасы буларак кулланылулары фәнни әдәбиятта инде расланган (30. 143—144 б.).

Соңгы елларда да ***-и, -ият (-ийат), -намә, -ханә, -стан, -пәрвәр, -кяр*** кушымчалары һәм ***би-*** алкушымчасы ярдәмендә берничә дистә яңа сүз барлыкка килде.

Исемнәрдән нисби сыйфат ясаучы **-и**, [а] сузыгына беткән сүзләрдән соң ***-ви*** (89. 839 б.; 57. 52 б.) суффиксы ярдәмендә түбәндәге сүзләр ясалды:

**Вазифаи** — вазифа (пост, хезмәт урыны) сүзеннән ясалган һәм рус телендәге «должностное лицо» тәгъбирен тәрҗемә иткәндә кулланыла: *... 360 тан артык* ***вазифаи*** *зат транспорт чараларын исерек хәлдә йөрткән өчен ... ГИБДД органнары тарафыннан тоткарланды ...* (В. Т., 1998, 28 окт.). Аны гомумән хезмәт урынына бәйле мәгънәсендә куллану да очрый: *Министрлык һәм ведомстволар үзләре дә алдан билгеләнгән* ***вазифаи*** *«кысаларга» куып кертеләчәкләр* (В.Т., 2007, 21 авг.). Гарәп телендә **вазыйфый** формалы сыйфат булса да, «чиновник, должностное лицо» мәгънәсендә тамырдаш **муваззав** сүзе кулланыла (АРС, 898 б.). Фарсы, төрек сүзлекләрендә дә **вазифаи** сүзе теркәлмәгән. Бу аның татар телендә ясалуын раслый.

**Вәсикави** (документаль) — **вәсика** (ышанырлык нәрсә, документ — ГТРАС, 58 б.) сүзеннән: *Мин үзем исә беренче татар мультфильмнарын эшләгәндә дә,* ***вәсикави*** *кино тасмалары иҗат иткәндә ... милләтемнең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлап эш йөрттем* (З.-Т., 1997, 28 март). Гарәп теленең үзендә бу сыйфат васа’икый формасында кулланыла, мәсәлән, фильм васаикый — документаль фильм (АРС, 872 б.).

**Гаммәви** (массакүләм) рус телендәге **массовый** сыйфаты урынына **гаммә** (масса, гади халык — ГТРАС, 78 б.) сүзеннән ясалган һәм бик актив кулланыла: *Татарстанның* ***гаммәви*** *мәгълүмат чаралары моны республиканың мәдәни тормышында аеруча күренекле вакыйга дип билгеләп үтте* (М.җ., 1997, 22 авг.). *Шул ук 30 нчы елларда яшь совет дәүләтендә чит ил халыклары өчен* ***гаммәви*** *туризм оештырырга ниятлиләр* (М. җ., 2007, 24 авг.).

**Җәлладн җәллад** (палач — ГТРАС, 774 б.) сүзен аергыч-сыйфат буларак куллану максатыннан ясалган: *... Ватанын тартып алсалар да,* ***җәлладн*** *хөкүмәт «сатлыкҗан» дигән исем тагып, җир йөзеннән юк итәргә тырышса да, аның карагруһ сәясәте барып чыкмады* (А-к, 1992, № 5—6, 91 б.). Гарәп телендә тамырдаш сыйфатның формасы — **җәлд** (АРС, 134 б.).

**Җәмгыяви җәмгыять** сүзеннән ясалган һәм оядаш **иҗтимагый** синонимы белән параллель рәвештә, **социаль** һәм **общественный** сүзләрен алыштыру максатында кулланыла: *Шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Фәйрүзә ханым Мостафина форумны ачып җибәрүгә,* ***җәмгыяви*** *эзләнүләр үзәге эшчесе, экономик фәннәр кандидаты Е.Маликова Чаллы хатын-кызларының* ***җәмгыяви*** *портретларын сурәтләп бирде* (С-ә, 1995, № 4, 23 б.). *Биредә бер* ***җәмгыяви*** *бәдрәф күрмәссең* (Ш.Ч., 2007, 19 сент.). Гарәп-фарсы телләрендә бу мәгънәләрдә **иҗтимагый** сыйфаты кулланылышта, **җәмагый** (массовый), **җәмгый** (җыелма) һ.б. оядаш сыйфатлар башка мәгънәгә ия (АРС, 138—139 б.; РПС, 505, 876 б.).

**Кабихи — кабих** (әшәке, начар — ГТРАС, 196 б.) сыйфатыннан, шул ук мәгънәдә: *... дингә карата башка халыклар* ***кабихи*** *мөгамәләдә булу, бәлки, Аллаһы Тәгалә тарафыннан хаклы рәвештә биреләдер* (И-л, 1995, № 5, 11 б.). Гарәп телендә **кабих** сүзе сыйфат функциясен үти (АРС, 617 б.), татар телендә дә ул шул формада кулланылган (ТТАС, II, 11 б).

**Кыйблави — кыйбла** сүзеннән, «табына торган» мәгънәсендә: *Үзен атеист итеп санаган кешенең дә һәр өлкәдә, һәр тармакта* ***кыйблави*** *өлгеләре, омтылышлары бар* (Ш.Ч., 1995, 7 дек.).

**Могҗизаи** — «искитәрлек, гаҗәп» сыйфатын ясауда гарәп грамматикасы кагыйдәләре сакланмаган — *-и* кушымчасы [а] сузыгына ялгана: *Моннан 10 ел элек Казанның Ирек мәйданында* ***могҗизаи*** *бер гүзәл бина пәйда булган* иде (М. ж., 2006, 29 дек.).

**Хакимияти — хакимият** сүзеннән, «хакимлек итүче» мәгънәсен белдерә: *Ягъни мәсәлән, җинаятьчелеккә каршы көрәшкә хокук саклау органнарын гына түгел, ә Татарстан Республикасының барлык* ***хакимияти*** *дәүләт структураларын тартуны да күздә тота* (В.Т., 1992, 6 март). Гарәп телендә бу мәгънәдә **хукуми** (АРС, 188 б), фарсы телендә **һөкумәти** (ПРС, I, 514 б.) сыйфаты кулланыла. Гомумән, гарәп телендә мондый формадагы сүзнең булуы мөмкин түгел, чөнки анда «фагыйләт» үлчәвендәге исемнәрдән һәм ахырында *-т* булган кыска сүзләрдән нисби сыйфат ясаганда, ахырдагы *-ат /-әт/ -т* төшеп кала (89. 839 б.). Бу исә соңгы елларда матбугат битләрендә очраучы **дәүләти, сәнәгати** (индустриаль), **сәнгати** (художестволы), **сыйфати** (качественный, сыйфат ягыннан), **тәгълимати** (директив), **хөкүмәти** (хөкүмәткә караган) кебек сыйфатларның да йә фарсы теленнән алынган, йә татар теленең үз җирлегендә ясалган булулары турында сөйли.

Соңгы елларда *-и/-ви* кушымчасы белән хәтта рус теле аша кергән исемнәрдән дә сыйфатлар ясый башладылар: *... сәнгать, әдәбият хобби гына түгел, бәлки башлык, түрәнең* ***идеяви*** *зирәклеген, хәтта булдыклылыгын раслаучы күрсәткечкә әйләнде* (К.у., 1998, № 8, 149 б.).

Гарәп телендә исемнәрнең күплек саны формасын, шулай ук сыйфат фигыль һәм кайбер исемнәрдән абстракт төшенчәле исемнәр ясаучы ***-ат, --ият (-ийат)*** кушымчалары (89. 815—817 б.) ярдәмендә дә кайбер неологизмнар ясала: *«Аргамак» журналының* ***мөхәрриәт*** *шурасына керү турындагы тәкъдимегезне рәхәтләнеп кабул итәм* (А-к, 1991, № 1, 18 б.). **Мөхәрририят** «редколлегия, редакция» мәгънәсендә Чаллы шәһәре басмалары «Аргамак» журналы, «Нур» газеталарында кулланылды. Гарәп телендә бу тамырның күплек формасы **мөхаррарәт** «корреспонденция, язма документлар» мәгънәсенә ия (АРС, 163 б.). *Тик шунысы хак: шигырь язу үзе бер* ***илһамият*** *ул!* (С-ә, 1991, № 4, 1 б.). Илһамият — илаһи халәт, күтәренкелек (вдохновение) мәгънәсендә. ***Ләззәтият*** (М.ж., 1997, 27 гыйнв.). Бу аффикс ярдәмендә татар теленең үз сүзләреннән дә уңышлы гына неологизмнар ясала: *Вузда телләр өйрәтү өлкәсендә яшәп килгән гомуми кимчелекләр (аны «ботарлап» өйрәтү,* ***сөйләмияткә*** *игътибар җитмәү, система төгәлсезлеге һ.б.) безнең бүлеккә хас, күрәсең* (М.ж., 1997, 31 окт.) *Сөйләмият — сөйләмне, тел ярдәмендә аралашу системасын өйрәнүче фән* (104. 61 б.).

Соңгы елларда барлыкка килгән яңа сүзләрнең шактые фарсы теленнән кергән ***-намә*** һәм ***-ханә*** кушымчалары ярдәмендә ясалган. Гомумән, составында бу формант булган сүзләр телебездә бик күп. Аларның телдә электән үк булып та, соңгы елларда активлашканнары, мәгънә төсмерен үзгәрткәннәре турында алдагы бүлекчәләрдә сүз булган иде. Биредә сүзлекләргә теркәлмәгән, ягъни соңгы елларда татар теленең үз җирлегендә ясалган сүзләргә тукталабыз. Шунысы кызык: ***-намә, -ханә*** аффикслары ярдәмендә неологизмнар татар теленең үз сүзләреннән дә, электән үзләштерелгән гарәп-фарсы алынмаларыннан да ясалалар. ***-намә*** фарсы телендә «хат, язылган нәрсә, китап» мәгънәләрендә мөстәкыйль сүз буларак та, «документ, язма» мәгънәле кушма сүзләрнең икенче компоненты буларак та кулланыла (ГТРАС, 442 б.; ПРС, II, 622 б.). Татар лингвистлары аны алынма аффикслар исәбенә кертә (74. 144—145 б.). Суффиксоид итеп карауччылар да бар (119. 12 б.). Соңгы чорга кадәр татар телендә «нәрсәнеңдер җыелмасы тупланган әсәр яки китап» мәгънәле бик чикләнгән сандагы ясалма исемнәрдә генә очраган (35. 294 б.) бу элемент ярдәмендә соңгы елларда берничә дистә яңа сүз ясалды. Алар арасында югарыда күрсәтелгән сүз ясагыч мәгънәле **елнамә** (аерым тарихи шәхесләр турында еллап язып барылган язма, истәлек) гомумән чор, дәүләт турындагы язмаларны туплаган **елъязма** сүзеннән аермалы буларак, **айнамә** (тарихи шәхесләр, патшалар тормышындагы вакыйгаларны айлап язып барылган истәлек-биография), **шәхеснамә** (аерым шәхескә караган документлар тупланмасы, личное дело) сүзләреннән тыш башка мәгънәләре дә бар, ягъни сүз ясагыч кушымчаның үз мәгънәсе дә киңәйде. Аерым алганда:

а) «рәсми документ, эш кәгазе» мәгънәсе: **сораунамә** — анкета, **сыйфатнамә** — характеристика, **тәкъдимнамә** — рәсми тәкъдим, рекомендация, **ышанычнамә** — доверенность, **эшнамә** — эшкә алучы белән урнашучы арасында төзелгән хезмәт килешүе, контракт, **хисапнамә** — отчет, **шаһитнамә** — шаһитлык, таныклык язуы; свидетельство;

ә) «нинди дә булса текст язылган кәгазь» мәгънәсе: **кайгынамә** — некролог, **котлаунамә** — котлау кәгазе, открытка, **чакырунамә** — чакыру кәгазе, **сурәтнамә** — рәсем, картина буенча инша, **тасвирнамә** — зарисовка, **тәбрикнамә** — котлау хаты, открытка, **хәбәрнамә** — рәсми органнарга җибәрелгән хәбәр; донесение.

Бу элемент белән артык мавыгып, аны **таныклык, ярлык** кебек сүзләргә дә ялгап ясалган шул ук мәгънәле **таныклыкнамә, ярлыкнамә** кебек артык сүзләргә, **каһәрнамә, кызыкнамә, лыгырдыкнамә, өметнамә, таләпнамә** тибындагы окказионализмнарга тукталып тормыйча, югарыда саналган сүзләрнең мәгънәләрен ныграк ача торган мисаллар китереп үтәбез (башта татар сүзләреннән, соңыннан гарәп-фарсы алынмаларыннан татар теле җирлегендә ясалган неологизмнар кергән җөмләләр бирелә).

*Кытайның элекке бөек ханнары, түрәләренең тәзкирә, **елнамә, айнамә** формасындагы тарихыдыр* (З.-Т., 1996, 6 дек.). *Күптән түгел Казанның бер татар гимназиясендә 110 укучыдан **сораунамә** (анкета) тутырттым* (Т.я., 1997, 27 нояб.). *Дания матбугаты бу эшмәкәрне авантюризмда, килешү йөкләмәләрен үтәмәүдә, **эшнамәләр** төзегәндә вөҗдансыз булуда гаепли* (В.Т., 1997, 21 февр.). *Китап ахырында **кайгынамә** язмасы бирелде* (М.җ., 1998, 20 февр.). *Бер **котлаунамәне** искә алмаганда, башка әйбер тапмадык* (А-к, 1993, № 2, 19 б.). ***Чакырунамәгә** сугылган ГАИ мөһерен күргәч кенә эченә төшкән кату бераз җибәргән сыман тоелды* (А-к, 1993, № 2, 28 б.). *Кайсының гына **шәхеснамәсен** ачып карама — ачы язмыш* (С-ә, 1996, № 8, 17 б.). *Мәскәү консерваториясенә Альбина бу юлы инде министрның **тәкъдимнамәсе** белән килә* (М. җ., 2007, 21 сент.). *Һаваи утрауларындагы океан белеме институты әзерләгән **хисапнамәдә** җәнлекләрнең кешедән тугрылыклы булуы хәбәр ителә* (Т. я., 1996, 17 дек.). *Туфанның үз-үзен фаш итә торган **шаһитнамәләрен** укыды* (К.у., 1991, № 5, 157 б.). *Ул миңа җавап итеп Маратның училище тәмамлау турындагы **шаһитнамәсен** ачып күрсәтте* (С-ә, 1995, № 11, 28 б.). *[Китапта] ... **сурәтнамә** әзерләү, характеристика бирү, сәнгатьле уку күнекмәләре өчен текст яисә биремнәр дә бирелә* (М-ф, 1997, № 1, 26 б.). *... инде төзәлделәр һәм азат ителүгә хаклылар дип үзем **сыйфатнамәләр** яздым ...* (М-н, 2002, № 8, 66 б.). *Ул ... үрнәк солдатлар, старшиналар, офицерлар турында аларның туган якларында гына чыга торган газеталарга очерклар, **тасвирнамәләр** җибәреп торган* (С-й, 1996, 2 окт.). *Рәсемдә Нәҗип Нәкъкаш ясаган бәйрәм **тәбрикнамәсе**, ягъни почта аша җибәрелә торган открытка сурәте* (Т.я., 1995, 8 авг.). *Закон гаммәви чаралар уздыру турында **хәбәрнамә** бирү тәртибен җайга сала* (М.җ., 2006, 20 гыйнв.). ***Ышанычнамә** нигезендә транспорт чарасыннан файдалану хокукын икенче берәүгә тапшыру беренче карашка гына уңайлы булып тоела* (В.Т., 2006, 3 нояб.).

***-намә*** кебек үк, ***-ханә*** дә фарсы телендә «өй, йорт, бина» мәгънәсендә мөстәкыйль дә кулланылучы берәмлек (ГТРАС, 649 б.; ПРС, I, 535 б.). Сирәк булса да татар матбугатында да аны аерым сүз буларак куллану очрый: ... *Скурат бистәсендәге сәнгать **ханәсендә** Минхан җитди рәвештә рәсем белән шөгыльләнә башлый* (А-к, 1993, № 6—7, 125 б.).

Ясагыч кушымча буларак ***-ханә*** компоненты ярдәмендә төзелгән сүзләр барысы да диярлек оешма; шул оешма урнашкан бина мәгънәсенә ия (**оешмаханә, тапкырханә** кебек уңышсыз, окказиональ төзелмәләрдән тыш) һәм күбесе рус-европа алынмаларын алыштыру максаты белән ясалган, шуңа да түбәндә аларның аңлатмасы рәвешендә, нигездә, үзләре алыштырган сүзләрне генә күрсәтәбез:

1) татар теленең үз сүзләреннән ясалган неологизмнар: **икмәкханә** — пекарня, **кабымханә/кабымлыкханә** — закусочная, **кизүханә** — дежур бүлек, **уенханә** — игорный дом, **чатырханә** — сәүдә павильоны, **чәчтарашханә, чәчханә** — парикмахерская, **эчкеханә** — рюмочная;

2) гарәп-фарсы алынмаларыннан ясалган сүзләр: **дәваханә** — поликлиника, **кәсепханә** — предприятие, **мәртханә** — морг, **мирасханә** — архив, **остаханә** — мастерской, иҗат лабораториясе, **сырхауханә** — больница, **шәфкатьханә** — медпункт.

*Район үзәк **дәваханәсе** начар ишеткән һәм ишетү җайланмалары кирәк булган хезмәт ветераннарының, реабилитацияләнгән гражданнарның, сәяси репрессия корбаннарының табиб-отоларинголог бүлмәсенә мөрәҗәгать итүләрен сорый* (Я.ю., 2006, 16 дек.). *Алманиядә төрекләр тарафыннан ачылган **икмәкханәләр** тиз арада зур абруй казанган икән* (З.-Т., 1997, 30 апр.). *Мулланур, Чаллы шәһәренә килгәч, Центральный урамындагы «Трактиръ» **кабымханәсенә** кереп, ашап чыгасы итә* (В.Т., 2007, 17 авг.). *Тәртип бозучыларны **кизүханәләргә** китерәләр ...* (И-л, 1996, № 4, 67 б.). *Мәсәлән, Париж төрледән-төрле кибет, кафе, ресторан, базар, **чатырханәләр** белән шул дәрәҗәдә тәэмин ителгән ки, ... җаның теләгән бөтен нәрсәгә ия булырга мөмкин* (С-ә, 1991, № 4, 8 б.). ***Чәчтарашханәдә** чират көтеп утырабыз* (К.у., 1995, № 10, 144 б.). *Кибет, **чәчханә**, ашханә, автомобильләрдә, кыскасы, футболсөярнең кул астындагы бөтен җирдә байрак вә вымпеллар урын ала* (И-л, 1996, № 2, 41 б.). *Сургут нефть эшкәртү заводы ... аякка басты, башка **кәсепханәләр** дә ишәйде* (К.у., 1998, № 7, 131 б.). *... күмү бюросы хезмәткәрләре ике алкаш мәетен **мәртханәгә** китерделәр* (А-к, 1996, № 5—6, 98 б.). *Кулъязма текстларның буыннар ягыннан иң тулысы — **мирасханәдә** 264-б эш берәмлеге булып саклανучы шәҗәрә* (М.җ., 1995, 12 март). *Чигү-туку **остаханәләре** ачу бу җәһәттән максатчан булыр иде* (С-ә, 1991, № 12, 8 б.). ***Остаханә** киләчәктә үзенең утырышларын газета белән берлектә үткәрәчәк* (В.Т., 1995, 25 нояб.). *Авариягә эләгеп, алты ай **сырхауханәдә** яттым* (Т. я., 1994, 10 февр.). *Кунак йорты, китапханә, **шәфкатьханә** булачак* (К.у., 1993, № 4, 190 б.). Рус һәм интернациональ сүзләргә дә ***-ханә*** элементы ялгау очрый: *Тоталар да ... **журналханәнең** үзенә шалтыраталар* (М. җ., 2006, 10 нояб.).

***-ханә*** компоненты шулай ук **гайбәтханә** (Т.я., 1997, 4 нояб.), **гамәлханә** (Ш. Ч., 1996, 3 февр.), **җәррахханә** (А-к, 1996, № 5—6, 98 б.), **тамашаханә** (С-й, 1995, 28 гыйнв.), **хәзинәханә** (И-л, 1995, № 4, 47 б.), **хөкемханә** (С-ә, 1995, № 10, 14 б.), **ширбәтханә** (И-л, 1996, № 7, 6 б.) кебек окказиональ сүзләр ясауда да актив кулланыла.

Фарсы телендәге иң продуктив исем ясагыч суффикслардан саналган (116. 819 б.) ***-стан*** кушымчасы татар телендә гадәттә ялгызлык исемнәр генә ясауда катнашса да (30. 144 б.), соңгы

елларда аны окказиональ кулланылыштагы күмәклек исемнәр ясау өчен дә файдаланалар; поэтик стильдә ***-стан*** компонентлы индивидуаль неологизмнар аеруча күп ясала: *Зөлфәт — **моңстан** иле* (К.у., 1991, № 6, 172 б.).

Фарсы телендә беренче компоненттан «яратучы, кайгыртучы» мәгънәле кушма сүзләр ясаучы -***пәрвәр*** элементы (ПРС, I, 292 б.; 89. 815 б.) белән дә сүзлекләрдә теркәлмәгән яңа берәмлекләр ясалды: *Динебезнең бүгенге яңарышы үзенең барлык уңышлары һәм чирләре белән менә шундый **ислампәрвәр** ватандашларыбызга бурычлы* (А-к, 1993, № 8, 122 б.). *1913 елда **мәгърифәтпәрвәр** Мәгъсут Мөхти Турпан Астанасында мәктәп ачып, балалар укыта* (М.ж., 2006, 27 гыйнв.).

Татар телендәге ***-чы/-че*** кушымчасының эквиваленты булган ***-кяр*** суффиксы (89. 851 б.) белән гарәп чыгышлы **иҗат** сүзеннән «иҗат кешесе, әдәбият-сәнгать әсәрләре тудыручы» мәгънәле **иҗаткяр** сүзе ясалды: *Бу соңгы сүз татар мәдәниятендә аерата күләмлелек, яңарыш чоры **иҗаткярләренә** хас күпкырлылыкны аңлата* (С-ә, 1996, 32, 34 б.). Соңгы елларда активлашкан **сәнәгать** (промышленность) алынмасы нигезендә төзелгән **сәнәгатькяр** (промышленник) сүзе дә гарәп-фарсы сүзлекләренә теркәлмәгән**:** *1919 елда Казанның Үзәк китапханәсенә **сәнәгатькяр** Ушаковлар йорты бирелә* (С-ә, 1995, № 11, 12 б.).

Фарсы телендә юклыкны белдереп, татар телендәге ***-сыз/-сез*** кушымчасы мәгънәсен бирүче ***би-*** алкушымчалы алынма сүзләр татар телендә шактый. Аналогия буенча аның ярдәмендә хәзер дә сүзлекләрдә теркәлмәгән сүзләр ясыйлар: *Ялгыз башка бозау шикелле сөйрәлү, тормыш борчуларыннан **бихәфа** итеп, озакламый күңелемне дә тынычландырды* (Я-н, 1996, № 3, 18 б.). Биредә **бихәфа** сүзе «борчусыз, кайгысыз» мәгънәсенә ия (хәфа — *г.* 3. Борчу, кайгы, эч пошу — ГТРАС, 687 б.). *Динебезнең нигезеннән **бихәбәрдар** кеше өчен, мондый аңлашуларның зыяны искиткеч* (В.Т., 1995, 11 гыйнв.) — бихәбәрдар — «хәбәрдар булмаган, мәгълүматсыз, белмәүче» мәгънәсен белдерә.

***Би-*** элементын, хәзерге чорда бик актуаль булган «децентрализация» төшенчәсен «татарчалаштыру» максатында, хәтта **мәркәз** (үзәк) гарәп алынмасына татар кушымчасы белән бер үк вакытта ялгап, префиксаль-суффиксаль ысул белән **бимәркәзләү** фигыле ясадылар: *Икенче — «урыс» Русиянең чагыштырмача мөстәкыйль регионнар исәбенә **бимәркәзләү** икәнен күрсәтә* (К.у., 1993, № 9, 167 б.).

### 2.4.2. Синтаксик юл белән ясалган сүзләр

Кайбер рус һәм Европа алынмаларын алыштыру өчен XX йөзнең 90 нчы елларында әдәби телдә аерым кулланылган гарәп-фарсы сүзләреннән кушма һәм парлы сүзләр дә ясалды: *Журналыбызда басылып чыккан әсәрләр өчен **каләмхак** күләме шактый арттырылды* (К.у., 1992, № 12, 193 б.). Биредә ике гарәп сүзен кушып, гонорар, ягъни «язып бастырган әйбер өчен акчалата «түләү» сүзенең «татарча» эквиваленты ясалган. Бу төшенчәне шул ук компонентлар белән ирекле сүзтезмә рәвешендә бирү дә очрый: *Татарстанда хәтта күрше җөмһүриятләргә караганда да **каләм хакы** күп мәртәбә кимрәк икән* (К.у., 1998, № 8, 148 б.). Фарсы телендә «автор гонорары» мәгънәле охшаш «хак әл-каләм» тәгъбире бар (РПС, 162 б.).

*1993 елда яңа оешкан Татарстан Фәннәр академиясенә әдәбият белеме белгечлеге буенча **мөхбир-әгъза** итеп сайланды* (С-й, 1996, 12 окт. — мөхбир-әгъза **член-корреспондент** сүзен алыштыра). Бу сүзне хәзер күбрәк сызыкчасыз гына язалар: *Ул профессор, **мөхбир әгъза** Фуат Ганиев җитәкчелегендәге зур төркем сүзлекче галимнәр тарафыннан эшләнде* (М. ж., 2006, 25 авг.). Аңлатмалы сүзлекнең яңа басмасында да ул шулай теркәлгән (ТТАС, 2005, 379 б.). ... *Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәр һәм район хакимиятләре журнал чыгымнарын уртактан күтәрү һәм аның турыдан-туры **нәшир-хәйриләре** булу турында килешүгә кул куйды* (А-к, 1992, № 11—12, 20 б. — нәшир-хәйри, безнеңчә, «учредитель» төшенчәсен «оештыручы, гамәлгә куючы» вариантларына караганда төгәлрәк аңлата).

### 2.4.3. Фонетик ысул белән ясалган сүзләр

Гарәп-фарсы алынмаларыннан фонетик юл белән яңа исемнәр ясау татар телендә шактый киң таралган күренеш (147. 189 б.). Соңгы елларда да бу ысул белән берничә яңа сүз ясалды.

Тукайлар чорыннан соң татар телендә бөтенләй диярлек кулланылмаган, аңлатмалы сүзлектә дә чагылыш тапмаган **эминиять** (1. Тынычлык, куркынычсызлык, хәвеф-хәтәрсезлек. 2. Ышаныч — ГТРАС, 738 б.) сүзе узган гасырның 90 нчы елларында беренче сузыгын үзгәртеп һәм бөтенләй башка — «страхование» мәгънәсендә кулланыла башлады: *Читтән кредитлар һәм инвестицияләр алудагы кыенлык, иң беренче чиратта республикада аудит үзәге һәм **иминият** (страхование) үзәге булмаудан килеп чыга* (В.Т., 1995, 9 сент.). *Бу юлы пенсиянең ике өлеше дә: база өлеше — 7,5, **иминият** өлеше 9,2 процентка артачак* (В.Т., 2007, 30 март). Чыганак гарәп телендә, шулай ук фарсы һәм төрек телләрендә бу сүз **эмният** формасында «иминлек, куркынычсызлык, ышанычлылык» мәгънәләрендә

генә кулланыла (АРС, 43 б.; РПС, 17 б.; Тур. РС, 127—128 б.). Моннан чыгып **иминият** (страхование) сүзен гарәп алынмасыннан татар җирлегендә фонетик ысул белән ясалган сүз дип карарга була. Дөрес, профессор Ф.Ә.Ганиев «иминият сүзе страхование сүзенең эчтәлеген ачып бирми» дип исәпли һәм аны «иминлек тәэминаты», «иминлек тәэмин итү» аналитик сүзләре белән алыштырырга тәкъдим итә (37. 20 б.).

Күпмәгънәле **маддә** алынмасын (гарәп теле сүзлекләрендә җиде мәгънәсе күрсәтелә — АРС, 745 б.), кириллицага күчкәч, татар телендә әйтелешкә яраклаштырып, **матдә** формасында куллану кабул ителгән иде. Аңлатмалы сүзлектә аның өч мәгънәсе теркәлгән: 1. *филос*. Материя. 2. Материянең сыйфат күренеше, физик җисеме тәшкил иткән нәрсә, әйбер. 3. *иск*. Аерым бүлек, параграф, пункт, статья (ТТАС, II, 372 б.). 90 нчы елларда бу сүзне соңгы — «статья, параграф» мәгънәсендә, яңадан, чыганак телдәгечә, **маддә** формасында куллану гадәткә керде: *Депутат булып сайланучыларның дәүләт хезмәтендә тормаска тиешлеге турындагы **маддәне** юкка чыгарырга кирәк* (М-т, 1995, 10 июнь). *Программа җиде зур маддәдән тора* (Т.я., 1995, 14 март). *Кодекс 133 **маддәне** эченә ала* (М.ж., 2006, 25 авг.).

Ә «материал, вещество» мәгънәсендә **матдә** формасын куллану дәвам итә: *Тәмәке төтенендә агулы **матдәләр**, бигрәк тә никотин күп* (К.к., 1996, 22 март). Моннан чыгып матдә һәм маддәне татар теле җирлегендә фонетик ысул белән ясалган мөстәкыйль сүзләр дип карарга була (3. 32 б.). Хәзерге фарсы теле сүзлекләрендә «материал» һәм «статья» мәгънәсендә ике омонимик **маддә** сүзе теркәлгән (ПРС, II, 438—739 б.; РПС, 386, 892 б.). Бу да **матдә** һәм **маддә**нең татар телендә мөстәкыйль сүзләр булуын дәлилли.

**Мәдхия** (мактау җыры, ода — ГТРАС, 299 б.; ТТАС, II, 417 б.) гарәп алынмасын мәдхия формасына «гимн» мәгънәсендә куллануны да фонетик ысул белән яңа сүз ясауга уңышлы омтылыш дип карарга була. Чөнки грек чыгышлы **гимн** сүзенең беренчел мәгънәсе — аллалар һәм батырлар хөрмәтенә мактау җыры (СИС, 1988, 128 б.): *Һәр борынгы шәһәрнең үз гербы, һәр дәүләтнең **мәдхия** — гимны була* (А.х., 1989, № 2, 9 б.).

Мисаллардан күренүенчә, соңгы елларда татар телендә гарәп-фарсы чыгышлы сүз ясагыч элементлар ярдәмендә алты дистәдән артык яңа сүз ясалды. Аларның зур күпчелеге — фарсы һәм гарәп кушымчалары ярдәмендә шул ук гарәп-фарсы алынмаларыннан ясалган неологизмнар. Иң продуктив кушымчалар: ***-намә, -ханә***, аларның һәрберсе белән кимендә унбишәр неологизм ясалды; ***-и/-ви*** элементы ярдәмендә ясалган яңа нисби сыйфатлар да дистәгә якын; ***-ият, -кяр, -пәрвәр, би-*** компонентлары ике-өч неологизм ясауда катнашты; ***-стан*** кушымчасы башлыча индивидуаль-окказиональ исемнәр ясауда файдаланыла. Синтаксик ысул белән, ягъни тулысынча гарәп-фарсы чыгышлы компонентлардан телнең үз калыплары буенча берничә кушма һәм парлы сүз; авазлар, дөресрәге, хәрефләр чиратлашу юлы белән ким дигәндә ике яңа сүз ясалды. Бу сүзләрнең барчасы да диярлек телебездәге рус-европа алынмаларын алыштыру максатында һәм татарчага бер сүз белән тәрҗемә итеп булмый торган рус сүзләре урынына ясалды.

### 2.5. Гарәп-фарсы алынмаларын яңабаштан үзләштерү процессы

Яңа алынмалар кебек үк, соңгы елларда әдәби телебезгә кире кайткан гарәп-фарсы сүзләре дә яңадан активлашу процессында кайбер үзгәрешләргә дучар булдылар. Бу үзгәреш-үзенчәлекләр семантика, грамматика һәм фонетика-орфография өлкәләрендә чагылыш таба.

#### 2.5.1. Мәгънәви үзгәрешләр

Гарәп-фарсы алынмаларының шактые яңа чорда үзләренең элекке мәгънәләрендә генә активлашмады, ә бәлки төрле үзгәрешләр кичерде. Күп кенә сүзләр яңа иҗтимагый-сәяси, икътисади вазгыятькә бәйле рәвештә яңа мәгънә төсмере белән баедылар, кайберләре аерым конкрет мәгънәләрендә генә активлашты.

Югарыда әйтелгәнчә, гарәп-фарсы сүзләренең күбесе үзләренең рус һәм Көнбатыш телләреннән кергән эквивалентларын алыштыру максатында кире кайтарылды. Бу исә аларның кайберләрендә яңа мәгънә төсмерләре тууга китерде. Түбәндә шундый сүзләрнең аеруча еш кулланылганнарын карап үтәбез.

**Вакыф** — соңгы елларда аеруча актив кулланылышка кергән сүзләрнең берсе. Аның заманында пассив запаска күчүенең сәбәбен «Мәдәни җомга» атналык газетасы түбәндәгечә аңлата: «вакыф» (кайбер очракта «вәкыф») сүзе телебезгә берничә ел әүвәл генә кире кайтты кебек. Аның 70 елдан артык кулланылмый торуына төп сәбәпне бу сүзнең мәгънәсеннән эзләргә кирәктер. Чөнки «вакыф» шәригать белән бәйле төшенчә дип саналган, гадәттә, әлеге сүз мәдрәсә, мәчет тоту һәм ярлыларга ярдәм итү өчен аерым байлар тарафыннан бүләк рәвешендә бирелә торган акчага яисә малга карата әйтелгән (М.ж., 1998, 20 февр.). Аңлатмалы сүзлектә дә ул «искергән, китап теле сүзе» билгесе белән

шул мәгънәдә теркәлгән (I, 247 б.). Гарәп һәм фарсы теле сүзлекләрендә аның ике мәгънәсе күрсәтелә: 1) дингә бәйле эшләр яисә хәйрия максатларында тоту өчен бирелгән, васыять ителгән мал, милек; 2) тартып алынмый һәм налог салынмый торган милек (АРС, 907 б.; ПРС, II, 706 б.). Хәзерге татар телендә бу сүз, нигездә, **фонд** алынмасы урынына аның «матди ярдәм күрсәтү оешмасы» дигән мәгънәсендә кулланыла. Күрәсең, **вакыф** сүзенең телебездә нәкъ шушы мәгънәдә активлашуы төрек теле йогынтысы белән бәйле: төрек телендә дә ул шул ук төшенчәне аңлата (Тур. РС, 372 б.; ТТС, 467 б.): *Аларны төрле җәмәгать оешмалары һәм* ***вакыфлар*** *(фондлар) оештыра* (З.-Т., 1994, 29 июль). *Бу* ***вакыф*** *үсеп килүче илләрдәге иҗтимагый оешмаларның ниятләгән эш проектына акча бирә* (В.Т., 1996, 17 май).

**Гыйбарә** алынмасы ТТАСтә «тексттан өзек, өземтә» мәгънәсендә генә теркәлгән (I, 280 б.). ГТРАС һәм гарәп теле сүзлегендә «язылган сүз; әйтем, фраза, сүз тезмәсе» мәгънәләре дә күрсәтелә. Соңгы елларда бу сүз аңлатмалы сүзлектәгедән бигрәк шушы чыганак телдәге мәгънәләрдә кулланыла, шулай ук аны формулировка сүзе урынына файдалану да очрый: *Әйе, «О темперо, о море» дигән латин* ***гыйбарәсе*** *юкка тумаган* (М-т, 1994, 18 июнь). *Преамбула өлешендә ислам, буддизм һәм яһүд диннәрен дә искә алуны яклап чыктылар һәм шундый* ***гыйбарә*** *(формулировка) тәкъдим иттеләр* (М.ж., 1997, 26 сент.).

**Казый** (*тар.* Шәригать законнары буенча хөкем итүче рухани — ТТАС, II, 22 б.) сүзе соңгы еллар татар әдәби телендә **арбитр**, **рефери** сүзләре урынына, ягъни «спорт уеннары судьясы» мәгънәсендә дә кулланыла башлады: *Ярышлар бик яхшы оештырылган иде, секторлар, стадиондагы юллар искиткмәле. Югары дәрәҗәдәге* ***казыйлар*** (Ш.Ч., 1998, 22 сент.). Чыганак гарәп телендә бу сүз дини мәгънәдән тыш гомумән судья, хөкем итүче мәгънәләренә ия булса да, конкрет «арбитр, рефери» мәгънәсендә башка — хаким, мухаккам сүзләре кулланыла (АРС, 644, 187, 188 б.).

**Кануннамә** (законнар җыентыгы — ГТРАС, 202 б.) сүзе төрле типтагы закон кулланмаларын атау белән бергә **конституция** сүзенең синонимы буларак та файдаланыла: *Китапны татар, башкорт һәм урыс милләтенең һәркайсын милләт һәм дәүләт буларак саклау өчен* ***кануннамә*** *(катехизис) дип тә кабул итәргә мөмкин* (М. ж., 1995, 15 дек.). *Ә Шартнамә безнең* ***Кануннамәне*** *РФ Конституциясе белән бергә төп чыганак дип игълан итә* (И-л, 1995, № 4, 61 б.).

**Мәкам.** 1. Дәрәҗә, тоткан урын. 2. Көйле тавыш, көйле тон — ТТАС, II, 418 б.) сүзе элек татар телендә тулысынча диярлек икенче мәгънәсендә генә очраса, хәзер ул беренчел мәгънәсенә яңа төсмер өстәп «хокукый хәл» мәгънәсендә **статус** сүзе урынына кулланыла: *Украина, мәсәлән, элеккеге Советлар Союзының иярчене Болгария* ***мәкаменә*** *(статусына) тиклем төшерелсә, инде башны авырттырмас иде* (И-л, 1995, № 2, 46 б.). *... Русия эчендә кайбер автономияләр дә үз* ***мәкамнәрен*** *күтәрүгә ирештеләр* (И-л, 1995, № 11, 38 б.).

**Мәхәллә** (1. Шәһәр һәм авылның бер мәчеткә караган өлеше. 2. Квартал — ТТАС, II, 423 б.) сүзе төп мәгънәләрендә активлашу белән беррәттән, яңа төсмерләр белән баеп, «дини-этник принципта төзелгән оешма», «төп территориясеннән читтә яшәүче халык төркеме» (диаспора) мәгънәләрендә кулланыла: *Анда гаилә кодексы икенче укылышта, милли мәгариф системасын булдыру һәм* ***мәхәллә*** *төзү концепцияләре беренче укылышта тикшерелде* (М. ж., 1996, 27 дек.). *Татарстанда яшәүче урыс* ***мәхәлләсе*** *үзенең милли-демократик парламент партиясен оештыра алса да, Татарстан өчен файдалы булыр иде* (А-к, 1992, № 1, 62 б.).

**Мөнбәр** (1. Мәчет эчендә мулла, имам хөтбә укый торган баскычлы биек урын. 2. Трибуна, кафедра — ТТАС, II, 379 б.) сүзен трибуна мәгънәсендә еш куллану анда күчерелмә «дәрәҗәле урын, нинди дә булса иҗтимагый эшчәнлекне башкару чарасы» мәгънәләре пәйда булуга китерде: *Айга ашкан көне булды бу яңа мөхәррирлек* ***мөнбәрен*** *яулаган кеше өчен* (А-к, 1993, № 4—5, 119 б.). *Әмма матбугат ярдәмендә дан* ***мөнбәренә*** *күтәрелгәннәр күпчелек иде* (В.Т., 1995, 29 апр.).

**Һөнәри** сыйфаты фарсы телендә «нәфис, художестволы» мәгънәсенә генә ия (ПРС, II, 731 б.). Ясагыч нигез һөнәр исеме үзе дә, чыганак телендә «сәнгать, осталык, сәнгатькә бәйле шөгыль» мәгънәсен аңлатып та (ПРС, II, 730 б.), татар теленә «эш, кәсеп, профессия» мәгънәсендә алынган кебек, һөнәри дә сыйфат буларак «профессиональ» билгесен белдерә: *Татарстан* ***һөнәри*** *уку йортлары 1 миллион 254, 5 мең квалификацияле эшче әзерләде* (М-т, 1995, 7 окт.). Бу сыйфатны исемләштереп, **профессионал** сүзе урынына да кулланалар: *Татар телендә иртәгесе көн* ***һөнәриләрен*** *(профессионалларын) әзерләү мөмкинме?* (М-ф, 1997, № 8, 60 б.). Шул ук төшенчәләрне бирү өчен тамырдаш **һөнәрмәнд** (1. Һөнәрче. 2. Һөнәрле, оста, махсус белемле — ТТАС, III, 827 б.; фарсы телендәге мәгънәсе — художник, сәнгать әһеле — ПРС, II, 1010 б.) сүзе дә файдаланыла: *Хәзер Татарстан Рәссамнары берлеге татар хатын-кызлары арасында иң беренче* ***һөнәрмәнд*** *рәссам Гайшә Рахманкулова музеен булдыру артыннан йөри* (И-л, 1994, № 1, 80 б.). *Милиция* ***һөнәрмәндләре*** *белән бергә бу көнне ... барлык хезмәт коллективлары да билгеләп үтәләр* (Ш.Ч., 1995, 10 нояб.).

Югарыда каралган сүзләрдә чыганак телдә дә, арадаш телләрдә дә булмаган яңа мәгънә төсмерләре барлыкка килү күзәтелә. Кайбер яңадан активлашкан сүзләр элек татар телендә кулланылмаган, аңлатмалы сүзлектә теркәлмәгән, әмма чыганак яисә арадаш телдә булган мәгънәләрендә дә кулланыла

башладылар. Әйтик, **мәдәни** алынмасы аңлатмалы сүзлектә «культуралы, алдынгы», ә **мәдәният** «культура» мәгънәсендә генә теркәлгән (ТТАС, II, 417 б.); гарәп, фарсы теле сүзлекләрендә аларның «цивилизацияле», «цивилизация» мәгънәләре аерым күрсәтелә (АРС, 746 б.; РПС, 1013 б.). Цивилизация сүзенең төп «тегe яки бу иҗтимагый-экономик формация ирешкән иҗтимагый үсеш һәм материаль культура дәрәҗәсе» мәгънәсеннән тыш икенче «дөньядагы алдынгы илләрнең хәзерге культурасы, мәдәнияте» (ТТАС, 2005, III, 392 б.) мәгънәсенә ия булуын да искә алсаң, **мәдәният** сүзен цивилизациянең синонимы буларак куллану үзен аклый: *Сез тормыш шартларын яхшыртыгыз, тормышка **мәдәни** мәгънә бирегез!* (А-к, 1991, № 1, 13 б.). ***Мәдәният** (цивилизация) дигәндә нәрсә күз алдында тотыла соң?* (И-л, 1995, № 3, 44 б.)

**Мәҗмуга** сүзе аңлатмалы сүзлектә «җыентык, сайланма әсәрләр» мәгънәсендә теркәлгән (ТТАС, II, 425 б.). Гарәп, фарсы телләрендә дә ул шул ук һәм «коллекция» мәгънәләрендә кулланыла (АРС, 139 б.; РПС, 334, 816 б.). Ә төрек телендә бу сүз «журнал» мәгънәсенә ия (Тур.РС, 256 б.). Соңгы еллар татар матбугатында да **мәҗмуга** журнал сүзен алыштыру өчен шактый еш кулланыла, ягъни төрек теле тәэсирендә **мәҗмуга** сүзе яңа мәгънә алды дип расларга нигез бар: ... *«Химия и жизнь» **мәҗмугасында** ... кызыклы бер язма укырга туры килде* (Ш. К., 1994, 20 окт.).

Татарча үз атамасы булмаган, моңарчы рус-европа сүзләре белән белдерелгән төшенчәләрне атау өчен, аерым авторлар гарәп-фарсы алынмаларына аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Мондый — сүзнең төп мәгънәләре белән бәйләнешле — яңа мәгънәләр өстәүне шартлы рәвештә окказиональ кулланылыштагы мәгънә киңәю дип атарга була. Телдә ныгып калу мөмкинлеге бар дип исәпләнгән берничә мисал китерәбез: *Бөтенләйгә ташлау — ваз кичү түгел, төп шәхесне, ничектер төпләрәк, гыйльми **этрафта** киңрәк дәлилләп яктырту теләге белән* (С-ә, 1993, № 11, 9 б. — **этраф** — *иск.* Тирә-як, әйләнә-тирә — ТТАС, III, 687 б.); тарафның күплек формасы булган (АРС, 472 б.) бу сүз «әйләнә-тирә» мәгънәсен «тирәлек, мохит» дәрәҗәсенә кадәр киңәйтеп, **среда** сүзе урынына кулланылган. ... *«Эдельвейс» ширкате башлыгы Вилсур Садыйков Караваево **вилаятенең** администрациясеннән чакыру ала* (К.у., 1997, № 7, 18 б.) — вилаять — өлкә, губерна, провинция, штат (АРС, 913 б.; ГТРАС, 53 б.) сүзе биредә һәм башка кайбер авторларда район, микрорайон сүзләрен алыштыра.

Чыганак һәм арадаш телләрдә туры һәм күчерелмә мәгънәдә «табышмак» төшенчәсен аңлаткан **мөгаммә** сүзен (РПС, 235 б.; Тур.РС, 264 б.; ГТРАС, 356 б.) «Идел» журналы **проблема** сүзе урынына куллана: *Ләкин тирәндәрәк яткан зур **мөгаммәләргә** (проблема) бу ачкыч ярамый иде* (И-л, 1994, № 3, 3 б.). ***Мөгаммәнең** субъект ягы да бик мөһим* (И-л, 1995, № 8, 3 б.).

Мәрд (1. Ир, егет, кешелекле кеше. 2. Батыр, кыю — ГТРАС, 319—320 б.) сүзенең күплек формасы булган **мәрдәнне** әлегә уңышлы татарчасы булмаган **гражданин** сүзе урынына куллану, безнеңчә, игътибарга лаек: *Б.Фаткуллин: «Мин үземне Башкортстан һәм Татарстан **мәрдәне** (гражданы) итеп тоям»* (В.Т., 1993, 8 дек.).

**Өммәт** (1. Нинди дә булса бер дин тарафдары, бер пәйгамбәр өндәгән диндә булган кеше // бер динне тоткан халык, бер диндәге халык. 2. Милләт —ТТАС, III, 703 б.) сүзен этнос төшенчәсен бирү өчен куллану да нигезсез түгел, чөнки чыганак телдә аның беренчел мәгънәсе — гомумән халык (АРС, 42 б.): *Рәсәй чыннан да төрле **өммәтләр** (этнослар) өчен уртак йорт булды* (М-т, 1995, 25 март).

**Сәрмая** (берәр нәрсәне башлап-корып җибәрү өчен билгеләнгән акча, төп капитал // гомумән, акча, байлык — ТТАС, II, 711 б.) сүзе инвестиция урынына кулланыла: *Белград Косово өлкәсенә шактый гына **сәрмая** кертте* (З.-Т., 1995, 9 дек.).

Телебездә соңгы чорда гына ныклап кереп бара торган кайбер алынмаларның, чыганак тел белән чагыштырганда, татар телендә мәгънәләрен тарайтулары, конкретлаштырулары да күзәтелә. Аңлатмалы сүзлектә теркәлмәгән берәмлекләрдән мондыйларга **гамәлият**, **зиһният**, **көллият** сүзләрен кертергә була.

**Гамәлият** (гамалия) сүзе гарәп телендә 1. Җитештерү, производство. 2. Операция (төрле мәгънәләрдә). 3. Эш-хәрәкәт, процесс — АРС, 542 б.) мәгънәләренә ия. Соңгы еллар татар әдәби телендә аны, күрәсең, төрек йогынтысында (Тур.РС, 31 б.), нигездә, икенче, операция мәгънәсендә кулланалар: *... , хөкүмәт хисабына йөрәгенә **гамәлият** ясаткач, Батулла да тынып калды, өстәгеләрне тәнкыйтьләми* (М.ж., 1997, 7 март). *Америкалы Винона Мелик яман шеш авыруыннан 4 тапкыр **гамәлият** ясаткан* ... (М.ж., 2007, 4 май). Сирәк булса да аны беренче мәгънәсендә производство сүзе урынына файдалану очрый: *... **гамәлият** (производство) мөнәсәбәтләренә кагылышлы җөмләләр төзергә маташуым аркасында бөтенләй кыен хәлдә калдым* (А-к, 1993, № 10, 111 б.).

**Зиһният** сүзенә гарәп-рус сүзлегендә татарчага төгәл тәрҗемәләү авыр булган 1. Склад ума, образ мыслей. 2. Умственный уровень, умственное развитие, интеллект (АРС, 272 б.) аңлатмасы бирелгән. Хәзерге татар телендә исә ул конкрет «интеллект» мәгънәсендә кулланылышка кереп бара: *Дөресен әйткәндә, бүгенге горур төрек милләтенең **зиһниятен** барлыкка китерүдә безнең бабаларыбыз да олугъ өлеш керткән* (Т.я., 1995, 6 апр.). *Беренче чор тәҗрибә туплау, осталык яулау, акыл, **зиһният** уяту вакыты* (К.у., 1996, № 8, 162 б.).

**Көллият** сүзе гарәп телендә «тулылык, бөтенлек; колледж, факультет, югары хәрби уку йорты, университет» мәгънәләренә ия (АРС, 695 б.). XX йөзнең 90 нчы елларында җөмһүриятебездә Көнбатыш илләре үрнәгендә яңа типтагы тулы булмаган югары белем бирүче уку йортлары — колледжлар ачылгач, аларның «татарча» атамасы итеп нәкъ менә шушы сүз алынды: *Югары уку йортлары галимнәре, **көллият** һәм педучилище укытучылары төрле курслар буенча укыту программалары эшләделәр* (М-ф, 1998, № 5, 3 б.).

Татар телендә күптән кулланылган **хаким** (1. Судья, хөкем итүче, казый // арбитраж. 2. Өстенлек итүче ... 3. Хуҗа, түрә, башлык ... — ТТАС, III, 360 б.) сүзе дә шул чорда конкрет «шәһәр администрациясе башлыгы» мәгънәсендә мэр сүзе урынына кулланылышка керде: *25 сентябрь көнне шәһәр **хакиме** Р.Алтынбаев Чаллы предприятие һәм учреждениеләренең профсоюз комитетлары җитәкчеләре белән очрашу үткәрде* (Ш.Ч., 1996, 26 окт.). *Кичә Илдар Халиковның Чаллы шәһәре **хакиме** итеп билгеләнүенә 4 ел тулды* (Ш.Ч., 2007, 15 авг.). Аны башка элекке мәгънәләрендә куллану очраклары юк диярлек.

Димәк, телнең үз сүзләре кебек үк, гарәп-фарсы алынмалары да активлашу процессында мәгънәви үзгәрешләргә дучар ителә икән. XX гасыр ахыры — XXI йөз башында күп кенә алынма сүзләр чыганак телдә булмаган яңа мәгънәләр белән баедылар, кайберләре исә чыганак яки арадаш телдә булып та, татар телендә элек кулланылмаган мәгънәләрен үзләштерделәр; аерым авторлар тарафыннан татарча эквиваленты булмаган рус-европа сүзләрен алыштыру өчен Көнчыгыш алынмаларын яңа мәгънә төсмере өстәп файдалану да еш очрый. Шул ук вакытта кайбер күпмәгънәле алынмалар чор өчен актуаль конкрет мәгънәләрендә генә активлашалар.

### 2.5.2. Грамматик үзенчәлекләр

Кире кайткан гарәп-фарсы сүзләренең грамматик үзенчәлекләре вазифа-һөнәр атамаларында род категориясен аеруның активлашуында һәм кайбер алынмаларның лексик-грамматик чикләрен киңәйтеп куллануда чагылыш таба. Гомумән, күп гарәп алынмалары татар теленә үзләштерелү процессында аерым морфологик мәгънәләрен югалтып, башка лексик-грамматик классларга күчкәннәр (88. 332 б.). Соңгы елларда активлашкан алынмаларның да сүзлекләрдә, аерым алганда аңлатмалы сүзлектә теркәлгәннән үзгә функцияләрдә кулланылу очраклары күзәтелә. Аеруча исемнәрне сыйфат һәм, киресенчә, сыйфатларны исем буларак куллану еш очрый. Берничә генә мисал карап үтик.

Сыйфат ролендә кулланылган исемнәр: *Аның тарафыннан камчыланган үтә **бәйнәлмиләл** партократлар шагыйрь өстенә ничек ташланганнары хәтерегездәдер әле (М-с, 2000, № 12, 134 б. —* бәйнәлмиләл — *и. иск.* Интернационал — I, 206 б.). *Өлкән сыйныф укучыларының фәнни эшләре ... **мантыйк** яктан камил булулары белән аерылып торганлыгы билгеләнде* (С-й, 1995, 13 дек. — мантыйк — *и. иск. кит.* I. Логика. 2. Схоластика — ТТАС, II, 366 б.).

Исем буларак кулланылган сыйфатлар: *Бушлай, **мәҗрухлар** карарга керешүләре* (М. ж., 1996, 1 март — мәҗрух — *с. иск. кит.* Яралы, җәрәхәтле (ТТАС, II, 425 б.). *Күпме **фидаилар** башын салды, күзалламый илнең бетүен* (А-к, 1993, № 10, 39 б. — фидаи — *с. иск. к.* Фидакарь (ТТАС, III, 342 б.).

Алынмалар теориясеннән билгеле булганча, алучы телдә чит грамматик категорияләрнең күрсәткечләре үз мәгънәләрен югалталар. Татар телендә род категориясе булмаганлыктан, гарәп теленә хас җенес төрләнешендәге сүзләр дә, нигездә, мөзәккәр (мужской род) формасында гына алынган (88. 333 б.); фәкать хатын-кызларга караган кайбер сүзләрдә бу категория сиземләнсә дә, элекке әдәбиятта да, гарәп сүзенең мөәннәс (женский родта) килүе — бик сирәк очрый торган хәл (89. 814 б.). 80—90 нчы елларда гарәп-фарсы сүзләре белән мавыгу тенденциясе вазифасы-һөнәре буенча хатын-кызларны атаучы күп кенә сүзләрнең мөәннәс формасын активлаштыруга китерде: ... *Мәдинә апа Рәхимкулова — элекке СССР География җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, педагог, **галимә*** (С-ә, 1995, № 2, 12 б.). *Әмма алтын куллы **маһирәнең** төп иҗат юнәлеше һәм максаты борынгы татар традицион гамәли сәнгатен торгызу ...* (Нур, 1995, 23 март). ***Мөгаллимәнең** журналистик эшчәнлеге 1952 елда башлана* (С-ә, 1991, № 4, 6 б.). *Балтач «Сельхозтехника»сында **сәркәтибә** булып эшләүче Ризада ханым турында сүзем* (Т.я., 1994, 6 гыйнв.). *Түгәрәк өстәл янында сөйләшүдә ... «Бодрость» санаторий-профилакторие баш **табибәсе** Закирә Разетдин кызы Шәфыйкова ... катнашты* (С-ә, 1995, № 1, 7 б.). *Урыс һәм татар талиб вә **талибәләре** нисбәте уртача 50 гә 50 процент туры килеп бара* (А-к, 1993, № 11, 19 б.). *«Аргамак» журналының баш мөхәррире А.Хәлим ... **шагыйрәгә** бүләкне, махсус медаль һәм шаһәдәтнамәне тапшырды* (А-к, 1994, № 6, 116 б.).

Алда саналган мисаллардан узган гасырның 80 нче елларына кадәр совет чорында **мөгаллимә** һәм **шагыйрә** формалары гына әдәби телдә актив иде.

### 2.5.3. Фонетик-орфографик үзенчәлекләр

Ш.А.Рамазанов, М.И.Мәхмүтов, И.Ш.Әүхәдиев һәм башка галимнәрнең махсус хезмәтләрендә күрсәтелгәнчә, гарәп-фарсы алынмалары татар теленә фонетик яктан шактый үзгәртелеп, телебезнең закончалыкларына буйсындырылып кабул ителгәннәр. Әмма бу үзләштерү бөтен алынмаларда да йөз процентлы түгел, әйтик, күп кенә гарәп-фарсы сүзләре сингармонизм законына буйсынмаган. Шунысы кызык: соңгы елларда активлашкан алынмаларны язуда аларны фонетик, дөресрәге, орфографик үзләштерүне дәвам итәргә омтылыш сизелә. Аерым алынмалар, сүзлекләрдә башкача теркәлгән булуларына карамастан, йә алгы, йә арткы рәт сузыклары белән генә языла, сүз ахырындагы яңгырау тартыкларны саңгырау парлары белән алыштыру да очрый.

Түбәндә шундый кайбер мисалларны җөмләләрдән тыш кына карап үтәбез. Җәяләр эчендә чыганактан соң сүзнең аңлатмалы сүзлектәге, анда булмаган очракта, сылтама ясап, ГТРАСтәге формасы күрсәтелә:

**Сузыкларны рәт гармониясенә «буйсындырып» куллану:**

Әбүнә (К.у., 1997, № 7, 192 б. — абунә, ТТАС, II,, әгълә (К.у., 1993, № 10, 16 б. — әгъла — ТТАС, III, 671 б.), вакыф (К.у., 1995, № 9, 88 б. — вәкыф — ТТАС, I, 247 б.), виләят (З.-Т., 1994, 19 авг. — вилаять — ТТАС, I, 239 б.), дәрелфөнүн (К.у., 1992, № 12, 143 б. — дарелфөнүн — ТТАС, I, 291 б.), зәвек (И-л, 1996, № 1, 4 б. — зәвык — ТТАС, I, 352 б.), истирәхәт (И-л, 1995, № 12, 41 б. — истирахәт — ТТАС, I, 425 б.), кануный (А-к, 1994, № 2, 13 б. — кануни — ТТАС, II, 42 б.), кәсәфәт (Ю-ш, 1996, 19 окт. — кәсафәт — ТТАС, II, 68 б.), мәддә (А-к, 1993, № 3, 135 б. — маддә, ГТРАС, 249 б.), монафыйк (К.у., 1993, № 11, 79 б. — монафикъ — ТТАС, II, 102 б.), мөхтәрият (М. җ., 1995, 15 дек. — мохтарият, ГТРАС, 282 б.), нәмәгълүм (М-н, 2002, № 6, 200 б. — намәгълүм — ТТАС, II, 434 б.), шәрекъ (И-л, 1995, № 8, 20 б. — шәрык — ТТАС, III, 535 б.).

**Сүз ахырындагы яңгырау тартыкларны саңгыраулаштыру**: җиһат (Т. я., 1996, 10 дек. — җиһад, ТТАС, III, 794 б.), мәдәт (К.у., 1993, № 10, 143 б. — мәдәд, ГТРАС, 299 б.), өслүп (М. җ., 1995, 17 гыйнв. — өслүб, ГТРАС, 760 б.) һ.б. Шул ук вакытта ТТАСтә әйтелештәгечә саңгыраулаштырып теркәлгән икътисат (ТТАС, I, 377 б.) сүзе хәзер күбрәк икътисад (М-т, 1995, 7 гыйнв. һ.б.) формасында языла, орфографик сүзлектә дә ул шул формада бирелгән (ТТОС, 1983, 65 б.).

Алынмаларны шулай, беренчедән, телебезнең закончалыкларына буйсындырып кулланугa омтылыш, икенчедән, аларны төрле чыганаклар аша активлаштыру соңгы елларда сүзләрне төрле вариантларда куллануга китерде. Бер үк алынмаларның төрле газета-журналларда, хәтта бер үк матбугат органының төрле саннарында яисә бер үк әсәрнең төрле басмадагы вариантында төрлечә язылуы — соңгы елларда киң таралган күренеш. Монда шулай ук кайбер берәмлекләрнең аңлатмалы сүзлектә — бер, орфографик сүзлектә — икенче, ә алынмалар сүзлекләрендә өченче һ.б. язылышта теркәлүе дә үзенең тискәре ролен уйныйдыр. Бу төрлелек, нигездә, аерым сузыкларны калын һәм нечкә вариантта язуда, сүз азагында яңгырау һәм саңгырау тартыкларны бутауда, увуляр [к] авазын белдерүдә чагыла. Гарәп һәм фарсы телләрен, аларның орфографиясен белмәү, бу телләрнең сүзлекләренә мөрәҗәгать итмәү матбугатта күпсанлы хаталар һәм төрлечә язу күренешләрен китереп чыгара. Түбәндә шушы вариантларны конкрет хәрефләр чиратлашу принцибы буенча төркемнәргә туплап карыйбыз. Һәр вариантка бер генә чыганакка сылтама ясала, беренче урында ТТАСтә теркәлгән, ә анда булмаган сүзләрнең ешрак очраучы язылышы бирелә.

**1. Алгы һәм арткы рәт сузыкларын белдерүче хәрефләрне төрлечә язу очраклары**

***а/ә*** чиратлашуы

а) сүз башында һәм беренче иҗектә: абунә (К.к., 1998, 13 нояб.) — әбүнә (А-к, 1993, № 7, 3 б.), афәрин (С-ә, 1992, № 3, 20 б.) — әфарин (К.у., 1992, № 10, 16 б.), вәзгыять (М-т, 1994, 15 гыйнв.) — вазгыять (М-т, 1996, 24 февр.), вәкыф (М. җ., 1998, 20 февр.) — вакыф (В. Т., 1996, 17 май) — вәкиф (З.-Т., 1995, 10 окт.), гамалият (В. Т., 1995, 30 июнь) — гәмәлият (А-к, 1993, № 10, 3 б.), дәрелфөнүн (К.у., 1992, № 12, 143 б.) — дарелфөнүн (Я-н, 1995, № 1, 21 б.), җәсәд (В. Т., 1995, 24 февр.) — җасәд (И-л, 1995, № 2, 29 б.), кәсәфәт (К.у., 1993, № 1, 158 б.) — касафат (А-к, 1993, № 1, 6 б.), маддә (М-т, 1995, 10 июнь) — мәддә (А-к, 1993, № 9, 90 б.), назари (М-т, 1994, 26 февр.) — нәзари (М-т, 1995, 25 март), назария (ТТАС, II, 432 б.) — нәзария (К.у., 1995, № 5, 175 б.), назарият (ТТАС, II, 432 б.) — нәзарият (И-л, 1995, № 9, 54 б.), сангатькяр (К.у., 1992, № 10, 154 б.) — сәнгатькәр (З.-Т., 1994, 14 окт.), хәрәм (С-ә, 1995, № 4, 23 б.) — харам (С-ә, 1992, № 7, 19 б.), шәһадәтнамә (К.у., 1990, № 1, 62 б.) — шаһәдәтнамә (А-к, 1992, № 11—12, 56 б.);

ә) икенче иҗектә: әгъла (А-к, 1995, № 8, 11 б.) — әгълә (К.у., 1993, № 10, 16 б.), афәрин (С-ә, 1992, № 3, 20 б.) — әфарин (К.у., 1992, № 10, 16 б.), вилаять (В. Т., 1995, 25 гыйнв.) — виләят (В.Т., 1994, 19 авг.), гавам (И-л, 1995, № 10, 43 б.) — гавәм (А-к, 1996, № 4, 57 б.), гаммәви (М.җ., 2006, 25 авг.) — гаммави (М. җ., 2007, 13 апр.), гамәлият (В.Т., 1994, 3 сент.) — гамалият (В. Т., 1995, 30 июнь), җәсад (М-т, 1995, 25 нояб.) — җәсәд (В.Т., 1995, 24 февр.), кәсәфәт (К.у., 1993, № 1, 158 б.) — кәсафәт (С-ә, 1993, № 2, 6 б.), мәрасим (С-й, 1995, 21 гыйнв.) — мәрәсим (И-л, 1996, № 4, 40 б.), мөхтарият (С-ә, 1992, № 9, 8 б. — мөхтәрият (М.җ., 1995, 15 дек.), мөһаҗир (М-с, 1992, № 6, 87 б.) — мөһәҗҗир (А-к,

1996, № 1, 82 б.) — сәркәтип (Т-н, 1995, № 1—2, 121 б.) — сәркатиб (А-к, 1991, № 1, 16 б.), тәхәллүс (И-л, 1996, № 2, 55 б.) — тәхаллус (А-к, 1991, № 1, 89 б.), хәрәм (С-ә, 1995, № 4, 13 б.) — харам (С-ә, 1992, № 7, 19 б.), хөтбә (И-л, 1994, № 9, 55 б.) — хотьба (С-ә, 1995, № 6, 16 б.), шәһадәтнамә (К.у., 1990, № 1, 62 б.) — шаһәдатнамә (А-к, 1992, № 11—12, 56 б.), ширкәт (Т. я., 1995, 18 май) — ширкать (Т.я., 1995, 13 апр.);

б) өченче иҗектә: истирахәт (М. җ., 1996, 26 гыйнв.) — истирәхәт (И-л, 1995, № 12, 41 б.), касафат (А-к, 1993, 31, 6 б.) — касәфәт (И-л, 1994, № 9, 5 б.), һөнәрмәнд (ТТАС, III, 827 б.) — һөнәрман (М. җ., 1998, 29 гыйнв.), шәһадәтнамә (К.у., 1990, № 1, 62 б.) — шаһәдатнамә (А-к, 1992, № 11—12, 56 б.);

***и/ый*** чиратлашуы

а) сүз уртасында: имам-хатыйб (З.-Т., 1995, 17 нояб.) — имам-хатиб (С-й, 1996, 28 сент.), монафикъ (И-л, 1995, № 1, 46 б.) — монафыйк (К.у., 1993, № 11, 79 б.), фазыйләт (З.-Т., 1994, 15 дек.) — фазиләт (Нур, 1995, 31 гыйнв.);

ә) сүз азагында: икътисади (С-ә, 1992, № 4, 7 б.) — икътисадый (Нур, 1995, 9 дек.), инкыйлаби (Т-н, 1996, № 8, 62 б.) — инкыйлабый (З.-Т., 1995, 9 дек.), кануни (А-к, 1992, № 11—12, 7 б.) — кануный (А-к, 1994, № 2, 13 б.).

***ы/и*** чиратлашуы

Вакыф (В. Т., 1996, 17 май) — вакиф (З.-Т., 1995, 10 окт.).

***а/ә/я*** чиратлашуы

Әгъла (А-к, 1995, № 8, 11 б.) — әгъләә (К.у., 1993, № 10, 16 б.) — әгъля (К.у, 1995, № 1, 167 б.), катип (З.-Т., 1995, 24 нояб.) — кятиб (А-к, 1993, № 12, 210 б.), лазем (М.җ., 2006, 18 авг.) — лязим (В.Т., 1995, 28 апр.), ляихә (Т-н, 1993, № 1, 46 б.) — лаихә (И-л, 1995, № 4, 58 б.), сәнгатькяр (К.у., 1992, № 10, 154 б.) — сәнгатькәр (З.-Т, 1994, 14 окт.).

***и/ү*** чиратлашуы

Мәүзигъ (А-к, 1995, № 10—11, 76 б.) — мәүзүг (К.у., 1991, № 3, 151 б.).

***ы/е*** чиратлашуы

Зәвык (Нур, 1994, 14 февр.) — зәвекъ (И-л, 1996, № 1, 4 б.), шәрыкъ (С-ә, 1993, № 4, 2 б.) — шәрекъ (И-л, 1994, № 8, 23 б.).

***ү/у*** чиратлашуы

Әбүнә (А-к, 1993, № 7, 3 б.) — әбүнә (К.у., 1997, № 4, 142 б.), тәхәллүс (И-л, 1996, № 2, 55 б.) — тәхаллус (А-к, 1991, № 1, 89 б.).

***ө/о*** чиратлашуы

Мөсафирханә (С-ә, 1994, № 2, 27 б.) — мосафирханә (К-н, 1996, № 3—4, 79 б.), хөтбә (И-л, 1994, № 9, 55 б.) — хотба (С-ә, 1995, № 6, 16 б.).

***е/ө*** чиратлашуы

Менбәр (ТТАС, II, 379 б.) — мөнбәр (С-ә, 1993, № 1, 20 б.).

***ө/э*** чиратлашуы

Өслүп (М. җ., 1995, № 3, 8 б.) — эслүб (К.у., 1998, № 6, 166 б.).

**2. Тартык аваз хәрефләрен төрлечә язу**:

1. Саңгырау һәм яңгырау тартыкларның чиратлашуы

**т/д**: җиһад (Нур, 1995, 23 май) — җиһат (Т. я., 1996, 10 дек.), иҗтиһат (А-к, 1993, № 4—5, 106 б.) — иҗтиһад (Т-н, 1995, № 5—6, 41 б.), икътисат (В. Т., 1994, 3 сент.) — икътисад (М-т, 1995, 7 гыйнв.), мөрит (А-к, 1994, № 8, 129 б.) — мөрид (К.у., 1996, № 2, 36 б.), тыйбабәт (З.-Т., 1994, 5 авг.) — тыйбабәд (З.-Т., 1994, 30 сент.).

**п/б**: имам-хатип (З.-Т., 1995, 17 окт.) — имам-хатыйб (З.-Т., 1995, 17 нояб.), инкыйлап (И-л, 1995, № 2, 7 б.) — инкыйлаб (А-к, 1992, № 1, 12 б.), катип (З.-Т., 1995, 24 нояб.) — кятиб (А-к, 1993, № 12, 210 б.), кәбап (А-к, 1994, № 8, 13 б.) — кәбаб (А-к, 1995, № 2, 8 б.), мәзхәб (И-л, 1994, № 6, 67 б.) — мәзһәп (А-к, 1996, № 2, 90 б.), мәктүп (И-л, 1995, № 7, 49 б.) — мәктүб (И-л, 1995, № 4, 56 б.), сәркәтип (Т-н, 1995, № 1-2, 121 б.) — сәркатиб (А-к, 1991, № 1, 16 б.);

2. тартыгын **з/д** хәрефләре белән язу: зарбә (М-т, 1996, 15 май) — дарбә (З.-Т., 1995, 12 дек.).

3. [**һ**] авазын **х** хәрефе белән язу: мәзһәб (И-л, 1994, № 6, 67 б.) — мәзхәб (И-л, 1995, № 9, 61 б.), мөһәндис (Ш.Ч., 1997, 31 окт.) — мөхәндис (Т. я., 1995, 5 авг.).

4. **ъ** хәрефен кулланып һәм аннан башка язу

а) сүз азагында: иттифак (Ш. Ч., 1997, 5 март) — иттифакъ (А-к, 1996, № 7, 42 б.), мәүзигъ (А-к, 1995, № 10—11, 76 б.) — мәүзүг (К.у., 1991, № 3, 151 б.), монафикъ (И-л, 1995, № 1, 46 б.) — монафыйк (К.у., 1993, № 11, 79 б.), шәрык (ТТАС, III, 535) — шәрыкъ (С-ә, 1993, № 4, 2 б.) — шәрекъ (И-л, № 8, 23 б.);

ә) сүз уртасында: тәкъбир (Ш. Ч., 1995, 5 май) — тәкбир (А-к, 1994, № 5, 101 б.), тәрәкъкый (З.-Т., 1995, 10 нояб.) — тәрәккый (ТТАС, III, 229 б.), тәрәккыят (М-т, 1995, 24 июнь) — тәрәкъкыят (М-т, 1995, 18 март).

5. **ь** хәрефе белән язуга бәйле вариантлар

а) сүз азагында: вилаять (В. Т., 1995, 25 гыйнв.) — виләят (З.-Т., 1994, 19 авг.), мохтарияlь (Т-н, 1993, № 1, 32 б.) — мохтарият (С-ә, 1992, № 9, 6 б.), тәрәккыят (М-т, 1995, 24 июнь) — тәрәккыять (А-к, 1993, № 3, 77 б.), хөтбә (И-л, 1994, № 9, 55 б.) — хотьба (С-ә, 1995, № 6, 16 б.), ширкәт (Т. я., 1995, 18 май) — ширкать (Т. я., 1995, 13 апр.);

ә) сүз уртасында: кальб (А-к, 1993, № 3, 94 б.) — калеб (К.у., 1992, № 2, 120 б.), хөтбә (И-л, 1994, № 9, 55 б.) — хотьба (С-ә, 1995, № 6, 16 б.).

Бер үк сүзне хәтта дүрт төрле язу очрагы да бар: кәсәфәт (К.у., 1993, № 1, 158 б.) — кәсафәт (С-ә, 1993, № 2, 6 б.) — касафат (А-к, 1993, № 1, 6 б.) — касәфәт (И-л, 1994, № 9, 5 б.). Безнең картотекада шулай ук 3 вариантта язылган 12 алынма теркәлгән, ә ике вариантта кулланылучы сүзләрнең саны 50 дән артык. Биредә басмадагы хата (опечатка) яисә сүзне аңламыйча кулланып язу очрагы буларак кабул ителердәй мисаллар исәпкә алынмаган. Аеруча [ә] һәм [а] сузыкларын бутап язу еш очрый (утыздан артык сүз), [и] [ый] сузыкларын куллануда да төрлелек күп. Тартыклар өлкәсендә сүз азагында яңгырау-саңгырауларны вариатив кулланудан тыш гарәп теленең специфик авазларын төрлечә язу очрый. Моннан тыш увуляр һәм тел арты [к], [г] авазларын һәм алардан соң килүче алгы яки арткы рәт сузыкларны белдерү, я хәрефенең эчтәлеген ачыклау максатыннан калынлык (ъ) — нечкәлек (ь) билгеләре куллану яки кулланмауга бәйле вариантлар да шактый. Күренүенчә, яңадан активлашучы Көнчыгыш алынмаларын язуда төрлелек, бердән, бөтенләй башка фонетик системага караган гарәп, фарсы телләре сүзләрен телебезнең үз фонетик закончалыкларына буйсындырып куллану тенденциясен чагылдырса, икенчедән, бер үк сүзне төрлечә язу татар теле алфавит һәм орфографиясенең бик үк камил булмавы, гарәп-фарсы алынмаларын гамәлдәге графикада язу принципларының тулысынча эшләнеп-канунлашып бетмәве белән дә аңлатыла. Әйтик, теге яки бу язылышны законлаштырып тәкъдим итәргә тиеш булган орфографик сүзлек тә күп кенә гарәп-фарсы алынмаларын ике вариантта тәкъдим итә: инкарь һәм инкяр, халәт һәм хәләт, хәрам һәм хәрәм, фидакарь һәм фидакяр, ядкарь һәм ядкәр һ.б. (ТТОС, 67, 221, 225, 228, 256 б.). Гарәп, фарсы телләрендәге күп кенә авазлар өчен кириллицада хәрефләр булмаганлыктан, бу телләрдән алынмаларны, рус-европа алынмаларыннан үзгә буларак, график принциптан чыгып язып булмый. Шунлыктан, безнең карашыбызча, аларның язылышын мөмкин булган кадәр әйтелешкә якынайтып, ягъни телебезнең фонетик законнарына таянып, шулай ук матбугатта кулланылу тенденцияләрен дә искә алып унификацияләү галимнәребез алдында торган кичектергесез әһәмиятле бурычларның берсе. Ф.Ә.Ганиев белән И.И.Сабитова тарафыннан 2002 елда чыгарылган орфографик сүзлек бу юнәлештә җитди адым буларак бәяләнергә хаклы.

### 2.5.4. Алынмаларны аңлатмалары белән параллель куллану

Күп гарәп һәм фарсы алынмаларының сүзлекләрдән төшерелеп, пассив кулланылышка күчүе нәтиҗәсендә инде берничә буын бу сүзләрсез яши. Шуңа да үзләре яңадан кулланылышка керткән гарәп-фарсы алынмаларының күпчелек укучы өчен аңлаешсыз икәнен истә тотып, авторлар һәм редакторлар еш кына аларны текстта аңлатмалар белән бирәләр. Бирелеше ягыннан бу аңлатмалар өч төрле: 1) җәя эчендә; 2) сызыкча аша; 3) ягъни теркәгече ярдәмендә өтердән соң аныклау. Аныклаучы буларак бу алынмаларны күбрәк интернациональ һәм рус сүзләре (а), аерым очракта татар сүзләре яки сүзтезмәләр (ә) алыштыра.

1. а) җәя эчендә интернациональ яисә русча эквивалентлары белән аңлатылган сүзләр кулланыла: *Алар ... сталинизмның **әсаси (фундаменталь)** төзелмәләрен һәм кагыйдәләрен **инкыйлаби (революцион)** рәвештә яңадан кору иде* (И-л, 1995, № 6, 49 б.). *Рәсми кимәлдә әле һаман империячел **бәйнәлмиләл (интернациональ)** идеология тантана итә* (И-л, 1996, № 3, 2 б.). *... Наилә Вильданова **вакыфка (фонд)** үзләрендә ясалган дивар сәгате бүләк итте* (М.җ, 1996, 8 март). ***Гаделия (юстиция)** кануннары ... гореф-гадәтләрдә беркетелгән яшәеш тәртипләренә тиңләшә алмыйлар* (М-т, 1995, 7 гыйнв.). *Татар тарихы төрле төзелешле һәм төрле кимәлдәге этник **гонсырларны (компонентлар)** исәпкә алган киң һәм системалы тарих кына була ала* (И-л, 1996, № 3, 73 б.). *... үзлегеннән укып, өйрәнеп тә **дәһри (атеист)** яки диндар булырга мөмкин* (В.Т., 1996, 19 март). *Җәмгыятьтә **җәмгыяви (социаль)**, икътисади һәм сәяси үзгәрешләр бара ...* (М-ф, 1996, № 1, 10 б.). *Дини тәгълиматка җимергеч **зарбә (удар)** ясарга тырыша ...* (М-т., 1996, 15 март). *Америкада яшәгән **зәнҗиләр (негр)** ... Вашингтон шәһәрендә зур **нәмаеш (демонстрация)** уздырдылар* (З.-Т., 1995, 3 нояб.). *Хәзерге вакытта республикада ... 6 **көллият (колледж)** ... эшли* (М-ф, 1995, № 1, 3 б.). *Авыл ул үзенә күрә Җир шарының бер **кыйтгасы (материк)** сыман ...* (Т.як, 1996, 13 авг.). *... 1 февраль **лаиһәсендә (проект)** сезнең дә имза тора* (И-л, 1995, № 4, 58 б.). *Япон конституциясендә сугыштан баш тарту турында **маддә (статья)** бар* (Т.я., 1998, 10 сент.). *Шәһәрләр, билгеле бер өлешләргә аерылып, **мәхәлләләргә (квартал)** бүленгәннәр* (З.-Т., 1995, 11 июль). *Укулары һәм кәсепләре буенча баш **мөһәндис (инженер),** журналист, юрист, педагог, балалар бакчасы укытучысы һ.б. булганнары да бар* (К.у., 1999, № 10, 165 б.);

ә) алынмалар җәя эчендә татар сүзләре һәм сүзтезмәләре белән аныклана: ***Бәгъзесен (кайберсен)*** *һичкемгә әйтмәскә кушты, бәгъзесен* ***өммәтенә (пәйгамбәргә иярүче нәселгә)*** *ирештерергә боерды* (Ш.Ч., 1995, 15 дек.). *Төркиядән берничә* ***вилаять (өлкәләр)*** *фольклор ансамбльләре катнашкан* (З.-Т., 1995, 3 окт.). *Чөнки* ***гарби (көнбатыш)*** *дөнья, гарәп илләре һәм Кытай тагын да зуррак мәдәни гомумилекнең өлешләре булып сакланмыйлар* (И-л, 1994, № 3, 44 б.). «*Шулай чорнап тора безне* ***җәһаләт (наданлык)****, шулай тын итмә!» — ди безгә* ***сәфаләт (түбәнлек)*** (В.Т., 1994, 6 авг.). *Татар халкының милләт буларак* ***инкыйразга (бетүгә)*** *табан баруын ачык тоеп, бик борчылып яшәдек ...* (К.у., 1995, № 8, 175 б.). *Исемнәрдәге хәрефләргә дә кеше* ***кальбе (күңеле)*** *үз мөнәсәбәтен белдерә* (Т.я., 1998, 1 окт.).

2. а) гарәп һәм фарсы алынмалары сызыкча аша рус-европа сүзләре белән аныклана: *Аделаидада Англия королевасының вәкиле Татарстан вәкиллеге оештырган* ***зыяфәткә-банкетка*** *да килде* (М.җ., 1995, № 24, 14 б.). *Ми күзәнәкләре дулкынына хәзер* ***инкыйлаби-революцион*** *көрәш турындагы хис-тойгы, ут чаткылары килеп керде* (К.у., 1996, № 11, 12 б.). ***Инша-сочинениеләрнең*** *темаларын дөрес формалаштырмыйлар ...* (В.Т., 1996, 23 авг.). *Кытайда бөтен мәмләкәтләрне тетрәткән* ***мәдәният инкыйлабы-культура революциясе*** *чәчәк аткан чор* (С-ә, 1992, № 3, 23 б.). *Алар ... аның тоткан* ***мәсләген-позициясен*** *яклыйлар ...* (Т-н, 1993, № 1, 3 б.). *... әдәби* ***тәхәллүсе-псевдонимы*** *белән әйтсәк — Рафаэль Сибат ...* (М.җ., 2006, 10 нояб.). *Шулай итеп, безгә, асылда, мәсәл сюжеты һәм аның* ***һөҗү-сатира*** *максатларын да файдалану кулай* (К.у., 1995, № 8, 180 б.);

ә) алынмалар сызыкча аша татар сүзләре белән аныклана: *Кадерле* ***мөштәриләр-газета укучылар!*** (М.җ., 1995, № 1, 24 б.). ***Сөхбәт-әңгәмә*** *булгач, гәп корып утыручы ике дилетант та кирәк бит инде* (И-л, 1995, № 11, 57 б.). *Ул* ***фәрман-боерык*** *биреп кенә утыра ...* (С-й, 1994, 4 май).

3. Алынмалар **ягъни** теркәгече белән өтердән соң аныклана: *Борынгы татар* ***гангәнәсе, ягъни традициясе*** *буенча батыр үзе ... тәкәне шул ук мәйданда Илаһи көчкә корбан китерергә тиеш* (Т.я., 1997, 29 авг.). *Инде минә кышкы* ***тәгътил, ягъни каникул*** *башланды ...* (Я-н, 1998, № 2, 13 б.).

Сирәк очракта аныклаулы компонент өтер аша синоним буларак кына да бирелергә мөмкин: *Остаз аның углын алып калды, бөтен* ***иҗтиһадын, тырышлыгын*** *биреп өйрәтте ...* (Я-н, 1996, № 1, 12 б.).

Бер үк алынма югарыда күрсәтелгән алымнарның төрлесе ярдәмендә дә аңлатыла ала: *Соңгы ун елда ... илдә* ***ислах (реформа)*** *хәрәкәте пәйда булды* (И-л, 1995, № 6, 44 б.). — **«Ислах-реформа»**ларына төкереп бирим әле (А-к, 1993, № 4—5, 48 б.). — ***Ислах, ягъни үзгәртеп кору*** *еллары* (А-к, 1993, № 9, 33 б.). *Миңа калса, иң әүвәл милли мәсьәләнең* ***нәзарияте (теориясе)*** *булырга тиештер* (И-л, 1995, № 1, 43 б.). — ***Сионизм (ягъни бөтен дөнья яһүдиләрен Фәләстыйнга кайтару назариясе — теориясе)*** *хәрәкәтенең башы итеп тарих китапларында 1898 елның 29—31 августында Швейцариянең Базель шәһәрендә үткәрелгән конгресс күрсәтелә* (З.-Т, 1997, 28 март) һ.б.

Аныклаучы компонент составында башка, элегрәк үзләштерелгән гарәп-фарсы алынмалары да кулланыла ала: ***Илаһи куә, ягъни кабилият****, олуг сәләт, бүгенгечә әйтсәк,* ***табигать (Аллаһы)*** *биргән талант* (М.җ., 1995, № 8, 14 б.).

Мисаллардан күренүенчә, әлегә киң кулланылышка кереп китмәгән «кире кайтарылучы» гарәп-фарсы алынмалары барыннан да элек җәя эчендә үзләре алыштырырга тиешле рус-европа чыгышлы сүзләр ярдәмендә аңлатылалар. Баштагы чорда текст эчендә шундый аңлатмалар белән бирелгән алынмаларның акрынлап әдәби телдә ныгып китүе — тарихта билгеле күренеш; әйтик, Петр I чорында рус теле үзләштергән Европа сүзләренең күбесе шундый юл үткән (176. 261—262 б.). Алда саналган алынмаларның да шактые соңгы еллар матбугатында, гадәттә, аңлатмасыз гына кулланыла.

### 2.5.5. Гарәп-фарсы сүзләрен куллануда хаталар

Шәрык алынмалары белән мавыгу еш кына кайбер сүзләрнең мәгънәсен дөрес аңламыйча яисә чыганак тел үзенчәлекләрен сакламыйча, ялгыш куллануга да китерә. Берничә характерлы мисал китерик: *Дөнья тарихында бик сирәк очрый торган мондый ... гайре инсани* ***дәляләтнең (пропагандаының)****, илдәге рухи тәрбия системасының тәмам җимерелүе ...* (М-т, 1996, 13 гыйнв.). — **Дәлаләт** сүзе татар теленә «эшкә һ.б. берәр җиргә урнашуда берәүгә ярдәм күрсәтеп, аның өчен җаваплылыкны үз өстеңә алу; рекомендация» (ТТАС, I, 318 б.) мәгънәсендә алынган. Дөрес, чыганак телдәге төп мәгънәсе «күрсәтү, исбатлау, дәлилләү» (АРС, 259 б.; ГТРАС, 114 б.) аны пропаганда сүзе урынына куллануга нигез бирә, әмма бер үк гарәп сүзен берьюлы ике интернационализмны (рекомендация һәм пропаганда) алыштыру өчен файдалану уңышлы түгел.

*Кызның бер* ***кәррә*** *гаебе юк* (И-л, 1995, № 9, 30 б.). **Кәррә** «мәртәбә, тапкыр» (ТТАС, II, 253 б.), «кат» (ГТРАС, 225 б.) сүзе гарәп телендә дә шул ук төшенчәне белдерә (АРС, 253 б.). Аны «бөртек, тамчы; гомумән, нәрсәнең дә булса бик аз микъдарда булуы» мәгънәсендә куллану, күрәсең, гарәп телендәге охшаш күрр () — «бөртекле матдәләрне үлчәү берәмлеге», ягъни бөртек (АРС, 681 б.) сүзе белән бутауга нигезләнгән.

*Шәһәр төзү **мәсләге** икътисади хаҗәтләр аркасында барлыкка килде* (А-к, 1993, № 4—5, 86 б.). Биредә **мәсләк** (1. Караш, дөньяга караш. 2. *куч.* Принцип, максат; тоткан юл, юнәлеш — ТТАС, II, 421 б.) идея сүзе урынына кулланылган.

*Кешеләр сугышны тизрәк бетерү, җиңү көнен күрү **намена** омтылып ... яшәде* (С-ә, 1996, № 10, 34 б.) ***-нам*** (1. Исем. 2. Данлы исем, яхшы ат — ТТАС, I, 441 б.) алынмасын бу мәгънәдә куллану — күрәсең, рус телендәге «во имя» гыйбарәсен уңышсыз калькалаштыру нәтиҗәсе.

*Сайлаучылар билгеле бер участокка беркетелмәгәнлектән, кулында нинди дә **низамнамәсе** булган һәр кеше теләсә кайсы участокка барып сайлый ала иде* (М-т, 1996, 8 гыйнв.). — «Берәр төрле мәсьәләгә карата язылган закон, кагыйдәләр җыелмасы, устав» (ТТАС, II, 442 б.) мәгънәле **низамнамә** сүзе биредә ялгыш «документ» мәгънәсендә кулланылган.

**Хакимият** сүзенең үзенең төп «власть, хөкүмәт, дәүләт идарәсе» (ТТАС, III, 360 б.) мәгънәсендә активлашуына югарыда мисал китерелгән иде. Соңгы елларда аны төрле мәгънәләрендә администрация сүзе урынына да кулланалар: *Шәһәр Советы һәм **хакимияте** халык мәгарифенә игътибарлы булды* (М-ф, 1995, № 2, 1 б.). *Предприятие **хакимияте**, урыннардагы башкарма **хакимият** һәм хокук саклау органнары ...* (К-н, 1995, № 5—6, 19 б.). Тел галимнәренең **хакимият** сүзен бу мәгънәдә кулланырга ярамавын дәлилләп махсус мәкаләләр бастыруына да карамастан (104. 125—127 б.; 37. 19 б. h.б.), матбугат органнары даими рәвештә администрация төшенчәсен шушы сүз белән белдерүне дәвам итәләр.

Алынмаларның мәгънәсен төгәл белмәү плеоназм күренешенә дә китерә: ***Гавам халкыннан** сирәк очрый торган сыйфатлар отып алам* (А-к, 1991, № 1, 43 б.). — **Гавам** үзе үк «халык, халык массасы ... » төшенчәсенә ия (ТТАС, I, 250 б.). *Шәрыкта яшәгән, шунда **гыйлем тәхсил иткән** бала шул ...* (М-т, 1994, 26 февр.). — **Тәхсил** үзе «уку, белем алу, гыйлем алу»ны аңлата (ТТАС, III, 234 б.).

*Сезнең **әмернамәгез** белән килешмим* (К.у., 1996, № 11, 18 б.). *«Миңа сәяси **васыятьнамәләр** белән чыгарга иртә әле», — диде ул* (В. Т., 2007, 27 апр.) җөмләләрендәге әмернамә, васыятьнамә сүзләрендә ***-намә*** компоненты артык, чөнки биредә сүз нindидер кәгазь турында бармый.

Гарәп-фарсы алынмалары белән мавыгу, чыганак тел һәм татар теле закончалыклары күзлегеннән караганда, дөрес булмаган кайбер сүз-формалар ясалуга да китерде: *... ул ... радиога **нәфисәи** тапшырулар редакциясенә режиссер булып китә* (М.җ., 1997, 26 сент.). *... милли **нәфисәи** сәнгатьнең казык баганалары образын тудыру ай-һай авыр эш* (М.җ., 1997, 18 апр.). **Нәфис** сүзе үзе үк татар телендә сыйфат сүз төркеменә карый һәм аңа алынма сыйфат ясагыч кушымча өстәүнең хаҗәте юк; соңгы җөмлә авторы белдерергә теләгән мәгънәне бирүче «нәфис сәнгать» төшенчәсе аңлатмалы сүзлектә дә теркәлгән (ТТАС, II, 454 б.). Арадаш фарсы телендә (гарәп телендә нәфис — «кыйммәтле» мәгънәсенә генә ия — АРС, 820 б.) **нәфис** сыйфат сүз төркеменә карый, ә **нәфиси**, киресенчә, абстракт исем (ПРС, II, 654, 650 б.).

*Зарурият кына түгел, **мөһимият** тә бар әле* (С-ә, 1994, № 4, 15 б.). — Гарәп телендә мөһим сүзеннән ясалган абстракт исем — әһәмият, ә кушымчалау юлы белән бөтенләй башка мәгънәдәге мөһиммат формасы ясала (АРС, 858—859 б.).

*Һәр халыкта рус шовинистлары арасында гына түгел, ялган тарих язучы намуссыз **мөтәгалимнәр** тирес корты урынына ни өчен үрчи икән?* (М-н, 2002, № 6, 176 б.) җөмләсендә автор, күрәсең, Г.Тукай әсәре буенча киң билгеле мөтәшагыйрь (ялган шагыйрь, үзен-үзе шагыйрь санаучы; шагыйрь булып маташучы — ГТРАС, 414 б.) сүзенә аналогия буенча «ялган галим» мәгънәле мөтәгалим неологизмы «ясаган», гәрчә гарәп телендә мөтәгаллим «өйрәнүче, укучы, шәкерт» мәгънәсенә ия (ГТРАС, 399 б.).

*Сүз аланында сак бул, **каләмкяр*** (В. Т., 2006, 3 нояб.) «каләм» гарәп тамырына ***-кяр*** фарсы кушымчасы ялгап ясалган неологизм да урынлы түгел, чөнки автор әйтергә теләгән «язучы кеше, каләм белән эш итүче» төшенчәсен бирү өчен электән үк реаль каләмкәш алынмасы кулланылган (ГТРАС, 201 б.).

Татар теленең үз сүзләренә абсолют синоним — дублет булган гарәп-фарсы компонетлы яңа сүзләр ясау яки искергәннәрен активлаштыру да үзен акламый: *Русиянең дистәләгән төбәкләреннән килгән артистлар, иҗат төркемнәре Минскиның **мәркәзи** мәйданнарын шаулаттылар* (В.Т., 2005, 1 июль).

Активлашкан гарәп-фарсы алынмаларын куллануда иң киң таралган хаталарның берсе дип охшаш әйтелешле (язылышлы) сүзләрне бутауны күрсәтергә кирәк:

*Аңлап бетереп булмаслык бу **җәһел** илдә ...* (М.җ., 1996, 26 гыйнв.). Биредә «наданлык, аң-белемсезлек» (ТТАС, III, 843 б.), «аңгыралык, томаналык» (ГТРАС, 778 б.; АРС, 146 б.) мәгънәле абстракт исем **җәһел** шул ук тамырлы **җаһил** (1. Надан ... . 2. Икейөзле, монафикъ (ТТАС, II, 753 б.) сыйфаты урынына язылган.

*Күгәрченнәрнең чәлтерләре сабый чагындагы шикелле зәңгәр **камәрдән** чигелгән, ә менә чыпчыкларның күзләре бәс төртке белән бизәлгән булырга тиеш* (А-к, 1996, № 9, 10 б.). **Камәр** (ай — ГТРАС, 201 б.) сүзе **кәмәр** (билбау, эзәр — ГТРАС, 224 б.) урынына кулланылган. Гарәп графикасында беренчесе «каф», икенчесе «кяф» тартыгы белән языла (АРС, 658, 659 б.).

**Матбага** (типография (ТТАС, II, 371 б.; АРС, 468 б.) сүзен **матбугат** белән бутау да еш кына күзәтелә: *Журнал белән нәшрият исемнәре ягыннан адаш булсалар да, «аш — ашка, урын — башка» дигәндәй, аларның һәркайсы — мөстәкыйль эш итүче* ***матбага*** *органы* (М-ф, 1995, № 4, 58 б.). *Бүгенге* ***матбагада*** *төшенке сүзләрне татар хакында бик еш язалар* (К.у., 1998, № 8, 159 б.).

Абруйлы матбугат органнарында зур язучылар тарафыннан да **мигъмар** (төзүче, архитектор (ГТРАС, 258 б.) сүзен **мөгамәр** (озын гомерле, карт (ГТРАС, 357 б.) белән бутау кебек хаталар очрый: *Уклейн Европада мәшһүр* ***мөгамәр*** *булган, Лиссабонда тимер юл вокзалын һәм Прагада бер министрлык бинасын аның проектлары буенча салганнар икән* (К.у., 1993, № 11, 82 б.).

Бу характердагы иң киң таралган хаталарның берсе — рус теленә дә узган гасыр ахырында гына кергән презентация сүзен **тәкъдим итү** урынына **тәкъдир итү**, тәкъдирләү гыйбарәләре аша тәрҗемә итү (37. 20 б.). Күпмәгънәле тәкъдир сүзенең татар телендә «бәя бирү, бәяләү» (ТТАС, III, 213—214 б.; АРС, 624 б.) мәгънәсе нигезендә ясалган бу формалар белән презентация сүзе арасында бернинди дә уртаклык юк: презентация — «ниндидер яңа әйбер, эшне тәкъдим итү акты» (СИС, 1997, 202 б.), «тәкъдир итү, тәкъдирләү — берәүнең эшләгән эшен тану, уңай бәя бирү» (ТТАС, III, 214 б.): *Әле менә шушы көннәрдә генә дә бу мәктәп-гимназия каршында оештырылган «Идел» балалар оешмасын* ***тәкъдирләү (презентация)*** *булды* (В. Т., 1995, 26 дек.). *«Чаллы» концерт-иҗат берләшмәсе җырчысы Лилия Букееваның беренче концерт программасын тамашачыларга* ***тәкъдир итү*** *кичәсе иде ул* (Ш. Ч., 1997, 25 гыйнв.). *Фәүзия Бәйрәмова шушы китабын Берлин, Лейпциг, Аусбург шәһәрләрендә* ***тәкъдир итте*** (М. җ., 2007, 6 апр.).

Түбәндәге мисалларда **хөкемдар (**1. Патша, хан, ил башлыгы, хөкем сөрүче. 2. *куч.* Бөек шәхес, хуҗа (ТТАС, III, 389 б.) сүзе судья мәгънәсендә, ягъни хаким — 1. *иск.* Судья, хөкем итүче, казый ... (ТТАС, III, 360 б.) урынына, ә хөкемдар төшенчәсен бирү өчен сүзлекләрдә теркәлмәгән ясалма **хакимдар** сүзе кулланылган: *Бәйгегә килү өчен 28 ноябрьдә* ***хөкемдарлар*** *киңәшмәсе дә шул ук көнне кичен үткәрелә* (Т.я., 1997, 20 нояб.). *... үз хоккейчыларын яклап бозга чыгуы һәм шуның өчен* ***хөкемдар*** *тарафыннан уеннан куылуы Билалетдиновның тамашачы алдында абруен бер башка күтәрде* (В.Т., 2007, 10 окт.). *Ятмаларның бу хәләте үҗәтләнү сымаграк тоелды, ахрысы,* ***хакимдарларыбызга****, алар мондый саегуны һич кенә дә өнәмәделәр* (А-к, 1992, 11 дек.).

**Хәттаб** (утынчы, урман кисүче — ГТРАС, 687 б.) белән **хәттат** (каллиграф — ТТАС, III, 388 б.) сүзен бутау да очрый: *Күчереп язучы* ***хаттабларның*** *берәр оятсызы тарихны бозып язадыр дип уйлыйсы килә дә бит ...* (М. җ., 1995, 14 июнь). Хаким сүзенең «3. Хуҗа, түрә, башлык (ТТАС, III, 360 б.) мәгънәсе дә бар (мисаллар 2.2. бүлекчәдә). Әмма аның урынына **хәким** (*и. иск. кит.* Акыллы һәм белемле кеше; белгеч, галим — ТТАС, III, 381 б.) сүзен ялгыш кулланалар: *Шәһәр* ***хәкиме*** *Илдар Халиков бу юнәлештәге эшчәнлекне югары бәяләде* (Ш.Ч., 2007, 19 сент.).

Сирәк булса да, гарәп-фарсы алынмаларын хәтта мәгънә ягына игътибар итеп тормыйча, әйтелеш-язылыш ягыннан охшаш интернациональ сүзләр урынына да файдаланалар: *Сәяси һәм икътисади авырлык кичергән көннәребездә иманлы кулыгыз белән җибәргән* ***гоманлы*** *ярдәмегез өчен рәхмәтләр инде Сезгә, Равил әфәнде!* (А-к, 1992, № 1, 4 б.). — Биредә гуманитар (бәлки, гуманлы?) алынмасы урынына **гөман** (уй, фикер; фараз, юрау — ТТАС, I, 287 б.) сүзеннән «өр-яңа» сыйфат ясаганнар.

Димәк, соңгы елларда гарәп-фарсы алынмаларын куллануда биш төрле грамматик һәм мәгънәви хаталар күзәтелә. Алар:

1) тамырдаш һәм тамырдаш булмаган паронимнарны, ягъни охшаш язылышлы сүзләрне бутау;

2) рус-европа чыгышлы сүзләрне алыштыру чарасы буларак, кайбер алынмаларны мәгънәләре белән исәпләшмичә яки артык киң мәгънәдә куллану;

3) бердәй мәгънәле гарәп-фарсы һәм татар сүзләреннән торган артык компонентлы сүзтезмәләр ясау, ягъни плеоназм;

4) алынмаларны нинди сүз төркеменә караганлыкларын исәпкә алмый куллану;

5) гарәп-фарсы компонентларыннан кирәксез һәм дөрес булмаган сүзләр ясау.

### 2.6. Бүлек буенча нәтиҗәләр

XX йөзнең 80—90 нчы еллары — XXI йөз башы әдәби телебез лексикасында гарәп-фарсы алынмаларын төрле яклап өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә:

1. Җәмгыятьтәге үзгәртеп корулар, демократия шартларында халыкның милли үзаңы уяну, тарихи үткәне белән кызыксынуы көчәю, әдәби телебездә күптәннән кулланылып та, совет чорында архаиклашкан күп гарәп-фарсы алынмаларының яңадан активлашуына китерде. Илдә хакимлек итүче тоталитар режимга булган тискәре карашның Октябрьдән соңгы чор лексикасында зур урын алган рус алынмаларына да күчерелүе, ислам диненең яңарышы, иске әдәби телдә иҗат ителгән мирасыбызның шактый өлеше һәм Көнчыгыш алынмалары сүзлекләре яңадан басылу, Шәрык илләре, аеруча Төркия белән мәдәни, икътисади һәм сәяси бәйләнешләр урнаштырылу да гарәп-фарсы сүзләренең әдәби тел лексикасына кире кайтуына уңай йогынты ясады.

2. Гарәп-фарсы алынмаларының активлашуы язма әдәби телнең барлык стильләренә дә, аеруча публицистик, фәнни, шулай ук поэтик, өлешчә эш кәгазьләре һәм, әлбәттә, яңарыш кичерүче дини культ стиленә хас.

3. Кире кайткан гарәп-фарсы сүзләре беренче чиратта рус алынмаларын һәм интернациональ сүзләрне алыштыру өчен, аларның абсолют синонимнары буларак кулланылалар (гамәли — практик, икътисади — экономик ...). Шулай ук татарча берсүзле атамасы булмаган төшенчәләрне белдерү өчен һәм мәгънә төсмере аеру максатында активлаштырылганнары да бар (гонҗә — ачылып бетмәгән чәчәк, кәсафәт — нинди дә булса эшнең начар йогынтысы ...).

4. Активлашкан алынмалар арасында татар әдәби телендә күптән кулланылыштан чыккан, бары алынмалар һәм гарәп, фарсы теле сүзлекләрендә генә теркәлгәннәре дә (гонсыр, җисмән, инкыйраз һ.б.), «искергән сүз» тамгасы белән аңлатмалы сүзлектә урын алганнары да бар (бәян, биниһая, тәрәккый ...). Бу алынмаларның зур күпчелеге — исемнәр. Тематик яктан алар тугыз төркемчәгә бүленә. Шулай ук сыйфатлар, рәвешләр шактый, алмашлыклар, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәренә караганнары да очрый, аналитик сүз компоненты буларак кына кулланылучылары бар. Гомумән, өйрәнелгән чорда яңадан телгә кайткан гарәп-фарсы алынмалары 400 дән артык.

5. Архаиклашкан алынмаларның яңадан әдәби телгә кайтуы белән беррәттән искерү төсмере булмаган, әмма элек аерым стиль чикләрендә генә кулланылган гарәп-фарсы сүзләренең стильара лексикага күчүе, сирәк кулланылыштагы сүзләрнең активлашуы да — соңгы чор әдәби теленә хас күренеш.

6. Соңгы елларда гарәп, аеруча фарсы сүз ясагыч элементлары ярдәмендә аналогия буенча һәм татар теленең үз калыплары нигезендә 100 гә якын яңа сүз ясалып кулланылышка керде. Алар, нигездә, морфологик юл белән, ягъни күптән үзләштерелгән гарәп-фарсы алынмаларына, сирәк очракта татар сүзләренә яисә рус теле аша кергән алынмаларга гарәп һәм фарсы аффикслары ялгап ясала (вазыйфаи, гаммәви ...; мөхәррият, сөйләмият ...; тәкъдимнамә, шәхеснамә ...; икмәкханә, мирасханә ...; иҗаткяр, сәнәгатькяр ...; бихәбәрдәр, бимәркәзләү ...). Тулысынча гарәп һәм фарсы компонентларыннан чыганак телдә булмаган кушма һәм парлы сүзләр төзү (каләмхак, мөхбир әгъза, нәшир-хәйри), фонетик ысул белән неологизмнар ясау очраклары да бар (иминият, маддә).

7. Яңадан активлашу процессында кайбер гарәп-фарсы алынмалары семантик (гыйбарә, казый ...) һәм фонетик-орфографик үзгәрешләргә дучар ителәләр. Рус-европа алынмалары урынына кулланылган гарәп-фарсы сүзләренең шактые чыганак телдә һәм элекке кулланылышта татар телендә дә булмаган яңа мәгънә төсмерләре белән баеды (кануннамә, мәкам ...). Кайбер күпмәгънәле алынмалар исә бер конкрет мәгънәләрендә генә активлаштылар (мәдәни, мәҗмуга ...). Алынмаларны фонетик яктан үзләштерү дә дәвам итә. Күп гарәп-фарсы сүзләрен соңгы елларда татарча әйтелешкә яраклаштырып — сингармонизм законына буйсындырылып, йә алгы, йә арткы рәт сузык аваз хәрефләре белән генә язу киң таралган (әгълә, виләят, истирәхәт ...), сүз ахырындагы [д], [б] тартыкларын саңгырау парлары белән алыштыру да еш очрый (җиһат, мәдәт, өслүп ...). Бу исә үз чиратында алынмаларны язуда күпвариантлылык, төрлелеккә китерде. Гарәп-фарсы алынмаларын текстта еш кына җәя эчендәге аңлатмалары белән куллану да күзәтелә. Мондый күренеш әле аларның әдәби тел тарафыннан тулысынча үзләштерелеп бетмәве турында сөйли.

8. Гарәп һәм фарсы сүзләренең кире кайту процессы телебезнең сүзлек составын баетуда һәм яңартуда зур урын алып тора. Хәзерге чорда бу алынмалар күп очракта, нигездә, урынлы кулланылсалар, икенче яктан, аларны «яңадан үзләштерү» процессы күзгә ташлана. Аерым очракларда татар теленә күптән һәм нык кереп урнашкан рус алынмалары һәм интернациональ сүзләр дә җәмәгатьчелеккә аңлашылмаган гарәп-фарсы алынмалары белән алыштырылалар. Бу күренеш галимнәрдә, матбугатны даими карап баручы укучыларда төрле фикерләр уята. Безнең карашыбызча, бу процесс чигеннән артып китсә, матбугат укучыларының саны кимергә дә мөмкин. Шуңа да гарәп-фарсы алынмаларын кире кайтару процессы белән фәнни-дәлилле идарә итү кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла булса кирәк.

# III БҮЛЕК

## ӘДӘБИ ТЕЛНЕҢ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ҺӘМ РУС СҮЗЛӘРЕ ИСӘБЕНӘ БАЮЫ

Гарәп-фарсы алынмаларының йогынтысы көчәю соңгы елларда телебезгә рус һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләрне үзләштерү белән параллель рәвештә барды.

Тоталитар дәүләт җимерелгәннән соң, илнең иҗтимагый-сәяси һәм икътисади нигезләре Көнбатыш үрнәгендә үзгәртеп корыла башлады (21. 31 б.). Бу исә яшәешнең төрле өлкәләренә караган күп сүзләрнең рус теленә үтеп керүенә юл ачты. Шулай ук җәмгыять тормышындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән яңа күренеш, төшенчә, оешма һ.б.ларга исем биргәндә гадәттә чит сүзләргә өстенлек бирелде. Чөнки тормышта булган чит ил товарларының престижлыгы тел өлкәсенә дә үтеп керде (26. 55 б.). Бер үк вакытта Совет власте елларында пассив сүзлеккә күчкән күп кенә рус һәм Көнбатыш сүзләре яңа тормыш реалияләренең атамалары булып активлашты (145. 72 б.).

XX йөзнең 70—80 нче һәм аеруча 90 нчы елларында Европа телләренә хас булган лексиканың интернациональләшү тенденциясе көчәюе дә (143. 6 б.; 76. 84 б.) хәзерге рус теле лексикасында чит тел сүзләренең артык күбәюенә китерде һәм матбугат битләрендә тел галимнәренең борчулы мәкаләләре дөнья күрүенә сәбәп булды (135; 26; 45 б. һ.б.).

Бер дәүләт-җәмгыять шартларында яшәгәнлектән, рус телендәге бу күренеш татар теленә дә йогынты ясамый калмады. Чөнки рус һәм татар телләренең лексикасында неологизмнар өлкәсендә дә уртаклык бар. Бу уртаклык «неологизмнарның даими терминологик мәгънәләренең үзара туры килүендә, структур һәм фонетик төзелеш бердәмлегендә чагылыш таба. Татар неологизмнарының шактый зур өлешен рус теленнән һәм аның аша башка телләрдән кергән сүзләр тәшкил итә» (182. 97 б.). Шунлыктан рус теленә кергән Көнбатыш алынмаларының барысы да диярлек теге яки бу дәрәҗәдә татар теле лексикасында чагылыш тапты.

Алынмалар теориясе белән күптән шөгыльләнүче галим Л.П.Крысин бер телдән икенче телгә сүзләр алуның биш төрле сәбәп-факторын күрсәтә: 1) яңа әйбер, төшенчәгә исем бирү; 2) төшенчәләрне чикләү яисә махсуслаштыру (мәгънә төсмере аеру); 3) сүтезмәләрне бер сүзле атамалар белән алыштыру; 4) телдә аерым тармакларга караган бер үк чыгышлы терминнар системасы булу; 5) социаль-психологик сәбәпләр: алынма сүзнең өстенлеге («престижность»), алынасы төшенчә һәм аның атамасының коммуникатив актуальлеге (74. 57 б.).

Татар теленә соңгы елларда рус һәм Европа телләреннән сүзләр үзләштерүдә бу факторларның барысы да роль уйнады. Әйтик, икенче төргә: **киллер** — ялланган үтерүче, **презентация** — яңа әйберне тантаналы шартларда тәкъдим итү; өченче төргә: **саммит** — иң югары дәрәҗәдәге очрашу, **иномарка** — чит илдә эшләнгән автомобиль ... мисалларын китерергә була. Дүртенче — һәр тармакта бер чыганаклы терминнар куллануга омтылу тенденциясе исә татар телендә дә информатика терминологиясенең инглиз, әйтик, җинаятьчел дөнья жаргонының, нигездә, рус сүзләреннән торганлыгында чагыла. Шулай да бу төр алынмаларның күпчелеге яңа предметлар белән, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле күренеш атамалары буларак телгә керде (**интернет**, **импичмент**, **кластер** һ.б.). Алынмаларның икенче зур төркеме татар дөньясында да чит илдә эшләнгән әйбер, чит тел сүзенә моданың көчәюе белән бәйле, ягъни татарча атамалы яисә русча эквиваленты булган төшенчәләр дә яңача атала башлады: **спонсор** — иганәче, химаяче; **офис** — контора, канцелярия; **брокер** — арадашчы һ.б.

Әйтелгәнчә, бу төр алынмалар татар теленә барысы да диярлек рус теле аша кергән. Дөрес, арада соңгы елларда еш күрсәтелүче чит ил телесериаллары аша турыдан-туры татар сөйләм теленә кергән **фазенда** кебек алынмалар да бар. Рус теленә исә бу алынмалар, белгечләр ачыклавынча, нигездә, инглиз теленнән, аеруча аның америкалы вариантыннан кергән (76. 85 б.; 138. 46 б. һ.б.). Татар теленә соңгы елларда кергән һәм алда күрсәтеләчәк тематик төркемнәр эчендә бирелгән рус-европа алынмаларының да 70 проценты, алынмалар сүзлекләре күрсәтүенчә, инглиз сүзләре: аудит, бартер, ваучер, дилер, дистрибьютор, инвестор, инфраструктура, лизинг, менеджер, менеджмент, офф-шор, риэлтор, спонсор, тендер, трансфер, холдинг, чартер; диссидент, импичмент, инаугурация, кластер, лобби, пиар, рейтинг, саммит, спикер; брифинг, пресс-релиз, респондент; киллер, рэкет, рэкетир; клип, дискотека, продюссер, хит-парад, шоу; дисплей, компьютер, листинг, монитор, принтер, пейджер, картридж, ксерокс; ралли, бодиболдинг, аэробика; гамбургер, сандвич, киви; зомби, уфология, хилер; дизайн, гламур, имидж, имиджмейкер, кемпинг, шоп, нонсенс, супермаркет; армрестлинг, кикбоксинг; скаут, тинейджер, панк, хиппи, баксы һ.б.

Башка теллəрдəн кергəн алынмалар берəмлеклəр белəн генə санала: француз теленнəн — анклав, визажист, дискета, интерпол, кадастр, коллаж, сертификат, сутенер, токсикомания; немец теленнəн — менталитет, паритет, путч; итальян теленнəн — мафия, мафиози, пицца; испанчадан — хунта, фейхоа. Кайбер грек-латин тамырлы һəм бер үк вакытта берничə Европа телендə кулланылучы сүзлəрнең кайсы телдəн алынганын билгелəү кыен. Мəсəлəн, диаспора сүзе инглиз телендə дə, немец телендə дə бар, вампир — француз һəм немец телендə дə кулланыла. Шулай ук аура, социум кебек латин тамырлы сүзлəр дə күп Европа теллəре өчен уртак.

Күпчелек лингвистлар тарафыннан өч һəм аннан күбрəк якын кардəш булмаган телдə кулланылучы охшаш мəгънə һəм формалы сүзлəр интернациональ сүзлəр дип танылганлыктан (151), ким дигəндə өч — чыганак, арадаш рус һəм татар телендə булуларыннан чыгып, бу сүзлəрне интернациональ сүзлəр дип яки тагы да кыскарак, соңгы елларда кулланылышка кереп баручы интерлексема (47. 5 б.) термины белəн атарга мөмкин.

Телгə яңа кергəн алынмалар арасында рус теленең үз сүзлəре бик аз. Рус телчелəре үзлəре дə соңгы елларда рус теленнəн башка теллəргə сүзлəр керүнең бөтенлəй диярлек тукталуы турында язалар (26. 56 б.). Чыннан да, соңгы чорда матбугатта урын алган рус сүзлəренə мисал итеп аббревиатуралар (АО, бомж, ГИБДД, ГКЧП, НЛО, омон һ.б.) һəм кайбер сүзлəрнең, нигездə, гади сөйлəм, жаргонга хас булган яңа күчерелмə мəгънəлəрен (братва, крутой, «крыша», ломка, частник, челнок) генə китерергə мөмкин. Яңа төшенчəлəрне белдергəн рус неологизмнары, алар булган очракта да, татар əдəби теленə гадəттə калькалаштырып алына. Шул ук вакытта «рус җирлегендə» кайчандыр үзлəштерелгəн алынмалардан яңа сүзлəр ясауга (21. 32 б.) шактый мисал китерергə була: аудиокассета, видеозал, евроремонт, иномарка, необольшевик, партократ һ.б.

Соңгы елларда пассив сүзлектəн актив лексикага кайткан берəмлеклəрнең дə зур күпчелеге — чыгышы буенча алынма сүз.

Түбəндə татар əдəби телендəге яңа алынмалар һəм телдə электəн булып та, соңгы елларда гына активлашкан яисə мəгънə, стиль-кулланылыш үзгəреше кичергəн алынма сүзлəр аерым карала. I бүлекчəдə татар теленең аңлатмалы сүзлегендə теркəлмəгəн, ягъни əдəби телгə XX йөзнең 70 нче елларыннан соң кергəн дип исəплəнүче алынмалар, икенчесендə исə ТТАСтə теркəлгəн, əмма соңгы елларда яңа мəгънə төсмере алган яки кулланылыш даирəсен-стилен, ешлыгын үзгəрткəн сүзлəр карала.

### 3.1. Яңа рус-европа алынмаларының тематик төркемнəре

Үзгəртеп кору елларыннан башлап əдəби телгə кереп ныгыган яңа рус-европа алынмаларын тематик яктан унике төркемгə берлəштерергə мөмкин. Сүзлəрнең саны киму тəртибендə санаганда, алар түбəндəгелəр: 1) икътисад-финанс, базар мөнəсəбəтлəре өлкəсенə караган алынмалар; 2) иҗтимагый-сəяси өлкəгə караган сүзлəр; 3) техника һəм җитештерү өлкəсенə караган лексика; 4) мəдəният, сəнгать өлкəсенə караган сүзлəр; 5) физкультура-спорт терминнары; 6) криминаль дөньяга караган лексика; 7) аномаль күренешлəр һəм традицион булмаган медицинага караган лексика; 8) кулинария өлкəсенə караган сүзлəр; 9) көнкүрештəге үзгəрешлəргə бəйле лексика; 10) абстракт мəгънəле сүзлəр; 11) татар җирлегенə күчерелгəн экзотизмнар; 12) гади сөйлəм стиле алынмалары һəм жаргон сүзлəр.

Түбəндə һəр төркемгə караган яңа алынмалар алфавит тəртибендə бирелə. Алынмаларның мəгънəлəре С.И.Ожегов һəм Н.Ю.Шведова тарафыннан төзелгəн «Рус теленең аңлатмалы сүзлеге»нең 1998 елгы басмасы буенча (ТСРЯ), анда булмаган сүзлəр рус теленең алынмалар сүзлеклəре нигезендə, ə аларда чагылыш тапмаганнары башка филологик яки энциклопедик сүзлеклəрдəн тəрҗемəлəп күрсəтелə, сүзлеклəргə теркəлергə өлгермəгəн кайбер берəмлеклəргə автор аңлатмасы бирелə. Һəр сүзгə иллюстрация рəвешендə бер җөмлə, мəгънə төсмерендəге аерманы күрсəтү соралганда гына ике-өч мисал китерелə.

#### 1. Икътисад-финанс, базар мөнəсəбəтлəре өлкəсенə караган алынмалар

**Аудит** — «гадəттə бəйсез белгечлəр яки оешмалар тарафыннан финанс һ.б. документларны тикшерү, ревизия ясау» (СИС, 1997, 36 б). Элек англосакс иллəренə һəм АКШка карата кулланылган «ревизор-контролер» мəгънəле аудитор сүзеннəн (СИС, 1988, 62 б.) ясалган бу термин яңа экономик шартларда фирмадагы керем-чыгымнарны документлаштыруның дөреслеген тикшерүгə бəйле рəвештə кулланылышка керде: *Җаваплылык КамАЗ АҖнең корпоратив планлаштыру һəм **аудит** идарəсенə йөклəнə* (Нур, 1996, 6 февр.).

**Бартер** (*махс.*) товар алыштыру килешүе, натуралата алмашу (ТСРЯ, 37 б.) рус теле сүзлеклəрендə дə беренче тапкыр 1992 елда гына чагылыш тапса да, сөйлəм телендə дə иң актив алынмаларның берсенə əверелде, чөнки узган гасырның 90 нчы елларына хас экономик кризис, үзара түлəмəүчелек шартларында төрле оешмалар һəм эшмəкəрлəр бер-берсе белəн исəп-хисапны товар алышу юлы белəн

ясарга мәҗбүр иде: *Аларга 1 тонна май белән* ***бартер*** *ясап, хуҗалыкларга ягулык-майлау материаллары белән ярдәм итәбез* (В. Т., 1996, 21 нояб.).

**Бизнес** сүзе, алда әйтелгәнчә, үзе активлашып кына калмады, «бизнеска кагылышлы» мәгънәле **бизнес-клуб**, **бизнес-план**, **бизнес-шоу**, **бизнесцентр**, **шоу-бизнес** кебек яңа алынма кушма сүзләр компоненты буларак та кулланылышка керде, шуларның аеруча актуаль берсенә генә мисал китерәбез: *Иван Михайлович, былтыргы* ***бизнес-планның*** *үтәлмичә калуынаниләр сәбәп булды?* (Ш.Ч., 1999, 22 гыйнв.).

**Брокер** — «кыйммәтле кәгазьләр, товарлар сату-алуда арадашлык итүче агент» (ТСРЯ, 60 б.). Рус телендә XX гасырның беренче яртысыннан ук билгеле булса да (СИС, 1997, 29 б.), аңлатмалы сүзлекләрдә 90 нчы еллардан гына теркәлде һәм рус телендә XVIII гасыр башыннан кулланылган (ШЭСРЯ, 177 б.) мәгънәдәш маклер сүзен тулысынча диярлек кысрыклады: *Бу сумма зур түгел, чөнки сатуларда катнашучылар (****брокер*** *конторалары) аз иде* (Т.я., 1991, 4 окт.).

**Ваучер** — «дәүләт милкен хосусыйлаштыруда катнашуга хокук бирә торган кыйммәтле кәгазь» (ТСРЯ, 69 б.). Бу инглиз алынмасы XX йөзнең 90 нчы еллары башында иң популяр сүзләрнең берсенә әверелеп, хәзер активлыгын югалтып бара, чөнки күпчелек халык Россиянең элекке дәүләт милкенең бу ваучер — хосусыйлаштыру чегында вәгъдә ителгән өлешенә хуҗа була алмады: *Чакырылган вәкилләр районнарда халыкка* ***ваучер*** *бирүнең барышы, шул уңайдан нинди тоткарлыклар килеп чыгуы турында сөйләделәр* (В. Т., 1992, 11 дек.).

**Деноминация** (акча әйләнешен җайга салу һәм милли валютаның тулы кыйммәтлеген тәэмин итү максатында илнең акча берәмлеген эреләндерү — СИС, 1988, 154 б.) сүзе Россиядә 1998 ел башыннан гамәлгә кертелгән күренеш атамасы буларак вакытлы матбугат лексикасына 1997 елның икенче яртысында гына килеп керде һәм 1998 елда иң актив сүзләрнең берсе булды. Рәсми лексикага караса да, халык телендә күбрәк тискәре төсмер белән кулланыла: ***Деноминация*** *ул хосусыйлаштыру түгел бит, 3 нульне кыскарттың да, шуннан кемгә ни зыян диярсез* (Т.я., 1997, 13 сент.) ***Деноминация*** *белән талап булмаса, процентлар белән талыйбыз дигән сыман* (Т.я., 1998, 13 гыйнв.).

Дәүләт казнасына салым җыюны арттыру максатында гражданнардан еллык керемнәре турында махсус рәсми документ тутыру гамәлгә кергәч, бу мәгънәсендә дә активлашкан декларация сүзеннән **декларант** — «чыганакларын күрсәтеп, еллык керемнәре турында документ-декларация тутырырга тиеш яисә тутыручы кеше» неологизмы ясалып, татар теленә дә керде: ***Декларантларның*** *төп өлеше бирегә февраль-март айларында гына килә* (В.Т., 1999, 16 гыйнв.).

**Дилер** — *махс.* (1. Үз исеменнән һәм үз хисабына эш йөртүче сату-алу белән шөгыльләнүче кеше яисә фирма. 2. Үз исеменнән һәм үз хисабына кыйммәтле кәгазьләр, валюта, кыйммәтле металлар белән сату-алу итүче банк, фонд биржасы әгъзасы — ТСРЯ, 166 б.). Рус теленә бу сүз инглиз теленнән XX гасыр ахырында кергән (СИС, 1997, 68 б.). Татар телендә ул, ике мәгънәсендә дә, чит илләргә карата да, үз җирлегебездә дә кулланыла һәм аңлатмалы сүзлекнең соңгы басмасында теркәлгән (ТТАС, 2005, 144 б.). *Ел ахырында ул хөкүмәтебезнең рәсми* ***дилерына*** *әверелә* (В.Т., 1997, 5 апр.). *Американың корал сату* ***дилерлары*** *моның нәтиҗәсендә болай да тотрыксыз позицияләрен бөтенләй югалталар* (Т.я., 1998, 7 гыйнв.).

**Дистрибьютор** (товарны куллanучылар яки дилерлар арасында бүлү белән шөгыльләнүче агент яисә сәүдә фирмасы — СИС, 1997, 73 б.) инглиз алынмасы, ирекле базар мөнәсәбәтләренә күчү уңае белән, телебезгә килеп керде: *Тауарларны таратучы* ***дистрибьюторлар*** *саны да шактый арткан* (Т.я., 1998, 24 гыйнв.).

**Инвестор** — «инвестицияләр салучы вкладчы (физик яисә юридик зат)» (ТСРЯ, 248 б.) рус теленә XX гасырның беренче яртысында ук кергән **инвестиция** сүзеннән ясалып (СИС, 1977, 92 б.), 1964 елда чыккан алынмалар сүзлегендә үк теркәлгән булса да, татар матбугатында өйрәнелгән чорда гына республика икътисадына читтән капитал кертү белән бәйле рәвештә кулланыла башлады: ... *Татарстан турында дөнья матбугатында пропаганда, реклама эшләре җәелдерделәр, безнең өчен* ***инвесторлар*** *эзлиләр* (В.Т., 1995, 13 гыйнв.).

**Индексация** (1. Бәяләр индексы үзгәрүгә пропорциональ рәвештә төрле түләүләрне яңача исәпләү. 2. Инфляция чорында: акча, түләү күләмнәрен арткан зурлыкларга тәңгәлләү — ТСРЯ, 246 б.): *Бәяләрнең* ***индексациясенә*** *карап пенсияләрне үзгәртү кирәк* (М-т, 1995, 25 февр.).

**Инфраструктура** *махс.* (Җитештерү процессларын һәм җәмгыятьнең яшәеш шартларын турыдан-туры тәэмин итүче икътисад; фән-техника, иҗтимагый тормыш тармаклары — ТСРЯ, 250 б.) алынмасы икътисад өлкәсендә дә, иҗтимагый термин буларак та актив кулланыла: *Очрашу вакытында республикадагы транспорт* ***инфраструктурасының*** *үсеш мәсьәләләре каралды* (Т.я., 1996, 23 июль).

**Ипотека** «күчемсез милеккә залог исәбенә бурычка бирелгән акча (ссуда), шул турыда документ» (ТСРЯ, 251 б.) алынмасы аеруча XXI йөз башында, дәүләт тарафыннан фатир алу өчен шундый кредитлар бирелә башлагач, актив кулланылышка керде: *Социаль* ***ипотека*** *программасында кайбер категория гражданнары өчен өстенлекле режим да күздә тотылган* (М-н, 2004, № 4, 163 б.).

**Кадастр** (... 2. Нинди дә булса объект турында периодик рәвештә яки өзлексез күзәтү-өйрәнүләр юлы белән төзелгән, системалаштырылган мәгълүматлар җыентыгы — СИС, 1988, 206 б.) сүзе бу мәгънәсендә рус телендәге алынмалар сүзлекләрендә XX йөзнең 70 нче елларыннан ук теркәлсә дә, татар телендә, нигездә, 90 нчы еллардан җир реформасына бәйле рәвештә кулланылышка керде: *Бөтен мәгълүматлар да җир* ***кадастрына*** *кертелә һәм автоматлаштырыла* (Т.я., 1988, 31 гыйнв.).

**Лизинг** (1. Хакларын файдалану чорында акрынлап түләү шарты белән озак срокка машина, җиһаз, транспорт чаралары, производство корылмалары арендалау. 2. Прокатка җиһаз бирү — СИС, 1997, 172 б.) алынмасы төшенчәсе белән бергә рәсми стильгә керде: *Инвестицияләрнең* ***лизинг*** *кебек формасын да киң файдаланырга кирәк* (В.Т., 1996, 28 дек.).

**Логистика** сүзе әлегә филологик сүзлекләрдә теркәлмәгән, базар мөнәсәбәтләренә турыдан-туры карый торган «халыкара складлар, базалар системасы» мәгънәсендә татар матбугатында урын алды: *Бу, беренче чиратта, аэропортны киңәйтеп, халыкара статуска ирештерү, икенчедән, телефон элемтәсен көчәйтү, өченчедән,* ***логистика*** *үзәге булдыру дигән сүз* (В.Т., 1995, 13 гыйнв.).

**Маркетинг** — *махс.* Хуҗалык эшчәнлеген оештыруның базар ихтыяҗларын, продукция сату, түләүле хезмәт күрсәтү мөмкинлекләрен өйрәнүгә нигезләнгән системасы (ТСРЯ, 343 б.), **маркетолог** — «маркетинг буенча белгеч», **менеджер** — «идарә итү, предприятие эшен оештыру буенча белгеч» (ТСРЯ, 350 б.), **менеджмент** — *махс.* Интеллектуаль, финанс, материаль ресурслар белән идарә итү сәнгате» (ТСРЯ, 350) алынмалары әле рус теленең узган гасырның 80 нче еллары ахырында чыккан сүзлекләрендә дә капиталистик җәмгыятькә карата кулланылучы сүзләр буларак теркәлсәләр, 90 нчы еллардан алар татар әдәби телендә дә үз җирлегебезгә карата кулланыла башладылар: ***Маркетинг*** *һәм сәүдә хезмәте кулланылучылардан акчаларны ай азагында гына түгел, көн саен «тартып торырга» тиеш* (Нур, 1995, 12 сент.). *Бу җәйнең бик матур көннәренең берсендә Дилә Нигъмәтуллина* ***маркетолог*** *белгечлеге буенча дипломлы булды* (В.Т., 2007, 17 авг.). *Дөньядагы иң абруйлы һөнәрләрнең берсе —* ***менеджер*** (С-й, 1996, 14 сент.). *Киләсе уку елы башында урта белеме булган кешеләрдән* ***менеджмент*** *һәм дөнья икътисады белгечлекләре буенча уку курслары оештырыла* (В.Т., 1995, 21 июнь).

**Мониторинг** (1. Нинди дә булса процессны аның көтелгән нәтиҗә яисә фаразларга туры килү-килмәвен ачыклау максатында күзәтү. 2. Кешенең хуҗалык эшчәнлегенә бәйле рәвештә әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтү, бәяләү һәм фаразлау — СИС, 1997, 194 б.) сүзе дә, нигездә, рәсми стильдә, икътисади термин буларак кулланыла: *...* ***мониторинг,*** *анализ, хәлне прогнозлау, планлы эшләү кирәк булачак* (Нур, 1998, 1 гыйнв.).

**Офф-шор** — «башка дәүләт территориясендә төзелгән яисә теркәлгән һәм салым льготаларыннан файдаланучы оешма һ.б.» (СИС, 1997, 208 б.): *Әгәр дә безне* ***офф-шор*** *зона дип тә игълан итсәләр, нинди генә мөмкинлекләр ачылмас иде!* (И-л, 1997, № 12, 46 б.).

**Риэлтор** — «күчемсез милекне сату буенча агент, арадашчы» (ТСИС, 610 б.): *Банк хезмәткәрләре һәм* ***риэлторлар*** *халыкка ипотека буенча консультация бирәчәкләр* (Ш.Ч., 2007, 15 авг.).

**Сертификат** *махс.* 1. Дәүләт органнарының финанс заемы йөкләмәсе, шулай ук кайбер заем билетларының исеме. 2. Нәрсә дә булса турында рәсми язма таныклык (ТСРЯ, 714 б.) алынмасы хәзер күбрәк икенче мәгънәсен конкретлаштырып, «дәүләт инспекциясе һәм башка вәкаләтле органнар тарафыннан сатыласы товарның сыйфатын раслап бирелә торган таныклык, документ»ны атау өчен, шулай ук, сирәгрәк булса да, беренче мәгънәдә дә кулланыла: *Хәзер автомашиналарның сыйфатын тикшереп,* ***сертификат*** *бирү мәсьәләсен хәл итү буенча Россиядә дә нәтиҗәле эш алып бара* (Ш.Ч., 1996, 23 апр.). *Менә шуңа үзеңнең кәгазь акчаң, акция, ссуда,* ***сертификатларны*** *кушсаң, чират буенча фатир алырга була* (В. Т., 1997, 23 гыйнв.). Бу сүздән рус теле җирлегендә «товарларның сыйфат яраклылыгын билгеләү» мәгънәле яңа **сертификация** сүзе дә ясалды: *... октябрьдән башлап илгә кертелә торган товарларга мәҗбүри* ***сертификация*** *үткәрелә башлаячак* (Ш.Ч., 1995, 15 сент.).

**Спонсор** (нинди дә булса эш — мероприятиене оештыручы, финанслаучы кеше яки оешма — ТСРЯ, 757 б.) алынмасы, **иганәче**, **химаяче** кебек синонимнары булуга карамастан, сөйләм стиленә дә, әдәби телгә дә керде: *Бәлки, Татар яшьләре көннәренең* ***спонсоры*** *булырга теләк белдерүче милли җанлы кешеләр дә бардыр* (М-т, 1997, 2 авг.).

**Тендер** — «нәрсәне дә булса мөмкин кадәр кулай бәягә сату-алу максатында оештырылган сәүдә чарасы» (БТСРЯ, 1314 б.): *Быел* ***тендерда*** *катнашырга теләгән барлык шәхси эшмәкәрләргә дә мөмкинлек бирелгән* (Ш.Ч., 2007, 10 окт.). *Җитмәсә, якын көннәрдә фондта өстәмә дарулар белән тәэмин итүче компанияләргә* ***тендер*** *(сайлап алу конкурсы) үткәрелергә тиеш булган* (В.Т., 2006, 23 нояб.).

**Трансфер** — (1. Чит ил валютасын яки алтынны бер илдән икенче илгә күчерү. 2. Исемле кыйммәтле кәгазьләргә ия булу хокукын бер заттан икенче затка тапшыру. 3. Халыкара килешү нигезендә дәүләтләр арасында кешеләр алышу, автомат рәвештә гражданлык алыштыру — СИС, 1988, 504 б.) инглиз алынмасы рус һәм аның аша татар телендә ил эчендәге мөнәсәбәтләргә дә кагылышлы термин буларак, шулай ук яңа «спортчыны акчалата компенсация исәбенә башка командага күчерү»

мәгънәсендә дә кулланылышка керде: *Шуның белән бергә беренче варианты буенча 1,75 миллиард сумлык **трансфер** рәвешендә федераль бюджеттан төшеп калучы керемнәрне компенсацияләү күздә тотыла* (В.Т., 1997, 17 сент.). *«Рубин» быелгы сезонда Гришин, Филонов, Гарибян кебек футболчыларын **трансферга** куйган* (Т.я., 1998, 24 гыйнв.).

**Холдинг** — «ия булу; эшчәнлекләрен контрольдә тоту һәм идарә итү максатында башка компанияләр акцияләренең контроль пакетына ия булган компания» (СИС, 1997, 295 б.): *Аларга шушы формадагы **холдинг** кирәкми инде* (В.Т., 1997, 26 март).

**Чартер** (йөк яисә пассажирлар ташу өчен рейс яллау договоры — ТСРЯ, 877 б.) алынмасы чит илләргә туристик сәяхәтләр ешаю һәм аеруча читтән товар ташу артуга бәйле рәвештә (110. 49 б.) гадәти расписаниедән тыш оештырылган махсус диңгез һәм һава рейсларын атау өчен телгә керде: *Быелның 30 июнендә һәм 14 июльдә Казаннан Мисырга туры **чартер** рейслары оештыра* (Т.я., 1997, 28 июнь).

**Челнок** (...3. Даими рәвештә бер урыннан алып башка җиргә сатар өчен товар ташучы алыпсатар — ТСРЯ, 879 б.) сүзенең сәүдә белән бәйләнгән бу мәгънәсе өйрәнелгән чорда гына барлыкка килде. Гади сөйләм стиленә караса да, матбугат битләрендә ул шактый еш очрый: ... *Төркия, Кытай, Польша һ.б. чит ил товарларын ташып торучы **«челнок»лар** ... тиздән эшсезләр армиясен тулыландырачак* (Ш.Ч., 1998, 11 дек.).

**Штрих-код** (товар турында төрле информация белдерүче, нечкә кыска сызыклар формасындагы шартлы билге) алынмасы чит илләрдән күпләп товар кертә башлауга бәйле рәвештә XX йөзнең 80 нче елларыннан ук үз җирлегебезгә карата 90 нчы еллар ахырында телгә керде: *ГЭС бистәсендә 1 нче универсам **штрих-код** системасы белән эшли башлады* (Т.й., 1998, 17 гыйнв.).

**Экю** (... 2. Европада 1979 елдан соң: Европа валюта системасына караган илләр тарафыннан кулланылучы региональ валюта берәмлеге — ТСРЯ, 909 б.) сүзе Европа илләренә карата гына түгел, алардан кредитка алган акчаны атау өчен дә кулланылышта булды: *1991 елдан алып 1994 еллар арасында гына да «ТАСИС» үзенең партнерларына кире кайтарусыз 1870 миллион **экю** бирде* (В.Т., 1998, 8 май). Кулланылышка керү вакыты төгәл билгеле булган кебек, бу алынманың күрсәтелгән мәгънәдә яңадан пассив лексикага күчү елы да ачык: 1999 елдан ул яңа валюта берәмлеге **евро** белән алыштырылды: ***Евро** яки долларның көчәюе икътисадның кайда һәм ничек үсүенә, финанс системасының ныклы һәм тотрыклы булуына бәйле булачак* (В.Т., 1999, 23 гыйнв.).

### 2. Иҗтимагый-сәяси өлкәгә караган сүзләр

**Анклав** *махс.* Дәүләт территориясенең барлык яктан да башка дәүләтләр территориясе белән әйләндереп алынган һәм диңгезгә чыгу юлы булмаган өлеше (ТСРЯ, 25 б.). Хәзер, нигездә, үзгәрәк. «1. Тулысынча башка дәүләт территориясендә урнашкан һәм диңгезгә чыгу юлы булмаган дәүләт ... 2. Этник яисә дини азчылык компактлы булып яшәгән территория» (СИС, 1997, 28 б.) мәгънәләрендә кулланыла: *Сан ягыннан күбрәк булган Себер татарлары да туган төбәкләрендә, мәсәлән, Төмән өлкәсендә автономияле **анклав** булдыра алыр иде* (Т-н, 1993, № 3, 11 б.).

**Глобализация** — «нәрсәгә дә булса глобаль ягъни дөньякүләм төсмер бирү» (БТСРЯ, 108 б.): *Ә хәзер моның өстенә **глобализация** дигән афәт тә өстәлде* (В.Т., 2007, 19 гыйнв.).

**Диаспора** *кит.* Туган илләреннән, тарихи ватаннарыннан читтә яшүче бер милләт кешеләре (ТСРЯ, 165 б.) алынмасы Россиянең башка төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән багланышлар җанлануга бәйле рәвештә телебезгә керде: *Татарстан бөтен татар **диаспорасын** берләштерүче булырга ... тиеш дип исәплим* (К.у., 1993, № 11, 139 б.).

**Диссидент** *кит.* (... 2. Хакимлек итүче идеология белән риза булмаган, башкача уйлаучы кеше — ТСРЯ, 167 б.) алынмасы беренчел, «диненнән читләшкән кеше, мөртәт» мәгънәсендә телебездә электән билгеле булса да (РТС, 1985, 133 б.), XX гасыр урталарында барлыкка килгән бу яңа мәгънәсендә (СИС, 1997, 72 б.) бездә, нигездә, 80 нче елларның икенче яртысыннан, тоталитар режимны ачыктан-ачык тәнкыйтьләргә мөмкинлек тугач кына кулланылышка керде: *Хәзер шушы ук тәнкыйтьчеләр: татар язучылары уңайга гына сыпырырга күнеккәннәр, бездә тыелган әсәрләр дә, **диссидентлар** да юк, ... дип тәкрарлыйлар* (С-ә, 1991, № 12, 6 б.).

**Импичмент** (*махс.* Югары дәүләт хезмәтендәге кешеләрне законны тупас бозган өчен вазифаларыннан азат итү процессы — ТСРЯ, 245 б.). Элек чит илләр турында сүз барганда гына, бик сирәк матбугат битендә күренгән, рус телендә XX гасыр уртасыннан билгеле (СИС, 1997, 89 б.) бу сүз үзебезнең Президентка карата да кулланыла башлагач, татар теленә дә ныклап кереп, хәтта рәсми булмаган жанрларда да очрый башлады:

***Импичмент!** — дип өркетәләр,*
*Чыгарабыз, төшерәбез* (М.ж., 1999, 8 гыйнв.).

**Инаугурация** (кайбер илләрдә дәүләт башлыгының тантаналы рәвештә вазифаларына керешү процедурасы ... — СИС, 1997, 91 б.) шулай ук үз җирлегебезгә карата соңгы чорда кулланылышка керде: *М.Шәймиев **инаугурация** вакытында, 1996 ел...* (М.ж., 1998, 16 окт.).

**Кластер** (төркем, шәлкем, бәйләм — Англ.РС, 46 б.) инглиз алынмасы хәзер бер юнәлештә эшләүче төрле дәрәҗәдәге уку йортлары мәгънәсендә еш кулланыла: *Юнәлешләренә карап уку йортларын һәм сәнәгать предприятиеләрен бер* ***кластерга*** *туплыйлар. Үзебезчә гадиләштереп әйтсәк, лицей, колледж, техникум, вузны база предприятиесе астындагы ояга утырталар* (В.Т., 2007, 17 апр.).

**Коррупция** (*кит*. Югары хезмәт урынында эшләүче кешеләрнең, җәмәгать эшлеклеләренең акчага сатылучанлыгы, хезмәт урыны хокукларын шәхси байлык туплау максатлары өчен файдаланудан гыйбарәт җинаять — ТТАС, II, 160 б.) алынмасының нык активлашуы тәэсирендә **коррупционер**, ягъни «коррупция белән шөгыльләнүче» неологизмы барлыкка килде: *Чичән сугышы дәвам итә, эш хакын вакытында түләмәү мәсьәләсе тагын үз урынына кайтты,* ***коррупционерлар*** *да үз эшләрен эшләп ята* (М-т, 1996, 6 сент.).

**Лобби** (дәүләт сәясәтенә йогынты ясаучы икътисади яктан көчле структура вәкилләре группасы — ТСРЯ, 330 б.) алынмасы да, нигездә, яңа парламентта төрле тармак, оешмалар мәнфәгатьләрен яклаучы төркемнәр тууга бәйле рәвештә үз җирлегебездә телгә ныклап кереп бара: *Моның өчен көчле яһүд* ***лоббисын*** *да майлыйсы бар* (З.-Т., 1998, 23 гыйнв.).

**Необольшевизм**, **необольшевик** сүзләре әле сүзлекләрдә теркәлмәгән, аларның беренчесе яңа икътисади шартларда илнең һәм күпчелек халыкның бөлгенлеккә төшүенә реакция буларак барлыкка килгән, яңадан коммунистлар партиясе хакимлеген урнаштыру, базар икътисадыннан социалистик мөнәсәбәтләргә кире кайту, СССРны яңадан торгызу идеологиясен, икенчесе шул идеология тарафдарын белдерә: *Илне* ***необольшевизм*** *сөреме каплый* (Т.я., 1991, 29 авг.). ... *социаль шартлаулар ...* ***необольшевиклар*** *яисә башка төрле экстремистлар тарафыннан әзерләнә* (К.у., 1996, № 2, 131 б.).

**Оптимизация** (... 2. Югары нәтиҗәгә ирешү максатыннан нәрсәнең дә булса интенсивлыгын күтәрү — БТСРЯ, 721 б.) алынмасы хәзер күбрәк тискәре төсмер белән кулланыла, чөнки ул финанс чыгымнарын киметү максатында авылның аз керемле мәктәп, шифаханә, китапханәләрен һ.б. кыскарту йә берләштерүне аңлата башлады: *Шунысы кызганыч: тирә-юньгә данлыклы Байсар хастаханәсе генә* ***оптимизация*** *афәтенә дучар булган* (В.Т., 2007, 25 авг.).

**Партократ** — «партократия, ягъни хакимлек итүче партия җитәкчелеге вәкиле» (ТСРЯ, 494 б.). Элек партия органнарында җитәкче урыннарда эшләгән кешеләргә карата, коммунистлар партиясе хакимияттән читләштерелгәннән соң, күп очракта тискәре төсмер белән кулланыла: *Элекке* ***партократлар****, кайбер урыс вәкилләре каршы килүенә карамастан (хәтта ышанмаслык та), шактый гына күңелле сабантуйлары узды* (С-ә, 1993, № 2, 18 б.).

**Патернализм** (оешма, предприятие җитәкчелегенең, хезмәткәрләрнең көнкүреш шартларын кайгыртуыннан торган хәйрия эшчәнлеге төре — СИС, 1997, 213 б.). 1990 елларга кадәр чыккан энциклопедик һәм алынмалар сүзлекләрендә «буржуаз җәмгыятьтә эшчеләрне алдауга корылган доктрина» буларак теркәлгән бу сүз (СЭС, 1985, 972 б.; КПС, 1989, 411 б.; СИС, 1988, 367 б.) соңгы елларда үз җирлегебезгә карата уңай мәгънәдә, шул исәптән дәүләтнең үз гражданнары турында кайгыртуын белдерү өчен дә кулланылышка керде: *Дәүләт* ***патернализмы*** *һәркем өчен тигез була алмый ул* (Т-н, 1993, № 8, 8 б.).

**Пиар** — «хакимият вәкилләренең җәмәгатьчелек белән махсус хезмәткәрләр яисә структуралар аша урнаштырган мәгълүмати бәйләнеш системасы» (БСИС, 439 б.): *Дәүләт Думасына сайлау вакытында «****кара пиар****»га каршы көрәш чаралары кырыслана бара* (В. Т., 2007, 13 окт.).

**Плюрализм** (... 2. Караш, идея, эшчәнлек формаларының күп төрлелеге һәм ирeклeлeгe — ТСРЯ, 523 б.) алынмасы — телебезгә М.С.Горбачев реформалары белән кергән неологизм: *Демократиягә,* ***плюрализмга*** *каршы бу законсызлыкны акларга сылтау табу кыен түгел иде* (Т-н, 1993, № 1, 14 б.).

**Политолог** (политология белгече), **политология** (җәмгыятьнең сәяси системасын һәм торышын, эчке сәясәт һәм халыкара мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган фән (ТСРЯ, 553 б.) — әле 1988 елны чыккан алынмалар сүзлегендә генә чит илләргә караган сүз буларак теркәлсә (СИС, 1988, 390 б.), 90 нчы елларда сәясәт белгечләрен дә политолог дип атый башладылар, югары уку йортларында политология фәнни коммунизм урынына махсус предмет буларак укытыла: *Үзебездәге һәм чит илләрдәге кайбер* ***политологлар****, Горбачев СССРны таркатуга үзе юл тазартты, дип язалар* (Т-н, 1993, № 1, 14 б.).

**Популист** — «сәясәтче — популизм тарафдары», популизм — «иҗтимагый проблемаларны тиз һәм җиңел хәл итәргә вәгъдә итеп, киң халык массаларына мөрәҗәгать итү сәясәте» (ТСРЯ, 563 б.) сүзләре рус теле белән беррәттән татар телендә дә 1989—1990 елларда киң кулланыла башлады, ә аңарчы ул үзгәрәк мәгънәдә термин буларак белгечләргә генә таныш иде (Хан-Пира, 1995, 125 б.): *Ләкин Явлинский* ***популист*** *түгел* (Т.я., 1995, 14 март).

**Презентация** — «нинди дә булса яңа эшне тәкъдим итү акты» (СИС, 1997, 222 б.) энциклопедик һәм алынмалар сүзлекләренең XX йөз ахырына кадәр чыкканнарында финанс термины (вексель күрсәтү) буларак кына теркәлгән. Әмма ул 1990 еллардан иң популяр сүзләрнең берсенә әверелеп бара. Һәр төзелгән яңа оешма, бина, дөнья күргән яңа әсәргә шау-шулы презентация — халыкка тәкъдим итү оештыралар дияргә була: *Фирмага* ***презентация*** *оештыруда Чаллы «Солан» тышкы сәүдә берләшмәсе ... булышлык күрсәтте* (Ш.Ч., 1992, 5 июнь).

**Путч** (фетнәчеләр группасы тарафыннан дәүләт перевороты ясарга омтылыш, шундый переворот — ТСРЯ, 634 б.) һәм **хунта** (... 2. Властьны кулга төшереп, террористик диктатура урнаштырган хәрби фетнәчеләр төркеме — ТСРЯ, 87 б.) сүзләре чит илләрдәге вакыйгаларга карата вакыты-вакыты белән матбугатта күренеп китсәләр дә, телебезгә ныклап 1991 елның мәгълүм август вакыйгаларыннан соң керделәр: ***Путчны** яклаучыларны, аңа теләктәшлек белдерүләрне кем белә, шулар хакында телефон аша хәбәр итүләрен сорыйлар* (Т.я., 1991, 5 сент.). *Ярый әле **хунтаның** эше барып чыкмады* (Т.я., 1991, 5 сент.).

Узган гасыр урталарыннан ук спорт термины буларак кулланылышта булган **рейтинг** алынмасы (СИС, 1997, 234 б.) 1980 еллардан, мәгънәсен киңәйтеп, «нинди дә булса кеше, оешма, шулай ук фильм, тамаша, матбугат органының популярлык күрсәткечен, шундый популярлык «дәрәҗәсен» белдерү өчен кулланыла башлады: *... хәзерге тел белән әйтсәк, Әминә Кәримованың **рейтингы** бик югары иде* (С-ә, 1995, № 6, 12 б.). *Партиянең **рейтингы** бер процентка артты…* (В.Т., 2007, 13 окт.).

**Саммит** (иң югары дәрәҗәдәге (мәсәлән, дәүләт башлыклары тарафыннан) очрашып сөйләшүләр — СИС, 1997, 242 б.) алынмасы халыкара сәясәткә караган матбугат материалларында хәзер еш кулланыла: *… Х.Салихов бу хакта Швейцария һәм Татарстан вәкилләре катнашында Казанда узган эшлекле **саммитта** әйтте* (М.ж., 2007, 19 окт.).

**Спикер** (парламент яки (кайбер илләрдә) аның түбән палатасының рәисе — ТСРЯ, 755 б.) сүзе Англия һәм башка кайбер илләргә карата электән таныш булса да, яңа типтагы Россия һәм Татарстан закон чыгару органнарының башлыгы атамасы буларак телгә узган гасыр азагында гына керде: *Татарстан парламенты **спикеры** Фәрит Мөхәммәтшин президентлыкка тагын бер исемне атый* (М.ж., 1998, 16 окт.).

**Электорат** (дәүләт яки башка эре җәмәгать структурасына сайлауда катнашучылар — ТСРЯ, 909 б.) алынмасы гадәттә нинди дә булса партияне яки кандидатны яклаучылар мәгънәсендә кулланыла: *…үзенең тотрыклы **электоратыннан** тыш, идеяләр платформасына да ия* (В.Т., 2007, 9 окт.).

Бу тематик төркемгә кергән сүзләрнең бер өлеше матбугат өлкәсенә карый, алар җәмгыятьтәге хәбәрдарлык сәясәтенә бәйле рәвештә телебездә активлаштылар:

**Аккредитация** сүзе «нинди дә булса мероприятие яки вакыйганы үз матбугатында яктырту өчен журналистларның бу чараны оештыручы ил яки оешмадан алдан рөхсәт алып теркәлүе» мәгънәсен белдерә: *[Бөтендөнья татар конгрессында катнашырга] бүгенге көндә газета-журналлардан, теле-радиостанцияләрдән 130 журналист **аккредитациягә** заявка бирде* (В.Т., 1997, 12 авг.).

**Брифинг** — «*рәсми* кыска пресс-конференция» (ТСРЯ, 60 б.). Аны гадәттә хөкүмәт яки дәүләт органы вәкилләре нинди дә булса мәсьәләгә карата рәсми карашны журналистларга җиткерү өчен үткәрә: *Татарстан Салым полициясе 1996 ел йомгаклары буенча журналистлар өчен **брифинг** уздырды* (М.ж., 1997, 31 гыйнв.).

**Пресс-релиз** — «хөкүмәт учреждениеләре, халыкара оешмаларның штаб квартирлары тарафыннан матбугат органнары өчен чыгарылган, тиз арада бастырылырга тиешле мәгълүматларны үз эченә алган бюллетень» (СЭС, 1985, 1052 б.): *18 августта матбугат үзәге республика, Россия, БДБ массакүләм мәгълүмат чараларына беренче **пресс-релиз** тапшырачак* (В.Т., 1997, 12 авг.).

**Респондент** (*рәсми* анкета сорауларына җавап бирүче яисә интервью бирүче кеше» — ТСРЯ, 677 б.) сүзен дә шартлы рәвештә шушы төркемчәгә кертәбез. Рус телендә бу мәгънәдә XX гасырның икенче яртысыннан билгеле булса да, татар әдәби телендә ул 80—90 нчы елларда гына ныгыды: ***Респондентлар** ни өчен «Сөембикә»гә язылмаганнар соң?* (С-ә, 1995, № 2, 30 б.).

**3. Техника һәм җитештерү өлкәсенә караган лексика**

Фән һәм техниканың үсүенә бәйле рәвештә һәр чорда телгә яңа сүзләр кереп тора. XX йөзнең 80—90 нчы еллары — тормышның һәр тармагына диярлек электроника һәм информатиканың ныклап үтеп керү чоры. Бу, билгеле, лексикада да чагылыш тапты. Әйтик, 80 нче елларда татар дөньясы да компьютер техникасын үзләштерде. Моңа бәйле рәвештә телебез бик күп яңа алынмалар белән баеды. Элек махсус әдәбиятта гына очратырга мөмкин булган күп электрон-хисаплау техникасы терминнары хәзер һәр мәктәп укучысына диярлек таныш. Шуларның матбугат битләрендә дә еш очраганнарына гына мисаллар китерәбез:

**Дискет/дискета** — «информацияне хисаплау (компьютер) техникасында саклау өчен сыгылмалы диск» (СИС, 1997, 70 б.): *Ул чагында майор хезмәт итүнең барлык елларында туплаган иң кыйммәтле серләрне **дискетка** җыйган да аны сату өчен Мәскәүгә алып килгән* (В.Т., 1997, 16 июль).

**Дисплей** — «электрон-хисаплау машинасыннан алынган информацияне (текст, сызым, схема рәвешендә) экранда күрсәтү җайланмасы» (ТСРЯ, 167 б.): *Замандашыбыз **дисплей** янында шуның кадәр вакытын үткәрә ки, хәтта кайвакыт киберпространство аның тормышын, яшәешен алыштырган дип уйлап куясың* (Ш.К., 1998, 13 гыйнв.).

**Драйвер** — «электрон-хисаплау машинасы өчен идарә итү программасы, системасы»: *Ягъни яңа татар **драйверы** дип йөртелә торган кечкенә генә, катлаулырак һәм күләм ягыннан чүп кенә бер программа кертергә кирәк* (Ш.К., 1998, 19 дек.).

**Интерактив** — «*с*. Компьютер белән аралашуга, «кеше-машина» диалогына бәйле» (СНИС, 57 б.): ***Интерактив** укыту чараларын куллану бик тә уңышлы булыр иде* (А.т., 2006, № 108).

**Интернет** — «халыкара компьютер элемтә челтәре»: ***Интернетка** кергәндә латин хәрефе белән дә, кириллица белән дә файдаланырга мөмкин* (М.ж., 1997, 19 сент.). «Интернет» компонеты кергән аналитик сүзләр дә арта: *Яңа елны кар белән каршыларбыз дип **интернет-сайтлар** да ышандыра алмый* (В.Т., 2006, 20 дек.). Интернет белән артык мавыгучыларны атаучы **интернетоман** сүзе дә барлыкка килде: *Гадәттә **интернетоманнарның** йокылары туймый* ... (В.Т., 2007, 17 авг.).

**Интерфейс** — «хисаплау системалары җайланмалары арасында мәгълүмат алмашу өчен унификацияләнгән сигналлар һәм аппаратура арасында бәйләнеш системасы» (СЭС, 497 б.): *Ул үзенең клиентларына элемтәнең төрле мөмкинлекләрен тәкъдим итә: мәсәлән, бер **интерфейс** аша интернетта эшләү, телевизор карау, кәрәзле телефоннан сөйләшү, хәтта видеотелефон куллану — боларның барысын да берьюлы эшләп була* (Т.я., 2006, № 75).

**Компьютер** — «электрон-хисаплау машинасы» (ТСРЯ, 289 б.): ***Компьютерлар** кешегә иҗат вакытын экономияләргә ярдәм итәргә тиеш* (Т-н, 1995, № 9—10, 49 б.).

**Листинг** — «электрон-хисаплау машинасына кертелгән информацион белешмәләр» (СИС, 1997, 173 б.): *«Татнефть»нең акцияләрен Лондон **листингына** керттерү өчен ул җаваплы иде* (В.Т., 1997, 19 февр.).

**Монитор** — «... 2. Компьютерның экранга текст һәм график мәгълүмат чыгару җайланмасы, дисплей» (БТСРЯ, 555 б.): *Чынлыкта исә компьютер радиациясе турында сөйләүче кешеләр **мониторны** атом-төш реакторы белән бутады кебек* (В.Т., 2007, 14 сент.).

**Принтер** — «компьютердан алынган информацияне хәрефләр-цифрлар рәвешендә бастыру җайланмасы» (ТСРЯ, 595): *Һәр бүлекчәгә бер генә булса да персональ компьютер һәм **принтер** алып куярга җыенабыз* (Т.я., 1997, 16 гыйнв.).

Яңа төр элемтә чараларына бәйле атамалар да телебезгә шактый керде:

**Блокиратор** — «бер абонент линиясенә ике телефон аппараты тоташтыру җайланмасы» (СЭС, 1985, 147 б.): *... фатирдагы шәхси кулланылыштагы телефон аппараты өчен 27 сум, **блокиратор** белән 21 сум ...* (Т.й., 1998, 10—17 гыйнв.).

**Виброзвонок** — «кесә телефонының шылтырау урынына тирбәнү хәрәкәтләре ясавы»: *Максим Галкин телефонына көй куеп азапланмый — **виброзвонок** белән генә канәгатьләнә* (В.Т., 2007, 17 авг.).

**Пейджер** — «абонент белән компьютер системасы аша берьяклы элемтә урнаштыру өчен дисплейлы шәхси кабул иткеч җайланма» (ТСРЯ, 497 б.): *Татарча телеграмма җибәрү, **пейджерга** татарча хәбәр тапшыру ... мөмкинлегеннән без әле һаман мәхрүм* (М. ж., 1997, 1 май).

**Радиотелефон** — «сөйләмә формадагы хәбәрләрне радиодулкыннар аша тапшыручы элемтә системасы»: ***Радиотелефон** элемтә челтәре башта Казан һәм аның тирә-ягына кертеләчәк* (Т.я., 1991, 12 сент.).

**Телекс** — (1. Хәбәрләшү телефон станциясе аша башкарылган халыкара абонемент телеграф челтәре. 2. Шундый телеграф аппараты. 3. Мондый аппарат аша алынган хәбәрнең тексты — ТСРЯ, 792 б.; СИС, 1997, 264 б.), **телефакс** — (факсимиль аппаратлар ярдәмендә электроканал буенча яссы сурәтләр тапшыручы элемтә челтәре; фототелеграф — ТСРЯ, 792 б.; СИС, 1997, 279 б.); **факс** — (... 2. Телефакс аша җибәрелгән яисә алынган хәбәр. 3. Телефакс буенча информация җибәрүче аппаратның абонемент номеры — ТСРЯ, 847 б.) алынмалары да безнең җирлек өчен яңа төшенчәләрне белдерсәләр дә, акрынлап телебез өчен гадәти сүзләргә әверелеп баралар: *Эшчәнлек өлкәсе, вәкаләтләр, фирма адресы, **телефакс**, **телекс** номерлары язу да мәҗбүри* (Я-н, 1995, № 11, 28 б.). *Өстәвенә аңа бер **факс** һәм бер язу машинкасы тәгаенләнгән* (Ю-ш, 1997, 24 дек.).

Башкару-күчермә ясау җайланмалары атамалары **ксерокс** (электрофотография ысулы белән төрле сурәт, текст, документлардан күчермә алу җайланмасы), **ксерокопия** (шул җайланма ярдәмендә алынган күчермә (ТСРЯ, 311 б.), **ризограф** (чагыштырмача аз тираж белән газета-журналлар, брошюралар, төрле бланклар бастыру җайланмасы; мини-типография) сүзләре татар җирлегенә карата ныклап XX гасыр ахырында кулланылышка керделәр: *Ләкин китапның бүлекләрен **ксерокс** аша чыгарып, группага бер-ике генә кулланма биреп интегәбез* (М-т, 1996, 15 дек.). *Анда утызга якын татар китабының титул битләре төшерелгән **ксерокопия** бар иде* (М-с, 1997, № 8, 54 б.). *Газета компьютерда җыелды, «Камгэсэнергострой» АҖ типографиясендә **ризографта** басылды* (Т.й., 1998, 16—23 май).

Ял итү, күңел ачу, көнкүреш хезмәте күрсәтүгә бәйле техник җайланма исемнәре дә бу чорда телебезгә шактый керде, аларның күбесе төрле тыңлау, карау аппаратлары атамалары — беренче компонентлары **аудио-** (тыңлау өчен, ишетү юлы белән кабул ителә торган — ТСРЯ, 31 б.), **видео-** (сурәт ясаучы электросигналлар өлкәсенә караган ... — ТСРЯ, 82 б.), яисә икенче компонентларын

**диск-** (грампластинка — СИС, 1997, 69 б.), **кассета-** (магнитлы лента урнаштырылган ябык яссы тартмачык — ТСРЯ, 268 б.) алынмалары тәшкил иткән кушма сүзләр: *«Бизнес-рекордс» студиясендә аның җырларыннан төзелгән **аудио-кассетасы** һәм Швециядә **лазер-дискы** чыкты* (Т.я., 1996, 16 нояб.). *... «Айдар» кибетенә **видеокамера** куйдырту өчен җитәкчене шактый үгетләргә туры килде, ди ...* (М.ж., 2006, 10 нояб.). ***Видеоплеер**, өй кинотеатры фәлән-фәсгуть дип ...* (В.Т., 2007, 7 гыйнв.). *«Тургай» тыңлаучыларны иң яңа кассеталар, **компактдисклар** белән таныштыра ...* (К.у., 1996, № 11, 192 б.).

**Плейер** — «уйнаткыч» алынмасы аудио- видео- аныклагыч компонентлары белән дә, алардан башка да кулланыла: ***Плейерны** бөтен көченә куеп тыңласаң, мескен колаклар 110 децибеллга чыдарга тиеш булалар* (И-л, 1997, № 11, 77 б.).

Сөйләм теле тәэсирендә соңгы елларда **видео** алынмасы да рәсми стильләрдә аныклагыч компонент буларак кына түгел, мөстәкыйль сүз буларак та файдаланыла: *Әмма хәзер аны яңача, ягъни хәзерге техник җайланмалар — **видео** һәм кино ярдәмендә җыю-туплауны оештырып җибәрү мөһим* (К.у., 1996, № 2, 172 б.).

**Денди**, **тамагочи**, **тетрис** кебек электрониканың соңгы казанышларына таянып ясалган кайбер балалар-үсмерләр уенчыкларының исемнәрен дә бу бүлекчәгә кертергә була: *Өйгә кайткач, **денди** алганга бик шатландым* (К.к., 1997, 2 апр.). *Озакламый сатуга **тамагочиның** данын төшерерлек яңа уенчык чыгарга мөмкин* (Т.я., 1998, 12 сент.).

Төрле уен җайланмаларының аерым состав өлешен белдерүче **картридж** сүзе алдагылары кебек үк татар сөйләм телендә дә, матбугатта да кулланыла: *Шулай ук бер үк фирма эшләгән приставканың төрле модельләренең **картриджлары** бер-берсенә тәңгәл килмәскә мөмкин* (Т.я., 1995, 18 февр.).

**4. Мәдәният, сәнгать өлкәсенә караган сүзләр**

Аудио-, видео- компонентлы кайбер сүзләр алдагы бүлекчәдә каралган иде, биредә аларның турыдан-туры техникага катнашы булмаган берничәсенә тукталабыз.

**Аудиоальбом** (магнитофонда уйнатып тыңлау өчен ниндидер авторның җырлары, көйләре яисә башка төрле текст язылган кассета), **видеоклип / клип** — (төрле күренешләр фонында язылган поп яисә рок эстрада җыры — ТСРЯ, 82 б.), **видеоролик** — (видеотасмага язылган фильм) сүзләре бүгенге яшьләр лексикасында иң актив сүзләрдән исәплән: *Сыңар **аудиоальбомыгыз** чыгарга өлгермәгән, ә **клипларыгыз** инде популяр телеканалларда әйләндерелә* (Т.я., 1998, 26 дек.). *Ул, «Соңгы балкыш» исемле **видеоклип** төшерелгәннән соң гына җыр сөюче тамашачыларга ирешәчәк* (Ш.Ч., 1998, 22 дек.). *Яңа башкаручыларга продюсерлык хезмәте күрсәтү, аларның җырларына **клиплар** төшерү, аудиоязмалар күбәйтеп тамашачыга җиткерү ...* (С-ә, 2005, № 12, 7 б.). *... алар экстремистик сайтларның берсенә шундый эчтәлектәге **видеоролик** урнаштырган* (В.Т., 2007, 21 авг.).

**Видеосалон** (видеомагнитофон тасмасына язылган фильмнарны күмәкләп карау урыны, кечкенә кинотеатр) сүзе, узган гасырның 80 нче еллар ахыры — 90 нчы еллар башында телгә кереп, актив кулланылышта булды һәм, күпчелек гаиләләр шәхси видеомагнитофонга ия булганнан соң, акрынлап 90 нчы еллар уртасыннан пассив сүзлеккә күчте: ***Видеосалоннардагы** экраннардан кан елга булып ага* (Ш.Ч., 1992, 21 апр.).

«Зур, тантаналы, бәйрәмчә» мәгънәле **гала** компонентлы (СИС, 1988, 107 б.; ТСРЯ, 125 б.) **гала-концерт** сүзе соңгы елларда «төрле эстрада йолдызлары катнашында зур концерт-тамаша» мәгънәсендә кулланылышка керде: *18 август көнне 18 сәгатьтә Г.Камал ис. Татар дәүләт академия театрында һинд мәдәният җәмгыяте **гала-концерт** оештыра* (Т.я., 1991, 15 авг.).

**Ди-джей** (музыкаль тапшыруларны алып баручы) сүзе яңа типтагы тапшырулар оештыручы дәүләти булмаган радио- телевидение каналлары ачылуга бәйле рәвештә шактый актив кулланылышта: *«Курай» [радиосы] **ди-джейларының** татарча гына сөйләве кайбер гайбәтләргә азык булды* (Т.я., 1996, 10 окт.).

«Дисклар, ягъни грампластинкалар җыелмасы яки саклау урыны» мәгънәсендә рус телендә XX гасырның икенче яртысыннан ук билгеле (СИС, 1997, 70 б.) **дискотека** сүзе 80 нче елларда (1. Музыка көенә бию өчен махсус җиһазландырылган зал, мәйдан. 2. Яшьләрнең биюле күңел ачу чарасы — ТСРЯ, 167 б.) мәгънәләрендә рус телендә дә, татар телендә дә бик актив сүзләрнең берсенә әверелде: *Ул үзе укый торган мәктәптә **дискотека** өчен музыка көйли иде* (Т.х., 1992, 25 дек.). «Радио аша дискотека өчен көйләр тапшыру» мәгънәле **радиодискотека** сүзе дә еш яңгырый: *Ә кичке сәгать уннан соң **радиодискотекада** барлык ди-джейлар да тыңлаучыларыбыз белән генә аралашачак* (В.Т., 2007, 17 авг.).

**Караоке** — «кушылып җырлау өчен язылган көй һәм текст»: *«Җырлыйк әле. **Караоке»** тапшыруында Русиянең төрле төбәкләрендә яшәүчеләр дә үзләренең җыр-моңга булган осталыкларын сынап карый алалар* (И-л, 2006, № 9, 9 б.).

**Кастинг —** «сәнгать өлкәсендәге ярыш-тамашага катнашучыларны алдан сайлап алу»: *... бу **кастинг** синең өчен* (В.Т., 2007, 17 авг.).

Сынлы сәнгать өлкәсенә караган «бер материалга башка төрле фактуралы, төсле башка материал беркетү; шул юл белән ясалган әсәр» мәгънәле (ТСРЯ, 283 б.) **коллаж** сүзе «төрле фотосурәтләрне берләштереп эшләнгән рәсем» мәгънә төсмере белән баеп, газета-журнал битләрендә фото-компоненты белән дә, аннан башка гына да еш урын ала: *Компьютер ярдәмендә эшләнгән һәм берләштерелгән фотографияләрдән торган һәр эш үзенчәлекле* ***коллаж*** *тәшкил итә* (Т. я., 1997, 13 февр.).

Алынмалар сүзлекләрендә дә чит илләргә карата гына кулланылучы сүз буларак теркәлгән **продюсер** (СИС, 1988, 401 б.) алынмасы соңгы елларда татар җирлегендә дә (сәнгать өлкәсендәге финанс эшелләрен) атау өчен кулланыла башлады: *«Казан егетләре» төркеме һәм аларның* ***продюсеры*** *Рафаэль Мәҗитов* (Т.я., 1998, 26 дек.).

**Рок** (иҗтимагый-драматик тәэсирлелек белән сугарылган, тиз ритмда, күбрәк электрон инструментларда башкарылучы сәер эстрада музыкасы — ТСРЯ, 633 б.) сүзен дә телебез үзләштерде дияргә җирлек бар, ул күбрәк музыка, фестиваль кебек компонентлар белән кулланыла: *Шимбә көнне, 21 сентябрьдә, Ленин мемориалы каршындагы мәйданда* ***рок-фестиваль*** *уздырыла* (Т.я., 1991, 24 сент.). *Җырларны альтернатив* ***рок, панк-рок*** *һәм* ***рок*** *юнәлешенең башка төрләрендә иҗат итәбез* (Ш.Ч., 2006, 13 дек.).

Халык телендә «япон тактасы» дип йөртелүче чорның иң популяр музыкаль уен коралы атамасы **синтезатор** әдәби тел тарафыннан үзләштерелде: ... *«Сабантуй»ны Матбугат бәйрәме белән котлап, үзенең яраткан җырларын баянда һәм* ***синтезаторда*** *үзе уйнап башкарган иде* (С-й, 1995, 11 нояб.).

**Хит-парад** (популярлык парады, аеруча популяр музыкаль әсәрләр һәм башкаручыларның, диск һәм грампластинкаларның һ.б.ш. сорау алу нәтиҗәләре нигезендә ... билгеләнгән һәм игълан ителгән исемлеге — СИС, 1997, 295 б.) неологизмы да хәзер татар җирлегендә кулланыла: ... *«Бизнес-рекордс» фирмасы үткәргән* ***хит-парадларда*** *һәрвакыт алдынгы урыннарда торган З.Фәрхетдинова, З.Билалов, аеруча С.Фәтхетдиновның исемнәре булмау аптыратты, әлбәттә* (Т.я., 1996, 12 нояб.).

**Шоу** (зур эстрада тамашасы, күңел ачу программасы — ТСРЯ, 899 б.) үзе дә төрле аныклаулы атамалар һәм кушма сүзләр составында да бик актив кулланылышка керде һәм инде киңрәк мәгънәдә күп халык җыеп үткәрелгән төрле шау-шулы чараларны белдерә: *Модаларны күрсәтү төсләр уенына корылган, театрлаштырылган* ***шоу*** *рәвешен ала* (С-ә, 1996, 11 нояб.). ***Аэрошоуга*** *мөкиббән китүчеләр Казансу елгасы ярында ... үзләренә җан азыгы таптылар* (К.у., 1998, № 10, 189 б.).

Шоу сүзеннән ясалган «эстрада тамашасын алып баручы артист, гомумән, күңел ачу программаларының алып баручысы» мәгънәле **шоумен** алынмасы «алып баручы, конферансье» синонимик рәтен киңәйтте: *Президиум белән рәтләр арасында кулына микрофон тоткан четердек* ***шоумен*** *чабып йөри* (Т.я., 1998, 27 гыйнв.).

Бу төркемгә шулай ук рус теленнән кергән **боевик** (шау-шулы уңыш белән баручы, мавыктыргыч сюжетлы кинофильм, тамаша (ТСРЯ, 53 б.) алынмасын да кертергә була: *Мәскәү каналлары берсен-берсе уздырып, уен-муен һәм атышлы, үтерешле* ***боевиклар*** *гына күрсәтеп, инсафлы да булып кала бирә* (Т.я., 1998, 7 май).

Охшаш «курку, кот алыну тудыруга корылган сюжетлы детектив-маҗаралы фильм яки китап» (ТСРЯ, 812 б.) мәгънәле **триллер** алынмасы да еш кулланыла: *Боевик-****триллер*** *карарга күнеккән хәзерге заман кешесе бу юлларны укыгач, бәлки, көләр генә* ... (Өмет, 2007, 20 сент.).

**5. Физкультура-спорт терминнары**

«КамАЗ» автомобильләренең халыкара ярышларда катнаша башлавы телебезгә **ралли** (махсус әзерләнгән автомобильләрдә һәм мотоциклларда билгеле график һәм маршрут буенча спорт ярышы (СИС, 1997, 229 б.), **авторалли** сүзләренең ныклап керүенә этәргеч бирде: *1998 елның соңгы көнендә, 31 декабрьдә, Франциянең Гренада шәһәрендә 21 нче мәртәбә Париж-Дакар* ***автораллие*** *старт ала* (Ш.Ч., 1998, 26 дек.). *Бу көннәрдә* ***раллины*** *оештыручылар маршрутларны үзгәрттеләр* (В.Т., 1999, 16 гыйнв.).

XX гасыр ахырында Көнчыгыштан — яңа көрәш төрләре, ә Көнбатыштан — тән фигурасын үзгәртү-матурлауга бәйле физкультура күнегүләре, тормышыбызга актив килеп кереп, телебезнең спорт лексикасын баеттылар: *Иң әүвәл, шахмат, шашка,* ***армрестлинг, мини-футбол*** *буенча район беренчелегенә ярышлар тәмамлануга, «Күңелле стартлар» үз тамашачысын бергә җыяр* (М-т, 1996, 6 дек.). *Бер-бер артлы* ***каратэ, тхэквандо, айкидо, кикбоксинг*** *кебек яңа спорт төрләре егет, хәтта кызлар арасында да таныла* (Я-н, 1997, № 6, 14 б.). *Аннан соңгы унъеллыкта төрле* ***аэробика, шейпинг, бодибилдинг*** *кебек күнегүләр популярлашып китә* (С-ә, 1996, № 11, 20 б.). *Балалар иҗат үзәгендә урнашкан «Джаги-Баги» исемле* ***брейк-данс*** *(акробатика элементлары белән бию) студиясендә шөгыльләнүләренә ел ярым гына узса да ... зур уңышларга иреште инде* (Ш.Ч., 2006, 13 дек.). **Пейнтбол** *ул — экстремаль спорт төре* (Ш.Ч., 2007, 10 окт.). *Бүген хоккей буенча* ***плэй-оффта*** *чирекфинал уеннары башлана* (В.Т., 2007, 20 март). *Үзәк стадион янәшәсендәге спорт мәйданчыкларында ике йөз егерме алты команда* ***стритбол*** *(урам баскетболы) буенча көч сынашты*

(Т.я., 1998, 16 июль). *Ләкин махсус **тренинглар** миңа бу халәттән котылырга ярдәм итте* (Ш.Ч., 2007, 10 окт.). *Хөкүмәт мондый **фитнесны** хуплый* (М-ф, 2007, № 9, 94 б.).

**6. Криминаль дөньяга караган лексика**

Элекке идеалларның җимерелүе, бер яктан, массакүләм хәерчелек-эшсезлек, икенче яктан, аерым кешеләрнең чамасыз баюы шартларында җәмгыятьнең криминальләшүе элек чит илләргә карата гына кулланылган кайбер сүзләрнең үз чынбарлыгыбыз атамалары булып, татар телендә ныгуына китерде. Шундыйларның аеруча активларына тукталып китәбез.

**Киллер** — «профессиональ, ялланган кеше үтерүче» (ТСРЯ, 273 б.). Чыганак Америка инглиз телендә, гомумән, үтерүчене аңлатучы бу алынма (СИС, 1997, 128 б.) рус һәм татар телләрендә конкретрак — заказ буенча билгеле суммага үтерүчене, профессия исемен аңлата: *Күрәсең, **киллер** йә танып җиткермәгән, йә бер-бер хәлгә очрап ялгыш атып җибәргән* (М-т, 1997, 20 сент.). Күчерелмә мәгънәдә дә кулланылуы киллерның телебездә инде ныклап үзләштерелүе турында сөйли: *Сәяси **киллерлар** бездә җитәрлек* (М-т, 1996, 29 нояб.).

**Мафия** (1. Эре җинаятьчеләрнең яшерен киң тармаклы террористик оешмасы. 2. *күч.* Үз максатларында яшерен һәм җинаятьчел эш итүче кешеләрнең оешкан төркеме — ТСРЯ, 347 б.), **мафиози / мафиоза** — «мафия члены» (ТСРЯ, 347 б.) алынмалары элек, беренче чиратта, мәгълүм чит ил сериаллары аша телгә кереп, хәзер аеруча сөйләм телендә актив сүзләргә әйләнделәр: *Бүген илдә **мафиянең** ачыктан-ачык чәчәк атуы күз алдында, җинаятьчелек үсә* (Т-н, 1995, № 11—12, 12 б.). ***Мафиози** атлы каһәр сукканнары сине теләсә кайчан бәреп китә* (М-т, 1995, 1 апр.).

**Наркотик, наркоман, наркомания** сүзләре ил тормышына бәйле рәвештә актуальләшү белән беррәттән телебезгә **наркобизнес** (наркотиклар белән законсыз сәүдә итүдән керем китерә торган бизнес) (ТСРЯ, 391 б.), **наркомафия** (наркотиклар җитештерү һәм күпләп сатуны оештыру белән шөгыльләнүче җинаятьчел оешма) кебек яңа сүзләр дә барлыкка килде: *Башкалабыз Казан шәһәренең **наркобизнес** үзәге булуы беркемгә дә сер түгел* (В.Т., 1997, 16 июль).

Наркоманиянең «кардәше» булган **токсикомания** (организм өчен агулы булган матдәләр, препаратлар куллануга әвәслек чире — ТСРЯ, 801 б.) сүзе дә телебездә ныгыды: *Сак булыгыз: Чаллыда **токсикомания** өрәге йөри* (К.к., 1996, 2 дек.).

**Рэкет** (куркыту, шантаж юлы белән кеше табышларын җинаятьчел үзләштерү), **рэкетир / рэкетер** «рэкет белән шөгыльләнүче кеше» (ТСРЯ, 690 б.) сүзләре рус матбугатында чит илләргә карата XX йөзнең 60 нчы еллары ахырыннан ук күренә башласа да (60. 144 б.), аларның телдә актив үзләштерелүләре 80 нче еллар ахырына карый: төрле кооперативлар, шәхси эшмәкәр-байлар белән беррәттән, алар исәбенә яшәүчеләр дә барлыкка килде: *Базар продукция тапшыручыны кабул итә, сатуны оештыра, ... **рэкеттан** саклый* (Т.я., 1995, 27 май). *Хакимият башлыгы урынына үзенең кандидатурасын тәкъдим иткән бу кеше «абруйлы» карак һәм **рэкетир** булып чыккан* (Т.я., 1997, 15 февр.).

Телебез өчен хәзер «хәлле кешеләргә түләүле җенси хезмәт күрсәтүне оештыру» мәгънәле **секс-бизнес** һәм аңа бәйле **сутенер** сүзләре дә чит түгел. Соңгысы сүзлекләргә теркәлгән «үзенең сөяркәсе-фахишә хисабына яшәүче кеше» (ТСРЯ, 781 б.) мәгънәсен киңәйтеп, «законсыз рәвештә түләүле җенси хезмәт күрсәтүне оештыручы кеше»не аңлата: *Быел Казан милициясе хезмәткәрләре кечкенә кызларны **секс-бизнеска** тарту белән шөгыльләнүче ике **сутенерның** җинаять эшчәнлеген фаш итте* (В.Т., 1999, 13 гыйнв.).

Юриспруденция өлкәсенә караган **интерпол** (халыкара криминаль полиция оешмасы (СИС, 1997, 101 б.) сүзе дә актив кулланылышка күчте: *Наркотиклар белән эш итүче банда **интерпол** күзәтүе астына эләгә* (Ш.К., 1998, 16 гыйнв.).

**Хакер** — «интернет челтәре аша җинаятьләр эшләүче» сүзе дә хәзер бик актив: ***Хакер** хәзер Нью-Йорк төрмәсендә мәхкәмә чыгаруны көтә* (М.ж., 2007, 12 окт.).

**7. Аномаль күренешләр һәм традицион булмаган медицинага караган лексика**

Идеологик чикләүләр бетеп, элек сөйләргә-язарга ярамый торган темалардан табу алынгач, әлегә фәнни яктан аңлатып булмый торган күренешләр, башка дөнья, галәмнәр белән бәйләнешләр, авыруларны гадәти булмаган чаралар белән дәвалауга бәйле күп кенә сүзләр телебезгә керде. Шуларның аеруча активларын алфавит тәртибендә карап үтәбез.

**Аура** — «тере организмнан чыккан энергетик нурларның җыелмасы; биокыр» (СИС, 1997, 36 б.): *Гадәттә **аура** гәүдәдән 3—5 см ераклыкта урнаша* (Т.я., 1998, 24 гыйнв.).

**Вампир** (1. Зур ярканат. 2. *миф.* Кабердән чыгып, терелләрнең канын эчүче мәет, убыр. 3. *күч.* Рәхимсез, канечкеч кеше — ТСРЯ, 68 б.) сүзе телебезгә әлегә сүзлекләрдә дә теркәлмәгән «кеше энергиясен үзләштерүче» мәгънәсендә керде. Башка мәгънәләре алда саналган татар сүзләре белән белдерелә (РТС, 59 б.): *Энергетик **вампирлар** ауraның әнә шул сыйфатыннан файдаланалар да инде* (Т.я., 1998, 24 гыйнв.).

**Зомби** — 1. *миф.* Үз җанын чакырып китергән кешенең ихтыярын үтәүче мәет. 2. *күч.* Үзенең ихтыярсызлыгы белән зомбины хәтерләтүче, башкалар ихтыяры тәэсирендә ваемсыз рәвештә эшләр башкарырга сәләтле кеше — СИС, 1997, 81 б.): *Ул хәтерен дә, ихтыярын да җуйган **зомбига** яки маңкортка әйләнгән* (Т.я., 1995, 28 март).

**Контактер** — «чит дөнья белән бәйләнеш тотучы; җиргә килеп йөрүче, хәбәрләр җибәрүче башка цивилизация вәкиле»: *Бүгенге көндә **контактерлар** аша Галәмнән бик күп кисәтүләр алына* (З.-Т., 1999, 5 гыйнв.)

**Оккультизм** — табигатьнең серле һәм гайре табигый, аерым кешеләр генә төшенерлек серләре турында суевер күзаллаулар системасы (СИС, 450 б.): ***Оккультизм** белән шөгыльләнүнең яман рухи нәтиҗәләре буларак, коточкыч вәхши җинаятьләр, эчкечелек, наркомания кебек яман авырулар саны да арта бара* (И-л, 2002, № 6, 66 б.).

**Полтергейст** — «йорттагы материалистик күзлектән аңлатып булмый торган төрле күңелсез күренешләрнең сәбәпчесе дип исәпләнгән зат» (СИС, 1997, 270 б.): *Рухани килеп дога укып китә, әмма **полтергейст** барыбер югалмый* (Т.я., 1998, 1 гыйнв.).

**Уфолог** — «уфология белгече» (ТСРЯ, 844 б.): *Былтыр әби яшәгән Сүрмәнә бистәсенә бөтен дөньядан **уфологлар** килеп, чит планетада яшәүчеләр белән элемтәдә булган Мәйвәш әбинең кабере янында аны искә алганнар* (З.-Т., 1999, 22 гыйнв.).

**Уфология** — «билгесез очып йөрүче объектларны (НЛО) өйрәнү белән шөгыльләнүче фән» (ТСРЯ, 844 б.): *Быел хәтта **Уфология** академиясе ачылды* (В.Т., 1999, 7 гыйнв.).

**Хилер** — «хирургия әсбаплары кулланмый гына операция ясаучы яисә гадәти булмаган биоэнергетик сәләт, дога, өшкерү һ.б. ярдәмендә дәвалаучы табиб» (СИС, 1997, 294 б.): *Казан **хилеры** беренче авыру янына килеп басты* (Т.я., 1996, 5 нояб.).

**Экстрасенс** — «экстрасенсор, ягъни гадәттән тыш тоеп белү сәләтенә ия кеше» (ТСРЯ, 908 б.): *Бу исемне ишетмәгән, белмәгән кеше бар микән: күрәзәче, табиб, **экстрасенс** дистәләгән, йөзләгән кешене үлем түшәгеннән торгызган савыктыручы* (Я-н, 1996, № 11, 28 б.).

Соңгы елларда күптөрле яңа дәвалау чаралары, дару препаратлары барлыкка килде. Махсус медицина өлкәсенә караган терминнар буларак, аларның атамаларына биредә тукталмыйбыз, бары аеруча киң кулланылышка кергән һәм инде рус теленең алынмалар сүзлегендә дә чагылыш тапкан **гербалайф** (табигый чималлардан чит ил фирмалары тарафыннан әзерләнгән, гәүдә авырлыгын нормальләштерү һәм организмны әйләнә-тирәлекнең зарарлы тәэсиреннән саклау өчен кулланылучы препаратлар (СИС, 1997, 52 б.) сүзе белән бер мисал китерәбез: ***Гербалайф** белән сату итүче оешманың хезмәт дәрәҗәләре баскычы да бар* (Т.я., 1994, 17 нояб.).

### 8. Кулинария өлкәсенә караган сүзләр

Илне чит дөньядан аерып торган тимер пәрдә күтәрелү, башка илләр белән сәүдә, аралашуның активлашуы хәтта кулинария өлкәсенә дә сизелерлек йогынты ясады. Телебезгә тиз арада предметлары белән бергә **гамбургер, пицца, сандвич**, **чизбургер** кебек ризык, «**Баунти**», «**Марс**», «**Сникерс**», «**Твикс**» тибындагы кондитер эшләнмәләре, элек күрмәгән-ишетмәгән **киви**, **фейхоа** кебек экзотик җиләк-җимеш исемнәре, **гриль-бар**, **макдональдс**, **пиццерия** кебек ризык әзерләү һәм ашау-эчү урыннары атамалары керде: ***Гамбургер, хот-дог** тәкъдим итүче автобар эшләде* (Т.я., 1998, 18 авг.). *Гөмбәле **пицца**, «Сюрприз» пирожные бәяләре арттырып сатылган* (Ш.Ч., 1998, 27 июль). *Уылдык, балык, сыр белән әзерләнгән **сандвичлар** куярга була* (Я-н, 1996, № 3, 26 б.). *Ашны аз һәм атнага бер тапкыр гына ашыйлар, **гамбургер, чизбургер** ишеләрне яраталар* (Ш. Ч., 2007, 10 окт.). *Әйе, чит илдән кертелгән, «**Марс**», «**Сникерс**», «**Баунти**»лардан безнең халык тәмам гарык булды инде* (Ш.К., 1995, 17 июнь). ***Киви**, биологик күзлектән караганда, җиләк ул* (Ш.Ч., 1998, 8 сент.). ***Фейхоа** — йод күп булу белән бөтен медицина дөньясына танылган җимеш* (Ш.Ч., 1998, 8 сент.). ***Пиццерия** һәм буфетларны кайнар шулпа ашап чыгарлык ашханәләргә әйләндерәсе бар* (В.Т., 1999, 16 гыйнв.).

### 9. Көнкүрештәге үзгәрешләргә бәйле лексика

XX йөз ахыры — XXI йөз башы көнкүреш өлкәсендә дә зур үзгәрешләр белән характерлы. Көнбатыш йогынтысында бездә дә көнкүреш хезмәте күрсәтүнең яңа төрләре барлыкка килде, чит илләрдән моңа кадәр таныш булмаган күптөрле гигиена-косметика кирәк-яраклары кайтып кибет-базарларны тутырды. Матбугат чаралары аларга һәрдаим реклама ясап тора. Бу исә лексикада да чагылыш тапты. Көнкүреш хезмәте күрсәтү белән бәйле берничә яңа сүз карап үтик:

**Визажист** — «макияж, косметик грим салу буенча белгеч» (ТСРЯ, 82 б.): *Казанның танылган **визажисты** Светлана Шулова — «Айсылу» кушымтасының кунагы* (С-ә, 1996, 11 нояб.).

**Дизайн** — «әйбер, машина, интерьерларны уңайлылык, экономия, матурлык принципларына нигезләнеп конструкцияләү, проектлаштыру» (ТСРЯ, 165 б.): *«Европа стандартларыннан калышмаган **дизайн** конструкцияләре пәйда булуны хупларга гына кала* (А-к, 1997, № 5—6, 128 б.).

*Программалаштыру, **веб-дизайн**, компьютер графикасы, анимация һ.б.ларга өйрәнә аласың* (В.Т., 2007, 17 авг.).

**Дизайнер** — «рәссам-конструктор, дизайн белгече» (ТСРЯ, 165 б.): *Аны зәвыклы **дизайнер** дип тә беләләр* (С-ә, 1993, № 11, 4 б.).

**Евроремонт** — «квартир, офис һ.б. ларны Европа илләре үрнәгендә, чит ил җиһазлары кулланып ремонтлау»: *Ул елларда **евроремонт**, чит ил җиһазлары дигәнне төштә дә күрә алмый идек* (К.у., 1998, № 1, 48 б.).

**Иномарка** — «чит илдә эшләнгән автомобиль»: *Тәрәзә-диварның теге ягында талгын гына карлар очкан Казан урамы, лекциягә ашыгучы студентлар, анда-санда узгалап китүче **иномаркалар**, тынгысыз шәһәр шау-шуы* (Я-н, 1995, № 2, 2 б.).

**Кемпинг** — «автотуристлар туктау өчен махсус җиһазландырылган урын»: *Ләкин Мозаффаров һәм Хәсәнов утырган машина **кемпингтан** ераклашкач, сержантлар зур тизлектә ... куа китәләр* (Т.я., 1998, 22 окт.).

**Сайдинг** — «төрле биналарның дивар һәм түшәмнәрен тышлау-бизәү өчен тактага охшатып пластиктан ясалган төзелеш материалы» (ТСИС, 620 б.): *Әтисе белән шул кичтә үк мунчаларын **сайдингка** төреп тә куйдылар* (В.Т., 2007, 14 сент.).

ТТАСтә теркәлмәсә дә, электән үк таныш **секс** сүзе соңгы елларда бик активлашып, көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсенә караган берәмлекләр составында да кулланыла. Нигездә, модалы чит ил товарларын сатучы кибетләрне хәзер күбрәк **шоп** алынмасы белән атыйлар. Түбәндә бу ике компонентны берләштергән «җенси мөнәсәбәтләргә кагылышлы кирәк-яраклар белән сату итүче кибет» мәгънәле **секс-шоп** интерлексемасы белән бер генә мисал китерәбез: *Ә ул ... тере хатын булмыйча, **секс-шоп** кибетләрендә сатыла торган резин курчак — җенси курчак икән!* (М.ж., 1998, 4 сент.).

Әйтелгәнчә, соңгы елларда телгә көнкүреш, гигиена кирәк-яракларын белдерүче бик күп яңа алынмалар керде. Сүзлекләрдә теркәлмәсәләр дә, мәгънәләре реклама буенча таныш. Шуларга бер генә мисал китерәбез: *Кечкенә балалы әниләр өчен **памперсның** уңайлылыгы бәхәссез* (Т.я., 1997, 20 февр.).

**10. Абстракт мәгънәле сүзләр**

**Гламур** — 1. Сөйкемлелек, сокландыру. 2. Тылсым ... (АнгРС, 601 б.) инглиз алынмасы киңрәк «матур тормыш» мәгънәсендә кулланыла: *Әгәр син **гламур** юлын сайласаң, соңгы чиккә барып, гомереңне харап итәсең ... (*В.Т., 2007, 25 сент.)

**Имидж** — «кеше турында аның кыяфәте, гадәтләре, сөйләү манерасы, менталитеты, кыланышлары нигезендә, матбугат чаралары, кешенең үзе һәм махсус белгеч — имиджмейкерлар тарафыннан тудырылган күзаллау» (СИС, 1997, 81 б.): *Заманалар үзгәргән саен, хатын-кызның **имиджы**, образы үзгәрә бара* (С-ә, 1995, № 12, 9 б.).

**Инновация** (1. Яңалык. 2. *экон*. Икътисадка яңа техника, технология, уйлап табулар кертүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы — БТСРЯ, 393 б.) сүзе, нигездә, мәгариф өлкәсенә карата укытудагы яңа технология, яңа типтагы уку йортларын белдерү өчен кулланыла: *Без бүген педагогик темаларга бәхәсләрдә «педагогик **инновация** — яңалыклар» дигән төшенчәне еш кулланабыз* (М-ф, 1996, № 1, 12 б.). *Бигрәк тә бу эшләр министрлык шөгыльләнергә тиешле ... дөрес алып барылган инвестиция һәм **инновация** сәясәте белән ныгытылса ... (*В.Т., 2007, 21 авг.).

**Менталитет** — «дөньяны кабул итү үзенчәлеге, фикер юнәлеше» (ТСРЯ, 350 б.): *Чөнки татарның **менталитеты** шундый — башкаларга хезмәт итү, буйсыну* (С-ә, 1996, № 5, 17 б.).

**Номинация** — «... 2. Конкурста катнашу, бүләк тапшыру өчен билгеләнгән иҗади эшчәнлек төре» (ТСРЯ, 421 б.): *Премия 4 **номинация** буенча тапшырылды* (М-т, 1996, 7 июнь).

**Нонсенс** — «тулы мәгънәсезлек» (ТСРЯ, 421 б.): *Рәсәй сайлауларында катнашу да юридик яктан караганда **нонсенс** булып чыга* (В.Т., 1996, 6 авг.).

**Социум** (кешеләрнең эшчәнлек шартлары бердәмлеге һәм мәдәният уртаклыгы белән характерланучы зур тотрыклы иҗтимагый берлек — СИС, 1997, 252 б.), ягъни «җәмгыять» (ТСРЯ, 752 б.): *Без бит кешеләргә билгеле бер **социум** әгъзалары итеп кенә карап килдек* (М-т, 1997, 29 нояб.).

**Тренд** — «өстенлек итүче тенденция, нәрсәнең дә булса үсеш, юнәлеше» (БТСРЯ, 1342 б.): *Әле күптән түгел генә өр-яңа **тренд** барлыкка килде — ирләр хатын-кыз сумкасы тотып йөри башлады* (В. Т., 2007, 12 окт.).

**Хобби** (буш вакытта үзең өчен башкарылган яраткан эш-шөгыль — ТСРЯ, 864 б.) сүзе матбугатта элек тә еш очраса да, татар теле сүзлекләрендә теркәлмәгән*: Эшсезлектән бозылмас өчен кеше яраткан гамәл, **хобби** эзли* (С-ә, 2002, № 8, 19 б.).

**Эйфория** — «шатлыклы, күтәренке кәеф, еш кына объектив шартларга тәңгәл килмәгән канәгатьлек, муллык-иминлек хисе» (СИС, 1997, 306 б.): *Югыйсә әлеге **эйфория** вакытында ук игътибарны аның асылына юнәлдерүчеләр дә булмады түгел* (С-ә, 1995, № 8, 3 б.).

**11. Татар җирлегенә күчерелгән экзотизмнар**

Чит көнкүреш, чит ил товарларының престижлыгы арту лексика өлкәсендә дә чагылыш таба. Рус телендәге кебек үк (74. 60 б.; 26. 56 б. һ.б.), татар матбугатында да чит ил реалиясе атамаларын үз җирлегебезгә карата куллану тенденциясе күзәтелә. Шундый сүзләрнең берничәсен карап үтик:

**Агрофирма** (авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүче хуҗалык) сүзе элекке колхоз-совхозларның күбесе юридик яктан бетерелгәч, аларны алыштырган төрле кооператив, ассоциация, берләшмә һ.б. кебек атамалар арасында, безнеңчә, иң уңышлыларыннан: *Калага терәлеп торган **агрофирма** — шуларның берсе* (Ш.К., 1994, 5 март).

Рус чыганаклы универмаг, универсам, лавка сүзләрен нәкъ шул ук төшенчәне белдерүче, әмма престижлырак **гипермаркет** (төрле товарлар белән сәүдә итүче зур кибет), **супермаркет** (нигездә, азык-төлек товарлары белән сәүдә итүче зур, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү кибете; универсам) (СИС, 1997, 260 б.), **минимаркет** (кечкенә кибет, лавка) сүзләре кысрыклый, яңа ачылучы заманча кибетләргә хәзер шушы исемнәрне бирәләр: *Ул кунакларны **супермаркет** белән таныштырды* (В.Т., 1996, 28 дек.). *Шәһәр яны вокзалында **минимаркет** ачылачак* (В.Т., 1997, 29 июль). ***Гипермаркетлар** үз акча әйләнешләренең якынча 5 процентына кадәр югалтырга мөмкин* (М.җ., 2006, 10 нояб.).

Яшьләрнең төрле төркемнәрен атаучы кайбер сүзләр дә үз җирлегебезгә кереп бара:

**Скаут** (уен, хезмәт, табигатьне өйрәнү аша яшьләрдә характер, үзара ярдәм, поход тормышы күнекмәләре тәрбияләү белән шөгыльләнүче бөтендөнья балалар һәм яшүсмер оешмасы әгъзасы — СИС, 1997, 250 б.) сүзе пионерны алыштырып бара: *Районда беренче **скаут** оешмасы 1991 елда барлыкка килде* (М-ф, 1996, № 11, 53 б.).

**Супермен** — «үзенең башкалардан өстенлегенә инанган кеше» (ТСРЯ, 780 б.): *Башка тарафлардан дәлил-мисал санап тормыйча, әлеге шул «мотоцикллы **супермен**» булу зәхмәтенә зирәк караш баглый* (К-н, 1997, № 5—6, 116 б.).

**Тинейджер** (20 яшькә җитмәгән үсмер — СИС, 1997, 267 б.) алынмасын заманча киенергә, яшәргә яраткан үз яшьләребезне атау өчен куллану да очрый: ***Тинейджер** әнә шул модельерлардан киенергә ярата* (Я-н, 1997, № 12, 42 б.).

**Панк** (нигездә, үзенең тышкы кыяфәте белән җәмәгатьчелекне шаккаттыру максаты куйган һәм аңа каршы булган яшьләр төркеме вәкиле (СИС, 1997, 211 б.), **скинхед** (яшь кешеләрнең, нигездә, Европада һәм Америкада бергә вакыт уздыру өчен формаль булмаган төркемнәргә берләшкән тибы; еш кына дорфа тәртипләре белән аерылып торалар; агрессивлык һәм экстремизмга хирыслар; тышкы яктан кием стиле һәм кырылган башлары, гадәттә, баш түбәсендәге чәч учмасы белән аерылалар (СНИС, 103—104 б.), **хиппи** (1. Җәмгыятьтәге гаделсезлеккә протестын сукбайларча яшәү рәвеше белән белдерүче яшьләр вәкиле. 2. Юри начар, шапшак киенгән, әмма һавалы кеше — СИС, 1997, 294 б.) сүзләре дә татар матбугатына чит түгел: ***Панклар, хиппилар** нәрсә эшләсә, мин дә шуның белән шөгыльләндем* (Т.я., 1999, 19 гыйнв.). *Ә Татарстанда 60 **скинхед** бар дип исәпләнә икән* (В.Т., 2007, 13 окт.).

**12. Гади сөйләм стиле алынмалары һәм жаргон сүзләр**

Рус телчеләре борчылу белдереп язуынча, соңгы елларда әдәби тел стильләре арасында чикләр «юыла бара», күп кенә гади сөйләм стиленә караган һәм хәтта жаргон сүзләре дә матбугат битләрендә зур урын алып, әдәби тел нормаларын какшата (42. 13 б.; 135. 99—101 б. һ.б.). Мондый, нигездә, рус чыгышлы гади сөйләм сүзләренең шактые татар теленә дә үтеп керде. Дөрес, матбугат битләрендә әле алар гадәттә куштырнаклар эчендә биреләләр. Берничә мисал карыйк:

**Бакс** (доллар — ТСРЯ, 34 б.) бездә әлегә ешрак стилистик максатларда, ягъни синоним буларак кулланыла: *Әгәр евро **«бакслар»ны** көчле кысрыклый башласа, ул чагында безнең гражданнар кулындагы долларларның бәясе төшмәсме?* (В.Т., 1999, 23 гыйнв.).

**Братва** (дуслар, иптәшләр — ТСРЯ, 58 б.) башкаларны контрольдә тотучы, абруйлы җинаятьчел төркемнәргә карата кулланыла: *Республика прокуроры әйтүенчә, ... төрмәләрдә дә «**братва**» идарә итә* (М.җ., 1998, 20 нояб.).

**Дебошир** — «шау-шу һәм сугышулы гауга чыгаручы, җәнҗалчы» (ТСРЯ, 155 б.): *Шәймардановны исә оештыру комитеты «**дебошир**» дип игълан иткән* (Т.я., 1998, 17 февр.).

**Дедовщина** (армиядә: яшь солдатларның элегрәк хезмәткә чакырылганнары тарафыннан кыерсытылуы — ТСРЯ, 157 б.) сүзе хәрби хезмәткә бәйле материалларда иң актив кулланылучы рәсми сүзгә әверелде: *Анда әле дә «**дедовщина**» хөкем сөрә* (М.җ., 1999, 22 гыйнв.).

**Запой** (тыелгысыз эчү, баш күтәрмичә эчү — РТС, 172 б.) сүзе хәзер чир исеме буларак сөйләм телендә дә, матбугатта да тәрҗемәсез генә кулланыла: ... *«массовый **запой**»дан чыгалмыйча агуланып үлеп китүчеләр ил халкының ел саен 700—800 меңгә кимүендә төп роль уйный да инде* (В.Т., 2006, 4 нояб.).

**Крыша** сүзе үзенең рус телендә узган гасырның 80—90 нчы елларында гади сөйләм стилендә барлыкка килгән яңа күчерелмә «яклаучы, саклаучы» мәгънәсендә татар телендә дә тәрҗемәсез

кулланыла: *КамАЗ һәм башка предприятиеләрдән кыскартылып, базарда сатарга мәҗбүр булганнар исә, боларга өстәп, «**крыша**»**га** өлеш чыгарырга мәҗбүрләр* (Ш.Ч., 1998, 11 авг.).

**Ломка** (наркоманнарда организмның наркотикларның чираттагы дозасын таләп итеп коточкыч авырту хәле) сүзе наркоманиянең татар җирлегенә дә күчүенә бәйле рәвештә телгә кереп бара: *«**Ломка**» вакытында кеше үләргә дә мөмкин* (М-т, 1996, 19 июль).

**Попса** — «таләпчән булмаган тыңлаучыга, тәрбиясез яшьләргә исәпләнгән музыкаль әсәр» (ТСРЯ, 563 б.): *Ул җиңел жанр саналучы эстрадада эшләсә дә, «**попса**»**ны** да, халык җырларын да бердәй оста башкара ...* (Т.я., 1998, 26 дек.).

**Тусовка** — «танышу, аралашу, күңел ачу өчен буш вакытта җыелу, очрашу» (ТСРЯ, 817 б.): *Санкт-Петербургта гадәттә танылган шәхесләр җыела торган «**тусовка**»**ларда** катнашасызмы?* (С-й, 1998, 19 сент.).

Мисаллардан күренүенчә, үзгәртеп кору чорыннан башлап телебезгә кергән рус-көнбатыш алынмаларының зур күпчелеге тематик яктан төп өч өлкәгә карый: икътисад-финанс, иҗтимагый-сәяси өлкә, яңа чор техникасы. Алда анализланган йөз җитмештән артык яңа алынманың яртысы алар исәбенә туры килә; бу тематик төркемчәләрдәге сүзләр сан ягыннан да якынча бер чама — һәр төркем алынма неологизмнарның унҗиде процентын тәшкил итә. Мәдәният-сәнгать өлкәсенә караган сүзләр тугыз процент, ә калган сигез тематик төркемнең һәрберсенә яңа рус-европа алынмаларының уртача бишәр проценты туры килә.

**3.1.1.** Югарыда саналган төркемнәр эчендә аббревиатуралар каралмады. Гәрчә яңа реалия атамалары буларак XX йөзнең 80 нче елларында рус телендә шактый күләмдә барлыкка килгән кыскартылма сүзләрнең (41. 47 б.) күпчелеге, беренче бүлектә каралганча, татар теленә калькалаштырылса да (1.3.3.), кайбер аеруча киң кулланылыштагы аббревиатуралар әзер килеш, үзгәртмичә кабул ителделәр. Аларга беренче чиратта соңгы чорда барлыкка килгән сәяси партия һәм хәрәкәт атамалары (ДПР, КПРФ, ЛДПР, СПС һ.б.), күпсанлы оешма, учреждение исемнәре кыскартылмалары (МММ, НТВ, ОРТ, ФНПР һ.б.) керә. Түбәндә телебезгә карата да үзләштерелгән **бомж, омон, СПИД, НЛО** аббревиатуралары белән генә мисаллар китерәбез, аларның беренче икесен — иҗтимагый тормышка, соңгыларын медицина һәм аномаль күренешләр өлкәсенә караган алынмалар исәбенә кертергә була: *Шәйхи Садретдиновка Галактионов урамының **бомжлар** рухы, мохите көн саен, сәгать саен усал, мәкерле тәэсирен ясап тормаган булса, ... Шәйхи Садретдинов яшәр дә яшәр иде* (М-т, 1996, 15 дек.). Бомж — яшәр һәм эшләр урыны булмаган кеше (ТСРЯ, 56 б.). *Эчке эшләр министрлыгында штатларны, оешкан төстәге җинаятьчелеккә каршы бүлекчәләрне арттырасы урынга, **омоннар** һәм «спецназ»лар ныгытылды* (К.у., 1996, № 7, 166 б.). Омон — махсус эш йөкләнгән милиция отряды (ТСРЯ, 452 б.). *Ә хәзер өстебезгә метеорит төшүдән һәм **СПИДтан** куркабыз* (В.Т., 1998, 22 апр.). **СПИД** — кешенең иммун системасы җимерелү авыруы — ТСРЯ, 755, 85 б.). *Узган елларда газета саен **НЛОлар*** төшкәне турында яза башладылар (Ш.К., 1995, 2 июнь.). **НЛО** — билгесез очып йөрүче объект.

Башка төр алынмалардан үзгә буларак, чыгышлары буенча яңа аббревиатуралар — рус теле сүзләре, хәтта татар җирлегендә ясалган төзелмәләрне русча язу очрый: *Моннан 5 ел элек «Татар интеллектуаль милек агентлыгы» (**ТАИС**) оешкан иде* (К.у., 1998, № 8, 192 б.). **ТНВ** *каналында яңа сериал* (В.Т., 2006, 20 окт.). **ТНВ** — Татарстан — «Яңа гасыр» телевизион каналы.

Яңа кыскартылма сүзләр арасында башка телләрдән рус теле аша кергәннәре сирәк очрый: *Бүген исә [татар язучылары], бөтен дөньяга танылу максатын-хыялын күздә тотып, **ПЭН-клуб** оештырдылар* (М.җ., 1996, 13 дек.). Бу мисалдагы интернациональ аббревиатураның телебезгә керүе бер төркем татар әдипләренең, язучыларның Бөтендөнья ассоциациясенә мөстәкыйль оешма буларак кабул ителүенә бәйле.

Кайбер яңа аналитик сүзләрне сөйләм стилендә кыскартып куллану матбугат битләрендә дә чагылыш таба: ***Автогражданка** турындагы закон инде гамәлгә кергәнче үк бәхәсләргә сәбәп булган иде* (В.Т., 2007, 13 окт.). **ОСАГО** (автограждандык җаваплылыгын мәҗбүри страховкалау ) аббревиатурасы белән параллель кулланыла). *Алла Пугачеваның **мобильнигына** гади шалтырау тавышы куелган* (В.Т., 2007, 17 авг. — **мобильный телефон** (кесә телефоны) сүзеннән. *Менә шулай булгач, нигә сезнең **соцпакетыгыз***? (Т.я., 2006, 2 нояб. — социаль пакет.)

### 3.2. Электән үзләштерелгән алынмалардагы семантик-стилистик үзгәрешләр

Яңа алынмалар керү белән беррәттән яңа тормыш шартлары, Көнбатыш йогынтысының көчәюе нәтиҗәсендә соңгы елларда телебезгә электән үзләштерелгән чит сүзләрнең дә бер өлеше аерым мәгънәви һәм стилистик-кулланылу үзгәрешләре кичерде. Дөресрәге, үзгәрешләр донор рус теле базасында булды һәм бер иҗтимагый-икътисади шартларда, бер үк дәүләттә яшәгәнлектән, татар телендә дә чагылыш тапты. Бу үзгәрешләргә кайбер сүзләрнең мәгънәсе киңәю яки кулланылыш

контексты үзгәрү, пассив сүзлектәге алынмаларның яңа чор реалияләренә бәйле рәвештә активлашу-актуальләшүе керә. Шулай ук, телнең үз лексикасындагы кебек, аерым алынмаларның уңай яки тискәре экспрессив-стилистик төсмерләре дә үзгәрде. Түбәндә бу төр алынмаларның ТТАСтә теркәлмәгән мәгънәләре, стилистик-чикләү тамгалары һәм үзгәрешләре күрсәтелә.

### 3.2.1. Мәгънә үзгәреше кичергән алынмалар

Алынмаларның мәгънәсе киңәю яисә конкретлашу күп очракта аларның кулланылу даирәсе, стиле, активлыгы үзгәрү белән бер үк вакытта һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә бара. Татар матбугаты материаллары күрсәткәнчә, татар телендәге алынманың мәгънәсе үзгәрү рус телендәге мәгънә үзгәрешләренә нигезләнә.

**Банкрот** — «1. Бурычларын үти алмаучы, бөлгенлеккә төшкән капиталист (бай, банкир); казалы сәүдәгәр. 2. *күч.* Исәбендә ялгышкан, карьерасы җимерелгән һ.б.ш. кешеләр, партияләр, группалар турында» (I, 122 б.). Базар икътисадына күчү бу сүзнең беренче мәгънәсен киңәйтте. Хәзер аерым кешеләр генә түгел, зур предприятиеләр дә банкротлыкка чыга. Шунлыктан бу мәгънәне хәзер «бөлгенлеккә төшү сәбәпле, бурычларын түли алмаучы, шунлыктан ябылу, мөлкәтен сату яисә башка хуҗага тапшыру алдында торган предприятие, оешма» дип үзгәртү сорала: *Заводларга **банкрот** булу, ябылу куркынычы яный* (Ш.К., 1992, 6 гыйнв.).

**Бизнес** — «*сөйл.* Алдашу, хәйлә юлы белән шәхси байлык туплауга нигезләнгән зур табышлы эш» (I, 160 б.). Рус теленең XX йөзнең 90 нчы елларына кадәр чыккан аңлатмалы һәм алынмалар сүзлекләрендә дә бу сүз шундый тискәре төсмер белән яки «капиталистик илләрдә ... » дигән өстәмә белән теркәлгән (СИС, 1988, 78 б.; СРЯ, 1986, 43 б.). 80 нче еллар ахырыннан ул «Табыш, керем китерә торган эшмәкәрлек, коммерция эшчәнлеге» мәгънәсендә стилистик чикләүсез кулланыла (СИС, 1997; ТСРЯ, 47 б.), татар теленең яңа аңлатмалы сүзлегендә дә «алу-сату, сату-алу эше» дип гомумкулланыш сүзе буларак теркәлгән (ТТАС, 2005, 85 б.): *Аларның күпчелеге бәләкәй **бизнеста** — сәүдә, контораларда хезмәткәрләр булып эшлиләр* (М-с, 1993, № 5, 108 б.). *Кондитер **бизнесы** бик катлаулы* (М-н, 2006, № 6, 155 б.).

**Демократия** (1. Югары властька халык ия булган строй. 2. Бөтен коллективның катнашы белән тормышка ашырыла торган җитәкчелек формасы. 3. *җый.* Демократлар һәм демократия яклы кешеләр; халыкның алдынгы катлавы — I, 297 б.) сүзе узган гасырның 80—90 нчы елларда иң актив, популяр сүзләрнең берсенә әверелде һәм әлегә сүзлекләрдә теркәлмәгән «ни теләсәң шуны әйтү, эшләү мөмкинлеге» мәгънә төсмере алды: *Хәзерге **демократия** заманында тынычлыкны яклау комитеты эшне яңача оештыра* (С-ә, 1991, № 1, 23 б.).

**Калькулятор** — «*мах.* Калькуляция ясаучы» (II, 35 б.). Электрон-хисаплау техникасының үсүе бу сүзне башка мәгънәдә, хәзер көнкүрештә киң кулланылышка кергән «автоматик исәпләүләр приборы»н атау өчен куллануга җирлек бирде: *Моны махсуслашкан оешмага тапшыру кулайрак икәнен кулга **калькулятор** тотып расларга туры килә* (В. Т., 1998, 22 апр.).

**Квота** — «*экон.* синдикатта яки картельдә катнашучыларның һәркайсы җитештерергә яки сатарга хаклы булган товарлар күләме» (II, 82 б.). Рус теленең соңгы сүзлекләрендә бу сүз киңәйгән — «налог, җитештерү, сату, илгә керү системасында рөхсәт ителгән өлеш, норма» мәгънәсендә, әмма «*экон.»* (СИС, 1997, 126 б.), «*махсус*» (ТСРЯ, 1998, 272 б.) билгесе белән теркәлгән. Соңгы елларда ул куллану даирәсен шактый киңәйтте, иҗтимагый лексикага да үтеп керде һәм тагы да киңрәк «аерым өлкәдә кем яисә нәрсә өчен дә булса югарыдан билгеләнгән өлеш, норма» мәгънәсендә кулланыла башлады: *Закон буенча ятим балалар өчен **квота** бүленергә тиеш* (М-т, 1996, 22 нояб.).

**Конверсия** — «1. *экон.* Дәүләт заемы шартларының үзгәртелүе ... . 2. *лингв.* Сүзнең нигезен яки формасын бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчерү юлы белән яңа сүз ясау күренеше ... » (II, 146 б.). Төрле өлкәләрдә термин буларак кына хезмәт иткән бу сүз яңа сәяси-икътисади шартларда «хәрби промышленность комплексы предприятиеләрен киң куллану товарлары җитештерүгә күчерү, көйләү» мәгънәсендә кулланылыш даирәсен киңәйтте: *Шуның өстенә кунакларны үз средстволарын Татарстандагы **конверсия** предприятиеләренә инвестицияләү мөмкинлекләре кызыксындыра* (Т.х., 1995, 30 июнь).

**Лицензия** (1. Чит илгә товарлар чыгарырга яки чит илдән товарлар кертергә бирелгән рөхсәт, шундый рөхсәт язуы. 2. Нәрсәдән дә булса бушлай яки льгота белән файдалану хокукы — II, 342 б.) сүзенең беренче мәгънәсе киңәеп, гомумән « ... нинди дә булса эшчәнлек башкаруга рәсми органнар тарафыннан билгеле срокка бирелгән рөхсәт; шундый рөхсәт кәгазе» формасын алды һәм хәзер төрле оешмаларга һәм аерым кешеләргә сәүдә итү, халыкка төрле көнкүреш хезмәте күрсәтү, белем бирү, дәвалау һ.б. өлкәләрдәге эшчәнлеккә бирелгән рөхсәтне билдерү өчен бик актив кулланыла: *Ликер-аракы әйберләре җитештерү һәм сатуга хокук бирүче 1,5 мең **лицензияне** юкка чыгарырга карар кылынган* (В.Т., 1997, 8 февр.).

**Пикет** (1. Берничә кешедән торган сакчы отряд. 2. Капиталистик илләрдә эш ташлаган эшчеләрнең штрейкбрехерларны предприятиегә кертмәс өчен куелган бер төркеме, шулай ук демонстрацияне төрле һөҗүмнәрдән саклау өчен куелган бер төркем сакчылар — II, 514 б.) сүзе демократия тәэсирендә үзебезнең тормыштагы күренешләргә карата да кулланыла башлады. Ул хәзер, нигездә, яңа «нәрсәгә дә булса карата протест йөзеннән яисә ниндидер таләпләр белдерү өчен кайда да булса җыелган кешеләр төркеме» мәгънәсен белдерә: *Хакимият бинасы янында **пикет** оештырырга теләгән милли хәрәкәтчеләр милиция тарафыннан кыйналды* (Ш.Ч., 1995, № 1—2, 2 б.).

**Реабилитация** (ялгыш яки явыз ният белән яла ягылган, гаепләнгән кешенең намуслы исемен (образын) кире кайтару, аклау — II, 581 б.). Бу мәгънәсендә кулланылышын татарча **аклау** синонимы файдасына киметеп, үзе күбрәк яңа «авыру һәм инвалидларның сәламәтлеген, хезмәткә сәләтлелеген торгызуга юнәлтелгән төрле чаралар комплексы» (СИС, 1997, 231 б.) мәгънәсендә файдаланыла: *Чаллы шәһәр хакимияте Яңа шәһәрнең 11 нче мәхәлләсендәге балалар бакчасы бинасын яшьләрнең социаль **реабилитация** үзәгенә бирде* (Нур, 1998, 7 февр.). Шушы ук мәгънәне бирү өчен татар теле материалында ясалган тернәкләндерү вариантын халык әлегә кабул итми.

**Репрессия** (җәза бирү, бастыру, кысу чарасы, җәзалау эше — ТТАС, II, 591 б.) сүзе тоталитар дәүләттә XX йөзнең 30 нчы елларында үз халкына карата кулланылган җинаятьләрен фашлауга бәйле рәвештә конкрет «хөкүмәт органнары тарафыннан башкарылган җәзалау чаралары» мәгънәсендә кулланыла: *1957 елда **репрессиягә** эләккән халыклар арасыннан беренче булып ... милли хәрәкәт башлап җибәрде* (М.ж., 1997, 5 сент.).

**Университет** (төрле гуманитар һәм табигать-математика бүлекләре (факультетлары) булган югары уку йорты һәм фәнни учреждение ... — III, 308 б.) алынмасы чит илләр тәэсирендә мәгънәсен киңәйтте дип карарга була, чөнки узган гасыр ахырында бик күп элекке институтлар, нигездә, бер конкрет тармак буенча гына белем бирүләрен дәвам итсәләр дә, исемнәрен техник, технологик, медицина, педагогик һ.б. университет итеп үзгәрттеләр; бу шаукым Татарстан вузларын да читләтеп үтмәде: *Күп еллар нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлек алып барган өчен Казан дәүләт **технологик университеты** профессоры Газизов Мөкатдәс Бари улына «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» ... Казан дәүләт **педагогика университеты** кафедрасы мөдире Гали Салихҗан улы Закировка ... «Русия Федерациясенең атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелде* (М.ж., 1999, 29 гыйнв.).

**Чек** (тапшыручысына агымдагы счеттан билгеле бер сумма акча бирү боерыгы язылган рәсми документ — III, 416 б.) сүзе «алынган товар өчен, түләнгән сумманы күрсәтеп, кассадан яисә сатучы тарафыннан кассага түләнәсе сумманы күрсәтеп бирелгән талон» (СРЯ, 1986, 763 б.; СИС, 559 б.; ТТАС, 2005, 650 б.) мәгънәсендә һәм әлегә сүзлекләрдә бөтенләй чагылыш тапмаган «хөкүмәт, хакимият органнары тарафыннан аз керемле кешеләргә, гаиләләргә яисә предприятие тарафыннан хезмәт хакы исәбенә эшчеләргә кибеттән азык-төлек, киң куллану товарлары алу өчен бирелгән талон» кебек яңа мәгънәләрдә, шулай ук «гражданнарга аларның хосусыйлаштырылган дәүләт милкендәге өлешен күрсәтеп бирелгән документ» мәгънәсендәге тотрыклы «**хосусыйлаштыру чегы**» калька сүзтезмәсе составында бик актив кулланыла башлады: *Редакциягә ... азык-төлек **чекларының** ничек, кайчан, кем тарафыннан бирелүен ачыклауны сорап язган хатлар еш килә башлады* (Ю-ш, 1998, № 4, 10 б.). *Лотерея уйнатуда үзләренең исемле **хосусыйлаштыру чекларын** (ИПВ) 31 декабрьгә кадәр Милли фонд акцияләренә алмаштырган кешеләр катнаштырыла* (Т.я., 1994, 27 дек.).

**Юрисдикция** (суд ясау хокукы — III, 614 б.) сүзе Федерация субъектларының мөстәкыйльлек дәрәҗәсе артуга бәйле рәвештә гомумирәк характердагы «юридик яктан билгеле бер хакимияткә буйсындырылган булу» мәгънәсе белән баеды. Әлегә бу мәгънә филологик сүзлекләрдә чагылыш тапмаган: *Анда республика территориясендә урнашкан Союз һәм Россия буйсынуындагы барлык предприятиеләр һәм оешмалар Татарстан милке дип игълан ителә, аның **юрисдикциясенә** күчерелә* (Т.я., 1991, 28 авг.).

Китерелгән мисалларның күбесендә чорга бәйле икътисади һәм иҗтимагый үзгәрешләрне чагылдыру өчен алынмаларның мәгънәләрен конкретлаштырып куллану күзәтелә: **банкрот**, **бизнес**, **демократия**, **квота**, **конверсия**, **лицензия**, **пикет**, **реабилитация**, **репрессия**, **чек**, **юрисдикция**. **Калькулятор** сүзенең яңа мәгънәсе исә техник прогресска бәйле, **университет** сүзенең мәгънәсен киңәйтүдә соңгы чор өчен хас булган Көнбатышка иярү модасы чагылыш таба.

### 3.2.2. Сүзләрнең кулланылыш сферасы һәм стиле киңәю

Иҗтимагый һәм икътисади тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә еш кулланыла башлау сәбәпле, элек билгеле бер сферада гына кулланылган кайбер сүзләр, мәгънәләрен үзгәртми генә, стильара лексикага күчтеләр. ТТАСтә икътисад өлкәсенә караган дип теркәлгән түбәндәге алынмалар соңгы елларда гомумхалык теле лексикасына күчте, ТСРЯның яңа басмасында (ТСРЯ, 1998) алар чикләү билгесез генә күрсәтелгәннәр:

**Дотация** — «*махс.* Планда каралган зыян-зарарны каплау өчен дәүләт-хуҗалык оешмаларына һәм учреждениеләргә, шулай ук материаль байлык җитештермәүче сфераның аерым оешмаларына җибәрелә торган бюджет ассигнованиесе» (I, 311 б.): *«Аларга **дотацияне** акчалата бирү гаделрәк булыр», — диде Р.Гафаров* (Ш.Ч., 1992, 5 июнь).

**Инвестор** — «*экон.* Озак срокка капитал салучы кеше» (I, 392 б.): *Озакламый аларга чит **инвесторлардан** 60–70 млн доллар акча керергә тиеш* (Т.я., 1997, 6 гыйнв.).

**Коммерсант** — «*махс.* Коммерция белән шөгыльләнүче кеше» (II, 142 б.): *Татарстанда һәр өченче контроль-касса аппаратын тикшерү **коммерсантларга** штраф түләү белән төгәлләнә икән* (Т.я., 1999, 19 гыйнв.).

ТТАСтә «китап теле» сүзе буларак теркәлгән **суверенитет** алынмасы узган гасырның 90 нчы еллары башыннан, чорның иң популяр сүзләренең берсенә әйләнеп, стильара лексикага күчте, ТСРЯда ул стилистик тамгасыз теркәлгән (ТСРЯ, 777 б.). Дөрес, хәзер күбрәк сүзлектәге «тулы бәйсезлек һәм мөстәкыйльлек» (II, 676 б.) мәгънәсеннән бигрәк ул Татарстанның эчке эшләрдә, икътисади һәм өлешчә тышкы сәясәттә элекке белән чагыштырганда берникадәр үзаллылыгын аңлата һәм «татарчалаштырылган» суверенлык вариантына караганда активрак кулланыла: *Бу эш татар халкына **суверенитетның** асылын аңлату өчен бик файдалы булачак* (Т.я., 1991, 3 сент.).

**Компенсация** (1. *кит.* Кайтару, каплау тәртибендә бирелә торган бәрабәр түләү // өстәмә эш өчен закон нигезендә хезмәт хакыннан тыш түләү // шундый очракта түләнә торган акча үзе ... — II, 144 б.) сүзе республика бюджетыннан халыкның шактый киң катлауларына түләүнең атамасы буларак гади сөйләм лексикасына да үтеп керде һәм аны хәзер стилистик яктан нейтраль сүзләр исәбенә кертергә дә була: *... сентябрьдә 120 мең сум **компенсация** түләүләре ясалды, Республика халкын адреслы яклау программасы нигезендә башкарыла торган **компенсация** түләүләре күләмнәре арттыру ягына яңадан каралды* (К-н, 1995, № 5—6, 22 б.).

**Коррупция** (*кит.* Югары хезмәт урынында эшләүче кешеләрнең җәмәгать эшлеклеләренең акчага сатылучанлыгы ... — ТТАС, II, 160 б.), **субсидия** — *«кит.* Гадәттә дәүләт тарафыннан җирле власть органнарына, фирмаларга, аерым кешеләргә яки чит дәүләтләргә бирелә торган акчалата яки натуралата ярдәм (ТТАС, II, 675 б.) сүзләре дә хәзер һәркемгә таныш һәм актив кулланыла: *Ельцин идарә иткән, ул **коррупциягә** каршы көрәш игълан иткән еллар **коррупциянең** ныклап аякланып килгән еллары иде* (М.җ., 2007, 27 апр.). *Расланган схема нигезендә, ТРДТФ бюджеттан **субсидияләр** килүне дә көтмичә, гражданнарга үз йортларын төзү өчен акча бүлеп бирә* (А.т., 2006, № 123.).

Сөйләм теле стиленә караган **недоимка** (*сөйл.* Налогның вакытында түләнми калган өлеше — II, 437 б.) сүзе бюджетка тиешле налогларын түли алмаучы оешмаларның артуы һәм алар белән эшләүче махсус оешмалар төзелү уңаеннан XX йөз ахырында стильара лексикага күчте: *Бездә һәр 100 мең салым түләүчегә салым җыю чиновниклары саны дөньядагы теләсә кайсы илдәгедән дә күбрәк: салым инспекциясе, салым полициясе, **недоимка**, төрле исемдәге мәҗбүри һәм ихтыярый-мәҗбүри взнослы төрле фондлар дисеңме ...* (Ш.Ч., 1998, 11 авг.). Бу мисал әдәби телнең гади сөйләм лексикасы исәбенә баюында алынмаларның да билгеле роль уйнавын күрсәтә.

### 3.2.3. Искергән яисә элек капиталистик җәмгыятькә карата гына кулланылган алынмаларның активлашуы

Бу төркемгә аңлатмалы сүзлектә «искергән», «тарихи сүз» билгеләре белән яисә «элекке Россиядә ... », «патша Россиясендә ... », «революциягә кадәрге Россиядә ... » (губерна, Дума, лицей, наместник, прогимназия), «патша Россиясендә ... һәм кайбер чит илләрдә ... », «буржуаз дәүләтләрдә ... » (акциз, бакалавр, вице-губернатор, гимназия, департамент, чиновник), «кайбер чит илләрдә ... », «Америкада һ.б.» (мэр, префект, колледж, бизнесмен, лоббист), «капиталистик илләрдә…» (антрепренер, биржа, префектура, фермер), «буржуаз җәмгыятьтә…» (коммерция, меценат), «капиталистик предприятиедә…» (акция, акционер, концерн) искәрмәсе белән теркәлгән сүзләр керә. Узган гасырның 80 нче елларына кадәр тарихи әсәрләрдә яки чит илләргә карата гына кулланылган бу сүзләрнең күбесенең актив лексикага кайтуы тормыштагы икътисади үзгәрешләр, дәүләт милкен хосусыйлаштыру, базар экономикасына күчү белән бәйле. Икътисади һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үзгәрүенә караган мондый мисаллар матбугатта да шактый урын алып тора.

**Акциз** (1. Капиталистик илләрдә һәм патша Россиясендә: илдә эшләп чыгарылган товарларга, бигрәк тә киң куллану әйберләренә салына торган өстәмә налог. 2. Шундый налогларны җыю учреждениесе — I, 38 б.). Социалистик экономикадан баш тартканнан соң, бу сүз икътисад-финанс өлкәсендә актив терминнарның берсенә әверелде. Ул бары беренче мәгънәсендә генә кулланыла: *Һәрвакыттагыча, казнага акчаның иң күп өлеше **акциздан**, өстәмә кыйммәткә салымнан һәм табышка салымнан керә* (В.Т., 1995, 29 апр.).

**Акция** (капиталистик предприятиеләрдә билгеле бер пай взносы кертелгәнне раслый торган кыйммәтле кәгазь — пай документы — I, 38 б.) сүзе барлык предприятиеләр дә диярлек акционерлык

җәмгыяте итеп үзгәртеп корылу уңаеннан нык актуальләште: *Бу, алдан ук уйланылганча, аерым даирәләргә төрле предприятиеләрнең **акция** пакетларын кулга төшерү мөмкинлеге ачты* (М.җ., 1997, 5 дек.).

**Биржа** (1. Капиталистик илләрдә эре сәүдә һәм финанс өлкәсе эшләрендә акцияләр һәм башка кыйммәтле кәгазьләр белән алыш-биреш итү турында килешүләр төзү урыны. 2. Сәүдә итү мәйданчыгы, базар; эшче көчләр тәкъдим итә һәм яллый торган урын — I, 167 б.) сүзе дә ике мәгънәсендә дә активлашты: *Казандагы универсаль **биржа** инде менә ничә көннән бирле Татарстан гражданнарының чекларын — ваучерларны сату белән мәшгуль* (Т.я., 1992, 2 авг.). *Республикада яшьләрнең **биржасы** рәсми төстә эшли башлады* (Ш.Ч., 1996, 19 апр.).

**Коммерция** (буржуаз җәмгыятьтә: сәүдә, сәүдә эшләре — II, 142 б.) — соңгы чор лексикасының иң актив сүзләренең берсенә әйләнде. Сәүдә эшчәнлеге белән беррәттән ул гомумирәк, «керем алуга юнәлтелгән эшчәнлек»не дә белдерә (СИС, 1988, 239 б.): *Бу **коммерция** шаукымы бик күпләрне һәм бик тиз үзенә тартып алды* (К.у., 1985, № 2, 26 б.). *Мондый банкларда кредитлар уртача 114 процентка алынды, **коммерция** банклары исә кредитларны 170 процентка бирәләр* (М-с, 1997, № 7, 152 б.).

**Концерн** (капиталистик монополияләрнең бер формасы буларак, гомуми финанс контрольлегенә нигезләнгән күпсанлы сәүдә-промышленность предприятиеләре берләшмәсе— II, 154 б.). Бөтенләй чит-ят тоелган бу сүз дә киң кулланылышка кереп бара: *Зәй районында «Зәй сөте» **концерны** оешты* (Т.х., 1995, 3 июнь).

**Казначейство** (акча средстволарының саклану һәм файдалануы, бюджет үтәлеше мәсьәләләре белән шөгыльләнүче дәүләт финанс органы (ТСРЯ, 259 б.) сүзенең язмышы бик кызыклы. Ул үзе рус теленә XIV гасырга кадәр үк үзләштерелгән казначы > казначей төрки-татар алынмасыннан ясалган (ЭСРЯ, II, 160 б.), «патша Россиясендә» һәм «кайбер капталистик илләрдәге җирле финанс органы» атамасы буларак рус теле сүзлекләрендә (СРЯ, 1988, 255 б.), шулай ук русча-татарча сүзлектә дә (РТС, 207 б.) теркәлгән. 1999 елдан Татарстанда да бюджет акчалары белән эшләүдә казначейство системасы кертелүгә бәйле рәвештә үз тамыр һәм ят суффикслы бу сүзне телебезгә яңадан кире кайтты дип исәпләргә була: *Шулай ук республикада беренче тапкыр бюджет **казначейство** аша башкарылачак, ә казна акчаларын тиешенчә тотмаган өчен штрафлар кертелә* (Т.я., 1999, 21 гыйнв.).

**Офис** (кайбер капиталистик илләрдә: контора, канцелярия — РТС, 375 б.) сүзе, ТТАСтә булмаса да, 1985 елны чыккан рус-татар сүзлегендә экзотизм буларак теркәлгән. Соңгы елларда инде ул үз җирлегебездә дә гадәти сүзгә әйләнде, чөнки үзен хөрмәт иткән һәр коммерция оешмасы диярлек урнашкан бина-бүлмәсен шушы сүз белән атый, ул аналитик төзелмәләр компоненты буларак та кулланыла: *Мин, шул сорауга җавап эзләп, 7 нче комплекста урнашкан **офиска** юнәлдем* (Ш.Ч., 1994, 22 дек.). *Оксана Матюнина туристик компаниянең **офис-менеджеры*** (В.Т., 2006, 19 дек.).

Милекчелек формасы үзгәрү базар мөнәсәбәтләре элек капиталистик илләргә карата гына кулланылган кайбер вазифа атамаларын да үз җирлегебездә активлаштырды. Әйтик, **акционер** (акцияләр хуҗасы, капиталист — I, 38 б.) сүзе бүген иң актив кулланылучылардан, чөнки хәзер һәр ике предприятиенең берсе акционерлар җәмгыяте, һәр кешегә таратылган Россия һәм Татарстан хосусыйлаштыру чекларын да күпләр төрле оешмаларның акцияләренә алыштырды, ягъни акционерга әйләнде. Бу уңайдан сүзнең ТТАСтә теркәлгән «капиталист» аңлатмасының искерүен, дөресрәге, чынбарлыкка туры килмәвен дә билгеләп үтәргә кирәк. Рус теленең аңлатмалы сүзлегенең соңгы басмаларында да ул мәгънә төшереп калдырылган (СРЯ, 1986, 22 б. һәм ТСРЯ, 1998, 20 б.): ***Акционерга** тиешле сумнар кемнәрнең кесәләрен калынайта икән?* (В.Т., 1997, 9 гыйнв.).

**Антрепренер** (капиталистик илләрдә шәхси театр, цирк тотучы — I, 60 б.) атамасы хәзер безнең ил өчен дә ят түгел: *Аннан үзенең гаиләсе, **антрепренеры** һәм пианисты Федор Иванович күренде* (К-н, 1997, № 3—4, 25 б.).

**Бизнесмен** (Америкада: һәр эштән зур табыш каерырга омтылучы эшкуар — I, 160 б.) сүзе исә сату-алу һәм башка табышлы эш белән шөгыльләнүчеләрне атау өчен эшкуар, малтабар синонимнары белән бергә шактый актив кулланыла: *Кем ничек, әмма безнең **бизнесменнар** һәм эшмәкәрләр, банкирлар ... һич зарлана алмыйлар* (Ш.Ч., 1996, 6 гыйнв.).

**Лоббист** (АКШ конгрессында теге яки бу закон проектын раслатырга яки раслатмаска тырышучы монополияләрнең түләүле агенты — II, 342 б.) алынмасы, даими нигездә эшләүче чын парламентлар төзелгәч, үз җирлегебез өчен ят булмаган сүзгә әверелде, аны киңрәк мәгънәдә тискәре төсмерсез генә закон чыгару һәм хөкүмәт органнарында үз регионы, оешмасы мәнфәгатьләрен яклаучыларга карата да кулланалар: *«**Лоббистлар** — региональ лидерлар» номинациясендә Президент М.Ш.Шәймиев ... беренче «бишлек»тә тора* (В.Т., 1999, 22 гыйнв.).

**Меценат** (буржуаз-дворян җәмгыятьтә: фән һәм сәнгать белән кызыксынып, аның файдасына материаль һәм мораль ярдәм күрсәтүче бай кеше — I, 387 б.) алынмасы, киңрәк мәгънәле спонсор, иганәче, химаяче кебек конкурентлары булса да, «әдәбият-сәнгатькә ярдәм итүче» мәгънәсендә

очраштыра: ***Меценатлар** бар, татар мәдәниятен үстерүгә күпмедер өлеш керткән алдынгы карашлы сәүдәгәрләр* (М-т, 1994, 17 сент.).

**Фермер** (капиталистик илләрдә ферма арендаторы яки хуҗасы —III, 340 б.). Авыл хуҗалыгы реформасы нәтиҗәсендә бу сүз хәзер үз җирлегебездә дә нык активлашты: *Җир аз булып тоелса, **фермер** калган җирне сатып яки арендага ала ала* (В.Т., 1996, 19 июль). Ул сыйфат мәгънәсендә дә кулланыла: *Әтнә һәм Кайбыч районнарында бер генә **фермер** хуҗалыгы да юк* (В.Т., 1995, 9 июнь).

Дәүләт төзелеше, ил, җирле органнар белән идарә итү системасындагы үзгәрешләр түбәндәге искергән һәм экзотик сүзләрнең активлашуына китерде: **Дума** (*тар.* патша Россиясендә һәм Мәскәү Русендә: идарә учреждениеләренең исеме. Дәүләт Думасы (1905—1917 еллардагы революция барышында төзелгән вәкиллекле, формаль яктан закон чыгару функцияләре булган учреждение) ... Дума урнашкан бина — I, 314 б.) — Россия Федерациясенең яңа конституциясе буенча «парламент — Федераль җыелышның түбән палатасы» исеме буларак яңадан әдәби телгә кайтты: *Дәүләт **Думасының** 1991 елда төзелгән Беловежск килешүләрен юкка чыгару турындагы карары сәяси даирәләрдә киң резонанс уятты* (М-т, 1996, 22 март).

**Губерна** (элек Россиядә һәм районнар бүленешенә кадәр СССРда административ-территориаль берәмлек — I, 279 б.). Бу сүз кайбер шовинист сәясәтчеләр һәм дәүләт эшлеклеләренең барлык Федерация субъектларын элекке кебек үк бер хокуклы губернияләр итеп үзгәртеп кору идеясен пропагандалавы һәм кайбер өлкәләрнең үзләрен шушы исем белән атау уңаеннан яңадан активлашты: *Татарстан халкының барлык матди хәле Русиягә, аның төбәкләренә бәйле булгач, безнең республика колония хәлендәге **губерна** булып чыга түгелме соң?* (Т.я., 1996, 12 дек.).

**Департамент** (1. Патша Россиясендә һәм күп кенә буржуаз дәүләтләрдә: министрлыктагы яки башка берәр югары дәүләт учреждениесендәге бүлек. 2. Министрлык (АКШта һәм Швейцариядә). 3. Иң эре административ-территориаль берәмлек (Франция һ.б. кайбер дәүләтләрдә — II, 298 б.) сүзе беренче мәгънәсендә актуальләште, хөкүмәт һәм җирле хакимият органының аерым бүлеге мәгънәсендә аеруча Татарстанда еш кулланыла: *Татарстан Президенты Указы белән республикабызда Дәүләт милек комитетының промышленность **департаменты** оештырылды* (С-ә, 1996, № 1, 29 б.). *Шәһәр хакимиятенең торак-коммуналь **департаменты** 700 млн. ... бурычлы* (Т.й., 1995, 5—12 авг.).

**Мэрия** (муниципалитет идарәсе, шул идарә урнашкан бина — II, 415 б.) сүзе дә шушы төркемгә керә, чөнки **муниципалитет** — буржуаз илләрдә җирле үзидарә органы (II, 410 б.). Ул күпсүзле «шәһәр Советы башкарма комитеты» атамасын тулысынча диярлек алыштырды: *Чаллы **мэриясе** 9 айда шәһәр бюджеты үтәлеше нәтиҗәләрен игълан итте* (В.Т., 1996, 23 июль).

**Префектура** (1. Рим империясендә административ бүленеш берәмлеге. 2. Кайбер капиталистик илләрдә административ-территориаль берәмлек белән җитәкчелек итү органы. 3. Префект ... һәм аның канцеляриясе урнашкан бина — II, 543 б.) сүзе кайбер зур шәһәрләрдәге (Казан, Чаллы) идарә эшен җиңеләйтү максатыннан төзелгән районнан кечерәк яңа административ-территориаль берәмлекләрне атау өчен кулланыла башлады: *«Электротехниклар» **префектурасы** каршындагы ветераннар хоры ... халык арасында танылырга өлгерде инде* (Ш.Ч., 1995, 18 февр.). *«**Префектура**» сүзе мәркәзебез өчен бераз ят булса да, Чаллы үрнәге бирегә дә күчә булса кирәк* (В.Т., 1998, 21 гыйнв.).

Оешма атамалары яңару белән беррәттән аларның җитәкчеләренең исемнәре дә үзгәрде, ягъни кайбер экзотик һәм искергән вазифа атамалары да актуальләште: **губернатор** (губерна башлыгы — I, 279 б.), **вице-губернатор** (патша Россиясендә һәм кайбер капиталистик илләрдә: губернатор урынбасары — I, 240 б.) сүзләре Россиянең башка өлкәләре җитәкчеләренә карата кулланыла (бездә — президент, премьер-министр), **мэр** (кайбер чит илләрдә: муниципалитет идарәсе башлыгы — II, 415 б.), **префект** (1. Борынгы Римда: башка консул һәм диктатор титулы, соңыннан — иң югары суд власте башлыгы. 2. Франциядә департамент башлыгы. 3. Кайбер буржуаз илләрдә полиция начальнигы — II, 543 б.) сүзләре Татарстанда, соңгысы «префектура башлыгы» мәгънәсендә аеруча актив кулланыла: *Казанга килгән өлкә **губернаторы** Б.Немцов радио корреспонденты белән әңгәмәдә Татарстан хөкүмәте алып бара торган политикага зур бәя бирде* (Х.д., 1996, 20 март). *Түбән Новгород **вице-губернаторы** вазифасында ... Иван Петрович шактый тәҗрибә туплый* (В.Т., 1998, 16 гыйнв.). *Ләкин **префект** буларак, И.Метшин бары тик башкала мэры Камил Исхаковка гына буйсына* (В.Т., 1998, 21 гыйнв.). *Казанның махсус бүләген шәһәр **мэры** Илсур Метшин «Мусульманин» фильмында төп рольне уйнаган Россиянең халык артисты Евгений Мироновка тапшырды* (В.Т., 2007, 14 сент.).

XX йөз ахыры — XXI йөз башында актуальләшкән сүзләрнең өченче төркеме мәгариф өлкәсендәге реформалар белән бәйле. Соңгы елларда дәүләти һәм хосусый, түләүле һәм түләүсез күп кенә яңа типтагы уку йортлары ачылды, аларга элекке Россиядә һәм күп кенә чит илләрдә яшәп килгән **гимназия**, **прогимназия**, **лицей**, **колледж** исемнәре бирелде. Болардан бары тик **прогимназия** (патша Россиясендә тулы булмаган урта мәктәп — II, 547 б.) сүзенең мәгънәсе генә шактый конкрет: «4 яки 6 еллык гимназиягә әзерлек курсы» (ТСРЯ, 607 б.), ә **гимназия**, **лицей**, **колледж** сүзләре, Л.А.Брагина хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, «әлегә дифференцияләшмәгән атамалар рәтен тәшкил итәләр» (22. 103 б.). Аларның мәгънә төсмерләре сүзлектәге аңлатмаларында ачык аерылмый: **гимназия**

(Революциягә кадәрге Россиядә һәм кайбер чит илләрдә гомуми белем бирә торган уку йорты — I, 270 б.). **Лицей** (1. *иск.* Революциягә кадәрге Россиядә: дворяннарның ир балалары өчен махсус, яхшы шартлары булган урта яки югары юридик ябык мәктәп. 2. Көнбатыш Европада: махсус урта мәктәп — II, 342 б.). **Колледж** (Англиядә һәм Америкада югары яки урта уку йорты — II, 134 б.). Рус теле сүзлекләрендә дә шул ук хәл диярлек (ТСРЯ, 130, 283, 329 б.). Бу исә ул сүзләрне хәзер дә аермыйча, бары яңа, престижлы исем булсын принцибы буенча гына куллануга китерә. Аеруча икесе дә тулы урта белем бирә торган гимназия һәм лицейны аеру кыен. Дөрес, соңгы елларда беренчесе — гуманитар, икенчесе техник юнәлеш буенча махсуслаша башлады кебек. Берничә мисал китерик: ***Прогимназия-лицей*** *директоры А.Либерман исә бу юнәлештә үзләренең традицион булмаган эш алымнары турында сөйләде* (Ш.Ч., 1996, 5 март). *Биредә 2 нче, 54 нче* ***гимназияләр****, 18 нче мәктәп, татар-төрек* ***лицее*** *укучылары Тукайның тормыш юлын, иҗатын белү буенча көч сынаштылар* (Ш.Ч., 1998, 21 апр.).

**Колледж** сүзе исә алдагы икесеннән бераз аерыла, ул гомуми урта белем түгел, ә махсус урта яисә тулы булмаган югары белем бирә. Элекке педагогия, медицина училищелары, кайбер техникумнар бүген, исемнәрен алыштырып, колледж булдылар. Әмма бу сүзне әле конкрет мәгънәле дип булмый, чөнки әлегә бездәге колледжларның күбесе махсус урта белем, кайберләре тулы булмаган югары, берничәсе исә югары белем бирә: *9 нчы классны тәмамлагач, Татар-Америка региональ* ***колледжына*** *укырга кердек* (Т.я., 1997, 30 гыйнв.). Дөрес, рәсми стильдә колледж сүзе гарәп чыганаклы көллият варианты тарафыннан кысрыклана бара.

Югары һөнәри белем бирүдә күп баскычлы системага, яңа дәүләт стандартларына күчүгә бәйле рәвештә аерым белгечлек исемнәре дә активлаша. Шундыйлардан **бакалавр** (кайбер илләрдә (революциягә кадәр Россиядә) кече гыйльми дәрәҗә — I, 112 б.), **магистр** (чит илләрнең кайберләрендә һәм революциягә кадәрге Россиядә гыйльми дәрәҗә ... — II, 353 б.), 2007 елдан бездә дә гамәлгә керәчәк югары белем бирүнең 1 нче һәм 2 нче баскычларын белдерүче **бакалавриат, магистратура** сүзләрен күрсәтергә була. *Ул — халыкара мөнәсәбәтләр* ***бакалавры****, бизнес-администрация* ***магистры*** (К.у., 1993, № 8, 191 б.). *Бу система буенча* ***бакалаврлар*** *булу өчен — 4 ел,* ***магистратура*** *дипломы өчен тагын ике ел укырга туры киләчәк* (Ш.Ч., 2007, 19 окт.)

Тикшеренүләрдән күренүенчә, искергән яки чит ил реалиясе атамалары буларак кына кулланылган пассив лексика берәмлекләренең активлашуы яңа икътисади мөнәсәбәтләргә күчү, ил-дәүләт белән идарә итү системасындагы үзгәрешләр һәм мәгариф өлкәсендәге реформалар белән бәйле.

### 3.2.4. Тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә актуальләшкән алынмалар

Иҗтимагый тормыштагы һәм икътисад, хуҗалык итү өлкәсендәге үзгәрешләр аңлатмалы сүзлектә махсус билгеләрсез теркәлгән булсалар да, татар җирлегенә карата элек бөтенләй диярлек кулланылмаган кайбер сүзләрнең кинәт активлашуына китерде. Әйтик, 1990 елның 30 августында «Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты» турында Декларация кабул ителеп, 1992 елның мартында аны Бөтенхалык референдумында раслау алда телгә алынган **суверенитет** алынмасыннан тыш **декларация**, **референдум** сүзләрен нык активлаштырды: *Тарихыбызның чираттагы сәхифәсен ачкан* ***Декларация*** *менә шундый әһәмияткә ия* (С-ә, 1995, № 8, 4 б.). *1992 елның 21 мартында үткән Бөтенхалык* ***референдумы*** *безнең буын өчен әнә шул илаһи мизгелебез иде* (С-ә, 1992, № 4, 1 б.).

Россиядә һәм Татарстанда даими нигездә эшли торган закон чыгаручы дәүләт органнары булдыру **парламент**, **фракция** кебек элек, нигездә, чит илләргә карата кулланылган сүзләрне активлаштырды: *Ул* ***парламентта*** *нинди дер бер* ***фракция*** *— Татарстан мәнфәгатьләрен яклардай блок төзү ихтималы юк та юк* (Нур, 1995, 26 окт.). Ил белән идарә итү системасындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә **президент**, **премьер-министр**, **вице-премьер** сүзләре үзебезнең дәүләт, хөкүмәт җитәкчеләренең атамалары буларак кулланыла башлады: *Татарстанлылар ел башында ук* ***президент*** *сайлау кампаниясенә керештеләр* (М-т, 1997, 10 гыйнв.). *Кичә Татарстан* ***премьер-министры*** *Ф.Мөхәммәтшин Мәскәүдә байтак эшлекле сөйләшүләр үткәрде* (Ш.К., 1998, 21 гыйнв.). *Татарстанның беренче* ***вице-премьеры*** *Равил Моратовтан да бу хакта сораштым ...* (Т.я., 1997, 6 гыйнв.).

**Президент** сүзе этимологик яктан беренчел «нинди дә булса оешманың сайлап куелган җитәкчесе» (СИС, 1997, 222 б.) мәгънәсендә дә нык активлашты, хәзер һәрбер оешма башлыгы дип әйтерлек үзен президент дип атый, гәрчә сайлап куелган булмаса да: *Тиздән* ***«президент»****,* ***«вице-президент»****,* ***«президент киңәшчесе»****, эш башкаручы 7 кешедән торган «****президент советы****» сайланды* (М-ф, 1995, № 1, 54 б.). Югарыдагы җөмләдә сүз мәктәп үзидарәсе турында бара.

Татарстанның чит дәүләтләр белән турыдан-туры мөнәсәбәтләр урнаштыруы да кайбер дипломатик терминнарны татар җирлегендә куллануга юл ачты: *Разия Мәрдәгалим кызы Гайнуллина — Татарстанның Үзбәкстандагы даими вәкиллегендә мәдәният буенча* ***атташе*** (Ш.К., 1995, 23 май).

Узган гасырның 80 нче еллары уртасында башланган сәяси һәм икътисади үзгәртеп корулар **реформа** сүзен матбугатта иң еш кулланылучы сүзләрнең берсенә әверелдерде: *Хәзер **реформаның** язмышы күбесенчә Борис Федоровның хөкүмәттән китүенә бәйләнгән* (Ш.К., 1994, 10 гыйнв.).

Элек, нигездә, төрле дәрәҗәдәге советларның еллык бюджетны раслауга багышланган сессияләреннән хисапларда һәм сирәк кенә гаилә бюджеты тезмәсендә очраган **бюджет** сүзе дә бүген публицистик стильдә дә, сөйләм телендә дә иң актив лексик берәмлекләрдән исәпләнә: *Ләкин җирле үзидарә советларының **бюджет** дефициты һәм районга каралган дотация суммасы алынып бетмәү сәбәпле, җирле үзидарәләр буенча әлеге премияләр түләнмәде* (Ю-ш, 1998, № 1, 10 б.).

Финанс-коммерция өлкәсенә караган күп термин-профессионализмнарның активлашуы турында алда сүз булган иде, биредә шул ук өлкәгә караган, сүзлекләрдә стилистик билгесез теркәлгән **вексель** сүзенең киң кулланылышка керүен күрсәтеп үтәбез: *Быел Татарстан хөкүмәте 500 миллиард сумлык **вексельләр** чыгарды* (Нур, 1996, 11 гыйнв.).

Ирекле базар шарларында җитештерү, сату-алу белән шөгыльләнүче бик күп оешмалар барлыкка килү чагыштырмача пассив запаска күчкән **кооператив** һәм элек, нигездә, чит илләргә карата кулланылган **фирма** сүзләрен активлаштырды: ***Кооперативта** эшләве дә бәхеткә булмады* (Т.х., 1992, 8 нояб.). *Алты ел эчендә **фирма** дөнья базарына чыгарырлык продукция җитештерүче гаять зур предприятиегә әверелде* (А-к, 1997, № 5—6, 125 б.).

Халыкка медицина хезмәте күрсәтү тәртибендәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә **полис** сүзе яңа «мәйданда» активлашты: *Шәһәребез шифаханәләрендә мәҗбүри медицина страхование **полислары** бирү дәвам итә* (Ш.Ч., 1997, 14 февр.).

Җөмһүриятебез күләмендә мәдәният, сәнгать, спортның төрле тармаклары буенча оештырылган бәйгеләр **гран-при** сүзен милли җирлектә дә куллана башлауга китерде: *Иң зур бүләк — **Гран-прины** тапшыру өчен сәхнәгә «Татнефть»нең генераль директоры Ринат Галиев күтәрелде* (В.Т., 1999, 23 гыйнв.).

Халыкның аерым катлавының тормыш-көнүреш дәрәҗәсе үсүе элек сирәк очраган **коттедж** сүзен көндәлек кулланылышка кертте: *Кимендә дүрт бүлмәле фатирга чыгарга, кимендә ике йөз квадрат метрлы, 3 катлы **коттедж** төзергә ...* (В.Т., 1998, 30 гыйнв.).

Яңа икътисади шартлар, банк системасының киңәюе, илдәге финанс тотрыксызлыгы күп кенә тармак сүзләре, финанс-экономика терминнарының, үз кулланылыш даирәләрендә калган хәлдә нык активлашып, матбугатта еш кулланылу сәбәпле, киң халык массаларына аңлаешлы сүзләргә әверелүенә китерде:

**Депозит** (финанс-кредит яки дәүләт учреждениесенә билгеле бер максат белән кертелә торган акча, кыйммәтле кәгазь яки документлар — I, 298 б.): *Россияннарның мондагы **депозитлары** миллиард долларлар белән исәпләнә* (Ш.Ч., 1997, 19 дек.).

**Дивиденд** (*махс.* Акционерлар Җәмгыятендә: табышның акция ияләре арасында ел саен бүленә торган өлеше — I, 302 б.): *Җитештерелгән тауар да сатыла, **диведентлар** да вакытында түләнә* (М.җ., 1997, 5 дек.).

**Инвестиция** (*экон.* Табыш алу өчен предприятиеләргә капитал салу — I, 392 б.): *Гамәлдәге предприятиеләрдә **инвестицияләр** килүен арттыру ... эшсезлекне кисәтүнең икенче юнәлеше булып тора* (К-н, 1995, № 5—6, 23 б.). *Безнең ил, моны мин һич шикләнми әйтәм, **инвестиция** җәлеп итү ягыннан күпләрне кызыктырырлык булып калачак ...* (В.Т., 2007, 9 окт.).

**Инфляция** (*экон.* Товар әйләнеше ихтыяҗларыннан артык итеп чыгару нәтиҗәсендә кәгазь акчаларның бәясе төшү — I, 401 б.): *Әйтүләре буенча, 1992 елгача саклык кассасында яткан һәм **инфляция** вакытында «янган» акчаларны да мең мәртәбә кире санаячаклар* (М.җ., 1997, 28 нояб.).

**Эмиссия** (*махс.* Кыйммәтле кәгазьләр, кәгазь акчалар чыгару — III, 574 б.): *Предприятие аннан, үз акцияләренең өстәмә **эмиссиясен** чыгарып, шул хисапка бюджет алдындагы бурычын капларга рөхсәт алган* (В.Т., 1997, 9 май).

Бу мисаллар соңгы чорда яшәешнең төрле өлкәләрендәге, аеруча дәүләт белән идарә итү һәм финанс-икътисад системасындагы үзгәрешләр йогынтысында дистәләрчә интерлексемаларның татар әдәби телендә үз җирлегебезгә карата актуальләшүен дәлилли.

### 3.2.5. Алынмаларны тискәре (пейоротив) төсмер белән куллану

Алдагы бүлекчәләрдә кайбер алынмаларның элекке идеология белән бәйле пейоротив, ягъни тискәре төсмерләреннән арынуын күргән идек (бизнес, бизнесмен, недоимка һ.б.). Шул ук вакытта үзгәртеп кору еллары һәм аннан соңгы чор матбугатында лексик берәмлекләрне, аеруча югары хакимият вәкилләренә караган сүзләрне пейоротив төсмер белән куллану тенденциясе көчәюгә бәйле рәвештә (85. 53 б.), күп кенә эмоциональ-экспрессив яктан нейтраль алынмалар соңгы елларда тискәре, өнәмәүне белдерүче төсмер алдылар. Чыгышлары ягыннан алар арасында интерлексемалар да, активлашкан рус сүзләре дә бар:

**Босс** (хуҗа, җитәкче, гомумән эшмәкәр — ТСРЯ, 57 б.) инглиз алынмасы, нигездә, партия җитәкчеләре, төрле җинаятьчел төркем хуҗаларына карата һәм ирония белән кулланыла: *Язмыш нинди борылыш ясаган: партия **боссы** мәдәният институты ректоры булып киткән* (Т.я., 1989, 14 гыйнв.).

**Делец** (уңышлы рәвештә (кайчакта бернидән дә тартынып тормыйча) эшләрне алып баручы — ТСРЯ, 159 б.) «малкуар, эшкуар, эшмәкәр» (РТС, 1985, 126 б.) сүзе шулай ук күбрәк өнәмәү төсмере белән генә кулланыла: *... Зыялы дустымның озын акча артыннан куучы «**делецлар**» рәтенә басканын күргәнем юк әлегә* (А-к, 1997, № 4, 91 б.).

**Демократ** (1. Демократия яклы кеше, демократия тарафдары. 2. Демократик партия члены ... — ТТАС, I, 297 б.) алынмасы үзенең бәяләү төсмерен капма-каршы якка үзгәртте, хәзер демократ дип күбрәк СССРны таркатучы, күп сөйләп аз эшләүче, илне XX йөз ахырындагы бөлгенлек хәленә төшерүче җитәкчелек вәкилләрен атыйлар: *Икенчеләре моны сәяси көндәшләрен юлдан бөтенләй алып ташлар өчен **демократлар** ясаган провокация дип карый* (Т.я., 1991, 29 авг.).

**Наместник** (Екатерина II вакытында бер яки берничә губернаның хәрби начальнигы — II, 433 б.) алынмасы югары дәүләт власте тарафыннан урыннарга билгеләнгән төрле түрәләрне атау өчен пассив сүзлектән алып кулланыла: *Империя **наместниклары** эре-эре завод-крепостьларын ташлап качып беттеләр* (Ш.Ч., 1997, 28 нояб.).

**Чиновник** (1. Революциягә кадәрге Россиядә һәм буржуаз илләрдә; дәүләт хезмәткәре, түрә. 2. Үзенең эшен бик хөрт, ихлассыз башкара торган, теге яки бу эшкә бик формаль карачы урындагы кеше — III, 429 б.) хәзер, гомумән, дәүләт хезмәткәрен өнәмәүче төсмер белән аңлата: *Кремль тирәсендәге **чиновниклар** арасында да аны яклаучылар булырга мөмкин* (Т.я., 1996, 26 дек.).

Чит ил телесериаллары аша турыдан-туры кергән **фазенда** (Бразилиядә зур алпавыт җир биләмәсе — СИС, 1997, 278 б.) алынмасының кулланылу үзенчәлеге кызыклы. Ул, бердән, гади сөйләм телендә шаян төсмер белән гражданнарның шәһәр, йорт янындагы кечкенә җир участокларын атау өчен, икенчедән, төрле фермерлар кулына күчкән элекке колхоз-совхоз җир биләмәләре атамасы буларак күбрәк тискәре төсмер белән кулланыла: *Сезгә сер итеп кенә әйтәм, бай мин. Фермалы һәм плантацияле **фазендам** бар* (Т.я., 1999, 23 гыйнв. — юмористик хикәядән). *Алар ... , шул ук халыкның үзеннән эшкәрттереп, үз «**фазендаларына**» ерактан — таш диварларыннан чыкмыйча гына җитәкчелек итәчәкләр* (А-к, 1997, № 8, 140 б.).

Алынмалардагы бу пейоратив төсмерләр күпчелек очракта рус теле тәэсирендә барлыкка киләләр.

### 3.3. Рус-европа алынмаларын куллланудагы аерым үзенчәлекләр

**3.3.1.** Язма матбугат, радио- телевидение аша һәрдаим кабатланып тору сәбәпле, интерлексемалар һәм рус сүзләре телгә җиңелрәк кабул ителә, чөнки алар әдәби тел һәм сөйләм теле тарафыннан параллель рәвештә диярлек үзләштерелә. Әмма күпсанлы алынмалар халыкның барлык катлаулары тарафыннан берьюлы гына үзләштерелеп бетә алмый, шуңа да, гарәп-фарсы алынмалары кебек үк, кайбер яңа кулланылышка кертелгән интерлексемалар матбугат битләрендә еш кына җәя эчендә, сызык аша һәм өтердән соң ягъни теркәгече ярдәмендә аңлатмалар белән бирелә. Әмма гарәп-фарсы алынмаларына караганда яңа яисә активлашкан интерлексемаларны аңлатып куллану очраклары күп тапкырга кимрәк, ә рус сүзләрен аңлатмалар белән бирү белән бөтенләй диярлек очрамый. Бу, бердән, мондый алынмаларның гарәп-фарсы сүзләренә караганда гомуми сан ягыннан кимрәк булуыннан килсә, икенчедән, аларның халыкка аңлаешлырак булулары турында сөйли. Аңлатма, нигездә, сүзтезмә-тасвирлама рәвешендә була, сирәк очракта гына мәгънәдәш татарча йә башка алынма сүз ярдәмендә бирелә. Рус-европа алынмаларын куллланудагы бу үзенчәлекләрне түбәндәге төркемчәләргә бүлеп бирәбез:

**1. Җәя эчендә мәгънә аңлату**

*Үзенең чыгышында М.Шәймиев **бартерны (тауар алыштыру)** бетерүне яклап чыкты* (Т. я., 1998, 17 окт.). *«**Девиант» (җәмгыять өчен куркыныч)** тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен ябык төрдәге укыту-тәрбияләү махсус учреждениеләрен бары тик ТР дәүләт идарәсенең республика органнары гына гамәлгә куя ала* (М-ф, 1997, № 10, 11 б.). «***Девальвация» (рубльнең кәгазь чүбенә әйләнүе)** белән августта таныштык. **Эмиссия (өстәмә акча бастыру )** белән безне якын араларда «шатландырырга» җыеналар булса кирәк, **инфляция дә (акча очсызлану, бәяләр арту )** алардан соң үзен озак көттермәс (Т.я., 1998, 24 сент.). Илнең көнчыгышында **демаркация (төзелгән килешү нигезендә ике территория арасындагы чикне билгеләү)** мәсьәләсе уртага салып тикшерелде* (В.Т., 1997, 11 нояб.). *Сөйләшүләргә әзерлек барышында **досье (кирәкле документлар тупланган папка)** булдыр* (Я-н, 1996, 26 б.). *Бу, беренче чиратта, ... **логистика (халыкара складлар, базалар системасы)** үзәге булдыру дигән сүз* (В.Т., 1995, 13 гыйнв.). *Әмма байтак кына сөйләшкәннән соң, бу феноменны мин **реинкарнация (җанның икенче берәүдә кабатлануы)** белән генә аңлата алам, — ди* (Ш.Ч., 1996, 23 гыйнв.). *Мәскәү галимнәре күренекле кешеләрнең **рейтингларын (популярлык***

***баганасы)*** *төзергә бик яраталар* (Т.я., 1997, 19 авг.). *Моны* ***русофобиядән (урысны яратмау хисе)*** *исергән кеше генә уйлап чыгара ала* (Т.я., 1995, 8 авг.). *Менә җиде ел майда һәм сентябрьдә Актанышта* ***стритбол (урам баскетболы)*** *ярышлары уздырыла* (А.т., 2006, № 122 ). *Үзгәртеп корулар башлангач, заводыбыз ябылды да, мин* ***челнок (чит илдән товар ташучы*** *) булып киттем* (В.Т., 2007, 13 окт.).

**2. Җәяләр эчендә мәгънәдәш сүзләр куллану**

*Президент һәм Халык мәҗлесенең* ***паритетына (тигезлегенә)*** *дә ирешелде* (Т.я., 1993, 2 дек.). *Әгәр дә аерым граждannар һәм оешмалар үзләренең планлаштырылган чараларын уздырырга телиләр икән, алар иң беренче чиратта җирле үзидарә органнарының* ***санкциясен (рөхсәтен)*** *алырга тиешләр* (Ш.Ч., 1996, 25 май). *27 июньдә Казанның Киров һәм Совет районнарыннан 35* ***скаут (пионер)*** *һәм 7 вожатый Франциягә сәфәр чыгачак* (Ш.К., 1995, 27 июнь).

**3. Рус-европа алынмасыннан соң сызык аша аныклагыч куллану**

***Авизо — акча җибәрү кәгазе*** *— чыннан да банк бланкасында, печате дә урынында* (В.Т., 1992, 24 май). *Аннары, акча түләп, заказ белән кеше үтертүләр дә соңгы елларда бик ишәеп китте, моңарчы без ишетеп тә белмәгән* ***киллерлар — түләүле үтерүчеләр*** *пәйда булды* (К.у., 1996, № 8, 134 б.). *Ни генә әйтмәсеннәр, нахакка гаепләнүчеләрне* ***реабилитацияләү — аклау*** *комиссиясенең җитәкчесе итеп Политбюро беркемне дә түгел, ә А.Яковлевны билгеләде* (М.җ., 1996, 2 февр.).

**4. Алынмадан соң ягъни теркәгече белән аныклау**

*Иртәгә менә шулай безнең колакка сәер ишетелгән* ***инаугурация, ягъни ТР Президентының тәхеткә утыру тантанасы*** *булырга тиеш* (Т.я., 1996, 8 авг.). *Бөтен җир биләмәләрен исәпкә алырга һәм жир* ***кадастры*** *дип аталган,* ***ягъни җирләрнең файдалану үзлекләре, уңдырышлылыгы, классификациясе*** *h.б. турында мәгълүматлары булган исемлек төзергә кирәк* (Нур, 1998, 7 февр.). ***Паритет, ягъни бертигез җаваплылык****, мөгаен, һәрвакыт хәрби термин гына булып калыр* (Т.я., 1997, 14 гыйнв.). *КамАЗ АҖнең җиңел автомобильләр чыгару заводында яңа корпус сафка керү уңаеннан* ***презентация, ягъни****, безнеңчә,* ***тәкъдим итү*** *уздырылды* (Ш.Ч., 1994, 3 дек.). ***Спонсор, ягъни химаяче,*** *көндәлек тормышыбызга төпле кереп урнашты* (Ю.т., 1995, 25 март).

Күргәнебезчә, күпчелек интернациональ һәм рус сүзләре ярдәмендә аныкланучы гарәп-фарсы алынмаларыннан аермалы буларак, яңа интерлексемалар текстта тулысынча диярлек төшенчәләрне татарчага тәрҗемәләү, тасвирлап бирү юлы белән аңлатыла, чөнки аларны телдә бер сүз белән генә алыштырырлык синонимнар юк, һәм яңа ясалганнары күпчелек халык өчен бик үк аңлаешлы да түгел.

**3.3.2.** Интернациональ сүзләр татар теленә рус теле аша һәм рус теленә кабул ителгән мәгънәләрендә керә. Рус телендә исә алар, гадәттә, бер конкрет мәгънәләрендә генә үзләштереләләр (172. 41 б.). Рус теленең үз сүзләрен татар теленә алганда да шуңа охшаш процесс күзәтелә: алынма бер — чор өчен актуаль күчерелмә мәгънәсендә генә үзләштерелә. Мәсәлән, инде алда телгә алынганча, **вампир** сүзе күчерелмә «кеше энергиясен суыручы» мәгънәсендә үзләштерелде, ә башка мәгънәләре «зур ярканат», «убыр», «кан эчүче» сүзләре белән белдерелә; **челнок** сүзе өченче — «сату өчен бер урыннан икенче җиргә әйбер ташучы» мәгънәсендә кабул ителде, беренче, икенче мәгънәләре өчен «каек», «соса» сүзләре бар (РТС, 696 б.); **братва**, **крыша**, **ломка** кебек гади сөйләм сүзләре дә татар телендә күчерелмә мәгънәләрендә генә кулланыла, ә рус теленнән кергән башка аз санлы яңа алынмалар чыганак телнең үзендә үк бер мәгънәле (**необольшевик**, **партократ**) булып кала бирә.

**3.3.3.** Грамматик төзелешләре ягыннан төрле типтагы телләргә караганлыктан, рус теле аша кергән алынмалардан бары тик исемнәр генә татар теленә үзгәрешсез кабул ителә. Башка сүз төркемнәре, төгәлрәк әйткәндә, сыйфатлар һәм фигыльләр, алда күрсәтелгәнчә (1.4.1.2.) ярымкалька формасында кабул ителәләр, ягъни сүзнең тамыры үзгәрешсез алына, ә ясагыч аффикслар татар кушымчалары белән алыштырыла. Сыйфатларны үзләштергәндә, флексия һәм соңгы суффиксны кыскарту, фигыльләрне аналитик форма белән бирү дә очрый: **мафиозный — мафиячел** (М-т, 1996, 8 март) һәм **мафиоз** (М-с, 1996, № 10, 45 б.), **деноминировать — деноминацияләү** (Ш.Ч., 1998, 5 май) һәм **деноминация ясау** (В.Т., 1998, 28 окт.).

**3.3.4.** Сирәк булса да яңа интерлексемаларның кайберләрен татарча әйтелешкә уңайлаштырып куллану матбугат битләрендә очрап тора. Әйтик, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Татарстан яшьләре» газетлары **компьютер** сүзен, гадәттә, **кампитр** формасында язалар: *Җитештерү комплексларында балаларыбызның* ***кампитр*** *өстәлләре янында утыруы буй җитмәслек хыял гына булып тоела иде* (М.җ., 1997, 18 апр.).

Яңадан активлашкан губерна сүзен **гөбернә** формасында куллану да күзәтелә: *Әллә ул киләчәктә* ***гөбернә*** *генә булып калырмы?* (М.җ., 1995, 11 авг.).

Моннан тыш электән үзләштерелгән алынмаларны һәм ялгызлык исемнәрен кириллицага күчкәнче кулланылган яисә сөйләм телендәге вариантта язуга күчү тенденциясе дә ят түгел: **эфисәр** (офицер — С-ә, 1996, № 2, 10 б.), **гәҗит** (В.Т., 1997, 25 сент.) — **гәзит** (К.т., 1995, 24 март), **көрешкә** (кружка — Ш.Ч., 1995, 4 май), **Рәсәй** (Я-н, 1995, № 4, 2 б.) — **Русия** (Россия — Ш.Ч., 1997, 5 март), **Тубыл** (Тобол — К.у., 1998, № 7, 132 б.) һ.б. Дөрес, мондый гади сөйләм вариантларын әдәби телгә күчерүне һәрвакытта да аклап булмый (36. 37 б.). Шулай да төрки чыгышлы булып та, рус теле аша яңадан кайткан **товар** сүзен (ЭСРЯ, IV, 681 б.) **тауар** формасында куллану (Т.я., 1998, 17 окт. һ.б.) хуплауга лаек.

**3.3.5.** Гомумән, күп кенә яңа рус-европа алынмаларын төрле язылышта куллану — чор өчен хас күренеш. **Дистрибьютер — дистрибьютор — дистрибутор**, **кикбоксинг — кик-боксинг, риэлтер — риэлтор**, **оффшор — офф-шор — оф-шор**, **рэкетир — рэкетер** кебек төрлечә язылышлар арадашчы рус теленнән үк килә (60. 144—145 б.; 110. 48—49 б.; 172. 38 б.), **дискета** (Т.я., 1997, 17 март) — **дискет** (С-й, 1996, 12 окт.) вариантлары сүзне татар теленең грамматик төзелешенә яраклаштыру процессы турында сөйли һәм соңгы сүзлекләрдә күп вариантлар арасында **газет** формасы канунлаштырылган кебек (130. 40 б.), **дискет** вариантының өстенлек алачагын фаразларга була. **Аудио-кассета** (Т.я., 1996, 16 нояб.) — **аудиокассета** (М. ж., 1998, 19 июнь), **компакт-диск** (К.у., 1996, № 11, 129 б.), — **компактдиск** (М-т, 1997, 28 февр.) вариантларының да соңгы, кушылып язылулары өстенлек алуы күзәтелә.

**3.3.6.** Чагыштырмача сирәк булса да, интерлексемалар һәм кайбер рус сүзләренең мәгънәләрен дөрес аңламыйча яисә башка охшаш сүз белән бутап куллану күренешләре дә очрый. Берничә мисал карыйк: *Бу төнне ГИБДДның язмада телгә алынган өч сержанты Мозаффаровны* ***автокемпингта*** *туктаталар* (Т.я., 1998, 22 окт.). **Кемпинг** сүзе үзе үк «автотуристлар өчен лагерь» мәгънәсенә ия (ТСРЯ, 273 б.; СИС, 1997, 127 б.) һәм аңа **авто-** элементы өстәп куллану артык.

*Ул үзенең* ***депозитарийларын*** *ача* (Т.й., 1995, 14—21 окт.). Биредә халыкара хокук термины булган **депозитарий** (халыкара договор текстын, аны ратификацияләү турында документларны үзендә сакларга йөкләмә алган дәүләт яки оешма — СЭС, 376 б.) алынмасы **депозит** сүзе урынына кулланылган.

*Башкаланың Сипайлово бистәсендәге базарны* ***челнокчылар*** *Мәккәсе дип атарга була* (К.т., 1996, 7 март). **Челнок** ул үзе зат исеме — бер урыннан алып башка җиргә сатар өчен товар ташучы алыпсатар (ТСРЯ, 879 б.), шунлыктан аңа зат атамасы белдергән сүз ясагыч ***-чы*** кушымчасы ялгау кирәк түгел.

### 3.4. Бүлек буенча нәтиҗәләр

1. Кискен иҗтимагый һәм икътисади үзгәрешләр нәтиҗәсе буларак рус теле аша лексикабызга соңгы чорда бик күп яңа сүзләр керде. Телебездә инде ныклап урын алган, югарыда анализланган неологизмнарның саны гына да ике йөздән артык. Алар арасында рус сүзләре һәм рус теле җирлегендә алынма компонентлардан төзелгән кушма сүзләрнең саны 10 проценттан артмый. Чөнки, беренчедән, соңгы елларда рус теленең престижлыгы кимесә, икенчедән, яңа төшенчә белдерүче рус неологизмнары күбрәк татарчага калькалаштырып кабул ителә. Хәтта рус җирлегендә ясалган аббревиатуралар да күпчелек очракта матбугатта һәм рәсми текстларда калькалаштырып язылалар. Яңа алынмаларның күпчелеге (70%) чыгышы буенча инглиз сүзләре булып, француз, немец, итальян, испан алынмалары берничә дистә генә, күпчелек Европа телләре өчен уртак грек-латин тамырлы неологизмнар һәм Көнбатыш телләре аша кергән япон чыгышлы спорт терминнары да шактый.

2. Тематик яктан алынмаларның яртысы — икътисад-финанс (бартер, инвестор, тендер), иҗтимагый-сәяси тормыш (диссидент, лобби, плюрализм) һәм фәнни-техник яңарышка бәйле төшенчәләрне атыйлар (дискета, интернет, компьютер). Шулай ук мәдәният-сәнгать (видеоклип, продюсер, шоу), физкультура-спорт (ралли, тхеквандо, шейпинг), аномаль күренешләр һәм традицион булмаган медицина (аура, полтергейст, экстрасенс), кулинария өлкәләренә караган (гамбургер, пицца, сандвич), көнкүрештәге үзгәрешләргә (визажист, дизайнер, кемпинг), җәмгыятьнең криминальләшүенә бәйле неологизмнар (киллер, рэкет, токсикомания), яшәешнең төрле өлкәсенә караган абстракт мәгънәле сүзләр (имидж, менталитет, социум), татар җирлегенә күчерелгән экзотизмнар (агрофирма, гипермаркет, панк) һәм жаргон-сөйләм лексикасыннан кергән (братва, дедовщина, крыша) алынмалар да шактый.

3. Телебездә электән үзләштерелгән рус-европа алынмалары соңгы елларда билгеле бер семантик-стилистик үзгәреш кичерәләр, һәм бу үзгәрешләр рус телендәге семантик-стилистик үзгәрешләр нәтиҗәсендә барлыкка килә. Дистәдән артык интерлексема, чорга бәйле икътисади һәм иҗтимагый үзгәрешләрне чагылдырып, мәгънәсен киңәйтте яки конкретлаштырды (банкрот, конверсия, чек), элек икътисад тармагы белән чикләнгән берничә сүз гомумкулланылышка (дотация, инвестор, комерсант), кайбер китап яки сөйләм теле стиле сүзләре стильара лексикага күчте (компенсация, субсидия,

суверенитет). Моннан тыш яңа икътисади мөнәсәбәтләргә күчү, идарә итү системасындагы һәм мәгариф өлкәсендәге реформаларга бәйле рәвештә элек үткән тормыш яки чит җәмгыять күренешләрен чагылдыру өчен генә кулланылучы өч дистә алынма сүз пассив лексикадан актив сүзлеккә күчте (акциз, губернатор, фермер). Аерым интерлексемаларның татар җирлегенә карата актуальләшүе дә күзәтелә (кооператив, полис, президент).

4. Яңадан активлашу процессында кайбер алынмалар элекке идеологик пейоратив (өнәмәү) төсмерләреннән арына (бизнесмен, коммерция, недоимка), шул ук вакытта югары хакимият вәкилләрен атаучы аерым рус-европа сүзләре, киресенчә, тискәре эмоциональ төсмер белән кулланыла башлады (босс, делец, демократ).

5. Язма әдәби тел һәм сөйләм теле тарафыннан параллель рәвештә кабул ителгәнлектән, яңа рус-европа алынмалары җиңелрәк үзләштерелә. Шуңа да аларны матбугатта аңлатмалар белән төрле вариантларда яисә ялгыш куллану очраклары чагыштырмача сирәк күзәтелә.

# ЙОМГАК

1. XX гасырның 80 нче еллары уртасыннан башланып киткән демократик үзгәртеп корулар тәэсирендә татар әдәби теле лексикасы, сан һәм сыйфат ягыннан шактый үзгәрешләр кичереп, үз үсешендә яңа этапка аяк басты. Бу этап, бер яктан, тормыштагы үзгәрешләргә бәйле яңа төшенчәләрне атау һәм совет чорында телебезгә күпләп кергән рус алынмаларын алыштыру өчен телнең үз җирлегендә яңа сүзләр ясау, электән кулланылган сүзләрнең яңа мәгънәләре барлыкка килү, искергән сүзләрнең, шул исәптән бик күп гарәп-фарсы алынмаларының яңадан активлашуы, кайбер чикләнгән кулланылыш берәмлекләренең әдәби телгә күчүе; ә икенче яктан исә рус теле аша бик күп интернациональ сүзләрне үзләштерү белән характерлы.

2. Милли үзаңның көчәюе тәэсирендә яңа чорда лексиканың үсеше беренче чиратта телнең үз җирлегендә барды. Телдәге бу үзгәрешләр иң беренче чиратта көндәлек матбугатта чагылыш таба. Матбугат яңа иҗтимагый үзгәрешләрне белдерүче сүзләрне күп очракта гомумкулланылышка кертеп җибәрә, аларга телдә яшәргә фатиха бирә. Шул ук вакытта матбугатта гомумкулланылышка кереп китә алмаган лексик берәмлекләр дә теркәлеп кала.

3. Татар теле нигезендә яңа сүзләрнең телебезгә хас сүзьясалыш ысулларының барлык төрләре белән ясалуы күзәтелә. Зур өлеше морфологик юл белән — кушымчалар ялгап ясала: ***-чы/-че, -лык/-лек, -даш/-дәш, -таш/-тәш, -еш/-ыш, -ш, -ым/-ем, -м*** кушымчалары продуктивлыкларын саклыйлар; аерым лексик берәмлекләр ясауда **-ман/*-мән, -ар/-әр, -р, -ма/-мә, -ык/-ек, -к*** кушымчалары да катнашалар.

Яңа сүзләрнең шактый зур өлеше, синтаксик юл белән ясалып, үзенчәлекле парлы сүзләр һәм аныклаулы атамалар рәвешендә формалашалар. Лексик-семантик һәм конверсия ысуллары белән яңа сүзләр ясалу да билгеле бер күләмдә чагылыш тапты: 30 дан артык татар сүзенең яңа мәгънә яки мәгънә төсмере белән баюы шул турыда сөйли.

Телдәге алынмаларны «татарчалаштырырга» омтылу кебек пуристик тенденция нәтиҗәсендә күпсанлы рус алынмалары калькалаштырылып кабул ителде. Аларның саны 200 дән арта.

Әдәби тел лексикасы төрле сүзлек катламнарының бер-берсенә актив тәэсир итүе нәтиҗәсендә дә шактый үзгәрешләр кичерде: 1) аерым гомумхалык теле сүзләре әһәмиятле иҗтимагый-сәяси терминнарга әйләнде; 2) кайбер гади сөйләм сүзләре газета-журнал лексикасына үтеп керде; 3) диалекталь сүзләрнең әдәби телгә йогынтысы көчәйде.

Җәмгыятьтәге үзгәртеп кору процессы телдә яңа бер тенденцияне барлыкка китерде: совет чорында рус алынмалары тарафыннан пассив лексикага кысрыкланган бер катлам архаизм һәм тарихи сүзләр, яңадан актив лексикага күчеп, әдәби телдә ныклап урын алдылар.

Татар теле җирлегендә туган окказиональ сүзләрнең күбәю тенденциясе дә күзәтелә. Алар арасында әдәби телдә урын алырдай, киң кулланылышка кереп китәрдәйләре дә шактый.

Югарыда ясалган нәтиҗәләргә нигезләнеп шуны әйтергә мөмкин: яңа чор татар әдәби теленең лексикасы үсеш-үзгәрешендәге төп юнәлеш үз җирлегебездә төрле юллар белән ясалган сүзләр һәм мәгънә киңәю исәбенә бара.

4. Җәмгыятьтәге үзгәртеп кору процессы, демократия шартларында халыкның милли үзаңы уяну, тарихи үткәне белән кызыксынуы көчәю, дин иреге һәм милли мирас кире кайту, Көнчыгыш илләре белән бәйләнешләр арту һ.б. әдәби телебездә күпсанлы гарәп-фарсы алынмаларының яңадан активлашуына китерде; бу әдәби телнең барлык функциональ стильләренә, аеруча публицистик, фәнни, әдәби, эш кәгазьләре стиле өчен хас.

Кире кайткан гарәп-фарсы сүзләре беренче чиратта интернациональ һәм рус сүзләрен алыштыру өчен, аларның синонимнары буларак кулланыла.

Активлашкан алынмалар кулланылышы ягыннан түбәндәге төрләргә аерылалар: 1) күптән кулланылыштан чыккан, бары алынмалар һәм гарәп, фарсы теле сүзлекләрендә генә теркәлгән сүзләр; 2) «искергән сүз» тамгасы белән аңлатмалы сүзлектә урын алган сүзләр. Алынмаларның күпчелеген төрле темаларга караган исемнәр тәшкил итсә дә, сыйфат, рәвеш, алмашлык, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәренә караганнары да очрый.

Шәрык алынмалары арасында стильара лексикага күчү, сирәк кулланылыштагы сүзләрнең активлашу күренешләре дә күзәтелә.

Гарәп-фарсы алынмалары татар теленең сүзьясалыш процессына да тәэсир итә: күптән үзләштерелгән гарәп-фарсы алынмаларына (яисә татар һәм алынма рус сүзләренә) гарәп-фарсы компонентлары өстәп, чыганак телдә булмаган яңа сүзләр ясала; бигрәк тә ***-ханә, -намә*** компонентларының активлыгы күзгә ташлана.

Яңадан активлашу процессында кайбер гарәп-фарсы алынмалары семантик һәм фонетик-орфографик үзгәрешләргә дучар ителәләр, элекке кулланылышында татар телендә булмаган яңа мәгънә төсмерләре белән баетылалар, кайбер күпмәгънәле алынмалар бер конкрет мәгънәләрендә генә

активлашалар, алынмаларны графо-фонетик яктан үзләштерү дәвам итә. Соңгысы телдә кирәкмәгән күпвариантлылык, төрлелек китереп чыгара. Гарәп-фарсы алынмалары еш кына җәяләр эчендәге аңлатмалар белән биреләләр, ә бу аларның әдәби телдә әле тулысынча үзләштерелеп бетмәвен күрсәтә.

5. Россия мохите белән иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни, көнкүрештәге аерылгысыз бәйләнешләр соңгы елларда татар теленә йөзләгән яңа рус һәм халыкара сүзләр алып килде. Рус сүзләрен калькалаштырып алу сәбәпле, яңа саф рус алынмалары берничә дистә генә (алары да, нигездә, көнкүреш өлкәсенә карый). Татар теленә рус теле аша инде «руслашкан» халыкара сүзләр керү алынмалар кабул итүдә төп тенденция булып тора. Яңа алынмаларның 70 проценты инглиз сүзләре булып, француз, немец, итальян, испан, грек-латин, япон чыгышлы алынмалар да бар.

Рус һәм халыкара алынмаларның 50 проценты — иҗтимагый-сәяси тормыш, икътисади-финанс, базар мөнәсәбәтләре, фәнни-техник яңарышка бәйле сүзләр. Мәдәният-сәнгать, физкультура-спорт, аномаль күренешләр һәм медицина, кулинария, көнкүреш сүзләре, криминаль өлкәгә караган абстракт мәгънәләрне белдерүче сүзләр, жаргоннар калган 50 процентны тәшкил итәләр.

Рус алынмалары һәм интерлексемаларның мәгънәләрендә дә үзгәрешләр күзәтелә. Алар рус теленең үзендә барган семантик-стилистик үзгәрешләрнең чагылышы булып тора. Рус һәм халыкара алынмаларның язма, сөйләм теле аша параллель рәвештә кабул ителүе, радио-телевидение тәэсире көчле булу, чагыштыргысыз күп кулланылу нәтиҗәсендә бу төр алынмалар җиңелрәк үзләштерелә, аларда нормативлык көчлерәк саклана.

6. Гомумән, безнең тикшеренүләр күрсәтүенчә, соңгы елларда татар әдәби теле лексикасында, яңа рус-европа һәм кире кайткан гарәп-фарсы алынмаларын да кушып исәпләгәндә, меңгә якын яңа берәмлек барлыкка килде, 60 тан артык сүз яңа мәгънә төсмере белән баеды, 200 дән артык сүз кулланылыш даирәсен, стилен һәм ешлыгын киңәйтте (барысы 1270 берәмлек анализланды). Бу үзгәрешләрнең 42 проценты — телнең үз җирлегендә үсешенә, 32 проценты — гарәп-фарсы сүзләренең активлашуына, 26 проценты рус-европа алынмаларын үзләштерүгә карый.

7. Соңгы еллар әдәби телебез лексикасындагы үзгәрешләр, әлбәттә, телнең төп сүзлек фондына нигезләнә. Яңа сүзләр, мәгънәләр барлыкка килү белән беррәттән кайбер (аеруча коммунистик идеологиягә бәйле) сүзләр искереп, пассив сүзлеккә күчә (бишьеллык, комсомол, октябрят, пионер, социалистик ярыш һ.б.).

8. Татар теленең үз җирлегендә яңа сүзләр ясау, икенчедән, искергән сүзләр һәм Көнчыгыш алынмаларының әдәби телгә кире кайтуы, өченчедән, рус теле аша яңа сүзләр кабул итү күп кенә төшенчәләрне белдерү өчен төрле сүзләрне параллель куллануга китерде: договор-шартнамә-килешү; характеристика-бәяләмә-бәһаләмә-сыйфатлама; компьютер-кампитр-санак; подпись-имза-култамга; бизнесмен-эшмәкәр-эшкуар-малтабар; вывеска-алтакта-элмә, такта-элмә, язу-күрсәтмә такта; спонсор-меценант-иганәче-химаяче һ.б. Мәгънәдәш сүзләрнең күп булуы, аларның иң отышлысын сайлап алу, төрле стильдә куллану мөмкинлекләрен киңәйтә. Әмма синонимнарның күплеге һәрвакытта да лексиканың байлыгы, сыгылмалылыгы турында сөйләми. Әйтик, больница, поликлиника сүзләрен алыштыру өчен шифаханә, дәваханә, сырхауханә, хастаханә, сихәтханә, шәфкатьханә кебек, ***-ханә*** компонентлы алынма һәм татар теленең үз җирлегендә ясалган сүзләр кулланылышка керсә дә, әлегә алар конкрет типтагы дәвалау учреждениесе атамасы булып махсуслашмаганнар, бу исә нәрсә турында сүз барганын аңлауны кыенлаштыра. Шуңа кайсы сүзнең нинди мәгънәдә ешрак кулланылуын искә алып, сырхауханәне — больница, хастаханәне — клиника, поликлиника, шифаханәне — санаторий, профилакторий, шәфкатьханәне — медпункт сүзләренең милли синонимы буларак сүзлекләрдә канунлаштыру һәм матбугат битләрендә аларны шул мәгънәдә генә куллану таләп ителә. Гомумән, соңгы чорда барлыкка килгән төрле чыганаклы сүзләрнең синонимикасы җентекләп махсус өйрәнүне сорый.

9. Чит телләрдән күпләп сүзләр алу һәм вариантлылык зур иҗтимагый үзгәртеп кору чорлары өчен барлык телләргә хас. Моңа охшаш күренешләрнең әдәби телебез тарихында 1905 һәм 1917 елгы революцияләрдән соң күзәтелүе хакында телчеләребез фәнни әдәбиятта язып чыккан иде инде. Өйрәнелгән чорның үзенчәлеге — яңа ясалган татар сүзләре һәм активлаштырылган гарәп-фарсы алынмаларының әлегә күбрәк язма әдәби тел һәм милли зыялылар сөйләменә, ә рус-европа алынмаларының беренче чиратта сөйләм теленә хас булуында, лексика үсешендә төрле сүзлек катламнарының үзара керешүе зур роль уйнауда чагылыш таба.

10. Безнең тикшеренүләр хәзерге татар әдәби телендәге үзгәрешләр җәмгыятьтә барган катлаулы һәм интенсив иҗтимагый-икътисади-сәяси факторларга бәйле икәнен тагын бер кат раслый. Лексикадагы XX йөзнең 80—90 нчы еллары — XXI йөз башындагы үзгәрешләр тормыштагы үзгәрешләрне, халкыбызның милли мөстәкыйльлеккә омтылышын чагылдыра. Яңа сүзләр, яңа мәгънәләр барлыкка килү — тел яши һәм камилләшә дигән сүз.

## БИБЛИОГРАФИЯ


1. *Абдуллин И.А., Ахунзянов Г.Х., Ганиев Ф.А.* Русский язык — один из источников обогащения и развития татарского литературного языка // Взаимодействие и взаимообогащение языков народов СССР. — М., 1969. — С. 84—104.
2. *Абдуллин И.А.* Большевистик сугышчан сүз. — Казан: Таткнигоиздат, 1987. — 280 б.
3. *Абдуллина Р.С.* Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. — Яр Чаллы, 1997. — 128 б.
4. *Абдуллина Р.С.* «Килмешәк» сүзләргә карашыбыз // Аргамак. — 1997. — № 7. — 10—116 б.
5. *Абдуллина Р.С.* Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. — 284 б.
6. *Алпаров А.Х.* Татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре // Сайланма хезмәтләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1945. — 329 б.
7. *Ахатов Г.Х.* Об основных признаках парных слов // Советское финно-угроведение. XVII. — Таллин, 1981. — № 2. — С. 81—86.
8. *Ахметьянов Р.Г.* Этимологические основы лексики татарского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. — Казань, 1970. — 19 с.
9. *Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. — М.: Наука, 1989. — 200 с.
10. *Ахунзянов Г.Х.* Регулярнообразуемые имена прилагательные на -лы // Татарская лексика в семантико-грамматическом аспекте. — Казань, 1988. — С. 3—29.
11. *Ахунзянов Э.М.* Русские кальки в татарском литературном языке // Вопросы татарского языкознания. — Казань: Изд-во КГУ, 1965. — С. 38—66.
12. *Ахунзянов Э.М.* Русские заимствования в татарском языке. — Казань: Изд-во КГУ, 1968. — 367 с.
13. *Әухәдиев И.Ш.* Гарәп алынмаларының фонетик үзләштерелүе турында // Татар тел белеме мәсьәләләре. III китап. — Казан: КДУ нәшр., 1969. — 112—131 б.
14. *Әхәтов Г.Х.* Татар диалектологиясе. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. — 116 б.
15. *Әхәтов Г.Х.* Татар теленең лексикасы. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. — 93 б.
16. *Байрамова Л.К.* Двуязычие и национальный характер билингва // Формы взаимодействия татарского и русского языков на современном этапе. — Казань, 1992. — С. 71—74.
17. *Баранникова Л.И.* Основные сведения о языке. — М.: Просвещение, 1982. — 112 с.
18. *Баскаков Н.А.* и др. О современном состоянии и путях дальнейшего развития литературных тюркских языков // Вопросы развития литературных языков народов СССР. — Алма-Ата, 1964. — 165 с.
19. *Баскаков Н.А.* Введение в изучение тюркских языков. — М.: Высшая школа, 1969. — 383 с.
20. *Бегматов Э.* Собственный пласт лексики современного узбекского литературного языка: дис. ... докт. филол. наук. — Ташкент, 1988. — 320 с.
21. *Бельчиков Ю.А.* Что было выражено словом, то было и в жизни // Русская речь. — 1993. — № 3. — С. 30—35.
22. *Брагина А.А.* Актуальные слова: школа, гимназия, лицей, колледж // Русский язык в школе. — 1997. — № 1. — С. 102—103.
23. *Будагов Р.А.* Введение в науку о языке. — М.: Просвещение, 1965. — 492 с.
24. *Будагов Р.А.* Что такое развитие и совершенствование языка? — М.: Наука, 1977. — 264 с.
25. *Бурнашева С.А.* Изменение словарного состава татарского языка в советскую эпоху: автореф. ... дис. канд. филол. наук. — М., 1952. — 15 с.
26. *Величко А.В.* О «русскости» русского языка наших дней // Русская речь. — 1995. — № 6. — С. 54—57.
27. *Виноградов В.В.* Избранные труды. Лексикология и лексикография. — М.: Наука, 1977. — 312 с.
28. *Вышкин Е.Г.* Проблемы систематизации лингвистического знания. — Самара: Изд-во Самарского ун-та, 1992. — 119 с.
29. *Ганиев Ф.А.* Некоторые итоги исследования словообразования в современном татарском языке и задачи его дальнейшего изучения // Вопросы татарского языкознания. — Казань, 1971. — С. 87—100.
30. *Ганиев Ф.А.* Суффиксальное словообразование в татарском литературном языке. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. — 231 с.
31. *Ганиев Ф.А.* Исемнәр ясалуда -лык/-лек кушымчасы // Совет мәктәбе. — 1975. — № 3. — 27—29 б.
32. *Ганиев Ф.А.* Пути развития лексической системы современного языка // Татар теле һәм әдәбияты. — 5 нче китап. — Казань, 1976. — С. 76—84.
33. *Ганиев Ф.А.* Суффиксальное образование глаголов в современном татарском литературном языке. — Казань: Изд-во КГУ, 1976. — 108 с.
34. *Ганиев Ф.А.* Образование сложных слов в татарском языке. — М.: Наука, 1982. — 150 с.
35. *Ганиев Ф.А.* Словообразование // Татарская грамматика: в 3 т. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. — С. 188—521.
36. *Ганиев Ф.А.* Җөмһүриятме, Республикамы? (Татар теле терминологиясе үсеше концепциясенең кайбер принциплары турында) // Мәгариф. — 1997. — № 4. — 35—37 б.
37. *Ганиев Ф.А.* Хәзерге лексикабыз // Мәгариф. — 1998. — № 5. —19—20 б.
38. *Ганиев Ф.А.* Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. — Казан: Матбугат йорты, 2005. — 272 б.
39. *Гарипова Ф.Г.* Топонимы: связь прошлого и настоящего // Межэтнические и межконфессиональные отношения в Республике Татарстан. Ч. 2. — Казань, 1993. — С. 213—215.
40. *Гарифуллин В.З.* Лингвостилистическая система татарского газетного текста: автореф. дис. ... докт. филол. наук. — Казань, 1998. — 50 с.
41. *Говердовская Е.В.* Новые существительные в лексике современного русского литературного языка // Русский язык в школе. — 1992. — № 3—4. — С. 46—48.
42. *Граудина Л.К., Козловская П.Л.* Рецензия на книгу В.Г.Костомарова. Языковой вкус эпохи // Русская речь. — 1995. — № 3. — С. 112—115.
43. *Гречко В.А.* Лексическая синонимика современного русского литературного языка. — Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1987. — 153 с.
44. *Дегтерева Т.А.* Пути развития современной лингвистики. — Кн. 3-я: Структурализм и принципы марксистского языкознания. — М.: Мысль, 1964. — 212 с.
45. *Денисова М.А.* Литературная норма и практика разговорной речи // Русский язык в школе. — 1996. — № 1. — С. 86—92.
46. *Дешериев Ю.Д.* Социальная лингвистика. — М.: Наука, 1977. — 360 с.
47. *Дубичинский В.В.* Лексические параллели. — Харьков, 1993. — 155 с.
48. *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. — Казан: Татгосиздат, 1947. — 134 б.

49. *Закиев М.З.* Некоторые вопросы развития татарского литературного языка // Вопросы татарского языкознания. — Кн. 2-я. — Казань, 1965. — С. 5—35.
50. *Закиев М.З.* Особенности развития литературного языка в различных социально-экономических условиях // Конференция по татарскому языкознанию, посвященная 50-летию СССР (тезисы докладов). — Казань, 1972. — С. 6—9.
51. *Закиев М.З., Юсупов Р.А.* Вопросы периодизации татарско-русского двуязычия // Проблемы двуязычия и многоязычия. — М., 1972. — С. 152—155.
52. *Закиев М.З.* О взаимоотношении татарского литературного языка и диалектов в различные периоды их развития // Лингвистическая география, диалектология и история языка. — Ереван, 1976. — С. 313—318.
53. *Закиев М.З.* Языковая политика в условиях перестройки // Коммунист Татарии. — 1989. — № 9. — С. 10—16.
54. *Закиев М.З.* Основные периоды функционального развития татарского национального языка: введение // Функциональное развитие татарского языка в условиях перестройки. — Казань, 1991. — С. 3—14.
55. Закономерности развития литературных языков народов СССР в советскую эпоху. Внутриструктурное развитие старописьменных языков. — М.: Наука, 1973. — 363 с.
56. *Зарипова А.Р.* Роль русского языка в освоении интернационализмов в башкирском языке // Русский язык в Башкирии и его взаимодействие с башкирским языком. — Уфа, 1988. — С. 71—75.
57. *Зәйнуллин Җ.Г.* Гарәп теле. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. — 208 б.
58. *Зәкиев М.З.* Туган тел үсеше. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. — 84 б.
59. *Зәкиев М.З.* Сүзлек составында терминнар һәм аларны тәртипкә китерү // Мәгариф. — 1997. — № 4. — 32—35 б.
60. *Зеленин А.В.* Рэкет и рэкетиры // Русская речь. — 1991. — № 4. — С. 144—146.
61. *Зинина А.С.* Функционирование окказионализмов в татарском языке // Формирование и функционирование татарского языка. — Казань: КГПИ, 1986. — С. 79—92.
62. *Зинина А.С.* Развитие лексики современного татарского литературного языка в условиях массового двуязычия: дис. ... канд. филол. наук. — Казань, 1987. — 190 с.
63. *Зинина А.С.* Вопросы изучения семантических неологизмов // Формы взаимодействия татарского и русского языков на современном этапе. — Казань, 1992. — С. 64—71.
64. *Зөлкарнәй Ф.М.* Татарның онытылган борынгы сүзләре // Идел. — 1996. — № 1. — 54—56 б.
65. *Зөлкарнәй Ф.М.* Заманчыл иҗтимагый-мәдәни мәгънәләр сүзлеге // Идел. — 1996. — № 5. — 42—44 б.
66. *Йосыпова Ә.Ш.* Онытылган сүзләр // Мәгариф. — 1997. — № 9. —24—25 б.
67. *Карпинская Е.В.* Все о ваучере // Русская речь. — 1993. — № 1. — С. 61—62.
68. *Кәримуллин Ә.Г.* Татар теле белеме библиографиясе. — Казан, 1958. — 115 б.
69. *Кәримуллин Ә.Г.* Тел — милләтнең сакчысы. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 256 б.
70. *Кодухов В.И.* Введение в языкознание. — М.: Просвещение, 1979. — 351 с.
71. *Кононов А.Н.* Грамматика языка тюркских рунических памятников VII—IX вв. — Л.: Наука, 1980. — 255 с.
72. *Костомаров В.Г.* Русский язык в иноязычном потопе // Русский язык за рубежом. — 1993. — № 2. — С. 59—64.
73. *Крысин Л.П.* К определению терминов «заимствование» и «заимствованное слово» // Развитие лексики современного русского языка. — М: Наука, 1965. — С. 104—117.
74. *Крысин Л.П.* Иноязычные слова в контексте современной общественной жизни // Русский язык в школе. — 1994. — № 6. — С. 56—70.
75. *Крысин Л.П.* Рецензия на книгу А.Д.Дуличенко. Русский язык конца XX столетия. — Мюнхен, 1994. — 347 с. // Вопросы языкознания. — 1995. — № 6. — С. 129—132.
76. *Крысин Л.П.* Словообразование или заимствование // Русский язык в школе. — 1997. — № 6. — С. 84—88.
77. *Крысин Л.П., Ю Хак Су.* О словообразовательных возможностях иноязычных неологизмов // Филологические науки. — 1998. — № 3. — С. 15—21.
78. *Кудашов Г.Х.* Татар телендә фонетик һәм морфологик үзгәрешләр // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 249—294 б.
79. *Курбатов Х.Р.* Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. — М.: Наука, 1978. — 218 с.
80. *Курбатов Х.Р.* Некоторые итоги и дальнейшие задачи изучения татарского литературного языка // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. — Казань, 1992. — С. 20—25.
81. *Латыпова Н.М.* Образование новых слов в башкирском языке от заимствованных основ из русского языка // Русский язык в Башкирии и его взаимодействие с башкирским языком. — Уфа, 1988. — С. 65—70.
82. *Мадияров Н.Г.* Дөрес язуйк, дөрес сөйләшик // Мәгариф. — 1993. — № 7. — 20—21 б.
83. *Максимов Н.В.* Аныклаулы атамалар // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. — Казан, 1992. — 49—58 б.
84. *Максимов Н.В.* Калькирование в татарском языке. — Казань, 1999. — 165 с.
85. *Мардиева Л.А.* Социальная трансформация картины мира и ее отражение в лексике современных русского и татарского языков // Языковая семантика и образ мира. — Казань: Изд-во КГУ, 1997. — С. 52—54.
86. *Мардиева Л.А.* Актуальные тенденции развития лексики русских и татарских газетно-журнальных текстов: автореф. дис. ... канд филол. наук. — Казань, 1998. — 19 с.
87. *Махмутова Л.Т.* Современный татарский литературный язык и диалекты // Вопросы татарского языка и литературы. — Кн. 4-я. — Казань, 1969. — С. 26—34.
88. *Махмутов М.И.* Фонетическое и грамматическое освоение арабских заимствований в татарском литературном языке: дис. ... канд. филол. наук. — Казань, 1966. — 361 с.
89. *Мәхмүтов М.И.* Татар әдәби теленә кергән гарәп-фарсы элементлары. Грамматик белешмә // Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. — Казан, 1993. — 791—853 б.
90. *Миңнуллин Ф.Г.* Хәзерге татар әдәби телендә аббревиация юлы белән сүз ясалышы // Сборник материалов итоговых конференций центра истории и теории национального образования 2004 — 2005 гг. — Казан, 2006. — 121—129 б.
91. *Мөхәммәдиев М.Г.* Татар теле лексикографиясенең һәм лексикологиясенең үсеше // Актуальные вопросы грамматики и стилистики татарского языка. — Казан, 1981. — 16—25 б.
92. *Мөхиярова Р.Х.* Соңгы еллар татар матбугаты лексикасы һәм аны мәктәптә өйрәнү мәсьәләләре // Системный подход в педагогическом образовании. — Яр Чаллы, 1995. — 114—115 б.
93. *Мөхиярова Р.Х.* Көндәлек матбугат теленә бер караш // Мәгариф. — 1996 — № 2. — 17—18 б.
94. *Мөхиярова Р.Х.* 90 нчы еллар татар әдәби теле лексикасы // Мәгариф. — 1997. — № 10. — 46—47 б.
95. *Мөхиярова Р.Х.* 80—90 нчы еллар татар әдәби телендә аныклаулы атамалар // Фән һәм мәктәп. — 1999. — № 1. — 89—91 б.

96. *Мөхиярова Р.Х.* XX гасырның 80—90 нчы елларында татар әдәби теле лексикасы. — Яр Чаллы, 2000. — 192 б.
97. *Мусаев К.М.* Лексикология тюркских языков. — М.: Наука, 1984. — 227 с.
98. *Низамов И.М.* Тел байлыгын — матбугат битенә // Казан утлары. — 1980. — № 9. — 156—161 б.
99. *Низамов И.М.* Матбугатның тәэсирле сүзе. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. — 144 б.
100. *Низамов И.М.* Яңалык һәм сүз. — Казан, 1990. — 28 б.
101. *Низамов И.М.* Терминны үзгәртергә ярыймы? // Мәгариф. — 1991. — № 11. — 23—25 б.
102. *Низамов И.М.* Сүз иҗаты — ләззәтле газап // Татарстан. — 1996. — № 3. — 86—93 б.
103. *Низамов И.М.* Татар теле — дәүләт теле // Мәгариф. — 1997. — № 12. — 49—52 б.
104. *Низамов И.М.* И туган тел ... — Казан: Мәгариф, 1998. — 207 б.
105. *Овезов А.* Пути развития слова и словарного состава туркменского языка: автореф. докт. филол. наук в форме научного доклада. — Ашхабад, 1990. — 59 с.
106. *Одинокова Г.И.* Формирование юридической терминологии в современном татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. — Казань, 1995. — 19 с.
107. *Пейсиков Л.С.* Лексикология современного персидского языка. — М.: Изд-во МГУ, 1975. — 206 с.
108. *Подчасова С.В.* Брокеры, дилеры и другие посредники // Русская речь. — 1994. — № 6. — С. 52—56.
109. *Подчасова С.В.* Новые слова ... «Адвертайзинга» // Русская речь. — 1995. — № 2. — С. 71—76; № 3. — С. 61—66; № 4. — С. 48—51.
110. *Подчасова С.В.* Оффшор — налоговый рай за рубежом // Русская речь. — 1996. — № 1. — С. 47—49.
111. *Попов Р.Н.* Новые слова и словосочетания в языке современной прессы // Русский язык в школе. — 1996. — № 1. — С. 70—73.
112. *Рамазанов Ш.А.* Совет чорында татар әдәби теленең үсеше (Татарстанның XXV еллыгына багышлап) // Совет әдәбияты. — 1945. — № 6. — 87—98 б.
113. *Рамазанов Ш.А.* Татар теле буенча очерклар. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — 200 б.
114. *Рамазанова Д.Б., Мухамадиев М.Г.* К вопросу о вариативности в татарском языке // Нормативность и вариативность в татарском языке. — Казань, 1987. — С. 3—4.
115. *Рахимова Р.К.* Общественно-политические термины в публицистике в период перестройки и развитие терминологии татарского языка за последние два десятилетия // Функциональное развитие татарского языка в условиях перестройки. — Казань, 1991. — С. 34—46.
116. *Рубинчик Ю.А.* Грамматический очерк персидского языка // Персидско-русский словарь. — М.: Советская энциклопедия, 1970. — Т.2. — С. 791—847.
117. *Сабирова Г.С.* К вопросу о появлении новых слов и значений в современном татарском языке // Языковая семантика и образ мира. — Казань: Изд-во КГУ, 1997. — С. 58—60.
118. *Сабирова Г.С.* Телебездә яңа сүзләр // Мәгариф. — 1998. — № 7. — 41—42 б.
119. *Сабирова Г.С.* Новые слова и новые значения в современном татарском языке (на материале периодической печати и словарей 1990-х гг.): автореф. дис. ... канд. филол. наук — Казань, 1999. — 20 с.
120. *Сабирова Г.С.* Татарско-русский словарь новых слов и новых значений. — Альметьевск, 2000. — 80 с.
121. *Сабиров К.З.* Лексикология // Хәзерге татар әдәби теле. — Казан, 1965. — 54—66, 77—81 б.
122. *Сабиров К.З.* О языке татарской периодической печати советского периода// Конференция по татарскому языкознанию, посвященная 50-летию СССР (тезисы докладов). — Казань, 1972. — С. 18—19.
123. *Сарьян Х.* Уеңны уйдырып сал. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. — 142 б.
124. *Саттаров Г.Ф.* Татар топонимиясе. — Казан: КДУ нәшр., 1998. — 438 б.
125. *Сафиуллина Ф.С.* Тел дигән дәрья бар ... — Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. — 136 б.
126. *Сафиуллина Ф.С.* Сүз — иясе белән йөри. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — 167 б.
127. *Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле. — Казан: Мәгариф, 1994. — 320 б.
128. *Сафиуллина Ф.С.* Калькирование как один из источников развития лексики современного татарского литературного языка // Языковая семантика и образ мира. — Казань: Изд-во КГУ, 1997. — С. 63—64.
129. *Сафиуллина Ф.С.* Телебезгә икенче сулыш // Мирас. — 1997. — № 1. — 31—35 б.
130. *Сафиуллина Ф.С.* Иҗтимагый тормыш һәм хәзерге татар теле // Мәгариф. — 1998 — № 8. — 38—42 б.
131. *Сафиуллина Ф.С., Мөхиярова Р.Х.* ... ханәләр, намәләр // Мәгариф. — 1998. — № 3. — 24—25 б.
132. *Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. — Казан: Хәтер, 1999. — 288 б.
133. *Сафиуллина Ф.С.* Тел гыйлеменә кереш. — Казан: ТаРИХ, 2001. — 384 б.
134. *Сәгыйтов Р.* Татар теле синонимиясендә гарәп-фарсы алынмалары // Мәгариф. — 1992. — № 10. — 22—23 б.
135. *Скворцов Л.И.* Что угрожает литературному языку (Размышления о состоянии современной речи) // Русский язык в школе. — 1994. — № 5. — С. 99—105.
136. *Сорокалетов Ф.П.* Главное дело в «дикционарий» // Русская речь. — 1995. — № 3. — С. 39—45.
137. *Сөләйманов Җ., Галимҗанов Ә.* Компьютер технологиясендә татар терминнары // Мәгариф. — 1997. — № 4. — 44—45 б.
138. *Сэшан Ш.* Существительные на -инг — символ американской языковой экспансии? // Русская речь. — 1996. — № 3. — С. 46—49.
139. Татар грамматикасы. — Т.1. — Мәскәү—Казан, 1998. — 512 б.
140. Татарская грамматика. — Т.1. — Казань, 1995. — 584 с.
141. Татарстан Республикасы Законы. Татарстан Республикасы халыклары телләре турында // Мәгариф. — 1996. — № 9. — 68—74 б.
142. *Тимофеева Г.Г.* Принципы и способы передачи заимствованных слов // Язык и письмо. — Волгоград, 1991. — С. 28—36.
143. *Тимофеева Г.Г.* Английские заимствования в русском языке (фонетико-орфографический аспект): автореф. дис. ... докт. филол. наук. — СПб., 1992. — 30 с.
144. *Тумашева Д.Г.* Хәзерге татар әдәби теле. — Казан: КДУ нәшр., 1978. — 221 б.
145. *Улуханов И.С.* О новых заимствованиях в русском языке // Русский язык в школе. — 1994. — № 1. — С. 70—75.
146. *Уфимцева А.А.* Лексическое значение (принцип семантического описания лексики). — М.: Наука, 1986. — 239 с.
147. *Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология нигезләре. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. — 200 б.
148. *Фаттахова Н.Н.* Развитие общественно-политической терминологии татарского языка. — Казань: КГПИ, 1985. — 101 с.

149. *Фәтхуллин В.* Техник фәннәрне татарча укыту һәм бердәм терминнар булдыру // Мәгариф. — 1997. — № 4. — 39—40 б.
150. *Фомина М.И.* Современный русский язык. Лексикология. — М.: Высшая школа. — 1978. — 256 с.
151. *Хайруллин М.Б.* Интернациональная терминология в татарском языке (на материале школьных учебников): автореф. дис. ... канд. филол. наук. — Казань, 1975. — 23 с.
152. *Хайруллин М.Б.* Некоторые вопросы единства интернационального и национального в разносистемных языках. — Казань: Изд-во КГУ, 1991. — 73 с.
153. *Хайруллин М.Б.* О языковом строительстве и терминотворчестве в разносистемных языках // Проблемы лексикологии и терминологии татарского языка. — Вып.3. — Казань, 1994. — С. 37—46.
154. *Хаков В.Х.* О некоторых закономерностях развития современного татарского языка // Взаимодействие и взаимообогащение языков народов СССР. — М.: Наука, 1969. — С. 211—214.
155. *Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1972. — 224 б.
156. *Хаков В.Х.* Татар әдәби теленең совет чорында үсеше (20—30 нчы еллар). — Казан: КДУ нәшр., 1985. — 150 б.
157. *Хаков В.Х.* Телебезнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге // Мәгариф. — 1997. — № 12. — 52—55 б.
158. *Хаков В.Х.* Татар әдәби теле. Стилистика. — Казан: Татар.кит. нәшр., 1999. — 304 б.
159. *Халит Г.М.* Татар теленең сүзлек составында гарәбизм һәм фарсизм // Совет мәктәбе. — 1939. — № 8. — 57—58 б.
160. *Ханбикова Ш.С.* Роль заимствований в обогащении синонимии языка // Взаимодействие и взаимообогащение языков народов СССР. — М., 1969. — С. 202—205.
161. *Хангилдин В.Н.* Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1976. — 95 б.
162. *Хан-Пира Э.* Популизм не так прост // Русская речь. — 1995. — № 1. — С. 124—125.
163. *Хәйруллин М.Б.* Яңа сүзләр һәм терминнар // Мәгариф. — 1995. — № 4. — 22—23 б.
164. *Хәйруллин М.Б.* Татар теле лексик системасындагы хәзерге этаптагы яңарышка карата // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. — Вып.2. — Казань, 1995. — С. 36—49.
165. *Хәйруллин М.Б.* Милли яңарыш һәм телдәге яңа сүзләр // Мирас. — 1995. — № 7—8.
166. *Хәйруллин М.Б.* Татар телендә халыкара фәнни-техник терминология кулланылышына карата // Мәгариф. — 1997. — № 4. — 38 б.
167. *Хәкимҗан Ф.С., Хәйретдинова Т.Х.* Татар тел белеме библиографиясе (1981—1997). — Казан: Татар дәүләт гуманитар институты нәшр., 1998. — 204 б.
168. *Хисамова Ф.М.* Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI—XVII вв., Ч.1. — Казань: Изд-во КГУ, 1990. — 154 с.
169. *Худиев Н.М.* Закономерности развития словарного состава азербайджанского литературного языка советского периода: дис. ... докт. филол. наук. — Баку, 1990. — 428 с.
170. *Хуҗин Р.Ш.* Кисек тел // Идел. — 1994. — № 3. — 54—57 б.
171. *Шамсутдинова Р.Р.* Употребление заимствованных компонентов в составе терминов существительных // Нормативность и вариативность в татарском языке. — Казань, 1987. — С. 20—23.
172. *Шапошников В.Н.* Иностранные слова в современной российской жизни // Русская речь. — 1997. — № 3. — С. 38—42.
173. *Шапошников В.Н.* Число и падеж: новые явления в русском языке // Русский язык в школе. — 1997. — № 2. — С. 81—87.
174. *Шацкая М.Ф.* Нейтралитет, суверенитет // Русская речь. — 1997. — № 2. — С. 115—118.
175. *Швейцер А.Д* Опыт контрастивного стилистического анализа: язык русских и англо-американских средств массовой информации // Филологические науки. — 1994. — № 1. — С. 45—47.
176. *Шмелев Д.Н.* Современный русский язык. Лексика. — М.: Просвещение, 1977. — 336 с.
177. *Щербак А.М.* Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков. Имя. — Л.: Наука, 1977. — 192 с.
178. *Юналеева Р.А.* Опыт исследования заимствований. — Казань: Изд-во КГУ, 1982. — 118 с.
179. *Юркина И.А.* Активные процессы в современном русском словообразовании (на материале словарей новых слов): дис. ... канд. филол. наук. — Казань, 1991. — 147 с.
180. *Юсупова А.Ш.* Проблема возвращения забытых слов // Языковая семантика и образ мира. — Казань: Изд-во КГУ, 1997. — С. 74—76.
181. *Юсупов Р.А.* Тәрҗемә һәм тел культурасы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. — 128 б.
182. *Юсупов Р.А.* Лексико-фразеологические средства русского и татарского языков. — Казань: Таткнигоиздат, 1980. — 256 с.
183. *Юсупов Р.А.* Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. — Казан, 1987. — 214 б.
184. *Юсупов Р.А.* Инсафлының теле саф. — Казан, 1993. — 160 б.
185. *Юсупов Р.А.* Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи. — Казань: Тат.кн.изд-во, 2005 — 383 с.
186. *Якупова Г.К.* Библиография по татарскому языкознанию. — Казань, 1988. — 134 с.
187. *Яфаров Л.* Татар теле үсештә. — Казан: Таткнигоиздат, 1955. — 170 б.
188. *Яхья Р.* И минем туган телем // Аргамак. — 1993. — № 10. —111—118 б.

**ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР**

**Газета-журналлар**

*А.о.* — Авыл офыклары
*А.т.* — Актаныш таңнары
*А.х.* — Азат хатын
*А-к* — Аргамак
*В.Т.* — Ватаным Татарстан
*З.-Т.* — Заман-Татарстан
*И-л* — Идел
*К-н* — Казан
*К.у.* — Казан утлары
*К.к.* — Көмеш кыңгырау
*К.т.* — Кызыл таң
*М-ф* — Мәгариф
*М-т* — Мәгърифәт
*М.җ.*— Мәдәни җомга
*М-н* — Мәйдан
*М-с* — Мирас
С-а — Сабыйга
*С-й* — Сабантуй
*С.к.* — Салават күпере
*С.Т.* — Социалистик Татарстан
*С-ә* — Сөембикә
*Т.й.* — Таң йолдызы
*Т-н* — Татарстан
*Т.х.* — Татарстан хәбәрләре
*Т.я.* — Татарстан яшьләре
*Т.як* — Туган як
*Х.д.* — Хезмәт даны
*Ч.-И.*— Чулман-Идел
*Ш.К.*— Шәһри Казан
*Ш.Ч.*— Шәһри Чаллы
*Ю-ш*— Юлдаш
*Ю.т.* — Ютазы таңы
*Я.ю.* — Якты юл
*Я-н* — Ялкын

**Сүзлекләр**

*Англ.РС — Аракин В.Д., Выгодская З.С., Ильина И.И.* Англо-русский словарь. — М: Русский язык, 1992. — 608 с.

*АРС — Баранов Х.К.* Арабско-русский словарь. Изд. 5-е, перераб. и доп. — М.: Русский язык, 1977. — 944 с.

*БСИС — Булыко А.И.* Большой словарь иностранных слов. — М.: Мартин, 2006. — 703 с.

*БТСРЯ* — Большой толковый словарь русского языка. — СПб.: Норинт, 2000. — 1536 с.

*ГТРАС — Мәхмүтов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш.* Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. — Казан: Иман, 1993. — 854 б.

*ДС — Борһанова Н.Б., Якупова Г.К.* Диалектологик сүзлек. — 2 нче чыг. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 263 б.

*ДТС* — Древнетюркский словарь. — Л.: Наука, 1969. — 676 с.

*КПС* — Краткий политический словарь / под ред. Л.А.Оникова и Н.В.Шишлина. — М.: Политиздат, 1989. — 624 с.

*ПРС, I* — Персидско-русский словарь: в 2 т. / отв. ред. Ю.А.Рубинчик. — М.: Советская энциклопедия, 1970. — 1 т. — 784 с.

*ПРС, II* — Персидско-русский словарь: в 2 т. / отв. ред. Ю.А.Рубинчик. — М.: Советская энциклопедия, 1970. — 2 т. — 848 с.

*РБС* — Русско-башкирский словарь / отв. ред. К.З.Ахмеров. — М.: Советская энциклопедия, 1964. — 986 с.

*РПС* — Русско-персидский словарь / под ред. А.Асадуллаева, Л.С.Пейсикова. — М.: Советская энциклопедия, 1965. — 1092 с.

*РТС* — Русско-татарский словарь / под ред. Ф.А.Ганиева. — 2-е изд. — М.: Русский язык, 1985. — 736 с.

*СИС, 1988* — Словарь иностранных слов / отв. ред В.В.Пчелкин. — М.: Русский язык, 1988. — 608 с.

*СИС, 1997* — Словарь иностранных слов: актуальная лексика, толкования, этимология / под ред. А.В.Боброва. — М.: Цитадель, 1997. — 320 с.

*СНИС — Комлев Н.Г.* Словарь новых иностранных слов. — М.: МГУ, 1996. — 144 с.

*СРЯ — Ожегов С.И.* Словарь русского языка. — М.: Русский язык, 1986. — 798 с.

*ССРЯ — Алексеев Д.И., Гозман И.Г., Сахаров Г.В.* Словарь сокращений русского языка. — М.: Русский язык, 1977. — 416 с.

*СЭС* — Советский энциклопедический словарь / отв. ред. А.М.Прохоров. — М.: Советская энциклопедия, 1985. — 1600 с.

*ТРС* — Татарско-русский словарь / отв. ред. Ф.А.Ганиева. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1998. — 464 с.

*ТСИС — Крысин Л.П.* Толковый словарь иноязычных слов. — М.: Русский язык, 1998. — 848 с.

*ТСРЯ — Ожегов С.И., Шведова Н.Ю.* Толковый словарь русского языка. — 4-е изд. — М., 1998. — 942 с.

*ТСРЯ, 2003* — Толковый словарь русского языка / под ред. Д.В.Дмитриева. — М.: Астрен.Аст., 2003. — 1582 с.

*ТТАС, I* — Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. — 1 том. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. — 475 б.

*ТТАС, II* — Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. — 2 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. — 726 б.

*ТТАС, III* — Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. — 3 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. — 832 б.

*ТТАС, 2005* — Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. — Казан: Матбугат йорты, 2005. — 848 б.

*ТТДС, 1969 — Борһанова Н.Б., Мәхмүтова Л.Т., Садыйкова З.Р., Якупова Г.К.* Татар теленең диалектологик сүзлеге. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. — 644 б.
*ТТДС, 1993 — Баязитова Ф.С., Рамазанова Д.Б., Садыйкова З.Р., Хәйретдинова Т.З.* Татар теленең диалектологик сүзлеге. — Казан, 1993. — 459 б.
*ТТКТЭС — Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2001. — 272 б.
*ТТС — Ганиев Ф., Әхмәтьянов Р., Ачыкгөз Х.* Татарча-төрекчә сүзлек. — Казан—Мәскәү: Инсан, 1997. — 496 б.
*ТТОС — Нуриева А.Х., Фасеев Ф.С., Мәхмүтов М.И.* Татар теленең орфографик сүзлеге. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. — 280 б.
*Тур.РС — Щербинин В.Г.* Турецко-русский словарь. — М.: Русский язык, 1977. — 408 с.
*ШАС — Зәйнуллин Җ.Г.* Шәрык алынмалары сүзлеге. — Казан: Мәгариф, 1994. — 144 б.
*ШЭСРЯ — Шанский Н.М., Боброва Т.А.* Школьный этимологический словарь русского языка. — М.: Русский язык, 1997. — 400 с.
*ЭСРЯ, II — Фасмер М.* Этимологический словарь русского языка: в 4 т. — СПб.: Азбука, 1996. — Т.2. — 672 с.
*ЭСРЯ, IV — Фасмер М.* Этимологический словарь русского языка: в 4 т. — СПб.: Азбука, 1996. — Т.4. — 864 с.
*ЭСТЯ, 1974 — Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков (общетюркские и межтюркские основы на гласные). — М.: Наука, 1974. — 768 с.
*ЭСТЯ, 1978 — Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков (общетюркские и межтюркские основы на букву «Б»). — М.: Наука, 1978. — 350 с.

## КУШЫМТАЛАР

КИТАПТА АНАЛИЗЛАНГАН СҮЗЛӘР ИНДЕКСЫ

**I кушымта**

**XX гасыр ахыры — XXI гасыр башы татар әдәби теле лексикасының үз җирлегендә үсешен чагылдырган сүзләр**

1.1. Яңа мәгънә яки мәгънә төсмере алган сүзләр

бәяләмә
белдермә
бергәлек
берлек
биләмә
бистә
җирлек
имгеч
ия
йөкләмә
кайнатма
киптергеч
колакса
колакча
коткы
култамга
малтабар
ташлама
тотак
төзекләндерү
төркем
тугра
тупланма
узаман
узыш
узышчы
эшкуар
эшмәкәр
юллама
ятакханә

1.2. Яңа ясалган сүзләр

1.2.1. Кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр

алыпсатарлык
әйдәр
бәһаләмә
буйсыныр
гамәлче
груһчы
гыйсъянлык
дәһрилек
зәркәнче
иганәчелек
икътисадчы
иминиятче
иминиятләштерү
инаугурацияләү
инсаниятче
иттифакчы
йөгенеш
кавемдәш
кәсәбәче
кәсәбәчелек
кертем
кертемче
көйче
көярмән
куларкадашлык
малкуарлык
мәзһәбче
мәсләктәш

мәхәлләдәш
мигъмарлык
мөлкәтче
моназарачы
мөһәндислек
нәзариятче
нәкышче
нәүбәтче
нигезләмә
оранчы
охшатымчы
өчләм
раслама
рәистәш
санак
сәнәгатьче
сәясиләштерү
сәясмән
сөйләрмән
сөйләүлек
сөйләшмәлек
сыйфатлама
сынамыш
тамгалык
ташламалы
тәгаенләмә
тәфтишче
тернәкләндерү
тиүче
төзләмә
төрем
төркемдәш
төстәш
түнтәрелеш
тыюлык
үземчәлек
фиркаче
хакимиятче
хәбәрдарлык
хәйрияче
хәйриячелек
химаяче
химаячелек
хосусыйлаштыру
һөнәрмәнлек
эшкуарлык
эшмәкәрлек
эштәш

1.2.2. Кушма сүзләр

алтакта
алхәбәр
анайорт
аскорма
аскуйма
астөшермә
аһәңсаз
башбирмәслек
җанатар
җанисәп
җанкыяр
җансакчы
җансатар
җирсөяр
илбаш
йортбасар
куларкадаш
кулчатыр
күзбуар
күпбелер
сансанак
тактаташ
таугизәр

ташкорма
үзкичереш
юлсөярлек

1.2.3. Парлы (куш) сүзләр

аракы-сыра
атама-термин
астөшермә-хашия
баш-сын
бәйге-тамаша
бәйсез-мөстәкыйль
белгеч-кадр
белдерү-игълан
бизәк-нәкыш
биләмә-урын
богау-зынҗыр
боерык-фәрман
булавка-каптырма
бүләк-ришвәт
икмәк-печән
карта-харита
келәм-ковер
килешү-договор
кулинар-ашчылар
монстр-албасты
оешма-учреждение
оратор-сөйләрмән
өндәмә-шигарь
план-ният
поликлиника-хастаханә
пропуск-юллама
рецензия-бәяләмә
секция-төркем
талант-сәләт
теоретик-нәзари
тотык-заложник
төбәк-почмак
фәрман-боерык
һөнәр-белгечлек
чыгыш-лекция
эталон-үрнәк
эшкуар-бизнесмен
якташ-җирдәш

1.2.4. Аныклаулы атамалар

автор-башкаручы
автор-рәссам
антенна-тапшыргыч
арендачы-фермер
әңгәмә-бәхәс
әңгәмә-диспут
әңгәмә-концерт
башкаручы-референт
бәйге-күргәзмә
бәйге-тамаша
белгеч-провизор
гамәли-янгынчылык
киңәш-мәҗлес
киңәшмә-летучка
концерт-бәйге
концерт-тамаша
координатор-оештыручы
күргәзмә-галерея
күргәзмә-презентация
күргәзмә-ярминкә
малтабар-химаяче
мәктәп-гимназия
мәктәп-лицей
мөнәсәбәт-караш
музей-күргәзмә
музей-утар
нәтиҗә-караш

палатка-кибет
плакат-шигарь
рәссам-бизәүче
рәссам-модельер
рәссам-сынчы
рәссам-төзүче
рөхсәт-юллама
сәркатип-эш башкаручы
семинар-киңәшмә
сөйләшү-зачет
сугышчы-мөҗәһит
сүзлек-белешмә
тамаша-бәйге
төзү-ачу
төзү-бизәү
уен-бәйге
утрау-ныгытма
фермер-игенче
фермер-умартачы
финанс-сәнәгать
шаукым-йөгенеш
эколог-белгеч
эшмәкәр-сәүдәгәр

1.2.5. Кыскартылма сүзләр

БТИҮ
БТК
ТДН
ТИҮ
ТР
ҮДН
ХТЯБ

1.2.6. Конверсия ысулы белән ясалган исемнәр

караучысыз
килешү
олпат

1.3. Калькалар

1.3.1. Тулы калькалар

1.3.1.1. Гади сүзләр

акчалаштыру
әйдәүче
бәрмә
боралак
бүлендек
иртәлек
йөкләнеш
кайгыртучылар
мәгълүматлаштыру
орлыкландыручы
сөйләүлек
сызылмалар
тартымлык
туңдыргыч
тыгызлаткыч
уйнаткыч
укылыш
чүкелмә

1.3.1.2. Кушма сүзләр

бөекмәмләкәтчел
катнашазык
күктерәү
күппартиялелек
төбәкара
үзөйрәткеч
яфраказык
янкорма

1.3.1.2. Тезмә сүзләр

авыру белешмәсе
антлы утырышчы
базар икътисады
базар мөнәсәбәтләре
Бәйсез дәүләтләр бердәмлеге
бүләк иясе
җаваплылыгы чикле ширкәт
җәмәгать үзәге
җирле үзидарә
җирле хакимият
икътисади планлаштыру идарәсе
икътисади тотрыклылык
икътисади тотрыксызлык
исемле тавыш бирү
кара базар
кече эшмәкәрлек
куллану кәрҗине
күзәнәкле элемтә
күчемсез милек
кыйммәтле кәгазьләр базары
мәҗбүри иминият
мәшгульлек үзәге
милли-мәдәни мохтарият
сәүдә бәясе
сәхнә чырае
сәяси тотрыксызлык
тәкъдим итү (тантанасы)
теркәү хезмәте
торгынлык еллары
үзгәртеп кору
үстерешле укыту
хезмәт базары
хосусый мәктәп
һөнәри берлек
шарчыклы каләм
элмә такта

1.3.2. Ярымкалькалар

1.3.2.1. Гади сүзләр

авторитар
адаптацияләү
акционерлык
акционерлаштыру
арендачы
аудиторлык
ваучерлаштыру
газлаштыру
глобаль
губерналаштыру
гэкачэпэчы
дизайнчы
иждивенчылык
индексацияләү
инновацион
инновацияле
коммерцияләштерү
компьютерчы
конвертацияләү
контрактчы
криминоген
легальләштерү
легитимлык
либеральләштерү
ликвидлы
ликвидлык
льготалы
маникюрчы
маркировкалау
мафиоз
мафиячел

менеджерлык
менталитетлы
муниципаль
омончы
пастерлау
приватизацияләү
политиканлык
продюсерлык
рациональ
реструктурлаштыру
рэкетчы
рэкетчылык
сертификацияләү
сигналлаштыру
спонсорлык
суперменлык
факсимиль
фермерлык
элитарлык

1.3.2.2. Кушма сүзләр

авиаһәлакәт
автосаклагыч
автотукталыш
автоүзәк
агрочара
азлитражлы
аудиоҗыентык
аэротамаша
аэрочана
биотикшерү
биотышча
биоягулык
видеотасма
видеоязма
дәүсовет
марсгизәр
микротирәлек
радиоманара
суперзаманча
телекүпер
тизйөрешле
фотоелъязма
фотокүчермә
фоторәссам
этносәяси

1.3.2.3. Тезмә сүзләр

акционерлык җәмгыяте
беркетү талоны
блок куючы акцияләр
газ санагыч
депозит кертемнәре
икътисади кризис
икътисади реформа
иминлек советы
ирекле әйләнештәге валюта
исемле хосусыйлаштыру чеклары
кече предприятие
крестьян хуҗалыклары берләшмәсе
махсус икътисади зона
лазер тәлинкәсе
магнит давылы
мәҗбүри медицина иминияте
микродулкын мич
милли инвестиция фонды
муниципаль берәмлекләр
озон ярыклары
пластик карточка
салым полициясе
сәүдә-сәнәгать палатасы

товар алмашу
уен бизнесы
уртак предприятие
утырышчылар суды
хезмәт һәм мәшгульлек бюросы
хисап палатасы
хосусыйлаштыру чеклары
Федераль җыен

1.3.2.4. Калька-аббревиатуралар

АҖ
АлАЗ
БДБ
БДИ
БТИ
ГКХ
ГХДК
ДВФ
ДКК
ДТРК
ДЮХИ
ҖЧҖ
ИПИ
ЛКЯС
МХХ
ТӘҺСИ
ТДГПУ
ТКН
ҮРИ
ФИХ
ФПБ
ХВФ
ЭХТ
ЮХКДИ

1.3.3. Семантик калькалар

зәңгәр каскалар
кайнар нокта
кайчы
коңгыз
тәлинкә
тере акча
түбә
текәләр
тимер пәрдә
яңа татарлар

1.4. Диалекталь сүзләр

1.4.1. Саф лексик диалектизмнар

алагаем
диңкетү
илерү
ихата
кәбәркә
күзелдерек
матавык
мокыт
наный
тәҗел
томса
чаган
өрәңге
чос
шыкаю
эркелү
яренгә

1.4.2. Алынма диалектизмнар

җәйгор
җәт
йубалгы
кимәл
көрәгә
көрәгәче
лабра
мәл
мәшәләнү
нәүрәп
пима
пучинкә
тәү
тәүдә
токсай
төпкел
шәлкем

### 1.5.1. Кулланылыш даирәсе, стиле, ешлыгы үзгәргән сүзләр

аклама
алгарыш
алыпсатар
арадашчы
ашчы
белешмә
белешмәлек
борылыш
иләт
канунлаштыру
кәрәзле
керем
кулдаш
күчермә
очкыч
салым
сынчы
таныкнамә
тизләнеш
торгынлык
тотрыксызлык
төбәк
үзгәреш
эскәнҗә
ярлыкау

### 1.5.2. Активлашкан архаизмнар һәм тарихи сүзләр

алтатар
әбүначе
баскак
баскын
басмаханә
җыен
зыялы
иганәче
йолдызнамә
качак
кизү
корылтай
сәясәтче
чәчтараш

### 1.6. Окказиональ сүзләргә мисаллар

айныткычханә
аслама
аумагалы
башлаткыч
бүленеш
гәзитханә
журналханә

җәйлек өй
игъланнамә
кабымлыкханә
канункүз
кәефханә
корыш
көлкелеш
назханә
нигезнамә
озатнамә
радиоханә
рөхсәтнамә
сәламдәш
сикергеч
сихәтханә
сынчыбагар
тәмнүшкә
токымдар
төмән
төнгизәр
уйдар
уйма
үзебезчәлек
уткызган
фәнсөяр
футболсөяр
хистәлекләр
хыялдаш
шомагур
эшсөяр
юксыллык
юлханә
ятулык

**II кушымта**

**Гарәп-фарсы сүзләре**

2.1. Яңадан активлашкан гарәп-фарсы алынмалары

агяһ (булу)
аләт
алиһә
афәрин
әбүнә
әгъла
әҗнәби
әләм
әсаси
бакый
бәгъзе
бәддога
бәйнәлмиләл
бәйтулла
бәләдия
бәян
бәяннамә
бәс
бихисап
вазгыять
вакыйган
вакыф
васыятьнамә
ватандар
ватанпәрвәр
вә
вәгазь
вәзен
вәйран (ителү)
вәрака
вәсика
вәсикави
вилаять
вөҗүд

гаделия
газават
гайре
гаклый
галиҗәнап
гамәли
гамәлият
гамил
ганганә
гаргарә
гареш
гаувас
гафләт
гидай
голәмә
гонсыр
горбәт
горуһ
госел
гөман (итү)
гөнаһкяр
гуаһнамә
гыйбарә
дарелфөнүн
даруханә
дәгъвәтия
дәгъватнамә
дәкыйка
дәляләт
дәресханә
дәстерхан
дәстүр
дәүләти
дәфен
дәһри
җасус
җәбраил
җәдвәл
җәлләди
җәмгысе
җәмгыяви
җәридә
җәррах
җәһаләт
җәһел
җилд
җисмани
җиһад
җөмһүрият
зарбә
зарурият
зәвал
зәкят
зәнки
зәүкый
зиһният
зөлмәт
зыярәт (кылу)
зыяфәт
иганә
иҗазатнамә
иҗтиһад
икътисад
илаһият
имамәт
имам-хатиб
инкыйлаб
инкыйлабый
инкыйраз
инсан
инсани
инсаният
инша
исламият

ислах
истирахәт
иттифак
ихсан
кабилият
кадим
кадими
казый
кальб
канун
кануни
кануннамә
кәррә
кәсәбә
кәхвәханә
кәшеф
кәшфият
кибаранә
Коръән хафиз
көллият
кыйсем
кыйтга
кярханә
кятиб
лаихә
лаф (ору)
ләкаб
лөгать
лязим
мантыйк
мантыйкый
матбага
мәгънәвият
мәдәт (бирү)
мәдех
мәҗбүрият
мәҗмуга
мәҗрух
мәзлүм
мәзһәб
мәйханә
мәйхур
мәкам
мәмләкәт
мәнфәгать
мәрасим
мәсләки
мәсьүл
мәэюс
мәүзугъ
мәхәллә
мәхбүс
мәхкәм
мәхкүм
мәхсулат
мәшгулият
мәэмур
мигъмар
мигъмари
милләтпәрвәр
миллият
мисле
моназарә
монафикъ
мосафирханә
мөбарәк
мөгаллим
мөгаллимә
мөгамәр
мөддәт
мөдһиш
мөҗаһид
мөнбәр
мөрит

мөтәвәллият
мөтәшагыйрь
мөхбир
мөхтәсиб
мөхтәсибәт
мөһаҗәрәт
мөһаҗир
мөһәндис
мөштәри
мөәррих
назари/назарият
нам
нәзарәт
нәҗат
нәҗасәт
нәкъкаш
нәмаеш
нәхү
низамнамә
нотык
өслүп
пайтәхет
пәрвәр
рәфика
ригая
рисалә
рухият
саим
сарыф
сафа
сәгадәт
сәҗдә (кылу)
сәйях
сәмави
сәнә
сәнәгать
сәнәгати
сәнәгатькяр
сәнәгый
сәнгати
сәнгатькяр
сәнәд
сәргаскәр
сәрдар
сәркатип
сәрмая
сәфаләт
сәхабә
сәясәт
сәяси
солыхнамә
сөаль
талибан
талибә
талип
тәбәссем (итү)
тәбрикнамә
тәваф (кылу)
тәгъбирнамә
тәгълим
тәгъриф (итү)
тәгътил
тәҗрибәханә
тәзкирә
тәкъдир (итү)
тәкълид
тәрәккый
тәрәккыйпәрвәр
тәрәккыят
тәсдыйк (итү)
тәхәллүс
тәшәккер (итү)
тәшвиш
тәшкиләт

тәэссорат
тыйб
тыйбабәд
фазә
фазыйләт
фал
фалнамә
фәгалиять
фәкыйф
фәлсәфә
фәрман
фәтва
фәтташ
фәхешханә
фәһем
фигълият
фидаи
фидая
фирка
хадим
хаҗ
хаҗи
хаҗәтханә
хаким
хакимият
хакыйкатән
хали
хашия
хәбәри
хәбәрнамә
хәерхаһ
хәйрия
хәким
хәрәм
хәстәханә
хәтимә
хәттаб
хәттат
хибесханә
хиҗап
хилаф
химая
хисси
хиссият
хосус
хөкемдар
хөррият
хөрриятпәрвәр
хөтбә
һәйәт
һәйкәлтараш
һәмишә
һәндәсә
һидият
һиҗрәт
һөнәрмән
һөнәрмәнд
һөнәрханә
чәчтараш
шан
шаһәдәт (бирү)
шаһәдәтнамә
шәкел
шәкерт
шәрабханә
шәрех (кылу)
шәрик
шәриф
шәүкәт
шәхсият
шәһит (китү)
шивә
шигарь
шикаять

шикаятьнамә
ширек
ширкәт
шифаханә
шура
шурави

2.2. Куллану даирәсен, стилен, ешлыгын үзгәрткән алынмалар

дивар
кавем
канун
кәсафәт
кыйтга
матәм
мәдәни
мәдәният
мәркәз
мәхкәмә
мөхәррир
рәис
рәссам
ришвәт
сәмән
сыйныф
табиб
фараз
хаста
хәбәрдар

2.3. Гарәп-фарсы элементлары ярдәмендә ясалган неологизмнар

2.3.1. Морфологик юл белән ясалган сүзләр

айнамә
бимәркәзләү
бихафа
бихәбәрдәр
вазыйфаи
вәсикави
гайбәтханә
гамәлханә
гаммәви
елнамә
җәлләди
җәмгыяви
җәррахханә
журналханә
иҗаткяр
икмәкханә
илһамият
ислампәрвәр
кабихи
кайгынамә
кәсепханә
кизүханә
котлаунамә
кыйблави
ләззәтият
мәгърифәтпәрвәр
мәртханә
мирасханә
могҗизаи
мөхәрририят
остаханә
сәнәгатькяр
сәнгатьханә
сораунамә
сөйләмият
сурәтнамә
сыйфатнамә
сырхауханә
тәкъдимнамә

тамашаханә
тасвирнамә
уенханә
хакимияти
хәбәрнамә
хәзинәханә
хисапнамә
хөкемханә
чакырунамә
чатырханә
чәчтарашханә
чәчханә
шаһитнамә
шәфкатьханә
шәхеснамә
ширбәтханә
ышанычнамә
эчкеханә
эшнамә

2.3.2. Синтаксик юл белән ясалган сүзләр

каләмхак
мөхбир әгъза
нәшир-хәйри

2.3.3. Фонетик ысул белән ясалган сүзләр

иминият
маддә
мәдһия

**III кушымта**

**Рус-европа сүзләре**

3.1. Яңа алынмалар

автогражданка
автоpалли
агрофирма
айкидо
аккредитация
анклав
армрестлинг
аудиоальбом
аудиокассета
аудит
аура
аэробика
аэрошоу
бакс
бартер
бизнес-план
бизнес-шоу
бизнесцентр
блокиратор
бодибилдинг
боевик
братва
брейк-данс
брифинг
брокер
вампир
ваучер
виброзвонок
видео
видеокамера
видеокассета
видеоклип
видеоплеер
видеоролик
видеосалон

визажист
гала-концерт
гамбургер
гербалайф
гламур
глобализация
гриль-бар
дебошир
дедовщина
денди
декларант
деноминация
диаспора
ди-джей
дизайн
дизайнер
дилер
дискет
дискотека
дипаритет
дисплей
диссидент
дистрибьютор
драйвер
евро
запой
зомби
инаугурация
имидж
импичмент
инвестор
индексация
инновация
иномарка
интерактив
интернет
интернетоман
интерпол
интерфейс
инфраструктура
ипотека
кадастр
караоке
каратэ
картридж
кастинг
кассета
кемпинг
киви
кикбоксинг
киллер
кластер
клип
коллаж
контактер
компактдиск
компьютер
коррупционер
крыша
ксерокопия
ксерокс
лазер-диск
лизинг
листинг
лобби
логистика
ломка
маркетинг
маркетолог
мафиози
мафия
менеджер
менеджмент
менталитет

минимаркет
мобильник
мониторинг
наркобизнес
наркомафия
необольшевизм
необольшевик
номинация
нонсенс
оккультизм
оптимизация
офф-шор
памперс
панк
паритет
партократ
патернализм
пейджер
пейнтбол
пиар
пинкод
пицца
пиццерия
плейер
плей-офф
плюрализм
политолог
политология
полтергейст
популист
попса
презентация
пресс-релиз
принтер
продюсер
путч
радиодискотека
радиотелефон
ралли
реинкарнация
рейтинг
респондент
ризограф
риэлтор
рок-фестиваль
русофобия
рэкет
рэкетир
сайдинг
сайт
саммит
сандвич
санкция
секс-бизнес
секс-шоп
сертификат
сертификация
синтезатор
скаут
скинхед
социум
соцпакет
спикер
стритбол
спонсор
спикер
супермаркет
супермен
сутенер
тамагочи
телекс
телефакс
тендер
тетрис

тинейджер
токсикомания
трансфер
тренд
тренинг
триллер
тусовка
тхеквондо
уфолог
уфология
факс
фейхоа
фитнес
фотоколлаж
хакер
хилер
хиппи
хит-парад
хобби
холдинг
хот-дог
хунта
чартер
челнок
чизбургер
шейпинг
шоу
шоумен
штрих-код
эйфория
экстрасенс
экю

3.1.1. Аббревиатуралар

АО
бомж
ВИЧ
ВЧК
ГИБДД
ГКО
ГКЧП
ГТРК
ДПР
ИПВ
КПРФ
ЛДПР
МММ
НДР
НЛО
НТВ
омон
ОРТ
ОСАГО
ПЭН-клуб
РКО
СНГ
СПИД
СПС
ТАИС
ТНВ
ФНПР
ФСБ

3.2. Мәгънә үзгәрешләре кичергән алынмалар

банкрот
бизнес
демократия
калькулятор
квота
конверсия
лицензия
пикет

реабилитация
репрессия
университет
чек
юрисдикция

3.3. Кулланылыш даирәсе, стиле һәм ешлыгы үзгәргән сүзләр

атташе
бюджет
вексель
вице-президент
вице-премьер
гран-при
декларация
депозит
дивиденд
дотация
инвестиция
инфляция
коммерсант
компенсация
кооператив
коррупция
коттедж
недоимка
парламент
президент
премьер-министр
полис
референдум
реформа
суверенитет
фирма
фракция
эмиссия

3.4. Татар җирлегендә актуальләшкән яки элек чит ил реалиясе атамасы буларак кына кулланылган сүзләр

акциз
акционер
акция
антрепренер
бакалавр
бакалаврист
бизнесмен
биржа
вице-губернатор
гимназия
губерна
департамент
Дума
казначейство

колледж
коммерция
лицей
лоббист
магистр
магистратура
меценат
мэр
офис
префект
префектура
прогимназия
фермер

Научно-популярное издание

**Мухиярова** Разина Хайбрахмановна

ЛЕКСИКА ТАТАРСКОГО ЛИТЕРАТУРНОГО ЯЗЫКА КОНЦА XX — НАЧАЛА XXI ВВ.

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Фәнни-популяр басма

**Мөхиярова** Рәзинә Хәйбрахман кызы

XX ГАСЫР АХЫРЫ — XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫ

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Т.В.Гредюшко*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.12.2008. Форматы 60г90 1/16.
Басма табагы 11,5. Шартлы буяу-оттиск 0000. Нәшер-хисап табагы 0000.
Тиражы 1500 д. Заказ Т-890.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.